# Казан утлары

11.1983



# КАЗАН УТЛАРЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС
ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-
ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН
ЯЗУЧЫЛАР
СОЮЗЫ ОРГАНЫ

11

1983

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

## Бу санда

**Ә. ГАФФАР. Бодай бөртеге һәм тегермән ташы.** Роман . . . 3
**Н. ДӘҮЛИ. Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар.** Шигырьләр . . . 84
**А. ШАМОВ. Бер җамаяк сөт.** Хикәя . . . 88
**Ш. ГАЛИЕВ. Очты яфрак...** Балалар өчен шигырьләр . . . 97
**Р. СӘЛИМҖАНОВ. Елан мөгезе.** Хикәя . . . 101
**Ф. САФИН. Безнең гомер.** Шигырьләр . . . 104
**Х. ӘЮПОВ. Өй өмәсе.** Шигырьләр . . . 110

ТАТАРСТАН НЕФТЕНЕҢ 40 ЕЛЛЫГЫНА

**Җ. РӘХИМОВ. Шөгернең икенче яшьлеге** . . . 114
**И. ЗАРИПОВ. Пар канатлы якташларым.** Очерк 118

«АВЫЛ ОФЫКЛАРЫ» КОНКУРСЫНА

**Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Республиканың көнчыгышыннан хатлар** . . . 125

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

**Р. КӘТИЕВ. АЭС һәм авыл.** Әдәби постта әңгәмә 132

БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР

**И. НУРУЛЛИН. Илең турында уйла** . . . 135
**Н. АКМАЛОВ. Күңелне кузгатамы!** . . . 139

БИБЛИОГРАФИЯ

**Т. ГАЛИУЛЛИН. «Тыйнак табын»га кил, укучы!** . . . 141
**И. АХУНҖАНОВ. Үзенчәлекле шигърият** . . . 144

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

**Г. САБИРҖАНОВ. Татарстанда культура революциясе** . . . 149
**М. ГАЛИЕВ. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән — мәгариф өлкәсенә** . . . 156

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

**Э. ГОБӘЙДУЛЛИНА.** Соңгы сәяхәт . . . . . . 163
**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Фатих Әмирхан ядкаре . . . 165

ЗАКИР ҺАДИНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

**М. ГАЙНЕТДИНОВ.** Бишенче ел әдибе . . . . . 166

ФОЛЬКЛОР

**А. САДЫЙКОВА.** Гыйбрәтле хикәяләр . . . . . 170

Батыр мәйданда чыныга. Интервью . . . . . . 174

**Р. ШӘМСЕТДИНОВА, Т. ДУНАЕВА.** Китап һәм укучы . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
**М. МАТВЕЕВ.** Легендар танкист . . . . . . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор* **РЕНАТ ХАРИС**

**Редколлегия:** ШАМИЛ БИКЧУРИН, МАНСУР ВӘЛИЕВ, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, РӘИС ДАУТОВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, *җаваплы секретарь* САЛИХ МАННАПОВ, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, *баш редактор урынбасары* РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ, ЗӘКИ НУРИ, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ

---

Техник редактор *Р. Сөләйманова*
Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина*

---

Адрес редакции: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары — 53-07-09, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза бүлеге — 53-07-61, поэзия бүлеге — 53-07-61, тәнкыйть бүлеге — 53-07-63, сәнгать бүлеге — 53-07-63, очерклар бүлеге — 53-07-61, хатлар бүлеге — 53-07-63, корректорлар — 53-07-65, техник редактор — 53-07-65, машинисткалар — 53-07-60.

Производствога бирелде 26.08.1983 ел. Басарга кул куелды 18.10.1983 ел. ПФ 07090. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65044. Заказ Я-350. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1983 ел.

## Әхәт Гаффар

# БОДАЙ БӨРТЕГЕ ҺӘМ ТЕГЕРМӘН ТАШЫ

РОМАН



Авылда дүрт йөз сиксән хуҗалык санала, эшкә яртысы гына чыкса да... Кәгазьләремдәге эш вакыты тагын ул хуҗалыкларның яртысында ат, ат юк икән, үгез-әхрәт булуын күздә тотып исәпләнгән. Өч ай, иң күбе дүрт, шул җитә. Идел буарга чыкмыйбыз.

Кичкә, көтү кайтканчыга кадәр үземне кая куярга белми йөдәдем. Башта су буенда тулгандым бугай, таяк белән комга нидер сызгаладым, аягым белән бозып аттым, тагын сыздым. Шушы «эт оясын» да китереп чыгара алмасаммы? Ул вакытта булдыксыз сөякләремне яңа пәлтәгә төреп, яңа бүрек белән каплап йөрүдән ни мәгънә?

Инеш буйлап түбән төшеп киттем. Тынычландым кебек. Крестьянның маңгаена тай типмәгәндер. Чыгачак. Ике йөз кырык кеше, дистәләгән ат, үгез. Илле көрәк, илле носилка, кырык балта, илле йөкче. Якынча, билгеле. И-и!.. Тапканмын да соң эч пошыргыч нәрсә! Башымны кайтарып, болытларга карап көлеп җибәрдем. Көлүем күк күкрәве булып, кайтаваздай, кире үземә әйләнеп кайтты. Әүмәкләшә-әүмәкләшә, өстеөстенә өерелешеп килгән болытларга күзем төште. Күңелем шул якны баскан эңгер-меңгер шикелле куе зәңгәр һәм зыңлап торган шом белән тулды. «Әгәр,— дип уйладым мин, төзелеш урынын карап,— әгәр ару гына башланып киткән эшне әнә шул болытларише бер хәвеф басып китсә?» Өч-дүрт ай... Шуның күпме көне аяз торыр бит әле! Корылык китсә дә харап. Тагын күпме «са-са-са» бар икән?

Боларның берсе генә дә кәгазьләремдә искә алынмаган, башыма кереп карамаган, күңелемә килмәгән. Аннары соң крестьянның печән чабасы, урак урасы,— тагын әллә никадәр эшләре бар ич әле?!

Сирәк, әмма эре тамчылы яңгыр яварга кереште. Мич, читән, абзар сыларга ак балчык ала-ала кәрнизләнеп калган куыш астына постым да, изүемне чишеп, сызымнарымны култык астына яшердем. Башымдагы уйлар, яшен тармакларыдай чуалчыкланып, таралып китте. Тау түбәсендә кайсыдыр бер төшкә яшен бәрде ахрысы, мин, таш ишелгән авазга куыштан чыгып, өскә карадым һәм чак кына читкә янтаеп калырга өлгердем: баш очыннан гына коточкыч тизлек белән чүлмәк кадәрле түгәрәк таш очып үтте дә яр кырыенда күздән югалды. Аның тоба суына төшеп дөбердәвен ишетми калдым, игътибарымны бүтән нәрсә җәлеп итте — югарыда ниндидер хәрәкәт сизеп алдым,

Ахыры. Башы 10 санда.

кемдер тау кашы артына качкан шикелле булып китте. Өстемә баягы таш кузгаткан яфрак коелды. Ниндидер көч югары әйдәде, тезләрем, күлмәк җиңе, иңбашларымны буйый-буйый, ташларга таяна-таяна, юеш ак балчыкта тая-тая, ныгып җитмәгән әрем, шайтан таякларына ябыша-ябыша өскә ыргылдым. Ак ташларны зәңгәрләтеп, яшел үләннәрне, вак куакларны агартып, тагын яшен яшьнәде, үзем үрмәләгән тауның эчендә генә күк күкрәде сыман. Манма чыландым, йөрәгем тыелгысыз тибә, тыным буыла, тырнакларым каерылуын да тоймыйм, уң кулым белән таянган җебегән ак балчыклы ташларда әйрәнгә изелгән җиләкләр төсле, җете кызыл кан таплары таралып кала. Әйтерсең лә мине бау белән һавага элеп куйганнар да, ярсуланып үземә ташланган карчыга белән сугышам. Тау күкрәгеннән шул кошның тырнакларыдай тырпаешып чыккан очлы ташлар, шуның каурыйлары сыман кытыршы һәм чәнечкеле гөлҗимеш куаклары тәнемне тырный. Төш күрәм күк, төштәге сыман, бөтен гайрәтем белән ыргылсам да, бер урынга кадаклап куйганнар диярсең. Инде көне буе үрмәлим шикелле. Берике тапкыр аягым таеп, бармак очларында гына асылынып калам.

...Ә өстә җан әсәре дә юк иде. Яңгыр пәрдәсе артындагы иңкүлектә ялгыз ат утлап йөри, күк күкрәгән саен, ул муенын турайта да башын тагын ия, кушаяклап алга сикергәндә, яшен яшьнәп, ялы ялкын телләре сыман җилфердәп куя, үзе тимерчелек учагыннан чыккан утлы тимергә охшап кала.

Аръяктагы киң болынга авыл көтүе таралган, юлдан үгез җигелгән арба бара, ә арбага утырган юлчы яңгыр астында җыр суза.

Мин авыз эчемнән генә көлеп куйдым. Кемдер иртәдән сагалап торып, өстемә таш тәгәрәтә дип уйлавым бөтен ахмаклыгы белән оялтып җибәрде. Андый адымга барган кешегә ташны мин текә ярдан күтәрелгән чакта күземә карап эшләве тәгаенрәк булмас идемени? Моны ул качмый-нитми, йөземә карап, көчсезлегемнән, үзенең өстенлегеннән ләззәтләнеп эшләр иде. Туктале, берни кылмас борын, кемгә хаҗәттә, кемнең мәкерле ниятенә каршы чыккан соң әле мин? Каян килгән алланың кашка тәкәсе!

Ә Рамазанов? Ул кемнең үт куыгына таш булып кергән дә ничек корбан булган соң? Урыныннан яңгыр кузгаткан очраклы таш белән Рамазановның кул астыннан табылган револьвер арасындагы уртаклык җир белән күк арасындагы бушлыкка тиңләшсә дә, үз-үземне аямыйча тау башына менүемне бушка санамадым. Яр читенә килеп, түбән карадым. Шундый текәлеккә менүем начармыни? Зыянга түгел. Һәрхәлдә, өстә торуы рәхәт. Мәгънәсе дә бар: кем белә, бүген булмаса, киләчәктә ниндидер хәвеф-хәтәр янавы ихтимал ич әле. Әнә шул ихтималлыкның барлыгын сизеп, күңелемә искәртеп куюым белән генә булса да, баш очымнан йомры таш очып китүен кичерүем һәм, алны-артны карамыйча, канатланып, шушы ярга ыргылуым файдасыз үтмәде. Табигать белән кеше арасында очраган теләсә нинди куркыныч очрак эзсез калмый, сабак бирә, үлем алдында тез калтыратмаска әзерли.

...Табигать белән минем арадагы мөнәсәбәт — аны тою, аңлау — гомерем буена шундый булды...

Ярга ыргылганда — күлмәгем астына тыгып куйган сызымнарым һәм саннарым шәмәхә карандаш белән сырланган иде — кәгазьләр җебеп, язулары җәелеп беткән булып чыкты.

Моны начарга юрадым.

Хәер, яттан беләм, аларсыз да мөмкин, тик төп документның һәрвакытта кул астында торуы кирәк, кем килеп сорамас я карамас, яңадан яңартып, төзәтеп сызасы булыр.

Бер кәгазем җиргә төште. Алырга иелдем. Кытыршы ташлар, кылганнар һәм шайтан таяклары арасында юеш балчыкта бер эз ярылып ята иде. Таштан-ташка сикерә-сикерә кемдер әле генә үткән, ахрысы.

Тау башындагы гаять зур ташка менеп күпме генә карансам да, тирә-юньдә җан әсәре чалынмады. Хәер, тауның ул ягы сөзәк, чикләвек, гөлҗимеш куаклары белән тулы, тирән-тирән ерганаклар белән телгәләнгән, сыеныр, посар өчен махсус яратылган кебек.

— Яра-а-р,— дип суздым. Гаҗәп, бу хәлгә гаять тыныч, һәм аптырамыйча каравымны тоеп алдым. Әйтерсең лә көтелмәгән нәрсә юк, шулай тиеш. Тик бу тынычлык язмышка баш иеп, ни килсә, шуңа буйсынырга әзер тору да булмаган икән.

«Яңадан сызасы»,— дип уйладым мин кәгазь битен күтәреп, барысын бергә түгәрәкләп төрә-төрә.

Яшенле болыт көтүләре инеш буенча түбән таба төшеп китте. Шунда юнәлдем. Яр буйлый сузылган юеш үләнле тугайлар, болын, ә аннары, түбәнге рус авылының ызанлы басулары башлангач, әле елга яры буенча сузылган киртләч-киртләч тайгак көтү сукмакларыннан, әле үги ана яфраклары, бөтнек һәм кыяк баскан тирән ерганакларның корыларын турылай кисеп, ә сулыларын әйләнеп чыгып, мин бардым да бардым. Ботинкам лычкылдап, лайлаланып, табанына үзле балчык-ябышып бетте, чалбар балаклары манма су. Инешнең ат дагасы кебек түгәрәк бер борылышыннан күтәрелеп киткән үр башында биш гөмбәзле һәм шәм шикелле колокольнялы куе кызыл кирпечтән салынган чиркәү, дүртпочмаклы пычрак сөремле кирпеч торба (соңыннан мин аның спирт заводы морҗасы икәнен белермен) күренеп тора. Хайван сөякләре чәчелеп яткан үләксә киртәсе янынннан борылуга, юеш үләнне ерып үткән эзгә юлыктым. Кемнеке? Иясе кайда?

Артка әйләнеп карадым. Баш очымда тәкәрлекләр очып йөрергә тотынды. Җирдән җылы пар күтәрелә иде инде, кояш чыкты. Җирнең яшеннән куркып, чытырдатып япкан офыгында, алтын сөрмәле күз кабаклары булып, сак кына салават күпере ачыла барды. Өстендәге болыт юрганын Кама ягына этеп төшергәч, бая мин басып торган тау, җирнең ак күкрәкләре булып, киерелеп җибәрде кебек. Бөркү һавага черкиләр, озынборыннар көтүе күтәрелде, аларны зәңгәр канатлы энә караклары аулый башлады.

Артымда тирән сулыш ишетеп, мин катып калдым. Кошлар авазын ишетмәс булдым, аның каравы колагыма үлән чыжлавы ярып керде. Кемдер миңа якынаеп килә. Аяк атлавы сак, әмма ул якка кинәт борылып карарга кыймадым, алай итсәм, артымдагы зирек агачлары арасыннан пәйда булачак ул кеше, бар гайрәтен туплап, шундук миңа ташланыр иде кебек. Әгәр дә тау башындагы әзнең иясе булып чыкса, минем аулак урынга килеп җитүемне көтсә? Ә бу тирәләргә кеше заты сирәк аяк баса булса кирәк. Берни сизмәгән атлы кыланып, кузгалып киттем һәм, ике-өч адым атлагач, кинәт алга сикердем, аяк табанна-рым җиргә тимәс борын һавада әйләнеп, үземә посып килүчегә йөз белән калдым. Үз алдымда мүкләк кара сыер күреп, кычкырып көлеп җибәрдем. Кисәк тавышымнан өркеп, ул алгы аяклары белән генә читкә сикерде дә бүтән кымшанмады, юеш, көдрә чуклы озын койрыгы белән үзен борчыган кигәвенгәме, сукыр чебенгәме, бөгәлчәнгәме селтәнде. Муенына бауга бәйләнгән агач асылган сыер, авызына капкан үләнне чәйни башлап, башын миңа борды, сул күзен вак чебен сарган, озын керфеген ул өзлексез каккалый, уң күз алмасына перламутр төймә ябышканмыни — ак төшкән: көтүдә йөрми торган сукыр сыер ахрысы.

Зирекләктә ат пошкырганы ишетелде, ул да түгел, куе үләндә сыер салган сукмак буенча кара бозау кадәр бер эт томырылып килә башлады. Әгәр дә ул миңа ташланасы булса, билгеле, елга ярына кадәр йөгереп җитәргә, ярдан сикерергә өлгермим инде, шуңа күрә сыер янына барып бастым, аңа өскә сикерергә ирек бирмәскә мөмкин иде әле. Эт томырылып килгән җиреннән артын чөйкәлтеп туктады да без-

гә борылды. Сыер, аны күреп, миңа елышкандай итте, дөресрәге, мин аңа сыендым бугай. Эт чия кебек кызыл күзләрен төбәп һәм шәмәхә борынын җыерып, зәһәр ырылдый, арада сукыр сыер булмаса, без аның белән кочаклашып, җирдә аунар идек инде. Ә кесәмдә кадак та юк.

— Трезор! Тихо!

Кырыс, көчле калын тавыш кара этне җиргә кысты, ул ырылдаудан туктап, тешләрен шыгырдатты да арт аякларына утырды, һәм аның селәгәйле авызыннан чабата хәтле алсу-зәңгәр теле салынып төште.

Юеш һәм ялтырап торганга күрә, кара яфраклы булып күренгән тәбәнәк ябалдашлы зиреклек арасыннан кара атка атланган брезент кожанлы җайдак килеп чыкты.

— Тихо, с-сук-ка!— дип кабатлады ул.

Туры итеп атланган, бер кулына өзәңге тоткан, икенчесе белән биленә таянган. Кояш каршы, карарга комачаулый. Җитмәсә ул, күзен каплап диярлек, киң кырыйлы эшләпә кигән.

Эт, шуышып диярлек, атның артына чыкты.

Без бер-беребезгә карап торабыз, сынашып. Ул өстән, мин астан. Аты таптана, боргалана шуңа күрә, мине күзеннән ычкындырмас өчен, аңа башын туктаусыз боргаларга туры килә.

— Внушительный пес, не правда ли?— диде ул.— Чистокровный доберман-пинчер.

— Бывают и хуже,— дигән булдым мин.

— Хуже? Тогда бы вам пришлось залезть на мою Настю, чтоб любоваться им.

— Настю?— дип сорадым мин аптырап.— На какую Настю?

— Которую за ухо чешете.

Настя — сукыр сыер икән. Миндәге киеренкелек юкка чыкты.

Аңа кырыклар тирәсе. Озын буйлы. Ияр аны тагын да озынайта. Кара сакал-мыеклы. Уң ягында тирән җөй, озын бугай, сакалын шуны каплар өчен җибәрмәде микән.

— Рәхим итегез,— диде ул.

— Кая? Рәхмәт, вакытым тар,— дидем мин рус авылы ягына карап.— Ераграк.

— Минем өем моннан өч йөз адымда.— Сораулы карашымны тотып, ул:— Монда хуторым бар,— дип өстәде.— Сатып алдым. Авырыксынмасагыз, мәгез, атка атланыгыз.

Ул, иярдән егетләрчә сикереп төшеп, өзәңгесен сузды. Кожаны коп-коры. Итәге дә. Ә күн итегенең гутолины ышкылып бетеп, башы агарып диярлек калган. Юеш үлән ерып йөргәнгәдер. Карашымны тоеп, ул:

— Я? — дип учын килгән эзенә таба сузды.

— Рәхмәт,— дидем мин, тик урынымда калдым. Ул, ризалыгымны аңлап, өзәңгене тоткан көйгә алга узды, мин ат артыннан иярдем. Ә эт — иң алда. Настя калды.

— Рамазанов урынынамы?— дип сорады ул бераздан. Җавабымны яки «Каян беләсез?» дип соравымны көтеп тормастан, ул:— Моны сезнең мине белмәвегез әйтеп тора,— диде.— Аннары яңа кеше килгәнен дә ишеттем. Инеш буенда йөргәч, сез инде.

Кожанының арттагы ертыгыннан зәңгәр бастон галифе чалбарының да юеш икәнен күреп алдым. Кожанын һәм эшләпәсен ул яңгыр туктагач кына кигән инде алайса. Ә яңгыр астында нишләп йөргән? Кайда?

— Юнус Юсупович минем яхшы знакомыем иде,— диде ул яртылаш борылып.— Авыр туфрагы җиңел булсын.

— Ничек таныштыгыз?— дип сорадым мин дәшми барудан уңайсызланып.

— Нәкъ сезнең белән танышкан кебек.

— Ул чагында да Настяны эзләдегезме?— Без хәзер кояш үтәли яктырткан көдрә, жыйнак ябалдашлы зирекләр тирәсеннән бара идек.

— Настяны?— дип сорады ул адымын әкренәйтеп.— Әйе, Настя адашкалый, бичара. Бүген көчкә таптым жанкайны.

Агачлык бетте. Күлгә килеп чыктык. Кечкенә генә, түм-түгәрәк яры куе үләнле су өсте яңа борнап чыккан үрдәк бәпкәләре төсле сары төнбоеклар белән капланып беткән диярлек. Агачлык белән күл арасында тәбәнәк, яшел мүк каплаган такта түбәле йорт тора, бер тәрәзәсеннән кала һәммәсенең дә капкачлары ябык. Капка юк. Келәт җимерелгән, абзар, күл буенда кабык түбәле мунча, тигәнәк һәм әрем басып кан алма бакчасы, арттарак арата белән уратып алынган, кайчандыр яшелчә бакчасы булган урын.

— Настяны озак эзләдегезме?— дип сорадым.

Иңбашы аркылы гына карап алды да:

— Быел яңгырлар еш ява,— диде ул, җавап бирмичә.

Атының тезгенен болдыр баганасындагы кадакка элде дә, эшләпәсен салып, кул сырты белән тирләгән маңгаен сөртте.— Узыгыз.— Ул, болдырга кереп, өйнең киез белән тышланган ишеген ачып куйды, үзе келәткә кереп китте.

Ишегалды чирәмле, ә болдыр баскычы төбе юеш шәрә җир, шунда аның эзе ярылып калды. Папирос кабызган һәм тарткан булып, баскычка утырдым да шул эзгә текәлдем. Тау башындагы эз уң аякныкы иде, ә монда — сул аякныкы. Ләкин шул ук күнитек эзе түгелме соң?!

Ботинкамны салып, оекларымны сыктым, кояшка куйдым да яланаяк өйгә кереп киттем. Киемнәрем кипшеп бетмәгән, өй эче күләгәле иде, туңдырып җибәрде. Ишек катындагы стенага ике ау мылтыгы, патронташ, тагын нииндидер каешлар эленгән. Сырлап ясалган агач караваттагы чәчәкле мендәрләргә, зур мич авызына тәрәзә капкачы ярыкларыннан көйрәп торган кояш нурлары төшкән.

Мылтыкны алып, ишеккә төбәдем. Шулчак хуҗа килеп керде. Өсбашын салган, якасыз эчке ак күлмәктән, шул ук галифе чалбардан, тик, минем кебек үк, яланаяк. Тозлы гөмбәле алюмин тәлинкә, кус көрән төстәге һәм ялтырап торган, мин белмәгән җимешле кызыл касә тоткан, әмма нигәдер бер генә кулы белән — алюмин тәлинкәне беләгенә куйган да корсагына терәгән. Уң кулы буш. Үзенә төбәлгән мылтык көпшәсен күргәч, уң кулы күз нярмәс тизлек белән биленә ятты, тик... Уң кулы мена ни өчен буш икән!..

— Түрдән узыгыз,— диде ул. Тавышы коры чыкты. Димәк, курку йөгергән. Чуклы яшел эскәтер җәелгән өстәл янына узды.— Ә мылтык корылмаган. Патроннарны ерак тотам.

Көлгән, һәм шаярган булып, мылтыкны чөйгә элдем, өстәл янына килеп утырдым. Ул өрәнге шкафтан рюмка алып карады, аны кире куеп, ике бокал, ике чәнечке алды, аннары мич артыннан сургычлы дүрткырлы шешә һәм җиз чүмеч белән су китереп утыртты.

— Ну-с — диде ул шешәнең сургычын ватып, бокалларны яртылаш тутыргач.— Спирт. Болай гынамы, әллә су кушасызмы?.. Алайса, отлично!— диде ул мин дәшмәгәч, бокалын күтәреп.— Танышу хөрмәтенә, Ислам Иманович!

— Имамович,— дип төзәттем мин, әчәргә ниятем булмаса да, бокалны тотып.— Каян белдегез?

— Номенклатура!.. Районда еш булам, ишеттем.

— Ә сез?

— Штабс-капитан Булганин,— диде ул урыныннан торып һәм баш кагып.— Әүвәлге.— Ул урынына утырды.— Аннары кызылларда сотня йөрттем.

— Сотня?

— Әйе, кызылларда сотня юк иде, сез хаклы. Ләкин минем отрядымда йөз кылыч йөрде... Әти мәрхүм спирт заводы тотты. Мин аны советларга бирдем. Хәзер шунда директор. Номенклатура, кем әйтмешли... Ну-с!.. С богом!

Ул, башын кисәк кенә артка ташлап, бокалын бушатты, берни капмады. Мин бер уртлап куйдым да суга ябырылдым, гөмбә каптым.

— Сез...

— Ярослав Борисович,— диде ул чак кына калка төшеп. Сүз әйтәсе килгәнемне онытып, Рамазанов (ул аны гел Юнус Юсупович дип кенә атады) белән шушы өйдә, районда очрашканнарын, үзенең дә аның янында кунакта булганын сөйләде. Аннары бу тирәләрнең матурлыгын, үзенең төп йорты авылда икәнен, ә бусын крестьян хезмәте белән яшәргә сусаганнан сатып алганын, хатыны барлыгын, биредәге күлләрнең (аның йорты янындагы шикелле салкын сулы бәләкәй, әмма тирән күлләр биредәге агачлыклар һәм әрәмәлекләр арасында тагын җидәү икән, ниндидер метеорит төшүдән тезелешеп калганнар) спирт ясау өчен гаять саф, яхшы сулы икәнен сөйләде. Ул тагын берике тапкыр эчеп куйды, мин инде аның сөйләвеннән арый башладым, әмма ул сизмәде.

— Сез нигә эчмисез? Менә, зәйтүн җимешеннән авыз итегез.

Мин бер җимешне авызыма каптым. Тәме ошамады, эчендә төше бар икән, анысын авызымда әвәли торгач, учыма алып карадым.

— Отличный закусон!.. Сез әле яшь, күп нәрсәне белмисездер.

— Ихтимал,— дидем карышмыйча,— әмма үземә тиешлесен...

— Сезгә тиешле нәрсәнең башкаларга өч тиенгә дә кирәге юк,— диде ул, лүштердәтеп гөмбә капкач.— Моны Юнус Юсуповичка да әйттем... Нәрсәгә ул карга оясы кадәр станция? Төкерек. Безнең авыл мужигы мунча тамызлыгына керосин әрәм итми, спирт тота! Аңа нигә хаҗәт ул — стан-ци-я? Тегермән өченме? Өч-дүрт капчык онны ул теше белән дә тарта. Өен яктыртыргамы? Нәрсәгә аңа якты — тавыклар белән бергә йокыга түнә дә таң тишегеннән кендек әбисен алмага чаптыра. Нигә аңа электр уты? Укыргамы? Биш намазны ул яттан да чыга, русның иконасы алдында лампадка мәңге янып тора... Эшче көч каян ялламакчы буласыз? Мужик хәзер печәнгә төшә, аннары урак, ә кыш көне ул арты белән мич ташы шомарта.

Ул тагын ярты бокал каплады да бармаклары белән чеметеп кенә зәйтүн җимеше ашый башлады. Мин бармы, юкмы — аңа барыбер иде ахрысы. Тик су эчкәндә генә чүмеч кырыеннан кырын карап алды, кулъяулыгы чыгарып, кырынганда кискән җирен сөрткән шикелле, тидереп-тидереп кенә сакалындагы су тамчыларын сөртте.

— Юк эш, Зәйнушин,— диде ул фамилиямне атап.— Китегез к чертям-матерям, укыгыз, Глеб Максимилиановичыгызның ГОЭЛРОсын төшегездә күреп, тыныч кына йоклагыз... Тәмугтан җәннәт ясый алмассыз!.. Неужели сез минем Настяма караганда да сукыррак? Ул ичмаса, кая барганын белмәсә дә, ни ашаганын белә. Ә сез?.. Ну, шул... карга оягызны корып куйдыгыз ди. Шуннан? Күктә бер йолдыз кабынды ни дә, сүнде ни. Меңнәрчә авыл: сезгә һәммәсендә дә электр станциясе төзетәчәкләрме? Шиш, Зәйнушин, шиш, дорогой. Советларның көчәнүдән эчәгесе чыгачак. Россия-анакай бурыч сазлыгына гына батмыйча, чит ил капиталына коллыкка төшәчәк, һәм — революциясез переворот. Пока сез НЭП запасын ашап торасыз. («Нигә «сез», ә «без» түгел?» — дип уйладым мин.) Сезне бу затеяның татар авылында башлануы шикләндермиме? Ә? Егерме беренче елгы ачлыкны хәтерлисезме?— Ул мәгънәсез генә кул селтәп алды.— Конечно, хәтерләмисез. Сезгә ул чакта...— Ул туп-туры йөземә, күземә текәлеп торды — яшем

не чамалады.— Хотя...— Хәтерләгәнемә ышанды бугай.— Менә шул, егерме беренче елда Поволжьега килгән икмәк яр буйларыннан әчкә узмады. Так вот, егерме беренче елны минем әти хохоллар җибәргән бер баржа бодайны спиртка куган...— Бераз тын торгач.— Сволочь!— дип өстәде.

Мескенләнеп, акланып утырасым килмәде.

— Боларны ник сөйлимме? Сезне кызганып... Юнус Юсупович ялгышын кабатламагыз.

— Нинди ялгышын?

— Кайда хата җибәргәндер, аллага да билгесез. Сезнең авылдан түбән тагын өч авыл бар, так что алар үз тегермәннәрен сез су җибәргәндә генә эшләтеп булуы белән килешмәсләр, станциягез кайберәүләрнең бугазларына торган сөяк булмагае.

— Әллә Рамазановны шуның өчен... дип уйлыйсызмы?

— Уйламыйм. Мин берни уй-ла-мыйм... Яхшы кеше иде. Яшеренбатырын түгел — матур итеп эчә дә белә иде;— диде ул алдымдагы болай да тулы бокалга спирт өстәп.— Минемчә, Юнус Юсуповичны корбан иттеләр. Политика корбаны. Аның станциясе белән кешеләрне котыртып, колхоз төземәкчеләр иде ахрысы. Ә крестьян дүрт күзле, ике башлы ул.

— Сез нигә эштә түгел?— дип сорадым мин.

— Спирт ул, дорогой, ат тизәгеннән ясалмый. Аңа бодай, бәрәңге кирәк. Ә хәзер аларны каян аласың? Жрать нечего.

— Ә эшчеләрегез?

— Аларга нәрсә? Кышын җәйгә җитәрлек спирт урлап куйсалар, яңа сезонга кадәр на подножном корму.

Әгәр җәелеп китсә, дилбегә бөтенләй аңа күчәр ахры.

— Миңа вакыт,— дидем.

— Тоткарларга базмыйм.— Ул урындыктан торды, ялгыш атлап, сөрлегеп китте дә караваат шарына тотынып калды. Ниндидер чын иштелде, карашым, ул караваат башының бер өлгесенә элеп куелга кара тасмага төште. Чулпы.

— Хатыныгыз татармы әллә?— дип сорадым.

Карашымны тоеп, көлеп куйды.

— Болыннан таптым. Былтыр печән өстендә җуйганнардыр.

Ул мине йөрештә булган чулпы көмешеннән бер кыш кар астында чыккан көмешне аермый дип уйлады микән? Ә бу көмеш тәңкәләр ап-ак иде.

Өстем бөтенләй кипшенгән, яңгыр туңдырган тәнемне шул бер-ике йотым спирт та кызыштырган, сөйләшү беркадәр зарыктырса да, мин сукыр Настя түгел, кайбер нәрсәләрне күрдем, сиздем.

Баскычка утырып, оегымны һәм ботинкамны кидем. Баскыч төбендәге күн итек эзе шома итеп тигезләнгән иде.

— Тагын килегез, Ислам Имамович!

— Рәхмәт, килермен.

— Адашмассызмы?

— Ә сез тау башында эзегезне калдыргалап торыгыз.

Күзе кысылып килде, кулы тагын, үзе дә сизмәстән, кобура торырга тиеш җиргә җәелеп ятты. Ләкин ул көр тавыш белән көлеп җибәрде, келәт астыннан койрыксыз доберман-пинчер атылып чыкты да канлы күзләрен миңа текәде, әйтерсең лә аның хуҗасын көлдерер дәрәҗәдә җәберләгәнмен.

Булганин бусага аркылы кулын сузды:

— Наверно, дуслар булып күрешербез,— диде ул.— Кстати, сезне Иван Иванович дип атасам ничек булыр? Ваня. Ванюша...

— Күз күрер.

— Детдомда үскәнгә охшагансыз...

— Сез аркамда ничә миң барлыгын да белмисезме?

— Тагын килегез. Минем күлемдәге карпларны күрсәгез сез! Шуларны тотканда, миңнәрегезне дә санарбыз. Детдомда икәнен каян белдемме? Безнеңчә шәп сукалыйсыз.

— «Война и мир»ны сукалап чыктым. Баштанаяк кулдан күчереп. Ике мәртәбә.

— Граф Лев Николаевичны... Все-таки графлар да кирәк, әйеме? Ә менә безне («Безне»? Юк, сезне түгел, безне, Булганин әфәнде!») кайчан күчерерләр икән, Ваня? И вообще, берәр вакыт күчерерләр микән? Сай йөзәбез шул, сай. Нәрсә инде — бер турбиналы станция дә бер казанлы спирт заводы.

Дәшмәдем. Ни дия ала идем соң? Исем китмәгән, кайгым юк дигән кыяфәттә ак болытларга карап тордым. Күлдә балык ухылдаганы хәтеремдә, ул сазлыклар өстендә акчарлаклар күп иде, акчарлаклар... Камадан бала чыгарырга менгәннәр иде күрәсең.

Булганинның тәкәббер сүзләре миңа озак тагылып йөрде. Гомеремнең ахырына таба оныттым. Безне хәзер андый-мондый графлар гына кузгатырлык түгел. Без дөнья йөзенә каныбыз белән язганны алар динамит белән көйдереп юк итәргә тырыштылар. Минем Днепрогэсның коточкыч җимерекләкләре өстендә басып торганым бар. «Безгә кадәрге барлык империяләрдән (римлыларны гына ал, үзеңнең борынгы болгар бабаларыңнан да ерак китәсе юк) мондый җимерекләкләр, хәрабәләр шулкилеш мәңгелеккә тапшырылганнар»,— дип уйлады ул чагында инженер-подполковник Зәйнушин. Ул вакытта Булганин Ярослав Борисович аның исендә иде әле... Бары тик Братски ГЭСын открыткалар итеп таратучы кына оныттым. Минем Братскием белән Усть-Илимымны кемдер күчереп ясарга җыена икән, риза — мине онытсыннар. Белмим, «Сугыш һәм тынычлык»ны Толстой үзе ничә тапкыр күчереп язды икән? Ә минем бер эшләгәнемне кат-кат күчерергә вакытым тимәде. Хәер, бүтәннәрнең дә. Братски ГЭСы — биш елда төзелеп беткән бердәнбер станция. Нәкъ иң беренче станциям кебек үк, ул да юктан бар булгандай корылды. Кеше аягы басмаган урында, сметага караганда очсызракка төшереп. Әйе, ул — минем бердәнберем. Тырышлар, мин «Сугыш һәм тынычлык»ны күчереп язып чыккан шикелле, аны да җирдә «кабатлап» карасыннар иде. Тарихка һәм киләчәк кешеләренә тәҗрибә рәвешендәге бүләгем... ГЭСлар — минем балаларым иде. Ә балаларны кабаттан табып булмый. Аларда ата-аналар үзләре генә кабатлана.

Ә бу станция... Менә хәзер мин аңа әйләнеп кайттым. Ул мине тудырды, ә мин... ә миң үлеп яткан ананың баш очындагы бала кебек, аның җирдән китүен карап торам. Ләкин аны җиргә күмәргә ярамый иде. Чөнки мин Булганинны искә төшердем. Ул карап тора, сыный, чыннан да, карга оясы, тузган карга оясы дип шатланмый микән?

Аңа ничек, белмим, ә миңа ул очрашуның файдасы тиде. Мине кинәт авыр тойгы биләп алган иде бугай. Күз алдымда — аның тагылмаган кобурага ябышырга торган житез, йөнтәс кулы. Килгән эзем буенча ялгызым гына агач арасыннан чыкканда үз артымда кемнеңдер сулышын ишетеп бардым кебек. Йөрәгем ярсып тибә, бу тирәдән тизрәк ерагаерга ашкынам, ләкин ашыга алмыйм, әрәмәлек арасындагы сазлык суларының куе кызыл төстәге боз кебек тын өстен игътибарга алам — матур; аяк очыннан күтәрелеп киткән кыр тавыгы сискәндереп җибәрә, кош авазларында ниндидер хәвеф бар сыман.

Чыннан да, Булганинга төшкән шигем алдамады. Соңыннан бу очрашуны күз алдымнан уздырганда беренче тапкыр кешеләрне үтәли күрү, яхшы аңлау, күзәтүчәнлек, сизгерлек тойгым барлыгына ышандым.

## VII

Каһир тырышкан: кичен кояш кызарып, офык артына төшкәч һәм зират каеннарындагы ояларына — ерак басулардан кара каргалар, ә мәчет манарасына чәүкәләр кайтып тулгач, морзалар өе, ягъни авыл советы янына кешеләр җыела башлады. Күңелләре көр: ирләр төркем-төркем булып гәп сата, көлә, тәмәке көйрәтә, хатын-кыз заты да бар, алар тирәли бала-чага куышып йөри.

Идрис Ярмиевнең хатыны Өрфәйдә апа кертеп куйган кабыклы бәрәңге, яңа сауган сөт, майлы арыш көлчәсен ашагач, бераз кәефем күтәрелде.

Күк тулы йолдызлар, якында гына бакалар кычкыра, ярсый-ярсый сандугач сайрый, этләр өрә. Вакыт-вакыт ерак аҗаган канаты кагынып куя.

Гармунчы янына елышкан яшьләрдән читтәрәк галифе чалбар кү земә чалынып китте. Шунда таба юнәлдем. Ике колач та житмәслек карт тупыл артында кара-каршы ике кеше басып тора иде. Яннан яктырткан ай тузанлы җиргә аларның озын сыек күләгәләрен сузып салган. Галифе һәм эшләпә! Бу, шиксез, ул иде. Алардан ерак та түгел өченче тупыл артына сыендым, тик аның төбенә өенә кайтмый калган ике каз (бәбкәсез булганга эзләмәгәннәр дә, күрәсең) кунаклаган булган, алар авыз эчләреннән каңгылдап, читкә тайпылдылар. Тегеләр пышын-пышын сөйләшүдән туктадылар, аннары тагын керештеләр. Тик ата каз зарлануыннан туктамады, аның калын авазы Булганин сүзләрен йота, һични аңламыйм. Алар әрләшә үк башладылар ахрысы. Булганинның пышылдауга сыймаган ярсу гөлдерек тавышы белән:

— Ну-с, пор-ручик, только посмей, то-олько пос-мей, голубчик! В петлю лезешь, в пет-лю-ю!— дигәнен аермачык ишетәм.

— Они поверили мне. Доверили детей! У них же нет ничего, кроме детей.

Бусын әле танымый тордым.

— Только посмей, ты только посмей, паскуда! Юсупыча пропишу, так и знай. Ей богу, Шереметьев! Не совращай, ей богу, не совращай, Христом богом прошу-с!

«Ширәмәтов?»

Кызык компания! Штабс-капитан белән поручик. Генераллары гына юк. Бәлки бардыр?

Каһирның җыелышка дәшкәне яңгырады. Морзалар йортының тәрәзәләрендә һәм ишегендә утлар күренде: берничә җиргә асылган лампаларга ут элгәннәр, халык, төтен кебек суырылып, эчкә узды.

— Шулайттем мин синең алланы, белдеңме? Шаһит тору сиңа килешми, Борисыч. Кагылсыннар гына, үзеңнең контрразведкаң белән дерьмом запахнешь! Рамазанов — синең өчен конфет кына ул. Кичерерләр димсең? Тот, Борисыч, учлап тот, понял?! Кичермәячәкләр. Койрыгыңны кыс та өеңдә генә шыңшып ят. Гөнаһыңны юып бетермәле түгел!..

Җитте. Кирәм дә Каһирны кочаклап алам. Безгә хәзер бергә булырга кирәк. Рамазановтан соң — минме? Ләкин козырь миндә иде шул инде.

Яшеренгән урынымнан чыгып, якты утларга таба киттем. Борылып карамыйча, коймага елыштым — танымасыннар, тик үзләрен тыңлап

торганны аңласыннар. Алар арасында — кара мәче. Ширәмәтов Булганинны чыгырыннан чыгарган нииндидер гамәл кылмакчы, тегесе аңа ирек бирмәү әмәлен дә табар иде, әмма мин аларның кайсыныңдыр картасын тетелеп беткәнче бутадым бугай.

Аркам һәм борыным тирләп чыкты. Ишеткәнем дулкынландырган-гамы, арттан пычак күтәп баргангамы шунда, белмим. Ачык ишеккә житкәч, борылып карадым: чыннан да кемдер ияргән, тагаен тегеләрнең берсе инде. Ул коймага сыенды да тәмәке кабызды — Ширәмәтов. Аның нияте ни? Аныкы билгесез, ә Булганинныкы изге түгел, факт. Аларның болганчык әрепләшүендә, сасы судан авызын калкытып калыккан балык булып, Ширәмәтовның «У них же нет ничего, кроме детей» дигән кызганулы, шул ук вакытта аңа ышаныч баглардай сүзләре тончыга иде. Ширәмәтов ул балыкны нишләтер икән?

Җыелыш башланган иде. Баскычтан күтәрелүгә, артка борылып карадым. Ширәмәтов ишектән җиргә такта табут әчен хәтерләтеп төшкән сүрән яктылыкка керергәмә, кермәскәме кыймыйча басып тора. Шул чикне узуы җиңел булсын дип, ишекне ябам да бусагада калам. Каһир күреп алып, мине түргә — Идрис абый, тагын берничә кеше утырган кызыл комач япкан өстәл янына чакыра. Стенага аркам белән ышкынып диярлек алга барам. Тәмәке төтенендә балта эләп куярлык, бөтен залга морҗа корымын изеп ясалган миләүшә кара лозунглар язып эленгән, почмакларда байрак булып пәрәвезләр җилфердәп тора, тузанлы тәрәзә өлгесендә төтеннән исергән һәм тавыштан тунгән вожан вырылдый. Түшәмдә штукатурка урыны-урыны белән купкан, кешеләрнең башына акбур тузаны коела.

Сөйләүче бер генә түгел икән. Өч унлы лампа көчкә яктырткан зур залдагы кеше йөзләре төнгә каршы томан күтәрелә башлаган су өстендә бата-калка торган соры ташларны хәтерләтеп селкенә, залның буеннан-буена яки аркылы-торкылы кара-каршы әйтешкән сүзләр очынып йөри.

Электрдан беркем баш тартмый, байтагының аны калада күргәне бар, җайлы нәрсә, югыйсә кеше булып торып, сукыр тычканнардай караңгы өннәрендә кармаланып гомер үтә, һәм башкалар, һәм башкалар... Каһир яшелләнеп беткән сулы графинны туктаусыз кага, тик тора-бара электр станциясе төзү онытылды, кемнеңдер яңага кадәр икмәге беткән икән, кемнеңдер сыеры үлгән дә соцстрахование түләмиләр, чуаш көтүчеләре ашату начарга күрә кайтып киткәннәр, берсенең хатыны өч бәби тапкан, мәчеткә җен ияләшкән, төне буе кеше төсле елап чыга, ди, Солтан авылы мәчетенең манарасын былтыр ук кисеп төшергәннәр ничу совет авылында җен симертеп яткырырга...

Каһир тимер каптырмалы карандашы белән графинга тагын суккалады. Минем әле мондый җыелыш күргәнем юк иде: аптырап, югалып калдым, рабфактагы ялкынлы комсомол җыелышларын хәтерлим, институттагы партия җыелышларында урыннан сүз кыстырганчы, җиде тапкыр уйлагач та телеңне тибрәтмисең, җиде тапкыр үлчәп, бер кисү һәрчак яхшыга түгел, анысы ни кисәсең бит әле, кайчан кисәсең. Ә биредә телләр камчыдай шартлап кына тора, шөпшә булып, берсенберсе чага, бөтенесе берәүгә ябырылып, тегене молотилка барабаныннан үткәргәндәй тетеп ташлый. Җыелыш шуннан ары узмас дип куркып, хәлне коткарырга ашкынып, алга уза башладым, ә Каһир кыңгыр эше өчен атасыннан әләгәсен сизенгән бала сыман, кисәк өстәл артына чүгеп югалды. Мин килеп җиткәндә, ул өстәлгә сары граммофон күтәреп куйды. Тагын иелеп, аның ялтыравыклы һәм чүкеп төшерелгән бизәкле быргысын алып кигезде дә халыкка борылды. Зал сагаеп, сабырсызланып Каһирны күзәтә башлады. Ә ул крокодил тиресеннән тегелгән портфеленең көмеш йозагын винтовка затворын коргандагыча күнегелгән, гайрәтле хәрәкәт белән шартлатып ачып, капкачын артка

каерып салды да, «Кызыл Татарстан» газите эченнән кара пластинка аралап алган, өргәләп граммофонга беркетеп куя; аннары келтерәтеп кенә боргычын бора һәм, әйләндереп җибәргәч, тавыш чыгаргычын тәлинкәгә чәнчи.

«Что такое Советская власть?»

Совет властена унбер ел ярым, аның ни икәнен яңа буынга ана сөте белән керә, ә безнең анда ул тамырлары торган саен тирәнәя, кәүсәсе ныгый, ә ябалдашы җәелә барган мәһабәт агач булып үсә, дошманнар аның куәтен чигенгәннән-чигенә барып таный иде инде. Ә монда кинәт тагын бер тапкыр:

«Что такое Советская власть?» дигән, тонык ераклыктан килгән киеренке, әмма нык сорау яңгырый. Ишек ачылып, Ширәматов кергәнен мин күз кырыем белән генә абайласам да, илтифат итмәдем. (Халык тәмам тынды, ачык тәрәзәләрдән бакалар сайрашканы гына ишетелеп тора башлады.)

«Что такое Советская власть?»

Минем моны рабфакта тыңлаганым бар. Ул чагында ни сөйләгәненнән битәр, кем сөйләгәне, ничек сөйләгәне кызыксындырган, күрәсең, мин инде әчтәлеген яхшылап хәтерләмим. «Что такое Советская власть?» — моны, минемчә, бөтен кеше белә. Ләкин терәп сорасаң, моңа сүз белән җавап бирүе җиңел түгел, аңа эш белән җавап бирү ансатрак кебек. Совет власте сулый торган һава, эчә торган су кебек бер нәрсәгә әйләнгән иде инде.

Совет властеның ни икәненә граммофон тәлинкәсе җавап биреп бетерде, әмма күңелемдә әнә шул кинәт әйтелгән «Что такое Советская власть?» дигән катгый һәм кырыс сорау үзе үк ачык җавап булып яктырып калды.

Тәлинкә әйләнеп бетте, чыжлап кына тора башлады. Залда пышылдау китте, ә Каһир граммофонның тавыш чыгаргычын янга кайтарып, боргычын борды да тагын әйләндереп җибәрде һәм урындыгына утырды. «Что такое Советская власть?» дигән сорау тагын кабатланды, тик бу юлы ул берәүнең күпләргә биргән соравы төсмерендә ерактан ишетелмичә, күбәүнең берәүгә анык җавабы булып бик якында — йөрәгемдә (димәк, барысынкында да) типте, йөрәгем аша җылы, тыныч кан агышы кебек үтеп, бөтен тәнемә таралды.

— Кем сөйләде суң, җәмәгать?— дип сорады алгы рәттәге бер хатын.— Безнеңчә дә әйтеп бирсен. Тәлинкәсен әйләндерсен.

Каһир рәхәтләнеп елмаеп җибәрде.

— Акылың алтын икән, Тәнзилә апа!— диде ул һәм халыкка карап:— Безнең пластинка ике яклы түгел, әйләндереп салырмын димә!— диде.

— Алайса, безнеңчә дә әйтеп бирсен! — дип тынмады хатын.

— Ә безнеңчә әйтмәдемени ул? Әллә байларча әйттеме?

— Кем сун ул, кем?

Алгы рәтнең иң кырыенда утырган, ак энҗе белән чигешле кара бәрхет түбәтәй, яшел күлмәк һәм кара казаки кигән утыз яшьләрдәге бер кеше безнең арттагы портретка карап тын, әмма үзен ишетәчәкләренә ышанган тавыш белән:

— Ул,— диде.

— Кем — ул?

— Ленин.

— Каян беләсең син, хәзрәт, әллә мәчеттә биш намаз чыгып киткәне бармы?

Көлделәр.

— Кем бу?— дип сорадым мин Каһирга таба авышып.

— Авыл мулласы.

— Күргәнем юк иде.

— Аның үз кайгысы әле: абыстай кирәксенеп йөри диләр. Йөзен авылының поп кызы Марийкага яучы җибәргән.

— Ул икәнен каян беләмме?— диде мулла.— Акыллы әйтте — шуннан. Болай шәрехләп Мөхәммәт галәйһиссәлам белән ул гына әйтә аладыр.

— Син, мулла, контра сүзләре сөйләп утырма, яме?— дип кычкырды Идрис абый сыңар кулы белән кобурасына шапылдатып.

— Корьән шәрифләре уйлап фараз кылуны мәслихәт саный, җәмәгать,— диде мулла тыныч кына.— Менә сез еликтр корыргамы дип җыен җыйдыгыз, ә фикерегез сукыр әле. Корьән яктыны хуп саный, власть сүзенә иярергә өнди. Минем мәсьүлем шуны ирештерү генә, муафыйк күрсәгез, утырган урындыгым язык булсын, чыгып китә алам.

— Ярый, утыр,— диде Каһир, аннары миңа сүз бирде.

— Совет властеның ни нәрсә икәне ачыкмы?— дип сорадым, терәткеле үргән урындыгым артына чыгып басып.— Иптәш Ленинның сөйләгәненә төшендегезме?.. Кабатлап тормас өчен сорыйм.

— Кем төшенмәде?— дип кычкырды кыл уртага эленгән лампа күләгәсендәге китәргән башлы бер ир йодрыгын болгап.— Урамга чыксын, аңлатып кертәм, алланы!..

Аның җиңенә шәл бөркәнгән хатын чытырдап ябышты:

— Затсыз, утыр, өйгә кайткач сүгенерсең, кеше алдында рисвай итмәсәң соң...

— Сүгенсә соң?! Рамазан ае мәллә? Әнә алланың кашка тәкәсе утыра, гөнаһлы булсам, ярлыкасын!

— Совет власте кирәкме безгә? — дип сорадым.

Соравым тынлыкка кереп батты кебек. Сүземне дәвам итәргә авызымны ачканда гына бер хатын чәчрәп торды:

— Ник кирәк булмасын, олан?— диде ул яулык очын күзенә тидереп алгач.— Әүвәл ничек тордык? Ләүхел-мәхвүздә язган дип, ана карыныннан пәйда булып, салкын гүрләргә иңгәнче, фани дөнья безгә гаурәттән битәр, ачык чырай күрсәтмәде. Әкәм-төкәм ише, һәркайсы үз кабыгына бикләнеп җәшәде, береңнеке икенчеңә артмады...

— Үзең белән үлчәмә! Әнә Мәүлиянеке бик арта әле, өенә төп юлы бакча артыннан салынган!— дип кычкырды нечкә яңгыравык тавышлы берәү.

Түшәм күтәрелеп, залга сыймаган шаркылдап көлү күккә ашты.

— Ыржаймасагыз сәнә! Сәвит влачына рәхмәт яусын инде, җир бирде, сыерым бар, ике кәҗәм, аллага шөкер,— шулые менәтерә әйтәсе килгәнем.

— Рәхмәт,— дидем.— Әйбәт әйттең, апа. Ә бит алып кына булмый, бирергә дә кирәк, Совет власте савым сыеры түгел.

— Әйтәм җирле кырып-себереп бетерә бара...

— Ул сезгә кирәк булган кебек, сез дә аңа кирәк!

Мин аларга бу рәвешчә кул кушырып, миллион ел көтсәләр дә чын яктылык һәм җылылык үз аягы белән киләчәк түгеллеген, мең еллар буена түзгәнне, тагын дүрт-биш ай ат дугасы шикелле киерелеп, камыт сыман көчәнеп, ат ише егылмыйча, арба төсле гел алга тәгәрәп, бәлки оныкларының да оныклары онытмаслык һәм әле бу якларда күзкүрмәгән гамәл кылырга — теләгән чакта күз ачкандай яки йомгандай итеп кенә теләсә кайсы караңгылыкны мең карышка чигендерерлек, эшкә җиксәң, теләсә нинди ташны ком итәргә сәләтле куәт чыганагы — электр станциясе салырга кыстадым. Үгетләдем. Үзегездән башка моны сезнең өчен беркем дә эшләмәячәк, чөнки аның сездән кала беркемгә дә хаҗәте юк, дидем. Бөтен әйләнә-тирәдә ничә йөз, мең еллар буена бу җирләрдә яшәгән кешеләр арасыннан иң беренче булып шушы эш аларга төшкән икән, моны бәхеттән гайре ни санныйсың?

Кайдадыр, кемдер — шул ук нарком — бармагын картадагы башка ноктага төртергә ихтимал иде. Ә бәлки нәкъ монда туры килүе очраклы түгелдер? Шулай тиештер! Чөнки бу — борынгы Болгар иленең, хәзерге Татарстан җирләренең кыл уртасы, һәм дөньяга таралган яңа тормыш калыбын шушында калыплап күрсәтү мәгъкульдер. Артта — җаннарны тез чүктергән коллык, алда — безне тилмерепләр көтеп торган бәхет.

— Сез шуңа лаек түгелмени?! — дип сорадым.

— Лаек! — дип кычкырдылар.

— Тик, — дидем, — Казаннан да, районнан да бюджет җибәрмиләр. Бары тик станция машиналары гына бирәләр дә тагын кайбер нәрсәләр...

— Бюджетлары шайтаныма кирәкме, безгә акча җибәрсәләр дә ярый!

Кычкырып көлдем, ачулары килде, без кеше көлкесе түгел, дип ярсындылар.

...Хәтерем диңгезе ярларына әнә шул җыелыш дулкыннары китереп кага да ишелеп төшә, китереп кага да ишелеп төшә... «Теге кыз кайда икән хәзер?» — дип сагаям. Тукта, тукта: нинди кыз иде әле ул?

Ул ишек төбендәрәк басып тора иде. Кызыл яулык япкан, иңбашлары күпертелеп тегелгән көлсу кофта кигән.

— Мин комсомолка, — диде ул. — Әти-әниләрнең җиде җанга бер сыер, бер атларыннан гайре артык җамаулыклары да җук. Мин аларның балаларының иң өлкәнесе, миннән аларга он да җук, җон да җук, ә минә бер сандык бирнәм бар. Шуны сатып, акчасын стансы төзүгә бирәм.

Шул кичне атасы аны мунчага бикләп, елый-елый кыйнаган да таң белән бирнәсен арбага салып, Казанга чыгып киткән. Ә икенче көнне ул авыл советына шуның керләнеп беткән акчасын кертеп салды.

— Безнең нәселдә әйткән сүз — аткан ук, оланнар, — диде ул Каһир белән миңа. Моңсу йөзле иде ул, Шәйдулла исемле.

Аннары соң мулла егет сүз сорады.

— Диндәшләр! — диде ул. — Вә иптәш динсезләр... Менә сез илаһи мәсчет манарасына җен иялашкан, төннәр бакый еглап чыга дисез. Хак бу, хэрендәшләр.

— Әйтәм ич, ышанмыйсыз, мөртәтләр! Әнә, хәзрәт үзе дә тана!

— Әгүзе әйтергә дә, манарасын җене-ние белән кисеп төшереп, утка салырга кирәк — шул!

— Фәрештәләрнең амин дигәненә туры китереп.

Мулла торып ук басты. Озын һәм нечкә гәүдәле, җеген-җеккә туры китереп теккән кием, кара тут йөз, кап-кара сакал-мыек арасында утлы күмер шикелле көйрәп торган иреннәр, май коңгызын хәтерләткән сабыр күзләр — мулла түгел, ә Иран шаһы илчесе диярсең!

— Минем башымны кисегез, манара гөнаһсыз. Манарага менеп, мин еглыйм.

— Башың кистерергә риза булгач, ни пычагыма чәч дип җылыйсың!

— Әти мине тәңре гыйлеменә Ыстамбулга җибәреп ирештерде, беләсез. Җиде ел тәүлеге ирешкән гыйлемемне кая куйыйм — менә шуңар елгыймын мин, хәрендәшләр. Мин изге туган илемә юл алганда, илемә юл алганда, әти тынчу Төркия мәмләкәтенә мөсафирлык кылган. Рәчәйнең асты-өскә килгән, адаштым — шуңа еглыйм. Гавам гыйлеме-

нә дә ия башым бар — я мәхәллә манарасы белән бергә кисегез, ә мөгаллимлек кәсебе бирегез. Менә бу мөрәвәтле бәндәнең,— диде ул миңа ишарәләп,— гакыллы өндәвенә шөкер кылган хәлдә изге эшегезгә фәтва хакына ике фарсы паласымны салам.

Колхозлар оештыру шаукымыннан бу авыл кешеләренең дә көнелләрендә, мич астындагы чикерткәләр шикелле, билгесезлек һәм курку чыңы дөрли башлаган, кем маңгаена «ярлы», кемгә «урта хәлле», ә кемгә «кулак» дигән төрле мөһерләр сугылачагын хэйләкәр, сак борыннары белән сизенәләр, кемнең үткәне нинди, кемнең туганы кем булган, кем җыелышларда нинди сүз ката, кем мәчеткә йөри — һәммәсе дә үлчәүгә салыначак икәнлеге өрәк булып авыл буенча мыштым гына йөрергә керешкән, шул сәбәплеме, әллә, чыннан да, күктән иман иңмәслегенә инангангамы, Җәмлихан мулла (әйе, аның исеме шулай иде, тик соңрак аны нигәдер мулла-мөәзин дип йөрткәннәре хәтердә калган) мәчетенә күрәләтә йөргән кеше сирәк булды, һәм Каһир Сафин мәрхәмәте белән ул көздән балалар укытырга кереште. Коры вәгазь белән генә калмады, станция салуда башлап, бирелеп, кулына кирәкбалта тотып булышты... Ә аның паласларын нишләтергә, ничек, нинди кәгазь белән рәсмиләштереп, нинди максатка юллап булачагын, алыргамы-алмаскамы икәнен әле уйламаган да мәлне, стена буеннан ышкынып, түргә Ширәмәтов үтте. Халык әле яшь мулланың гамәленә нинди бәя бирергә белмичә аптырабрак утыра, ихтимал, байтагы моның үзләренең мыскыллап җыйган соңгы акчаларын чыгартыр өчен уйлап табылган мәкерле капкын булмагае дип, өнсез калдылар. Ширәмәтов өстәл янына килде, халыкка аркан басып, уң кулын куен кесәсенә тыкты. Каһир, кемдер чәченнән тартып торгызгандай, күтәрелә барды, ә уң кулы пинжәк итәген бармаклары белән югары кайтара төшеп, чалбар кесәсенә тыгылды. Ә анда ни икәнен мин бик яхшы беләм ич инде. Ширәмәтов ирен кырые белән генә көлемсерәп (ниндидер мыскыллау, тантана билгесеме?) куйгач, Каһир аннан күзен алмыйча гына урынына утырды. Күрәсең, алар бер-берсенең кем икәнен бик яхшы беләләр, бер-берсе ягыннан теләсә нинди көтелмәгән хәлгә һәркайсы әзер). Алар арасындагы киеренке мөнәсәбәт соңыннан да һичкайчан бушамады, бер заманны төзелештә яңа юнган агачларга «Салып бетерүегезгә ут төртәбез» дип, дегет белән язулар башлангач, Каһир иң әүвәл гел аны тикшерә, Идрис Ярмиевне аннан әледән-әле сорау алырга кыстый иде, тик Ширәмәтов моңа гарьләнмәде, горур кала белде, алай да ул Каһирның коры үртәлүеннән тәм таба иде ахрысы). Билал Ширәмәтов хәрбиләрчә тартылып, халыкка каршы борылмакчы иде, ишеккә текәлеп, ярты юлда туктап калды: ишек янагына зәңгәр ефәк яулык ябынган Ниса сөялеп тора иде — хатыны.

— Ширәмәтов,— диде Ниса ниндидер моңсу, хәлсез елмаю һәм ярдәм сораган тавыш белән.

— Шулай кирәк, Ниса, кичер... Миңа да рәхәт түгел. Нишләтим соң, шулай кирәк... Аңла, зинһар...

Ширәмәтов, инде беркемгә дә карамыйча, сул учына салган кулъяулыклы учыннан уң яңагына пәрәвез җебе нечкәлегендәге ямь-яшел нур килеп кадалды.

— Шулай кирәк... нишләтим соң... нишләтим... — дип кабатлады йөзе кинәт агарып калган Ширәмәтов. Иренс вак кына дерелди, битенә күз яше сузылып төште, һәм тере яшел нокта аның күз яшенә чыланып эрегәндәй юкка чыкты.

Ниса ирексездән ачылган авызын учы белән томалады, чыланган һәм дәү ачылган күзе аңлаешсыз бер караш белән иренең кулъяулыклы учына төбәлгән. Ул тәссез, салкын тавыш белән:

— Нишләдең син, Ширәмәтов?! — диде.

Күз алдында ниндидер, хәтта Каһир Сафинны да югалтып калдырган онытылмаслык фаҗига тәгәлләнде бугай.

— Ул асылташ синең өчен мин идем ләбаса, Ширәмәтов! — дип, Ниса шәлене төренеп чыгып китте.

Ширәмәтов кулъяулыгын ике учы белән тотып, безнең өстәлгә китереп куйды.

— Син әле шулаймыни?— диде Каһир алга иелеп. — Шулай дип уйлаганыем аны. — Ул кулъяулыкка бөтенләй карамады да ахрысы.— Шушыңа кайттыңмыни? Калганнары кайда?

— Бүтән юк,— диде Ширәмәтов хром итек кигән аякларын киң аерып баскан килеш. — Нәсел ташы безнең каннан гаеп булды... Хәзер мин морза түгел инде, иптәш-ш Саф-фин! Хәзер мин синең шикелле үк азат.

— Ни бу? — дип сорадым мин ак кулъяулыктагы айсыз һәм төпсез төннән китеп алынган караңгылык кисәген хәтерләткән саф асылташтан күземне ала алмыйча.

(Ул асылташның бөтен гомерем буена күңелемдә нindидер төпсез ераклыктан чиксез киләчәккә өмет белән баккан ак битле Кәүсәриянең йөрәге булып типкән кара кайгысы рәвешендә калачагын бу мизгелдә белми идем әле.)

— Ни бу? — дип кабатладым залда киндер җәймә кебек ертыла башлаган тынлыкны коткарырга тырышып.

— Сезнең хыялыгыз,— диде Ширәмәтов.— Станция... Теләсәгез, трактор да... атлар... яңа мәктәп. — Ул миңа: — Бәхетле кеше сез,— дип елмайды да итеген шыгырдата-шыгырдата чыгып китте. Артыннан иярәсем, Рамазанов белән Булганин турында сөйләтәсем килде тыелып калдым: хәзер анда моның кайгысы юк, дөнья гаме аннан ерак икәнен төшендем. «Өлгерелер,— дип уйладым.— Иртәгә һәммә кеше белән булсын өчен бүген аңа ялгызлык кирәк».



## VIII

...Соңыннанрак Каһир Сафинның язмышын һәм яхшы әңгәмәдәш икәнен белдем. Ул салмак яки, киресенчә, гаять ярсу сөйләшә иде. Урынына һәм вакытына карап. Салмак икән — аның һәр сүзе төгәл, ачык, мәгънәле, чуерташка чуерташ бәрелгәндәге шикелле. Ярсу икән— син үзеңне коры утыннар янган учак алдында торган сыман тоясың. Андый чакларда сүзләре һәм фикерләре ялкын телләредәй бии башлый.

Сугышта ул пулеметчы булган икән. Һәм нинди генә әле! Аклар белән кызыллар арасында аның «Кара пулеметчы» дигән кушаматы һәм даны таралган булган. Аклар аның башы өчен ун мең сум акча вәгъдә иткән игълан да бастырып таратканнар. «Кара пулеметчы» булган урында аларның психик һөҗүмнәре канлы сугыштан битәр ниндидер бер салкын акыл уенына охшаган. Шахмат уены кебегрәк. Ихтыяр уены. Башка фигуралардан аерылып, каршы якның үзәгенә кире каксыз рәвештә нәкъ вакытында бәреп кергән бәләкәй пешка сыман, алтын погонлы офицерлар рәтен ул аптыраштa калдыра һәм, үгез көтүендәге ялгыз кигәвендәй, ярсыта торган булган. Ә ярсулык һәм ачу кабарту — психик һөҗүмнең салкын канлылыкка исәпләнгән барышына мат. Моны аның үзеннән дә остарак итеп сөйләп тә булмас.

— Алар көпә-көндез килә. Ачылган шампански күк ташып. Тын. Кысан кабердә ятасыңмыни! Кышын тиргә батасың, җаен тәнгә салкын «каз тиресе» чәчрәп чыга. Янәшәңдә чалгы шикелле үткер егетләр, атаң шикелле, сине сынап, ирләр ята... Пулеметтан атасың — алтын погонлылар рәтендә берәү ачылган ишек күк янтая да күздән югала, ә икенчесенә тәзәгендә ишек кире ябыла инде — ятып калганы урынына

арттагысы баса, алгы рәт гел тулы. Бер шулай, ике — аннары күзне караңгылык баса. Инде күзгә карап кына түгел, мигә дә карап килә-ләр. Кайчак безнекеләр чыдамыйлар, командирны көтүче урынына да күрмичә, койрык чәнчеп кача башлыйлар.

— Ә син кайда?

— Күзгә чыккан сөял кебек — иң алда. Тегеләр кычкыра: Сафин фәлән дә төгән... Башта дәшмисең әле. Син бит, наганда үзеңә генә калдырылган соңгы патрон кебек, бәлки бөтен полкка бер генәдер... Алар барабан кагып килә. Мин дә пулеметтан шул көйгә атам. Анда кем кемне күпме кыра — не важно. Бер-береңнең ихтыярын сындыру — минә иң мөһиме. Сукырның таягын сындырсаң, нишли? Ул чакта аңа ни аннекция, ни контрибуция. Шуның өчен мин урта бер җиргә генә сиптерәм — ишекне гел ачык тотам, шуннан миләренә сквозняк бәрә башлый да. Бер ноктага ату җиңел дисеңме?! Шул чак алар икегә бүленә, ишекне ябар өчен артта кешеләре бетә, ул чагында рәт буйга сузыла башлый. Менә шунда инде алар артларына җибәрергә керешә. Шунда инде кире элдерә башлыйлар. Аннары алар минем әти белән әнине астылар. Минем өчен. Ә уналты яшьлек сеңлекәшемне... взводка... Шуннан мин аларны ата алмый башладым. Уен бетте. Чөбен урынына кырдым гына.

— Ә бу барыбер түгелмени?

— Уйнаганда мин җиде кат күккә менә идем. Ә үтергәндә... Кешене үз үчең өчен үтергәндә кисәкләп-кисәкләп үзеңне дә үтерә башлыйсың... Ә үтерү — ул инде җиңү түгел. Мин үтергән офицерларның күбесе папирос кабып, күзгә карап үлә белә иде... Үтергән һәр кешең кайчандыр барыбер төшеңә килеп керә... Кабат үтерүчегә әйләнәсең...

— Сугыш — шуның өчен сугыштыр инде ул,— дим мин көчсез тавыш белән.

— Белмим.

— Син ник өйләнмәдең?

— Кая анда!..

— Ә хәзер?

— Сугыш түгел дисеңме? Сугыш башлана гына әле. Ник гаҗәпләнәсең? Моңынчы без дошман белән күзгә-күз сугыштык. Хәзер күзләр бәйләүле. Хәзер атаң белән генә түгел, үз-үзең белән дә бугазга-бугаз килү заманы. Кайберәүләр аталарыннан гына түгел, үз-үзләреннән дә ваз кичәчәк әле. Идеяләрен сатып... Аңладыңмы?

Иңбашымны җыерам, дәшмим.

Тик Каһир Сафинның соңыннанрак үз идеяләрен үзе сатканын аңлап җиткермәдем. Ягъни...

Ягъни утыз өченче елда ул колхоз ындырын «хет борча сытарлык» буш калдырган да, галәмәт күп кеше ачлыктан җәфа чиккән.

Ул вакытта бу авылда түгел идем инде.

Хәзер менә тагын очраштык.

Төнге тынлык йокларга ирек бирми. Шәһәрнең өзлексез гөрелтесенә күнеккән колак тынлыкны каты шартлау кебек үк сискәнеп кабул итә. Фронтта, шулай, тынлык колакны контузияләнгәндәге шикелле томдыра иде. Кул сәгатен үрелеп алам да мендәр белән колак арасына тыгып куям. Юк, тавыш юк.

Торып, өстәл лампасын кабызам. Җәймә җылысы ярканат сыман өнсез генә очып китә, иңбашыма төннең салкын шәле ябына.

Портфельдән ачылмаган коньяк шешәсе алам. Эчәргә ярамый, беләм, бигрәк тә коньяк: бавырны Трусковец суы белән язын гына «юдыртып» кайттым әле, ләкин үземне алдарга «әзрәк изрәтмәсме» дигән сылтавым бар. Дару йоткан кебек көчләп, йөземне чытып кына, мылтык аткандагыча сулышымны тыеп эчәм — кан тамырларыннан

кырмыскалар йөгерешә. Бераздан уң як кабырга астында авыру мәче уянaчак та сыкрау башланачак, әмма бу мәлдә ялкынлы әчемлекнең канга таралуы аңа гына торырлык. Салкынлык шәлс иңемнән идәнгә шуып төшә, кәеф күрәеп китә. Бала чагымда бөтен йөзем белән капланып, әни пешереп биргән көлчә кайнарлыгын сулыйм кебек.

Майка өстеннән генә пинжәгемне элеп, баскыч төбенә чыгып бастым.

Сигарет кабызып, аны иренемнең бер почмагыннан икенчесенә куып йөртәм. Аның әче төтене күзне кысылырга мәҗбүр итә, андый чакта игътибар бер ноктага төбәлә. Дөрес уй килсә, шуны раслагандай, чирткәләп көлен кагам.

Сигаретны, җиңелчә генә итеп, күккә чөеп җибәрәм. Аның уты Киек Каз юлындагы миллиард йолдызларның берсенә әверелә, аннары, әйләнеш ясап, түбән борыла. Җирнекен җир тарта. Нишләсәк тә, без дөньяга килгән урынга әйләнеп кайтабыз. Хәтта җинаятьчене дә җинаять кылган урыны тарта, диләр. Бөтенесенә дә хәтер сәбәпче. Ул, сүнәр өчен кабынган учактай, онытылыр өчен хәтерли. Кеше гомере — әйләнә. Аны түгәрәкләр өчен гомер ахыры гомер очын эзләп таба. Чынында безнең хәтеребез яши. Үзебез түгел. Без хәтерләр өчен яшибез. Балабыз дөньяга килә икән, бу — безнең бала чагыбызга әйләнеп кайтуыбыз. Үлгәндә без киләчәк буыннарга иң зур мирас итеп хәтеребезне калдырабыз.

Ачылмаган серләр юк. Онытылган хәтер генә бар.

Һәрнәрсә бер тапкыр булган инде. Ә, ихтимал, хәтта күп тапкырдыр.

Яшьтәшләр һәм исән калган өлкәннәр менә бүген таныды. Сөйләштек. Бигрәк тә Идрис абый белән. Күр күңелле, мәгънәле карт. Җәмлихан мулла колхозның яшелчә бакчасында каравылда тора икән, иртәгә күрәм әле. Азамат карт авылга кайтып дөнья куйган. Малайларының дүртесе дә сугыштан кайтмаган. Дүртесе дә. Кайтмаган. Үзе генә кайткан да авылында җан биргән...

Ни ишетсәм дә, үзебез күрәшнең — ачлыкка, ялангачлыкка, мәхрүмлекләргә карамастан, кылган эшләребезнең матур нәтиҗәләрен күрәм. Биредә булган һәр вакыйга тарихында һәм һәр кеше язмышында бу авыл халкының горур, буйсынмас, илен, халкын, хезмәтен яраткан рухы күренә... Кунакка дәшәләр — әлегә рәхмәт әйтү белән генә чикләнәм. Өлгерермен. Әлегә минем өчен ялгызлык татлы. Бу якларның тарихы һәм язмышы белән тулган ялгызлык. Шул ук вакытта һәр ялгызлыкның, үткән гомер шикелле, үз сагышы бар. Шул ирек бирми уйландыра. Нидер үкенечле, нидер сагындыра. Тән буенча кан түгел, вакыт агадыр сыман. Кичә, бүген, иртәгә — аермасы бетте.

...Ә кунакханәне уратып алган койма капкасын ачып кем керде анда?

— Йокламыйсыңмыни? — дип сорый караңгылык.

Таныдым.

— Синме бу, Каһир?

— Уяттың. Каберемнән чыгып килдем әле. Картайгач — хәтер, үлгәч кабер күмә.

Тәрәзәдән төшкән утны урталай бүлеп, Каһир баскычка утыра да папирос кабыза. Юка тиреле, җыерчыксыз киң маңгае, тирән утыртылган күз төбендәге күләгә, төтен суырганда эчкә баткан яңагы, шырпы уты җәйпәкләтеп күрсәткән борыны аның йөзен баш сөягенә охшата. Нәкъ теге вакытта станция астында күренгән кебек. Кыш көне... Ә хәзер аннан аракы исе килә, тик ул исерек түгел... Баскычка утырам. Без, яр буендагы балыкчылар төсле аяк салындырып, баскычта утырабыз. Хәтеребез балыкчылары. Күк йөзе — су, йолдызлар — калкавычлар.

— Сиңа бер әйбер кайтарып бирәсем бар,— диде Каһир.
— Үлгәннәрдән бурыч алмыйм.
— Чә! Мин әле исән! — Папиросын тирән суырып, ачуын йотып җибәрде сыман. Сары ут яктысында яңагы уйнаклап алды, чигә тамырлары бүртеп килде.
— Минем хәтеремдәге үлгәннәр исемлегендә син — иң беренчеләрдән.
— Мактаулы урында икәнмен,— диде ул, күзе кысылып килде. — Ә ул?
— Кем?
— Ул.
Мин аңладым: Кәүсәрияне әйтә.
— Ул тереләр исемлегендә.
— Тереләр?.. Ә мин аның сөякләрен күрдем. Зират күчергәндә.

Яңа зират... Ул таш койма белән уратып алынган; урта бер җирендә капка; аның өстендәге яшел манара башында җиз ай урагы; капка төбенә алюминнан кайгылы ана сурәте бастырып куйганнар — Казандагы Татар зиратына охшатыбрак. Зур ихтирам, нечкә зәвык, пөхтә осталык, төгәл исәп белән. Эчтә нивелир белән тигезләгәндәй туры тезелеп киткән каберләр. Игезәк каберләр. Койма буйлый өч рәт тезелешеп торалар. Һәркайсының өстендә исем язылган бер төрле таш. Бер почмакта исемсезләр тезелешеп тора.

Һәм мин шуны аңладым: һәр халыкның үз үткәненә карашы зиратында күренә. Киләчәкнең тарихка мөнәсәбәте нинди булачагын шул яңа зиратта төшендем.

Каһир сүнгән папиросын кабызды. Кабызыр нәрсә калмаган, кисәк тын белән аны аяк астына төкереп атты.
— Синең юкмы?
— Эчтә,— дип бүлмәгә кереп чыктым, кулыма теге коньяк шешәсен һәм стакан да эләктердем.

Кире какмады. Йөзен читкә борып, салганны эчеп бетерде.
— Иртәгә яңа каберен күрсәтерсең әле, Каһир,— дидем мин тыныч кына. Баскычка утырып, үзем дә салып эчтем.
— Уһу... Ә бүген — мә. — Кулъяулыгын таратып, ике бармагы белән нидер эләктерде дә карамыйча гына миңа сузды.— Мә.

Кулым үзеннән-үзе сузыла. Яктыга янтайтып, учыма карыйм, бугаз төбенә, су гына түгел, хәтта ут эчәсе килгәндәй, нидер тыгыла, телемә салкын тимер тигән шикелле. Ышанмыйча, учыма текәләм: ә анда — алка. Сыңар алка.
— Алка,— диде Каһир.— Алтын. Аныкы.
— Каян алдың?
Очкылык тотып, күкрәгенә сугып куя.
— Хәтерлисеңме теге янгынны? Төнлә. Тарханныкылар янган төнне. Ул станциягә кергән... Син беләсең! Исеңдәме?.. Шушы алканы эзләгән...
«Исемдә, исемдә!» — ди хәтерем ашыгып.
«Ядәч!» — ди миңа язмышым.
Хәтеремне киереп, язмышым ядәчен аерам.

— Тыңла әле, Каһир... Әй, Каһир, тыңла әле!
...Ул чагында бөтен дөньяны боз баганалары терәтеп торадыр кебек тоела иде. Безгә дигәнем — миңа һәм Кәүсәриягә. Кояшның салкын чагы иде. Кыш. Дөресрәге, кыш ахыры, яз башы. Кичләрен яз исе килә, иртәләрен — иссез кыш. Имән баганаларга утыртылган агач станция. Кыяфәте белән ул бер әкияти кошка тартым.

— Сәмруг кош диләр иде аны. Станцияне,— ди Каһир.

Әйе. Буаны чыгып карый торган балкон аның томшыгын хәтерләтә иде. Авыл ягына караган тәрәзә капкачлары ябык чакта ул күз элпәсен йомып йоклыйдыр кебек. Тәрәзәнең почмаклап эшләнгән йөзлегенә кунган юка кар — аның чаларган кашы. Бу аны йоклаган чагында да сак, уяу итеп күрсәтә. Такта түбәсендәге кар катламы төньякта көртләп өелә, гүя ул кош, вәкарь белән генә кыңгыр салып, йөнтәс бүрек кия. Ул, горур кыяфәт белән, тирән чокырдан калкып тора.

Айлы төн.

Ташлы чишмәнең зәңгәр сукмагыннан аерылып, кар юрганын вак адымнарыбыз белән ерта-ерта, түбән төшәбез. Станциянең идәне яр белән тигез булса да, турбина залын һәм корыч су юллыгын томалап, стена тагын бер сажинга чокыр эченә дә төшеп китә. Зәңгәр күләгәләребезне артта калдырып, шул «итәк» астына килеп керәбез.

Ялгыз эт өрүе, инеш аръягындагы кала юлындагы атлы чана шыгырдавы, тулган ай, Җидегән, Казык йолдызлары, без белмәгән планеталары булган дөнья яр өстендә кала, ә без шарлама тавышы, юеш таш, күгәрчен тизәге, томан белән тулы мәгарәдә инде.

Тегермән тартмаса да, станция, авыл өйләренә ут биреп торыр өчен тагын берәр сәгать чамасы эшли иде. Безгә шул җитә...

— Кайтам мин, Ислам,— диде Каһир.

— Юк, син тыңла, Каһир! Әйе, тыңла... Тыңла, Сафин!

Ул бүтән берни дә әйтми, караңгылыкка карап кына тора. Ә мин сөйлим дә сөйлим...

...Без мәгарәдә инде. Беренче тапкыр гына түгел. Сулу капкан була. Бер-беребездән аеры, ләкин чокырга төшкәндә тотынышкан кулларыбызны аермыйча, боз колонналарына терәлеп, кара-каршы баскан килеш беравык тын торабыз. Дүрт колачлы корыч су юллыгын тутырып, туры багана булып аккан суның гүелдәве колакка мамык тыгып куйган шикелле итә. Башта гына шулай. Тора-бара күнегәсең.

Менә шул тавышта гаҗәп бер ачыклык белән йөрәк тибеше ишетелеп, кан агышы сизелеп тора.

Башта сүзсез торабыз. Кәүсәриянең кулы җылы. Бөтен тәнгә аның җылысы тарала сыман иде.

Тәрәзәләрдән балкып торган ут көлтәләре, чокырның сөзәк ярындагы су тузаны кунып катканга күрә ялтыраган кардан кире чагылып кайтарыла.

Кауз һәм турбина идәнендәге ярыклардан саркып чыккан су кышкы салкыннарда ката, Рим империясеннән калган хәрабә колонналары диярсең. Яктылык шәүләсе аларның кайсысын алсу, кайсысын яшькелт, кайсысын зәңгәр төсләргә манчыган. Станция шул колонналарга салынган күк. Нindидер җанварның зур итеп ачылган авызыннан күренеп торган әллә ничә катлы тешләр сыман, түшәмнән хисапсыз боз сөңгеләре асылынып төшкән, аларга каршы түбәннән күтәрелгәннәре дә — дөнья. (Андый тамашаны Абхазиядәге Яңа Афон мәгарәсендә дә күрдем. Аерма — анда сталагмит, сталактитлар, ә монда — боз.) Очлары белән өскә каратып кадалган кылычлар арасында басып торабыз кебек. Шарлама гөрелтәсендә вакыт-вакыт Кәүсәриянең тирән-тирән итеп сулаганын ишетәм дисәм, юк икән: боз колонналары арасында кышның адашып калган соңгы җилләре уфтаныша, күгәрченнәр гөрләп ала.

— Нишлим инде мин хәзер? — дип пышылдый Кәүсәрия.

Кисәк җил сарылып узган каен чукларыдай бармакларының калтырануын тоям. Аның пышылдавына колак салырга теләгәндәй корыч

юллык эчендәге тыгыз шарлама тына төшә, кайдадыр — нидер чылтырап куя. Аны башта ташлы чишмә челтерәве, аннары Кәүсәриянең плүш жакеты өстенә салынган толымнарындагы чулпы чыңы дип уйлыйм — шлюз чыгырының чылбыры икән. Шарлама тынганнан-тына, ярдагы боз каткан карны көзгедәй терәтеп торган ут көлтәләре сүнгәннән-сүнә бара.

Шлюзны ябалар. Турбинага су кермәс була. Сәмруг кош бер-ике тапкыр гырылдап ала да йокыга тала. Димәк, сәгать кичке тугыз.

Ә Кәүсәриянең бүген соңарып чыгуына сәбәп бар иде. Кайгы кебек зур, олы сәбәп. Очрашкан җиребезгә Кәүсәрия Гыйфрит атлы этләрен дә иярткәли иде, бүген ул да буыла-буыла өреп, чылбырында калды.

— Ишетәсеңме — нишлим?!

Пышылдап кына әйтмәгән икән. Аны станция шавы гына шулай ишеттергән. Кабатлап әйтүе куе тынлыкта боз баганалары арасында катлы-катлы кайтаваз ясап яңгырады.

— Чү! — дидем пышылдап һәм аны кочагыма тартып китердем дә йөзен туным изүенә яшердем. Басмада кар шыгырдады. Станцияне карап тотучы Фәтхи абый.

Борыныма аның җылы чәч исе бөркелеп тора, кулым, нигәдер, аның әле кытыршы, әле шома тоелган жакетының ат күзе хәтле иң өскс төймәсен ычкындырырга азаплана, моның урынсызлыгын басмада кар шыгырдавы гына искәртеп өлгерә һәм мин Кәүсәрияне ике боз колоннасы арасындагы тар аралыктан эчкәрәк — караңгыга этәм дә үзем дә шунда узам. Бары тик икебез генә сыярлык куыш түшәмендәге өч боз сөнгесен җил йөрсенгә стенада махсус калдырылган тишекләрдән кергән ай нуры яктырта. Ул сөңгеләр катырак тын алудан да өзелеп төшәр сыман.

— Күргәннән күрмәгәне яхшы,— дип пышылдыйм мин Кәүсәрияне монда алып керүемә сылтау тапкандай.

— Әйе, хәзер сиңа минем белән күренмәү хәерле,— ди ул «хәзер» сүзенә чак сизелерлек басым ясап.

Өстә салкынлык шыгырдавы белән ишек ябыла, аны биклиләр.

— Хәзер кулак кызы шул инде мин.— Кәүсәрия читкәрәк тартыла, аяк астындагы боз сөнгесе сынып төшә дә чылтырап ватыла, кисәкләре каядыр түбән шуа, аның суга барып төшкән тавышы боз залларына тарала. Тынычсызланып, берничә күгәрчен канат кагына.

— Кем анда?

Фәтхи абый. Каһир станциягә ут төртергә янап язган язуларны, сәнәкчеләр вакыйгасын онытмый, ул хәтта хатын-кызның станция янындагы Ташлы чишмәгә йөрүләрен дә тыярга кирәк дип карады, тик без моны җитди кабул итмәдек. Шигенең нигезе дә бар, билгеле. Колхоз оештыруга ризасызлар юк түгел.

Кар шыгырдый, авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана, Фәтхи түбән төшеп килә иде. Кулында — керосин фонаре. Төн якты, аста караңгы, фонарен баш очына күтәргән килеш «мәгарәгә» килеп керде. Кәүсәрия, калтыранып, миңа елышты. Аны бар тәнем белән тоеп кочакладым.

Фәтхи абыйдан өркеп, бер күгәрчен урыныннан купты да, хәнҗәр булып ялтырашкан нечкә сөңгеләрне коя-коя, бераз очынып йөрде. Ул да сискәнеп чүгәләде, ялт-йолт каранып алды, аннары кергәндәгечә үк мыгырданып чыгып китте. Безне күрмәде, боз колонналарының эчтә пар субай белән стена ясап тоташкан җиренә үк сыенган идек.

Күгәрчен тынычланды, тагын тынлык. Корыч юллык астыннан ургып чыкканда таралган тузан шикелле вак суның җиле биткә, кулларга орынмас булды. Хәрәкәтсез калган һава хәтта җылынып ук китте сыман. Безнең сулышыбыз беләнме? Әллә кайларда тамчылар тама. Без сыенган урында аяк асты боз, туңдыра. Кочагыма сарылган җылы, иллс, элеккеге уяулыгын оныткан җан иясен, караңгылык яки яшькелт ай

тартып алмасын дигәндәй, тагын да кысыбрак кочаклыйм. Фәтхи абый төшмәсә, болай кочаклашырга кыймас идек әле. Сүзсез калдык, ләкин дәшми тору мине элеккечә интектермәгәнен сизеп алдым. Хәер, мондый халәттә сүзнең кирәге дә юктыр. Аның якынлыгын, кадерле җан икәнен бөтен тәнем белән тоеп, кыймылдарга да кыймыйча торам. Гүя үтә күренмәле, уалучан пыяла тотканмын. Сүз катсам яисә аны кочаклаган кулларымны бушатсам, ул пыяла төшеп чәлпәрәмә килер сыман. Беренче сүз кату ук аны исенә китерер дә аңлата алмастай мондый рәхәтлектән мәхрүм калырмын. Ник икәнен дә белмәстән, аның баядан бирле кытыклап, чишәсене китергән төймәсен ычкындырам.

Кинәт ул тартылып куйды, әйтерсең лә үзен бәйләп торткан бауларны кагып төшерде. Аның җылы бәреп торган гәүдәсе киерелеп турайды, читләште. Ярдан аерылган ишкәксез көймәдә калдым кебек. Тезләрем аның тезләрен эзли, таба, тик алар баягыча рәхәт түгел инде, тыгыз каршылык белән этеп торалар.

— Курыктыңмыни?— дидем.

— Кемнән?

«Миннән димме, Фәтхи абыйданмы?»

— Миннән.

«Әйе» дә, «юк» та димәде, әкүкрәген тутырып тын алды да ыңгырашып куйды.

— Ислам...

Учларым белән битеннән тотып, башын чак кына янтайта төшәм дә, иренем белән эссе сулышын тоеп, йөземне аңа якынайтам. Ләкин ул кисәк хәрәкәт белән иягем астына каплана. Иренем салкын маңгаена кагыла.

— Әй, Ислам!.. — ди ул һәм, авырттырып, муенымны тешләп ала.— Нишлим икән, нишлим икән?..

— Нәрсәне әйтәсең?

— Сорама, сорама! Берни сизмисеңмени соң?

Ул гүя икебезнең арада торган пыяланы сулышы белән эретте дә ирене белән минем иренемне эзләп тапты.

— Белдеңме инде, белдеңме?— диде ул мамык шәлен бушата төшеп.

— Нәрсәне?

— Минем нишлисене...

Буталчык уйларым аның «Нишлим инде мин хәзер?» дигән сүзләренә җавап эзли иде.

— Күрәсеңме минем нишләгәнемне?..

— Чынмы бу?

Ул кичне бездән дә катлаулырак, чишәр өчен авыррак табышмак булдымы икән?

Кәүсәриянең кулын тотып алдым, ә ул учымны кысты. Бармакларыбыз аерылгысыз төен булып укмашты. Әйтерсең лә боз дөньясында яклаучысыз утлы йөрәк пәйда булды. Ә минем күкрәгемдәге йөрәк, кемдер боз кисәге белән орынгандай, кысылып-кысылып куйды.

— Авырттырасың... — Нидер көтеп, ул сагаеп калды сыман.

Мин бармакларымны бушаттым, тик ул, ашыгып, аларны тагын да кысарак төште.

— Йөрәкне авырттырасың... — диде ул. — Каласың ләбаса!..

Ул тынды. Бармаклары бушады — мин аның җавап көтүен сизәм. Нидер әйтсәм, хата булыр, чөнки аның сүзләреннән соң ни генә дисәм дә, мәгънәсез, буш яңгырар. Димәк, ул үзе турында уйламый, бар кайгыртканы — мин. «Каласың ич». Баягы: «Нишлим инде мин хәзер?»— диюе күз алдымда яңадан балкып, кабынып китте. «Нишлисең инде син хәзер?» — аның сүзен менә ничек аңларга кирәк икән лә! Әйе, нишлим инде мин хәзер?

Аның атасын, бар гаиләсе белән, кулак дип авылдан сөрергә тиешләр иде. Бар фаҗига шунда — моңа мин дә кушылырга мәҗбүр.

— Мин сине җибәрмим, Кәүсәрия!

— Синнән сорап тормаслар...

Аның киләчәк язмышы өчен бары тик мин генә җаваплы, һәм мин нидер эшләргә тиеш идем. Бүген. Иртәгә. Юк, юк, иртәгә соң. Бүген. Бүген үк. Иртәгесе көндә тапшырып һәм коры очраклылыкка ышанып, бүген нидер кылмасам, аның йөрәге кайнарлыгын тоярга иртәгә мәңгегә соңга калачагым аңымда озак бирешми интектергән йозак кебек ачылып китте. Аның үзем өчен кем булганлыгына бар авырлыгы һәм татлылыгы белән шул мәлдә генә төшендем. Әгәр ул каршымда бар дөньямны оныттырып басып тора икән, димәк, бу дөньяны миңа ул алыштырган. Ул минем барлыгым иде.

Мине аермачык бер хис биләп алды — үлгәнче яшисе килү теләге. Гаҗәеп бер ачыклык белән, кемдер яктыртып торган шикелле, вакытны икегә бүлгән чик сызыгын тойган, күргән кебек булдым. Тойган, күргән кебек кенә түгел, ә үз кулымда тоткан шикелле. Ул сызыкның теге ягында — мин, ялгыз, сагышлы, үкенеч белән тулган мин.

Кинәт ул миңа кызганыч, сәер сагышлы кызганыч булып китте. Мин аның иренәнә сарылдым. Әйтерсең лә соңгы кабат. Татлы. Җылы. Тере...

— Әйдә, Кәүсәрия!— дидем, ул, тыны бетеп аерылгач.

Кая икәнлеген сорамады. Кулым тун кесәсендәге ачкычлар бәйләмен капшады — станциянең ачкычлары миндә дә бар иде. Ул ачкычлар белән нинди генә ишекләр йозагын ачып керсәм дә, Кәүсәрия ияречәк, дөресрәге, калмаячак, карышмаячак. Дөресрәге, мине үзе артыннан теләгән җиремә әйдәп барачак.

Боз баганалар арасыннан чыгуы кергәннән авыррак булды. Алдан үзем, аннары Кәүсәрия, ялан кулларыбыз белән боздан этелә-этелә, иркен җиргә аяк бастык. Тун төймәләрем ычкынып беткән, кызган канны салкын һава куырып алды. Хәзер Кәүсәрияне кая әйдәвемнең әһәмияте юк, кая булса да барыбер. Станция ачкычларын кулыма алдым. Өскә менеп, карны шыгырдата-шыгырдата басмага кердек, ишектә ике йозак, аларны ачканда, аның кулын җибәреп тордым. Ул шундук, шәлен төзәтте һәм, битен сыпырып, чәчен шәл астына тарады, жакет төймәләрен дә төймәләде, менә-менә борылыр да йөгереп китеп барыр шикелле. Ләкин бу аның күңеле белән бусаганың теге ягына үтәргәме-үтмәскәме дип бәхәсләшүе генә икән. Ишек ул сыярлык булып ачылуга, җиңелчә генә сикереп, биек бусагага менеп басты, үзен генә бикләп куймасын дип шикләнгәндәй, кергәнемне баскан җирендә генә көтте.

Моннан чыкканда мин — мин, Кәүсәрия — Кәүсәрия булмаячактыр инде... Тыңлаусыз бармакларым белән эчке келә очын элмәк тишегенә капмалап керттем...

Ишегалдында торган кара «Волга»быз тирәли йөреп килгәч, кырлы стаканга салынган коньякта өстәл лампасының чагылышын карап, уйга бирелəм.

— Тыңлыйсыңмы, Каһир?

Күз алдымда — икенче көннең иртәсе. Җирне каплаган сукырайтырлык аклыкка чыдый алмыйча, күземне кысам. Мин яланбаш, муенымда сарык йонынннан бәйләнгән бүз шарф, өстемдә шуның төсле үк свитер, җирән якалы каеры тун, яшькелт чалбар, аягымда кирза итек. Тамак тук (Өрфәйдә апа миңа аш-су пешереп тора, күпмедер түләгән булам, тик эш андамыни, изге хатынның аналарча кайгыртуы бу авыл-

дагы зур шатлыкларымның берсе): сарык ите салып пешерелгән шулпа ашадым, чүлмәктән кайнаган сөт эчтем. Яктылыкка иялəшеп бетмим әле, күз алдымда вак кына кара куыклар очына кебек — тирә-юнь шундый җете ак! Төнлә кар яуган, ә иртән салкынайтып җибәргән. Һавага тимерче алачыгындагы өйгә күректән салкын өрдерәләрмени! Тын кысыла, кан зыңлый. Агачларны мул бәс сарган. Кояш җирнең эченнән яктырып тора бугай — бәсле агачлар аның нурлары сыман. Күкне аертылган сөт төсендәге зәңгәрсу пәрдә томалаган.

Урам буенча баганадан баганага сузылган тимер чыбыклар мандолина кыллары булып тоела. Алар кулак тамгасы салынган һәм колхозга кермәгән ялгызакларның берничә өенә сугылмыйча үтә. Шуларның берсе — Тархановлар. Моңа карап, аларның өе һич тә боек, нурсыз тоелмый. Киресенчә, анда барлык лампочкалардан да яктырак, кайнаррак, нурлырак зат бар — Кәүсәрия.

Туп-туры аларга барам. Сәгать инде ун, соңга калдым. Мине анда Каһир Сафин, Ярмиев, Шәйдулла белән Фәтхи абыйлар көтә. Тагын — кәмит көткән кешеләр.

Байлар буларак, Тархановларны сөрергә карар кылдылар, ярый, таләп шундый, аңлашыла.

Азамат карт малайларының «атлы казаклар» дигән кушаматлары бар. Чәч йөртәләр, дүртесе дә мыеклы, кара җилән, яшел сатин чалбар, читек, кара кәләпүш киеп җибәрсәләр, әллә ниткән укымышлыларга охшап калалар — синең самавыр шикелле ялтырап торган галстуклы студентларың ишеме соң! Икесе өйләнгән, әмма башка чыкмаганнар, Ширәмәтовка кияүгә чыгып та, озакламый аерылып, бер карчыкта торган «шайтан кызларыннан» калганнары һәммәсе дә ике катлы агач өйдә яшиләр. Биш атлары бар: ир затларының һәркайсында. Биш сыер: өчесе үзләренеке, икесе киленнәре бирнәсе. Аларны тотарга имән сайгак җәелгән абзарлар, ашлык салырга нарат келәт, ак мунча, әвеннәрендә — молотилка, кул җилгәргече. Ачлык елны ил күргәнне кичергәннәр, билгеле, үләр чиккә җитмичә.

Мин менә Тархановныкыларның җылы куышларын туздырышырга барам.

Кәүсәрияне дә кертеп, алар тугыз җан. Бер киленнәренең авыру аналары да боларда тора, аны кайберәүләр хезмәтче итеп күрсәтте. Төенләнгән ун бармак — ике йодрык. Колхозда әлегә ике йөз җиде хуҗалык, утыз ике баш ат, утыз дүрт сыер һәм — электр станциясе, тегермән! Тархановныкылар — колхозга кермичә, икеләнеп, көтеп торучыларның тереләреннән берсе. Аларны шушы тирәктән мәхрүм итәргә, «үзең генә дә яшәп була» дигән ышанычларын какшатырга, җимерергә кирәк иде, факт. Кыскасы, сабак укытырга.

Гыйфрит мине гадәтенчә койрык болгап, бер багана арасы каршы килеп, борын эченнән генә шат шыңшып каршылады. Дегет чиләгенә манчылган мунчала шикелле кара йөнтәс эт. Зур, көчле һәм сыгылмалы гәүдәле. Аны Каһир бик үз итә тагын. Мин үзем этләрне бик өнәп бетермим.

Урам буш, җан әсәре юк. Мин узганда, өйләрнең тәрәзә пәрдәләре генә күтәрелгәләп калды. Алты баганалы урыс капканы шыгырдатып ачам да ишегалдына үтәм. Киң, тигез, чиста, пөхтә. Утлык тирәли унбишләп сарык тезелешкән. Озын тагарак буенда әллә ничә ана һәм ата каз каңгылдаша. Келәт почмагында бер кочак көрәк, себерке сөяп куелган, абзар стеналарында ат сбруйлары. Лапас астында тимер күчәрле арба, үрәчәсенә ике яктан ике ат бәйләнгән, алларында мул печән. Капка төбендә үрәчә башындагы тактасына кызыллы-яшелле чәчәк рәсеме төшерелгән чана. Бөтенесенә кар кунган, аклыкта ялтырап, салкында ныгып күренә. Һәр нәрсәдән ныклы кул көче сизелеп тора. Тынычлык, ышаныч, көрлек. Әйтерсең, биредә йөз ел элек тә шушылай

булган, йөз елдан соң да шушылай булачак. Бер стакан су, бер телем ипи, бер чәмтем тоз кебек үк гади күренеш.

«Кайда болар?» — дип уйлап бетермәдем, ишегалдына караган дүрт тәрәзәдә дүрт ир кеше йөзе төсмерләнде. Хәзер, яшендәй чатнап, тәрәзә пыялалары коелып төшәр дә миңа дүрт мылтык көпшәсе төбәләр сыман. Җитди йөзләр, үз дигәннәреннән чигенмәс үткер карашлар, күзләре кебек үк кысылган иреннәр — кирмән тишегеннән дошман һөҗүмен көтеп торган сугышчылармыни!

Баскычка Каһир чыгып басты. Аның артында — иңенә тун элгән Азамат карт. Күзлек кигән, түгәрәк чал сакал. Лекция укырга дип, кафедрага чыгып баскан профессормыни!

— Ну-с? — дияр сыман ул каш астыннан сөзеп карап. — Нидә калган идек әле? Рим империясендә Гай Юлий Цезарьдан соңгы бөек триумвират белән сенат мөнәсәбәтләрендәме? Кхм, кхм...

Абзардан Идрис абый, Фәтхи, Азамат картның өлкән килене, Ширәмәтов чыкты. Ширәмәтов... Күшәүләреннән туктап, атлар сагаеп калды. Гыйфрит өрә башлаган иде, Фәтхи аны көрәк белән куркытып, абзарга куып кертте, ул шунда һаударларга кереште. Ширәмәтов кулында — кәгазь, кәгазьдә Тархановларның малы теркәлгән «опись», ирене карандашны төкереклэп язудан күгәреп калган, туңган кешенеке шикелле шәмәхә.

— Синме, Ислам Имамович? — дип сорый Каһир, мин икәнне күзен чокып чыгарсалар да таный ич инде.

— Эшләр ничек? — дип сорыйм.

— Бара. Алар монда солых тәкъдим итә әле.

— Нинди?

— Ә!..— Ул, чебен кугандай, сул кулын селтн.— Чүп. Безгә Брест солыхы да бик җиткән — хурлыгы таракан шикелле каралып ята... Колхозга кермәкчеләр, язва!

— Начар түгел!— дим.— Карарга кирәк!

— Чабата астына үзле балчык ябыштырган ишеме? Юк инде. Тиреләрен җиде кат тунамыйча, туктау юк, шәфкать көтмәсеннәр!.. Ишеттеңме? — ди ул Азамат картка бармагы белән төртеп.— Тирегезне каезлап, чабата гына үрәбез — сүз кыска!

— Кызмале син, Каһир энем,— ди Азамат карт сакалын сыйпап.

— Мин сиңа иптәш председатель һәм партячейка секретаре!..

— Кызмале, иптәш Сафин, уйларга кирәк... Без сиңа кара мунча ташлары түгел, тәпәне белән бозлы су коясың...

— Элегрәк уйларга кирәк иде, карт. Хәзер башыңны түгел, к... кашысаң да юк.

Ширәмәтовтан алып, кәгазен карыйм: язуы йөгерек, гайрәтле, яшен эзе кук. Параграф бер — терлекләр; параграф ике — хуҗалык корылмалары; параграф өч — сабан, молотилка, кул җилгәргече, тырма, арба, чана... параграф дүрт — шкаф, көзге, скрипка, китаплар... һәм башкалар. Аста — калын сызык, сызык астында резолюция: кулак буларак, сөрергә.

Бераздан таралышалар. Мин мунча себеркеләре, миләш, балан тәлгәшләре эленгән колгалы өйалдыннан өйгә керәм. Кече Тархановларның дүртесе дә өстәл янында. Чәй эчәләр! Куллары шикәрдәй ак эскәтердә, җиңнәре сызганулы. Яңа гына мәет чыккан кебек тын.

Өйләренең эче әллә ни түгел. Кашага-пәрдәләр, ян-якта икешәр кешелек караватъ, чигешле тышлык кидертелгән дүрт мендәр, олы мич буенда вена урындыклары, өрәңге шкаф, каршы почмакта аяклы сәгать, ишек өстендә изге сүзләр... Ә күзгә иң ташланып торганы — бүлмә тактасы буендагы ике зур шкаф, шкаф тулы китаплар, дәфтәр юкалыгыннан кирпеч калынлыгынача.

Өске катта нидер, белмим.

— Кызым, чәй чыгар,— ди Азамат карт, өстәл янына урындык куеп. Ул чыкмас; чыккан шәттә дә миннән карашын яшерер дип көтәм — кая ул! Тыштагы аклыкка биргесез йөз, риясыз, үпкәсез караш. Кызыл чәчәк төшкән утыртма якалы күлмәктән, муенында кус көрән гәрәбәләр. Толымлап үргән чәч, чулпы зыңы, кулында үзе кебек үк чиста ак самавыр — анысын куеп, өстәлдәге җизен алып китә.

Колак өендә чәй эчеп утырган дигән дан алырга ярамый иде.

— Рәхмәт,— дидем.— Колхоз председателенә бирелгән вәкаләт нигезендә һәм партячейка карары белән...

— Куасыңмыни?— диде өлкән уллары Бәдәмша.

— Халык ни кылса...

— Китмибез без моннан, энем. Китмәскә хәл кылдык без. Карарыбыз нык, ихлас.

Икенче уллары Әмирхан көзге астындагы комодтан дүрт дәфтәр бите алып, сүзсез генә миңа суза. Ачып карыйм: дүрт Тарханов та үзләрен колхозга алуларын сорап, гариза язган. Бөгәрләп кесәгә тыктым да чыгып киттем. Ишегалдыннан тәрәзәләргә карадым. Берсендә — Кәүсәрия, калганнары буш.

«Инде боларга да ут кертергә кушарга»,— дип күңелемә салып куйдым. Сүзем үтәр кебек иде.

Каһир Сафин һәм башкалар минем фикерне ишетергә дә теләмәделәр.

— Сыйнфый дошманнарны үз арабызга алыргамы?! — дип ярсыды Каһир. — Куенга күрәләтә торып елан кертү бу!

Тавышка куям: миннән кала һәркем каршы.

Кичкырын тагын Тархановларга килеп хәлне ирештерәм.

— Ярый,— ди Бәдәмша,— илдә олтан итмәдегез, читтә барыбер солтан булырбыз.

Ишегалдында туктап калам. Юкәдән ишкән баулар сузып, бөтен җиргә кер элгәннәр. Яңа уылган кер исе салкында аңкып тора. Келәт ишеге ачык. Анда кемнеңдер он иләгәне ишетелә. Мунчадан шадра битле йомры хатын чыга, Азаматның икенче килене. Аркасында тәртә юанлыгы толымнар. Мунча якын: морҗадан аксыл төтен ургыла. Югары кыстырылган итәкләрен төшереп тормастан, ул ваемсыз караш ташлады да, такта сәкедәге тәпәнне эләктереп, мунча алачыгына кереп китте. Аның эчтә: «Тагын шул»,— дигәнен ишетәм. Үз-үзе белән сөйләшәме дисәм, юк икән, аңа каршы ир-атныкыдай калын тавышлы бүтән килен сүз ката:

— Кәүсәрия артыннан сөйрәлә диләр, хакмы соң?

— Маңкасын сөртсен әле!.. Сөйрәлсә, авылдан сөрмәс ие...

— Халхузда ат та, хатын да уртак дигәннәрие, Кәүсәрия дә уртак биягә әйләнсенмени, прәме?

Мунчадан уттай кызарган олы килен чәчрәп чыга. Манма тиргә баткан, чәче тузган, эчке күлмәктән генә. Минем якка агач тәпәнне чайкый-чайкый юынтык су сибеп җибәрә — чак читкә тайпылып калам. Салкын һаваны тутырган бу аша аның мендәрдәй имиләре чайкалып, култык астындагы кус төкләре чагылып кала.

Баскычта Азамат карт пәйда була.

— Ник ишегалдына түгәсең?— дип кычкыра ул.

— Түксә соң, эти. Барыбер кяферләргә кала.

— Әле монда без яшибез, килен.— ди ул тыныч кына.— Көрәк белән кырып аласы бул, кара аны!

Миңа кырын борылып, хатын уч-уч кар белән битен, беләкләрен уа да кереп китә. Мондый хатынның ирс тыкрык чатларында гәп сата тор-

ган ирләр янына килеп кушыламы соң яки каравыл өендә лото уйнап ятамы?! Ул өйдә кирәк, аны бала тапкан саен гайрәтләнә генә барган хатыны көтә һәм... эш, эш, эш!.. Бәдәмшаның дүрт баласы бар, Әмирханның хатыны бәби тапмый, ди.

Бәдәмша Тархановның: «Илдә олтан итмәдегез, читтә барыбер солтан булырбыз»,— дигәненә шушында ышандым. Әйе, югалачак түгелләр. Авылдан сөрелер алдыннан бәйрәмгә әзерләнгән шикелле чистарыналар.

Тархановлар хуҗалыгы, үзенең һәлакәте алдында торса да, тыныч һәм какшамас иде. Әтәч кыткылдый, сарык һәм бәрәннәр кычкыра, казлар каңгылдаша, морҗалардан төтен чыга. Һавада печән һәм ат исе. Монда сәламәт рух, монда яшәргә дәрт бирә торган ышаныч... Монда хезмәт итәләр һәм бала табалар.

Үз бурычымны, каз оясын бөлдергән төлкедәй, бу пөхтә хуҗалыкны туздыруда күрмим. Бурычым кешеләрне рәхәт һәм житеш яшәтерлек хезмәт оештырудан гыйбарәт иде түгелмени соң? Эш эшләр, бала табар, тыйнак кына яшәр, оныкларның бәхетле киләчәгенә ышанып үләр өчен.

Тарханныкылар кичкенә бер күмәк хуҗалык, гаилә колхозы. Бер гаиләдәй яшәү — кешелекнең идеалы лабаса.

Мунчада кер уалар. Келәттә кемдер он или. Мөгаен, Хәдичә ападыр, Кәүсәриянең әнкәсе. Керим әле, сөйләшим әле. Кызын сорыйм!

Нык имән баскычтан келәткә күтәрелгәндә өй тәрәзәләренә, мунча ягына карап алам. Беркем күзәтми, миндә беркемнең эше юк.

Онны Кәүсәрия или икән.

— Әнкәң кайда?— дип сорыйм мин.

Әнкәсеннән кызын сорыйм дип кердем — кызыннан әнкәсен сорыйм!

Ул да югалып кала, әзрәк кенә оялган да шикелле. Иөзендә сизелер-сизелмәс шук елмаю уйнаклап ала. Ләкин сагышлы. Кашына, керфегенә, чәченә он тузаны кунган: яшь чырайлы чал әби.

— Картайгач нинди матур булачаксың икән! — дим.— Чәчләрең, кашларың чаларгач.

— Картайгач?

— Сине он чаларткан.— Ул кулы белән «картлыгын» сөртеп алмакчы була, ике сикереп каршысына барып басам да кулын тотып калам.— Тимә! Шулай матур...

— Кирәкмәс, карама алай.— Карашын идәнгә күчерә, ирен читләрендәге елмаюы боек күзенә кереп кача. — Оныт, җәме?

— Үпкәләттем, әх, үпкәләттем дә инде сине!..

— Үзем гаепле.

— Син — үз гомеремдә очраткан иң зур табышым минем.

— Югалтуың түгелмени?

Чынаяк тәлинкәсен тоткандай җиңел генә итеп, ул өч бармагының битләре белән генә астан җилпучны эләктереп ала да, икенче кулы белән дә күтәреп, иңбашына куя: иңенә кар көрте кундымыни! Ишек бусагасына менеп баскач, ул борыла, чәче бәс иңәләредәй балкып, нурланыш белән каймалана, бер генә мәлгә йөзе танымаслык була. Өстендә бил дугасын узар-узмас кына сырма, җилпуч авырлыгыннан биле сыгылып тора, аягын чак аера төшеп баскан. Кичәгене сагынып, төпсез бер үкенеч белән тулам. Яратуым галәмәтедер. Тәгаен. Мин әле яратып карамаган, белмим. Белмим. Белмим. Әгәр хәзер җилпучын куеп, кичәгечә, күкрәген кайнар киереп... Мине аның аягындагы көя кискәләгән, башак болгатканда чәчрәгән һәм инде касмакланып каткан онлы киез итеге туктатыр иде микән? Әгәр, әгәр, әгәр... Хәзер моны юравы мәгънәсез инде. Үземнең кайдалыгымны бөтенләй онытып, аның онлы маңгаен үбәргә үреләм. Ул курыккан шикелле, бусагадан кире келәт идәненә төшә, иренемә он тузаны ягылып кала.

— Җуләрләнмә,— дип пышылдый.

Биленнән тотып, үземә таба тартып китермәкче булам, тик биреш-ми, күкрәгемә җилпуч башы төртелә.

— Яратасың бит, әйеме?— дим мин.

— Җүләр... — ди ул.

«Күрмисеңмени, җүләр?» — диюеме? Кичәгедән соң мондый сорау ямьсез булды ахрысы. Ул читкә борыла.

— Кирәкми, елама,— дим, аны аңлап.

— Бетте.

Аңа барысын да ачып салырлык сүз эзлим — таба алмыйм. Нидер хәтерләргә тырышам, күңелем дә, башым да һич кирәкмәгән кичереш һәм сурәтләр белән генә тулган.

— Әллә нәрсәләр әйтәсем килә. Иң әүвәл... рәхмәт, яме?

«Бусы ни инде тагын, я?»

— Кичә түбәнсенмәгәнне, бүген мескенләнмә инде,— ди ул.

— Син горур.

— Күп сөйләшәсең.

Әйтерсең лә башымда ниндидер серле йозак ачылып китте. Кәүсә-риянең соңгы сүзләре күңелемдәге ниндидер авыр табышмакка җавап булып яңгырый. Кичәгедән соң Кәүсәрия өчен бер генә сүземнең дә кадере калмаган ләбаса инде. Аның эшенә мин сүз эзләп торам. Гөбедә май урынына су язган шикелле. Яисә бушка тегермән ташы әйләндер-гән эше. Бүген аңлашкан булып маташуым кичәге каршында чүп кенә, һәм бүгенге сүзләрем кичәге белән иртәгәге көн арасына күпер итеп салырга ярамыйлар. Черек такталар — артык берни дә түгел.

— Кәүсәрия, мин карар кылдым,— дим. — Чыгасыңмы?

— Кияүгәме?— ди ул ашыгып.

— Миңа.

Күз алдымда кичә аның сәкедә яткан сурәте, тузгыган чәче, мин үпкән чактагы тыелгысыз ыңгырашуы чагылып, ишетелеп ала. Хәзер бөтенесе бүтәнчә булачак. Бүлмәм якты, җылы. Электр нуры түшәм алтынында балкый. Йолдызлы күк, ә аста — без.

Кәүсәрия аскы иренен тешли (ул тешләрен күрсәтергә һәрчак чи-тенсенә: өске бер теше чыгыбрак тора, шуны күрсәтергә теләмәүдән), каш астыннан карап ала.

— Икенче тапкырмы?— ди ул. Сәерсенеп китәм, моны ул да сизеп ала.

— Икенче? — дип сорыйм мин.

— Мин сиңа кичә үк чыктым инде. Ә син хәзер генә үреләсең. Ан-дый чакта кызлар...

— Син бүген әллә нинди?

— Беләм. Нинди булсам да, кичәгедән начаррак.

— Алай димә. Хәзер, мин карар кылгач,— аңлыйсыңмы: карар кыл-гач,— яшисе дә яшисе инде!

— Я үләсе... Барыбер.

— Җүләр,— дим.— Үләсене истә тотсаң, яшисе дә килмидер ул.

— Һәр әҗәтен кеше... үлемгә түли.

— Әҗәтен? Нинди әҗәтен?

— Әнә, Рамазанов абый. Ул апаны яратты.

— Нисанымы? Шул шайтан кызынмы?

— Әх, син! Синен үз учыңдагы фәрештәне качыруың белән аның «шайтан» кочакларга теләве арасында ни аерма?

Кәүсәрия бусаганы атлап чыга. Кинәт пәйда булган кояш яктысы аның аяк астына җәелеп ята. Чиләктән алтын бодай чәчеп җибәрделәр-мени!

— Җавап бир: бүген я...

Ул кулын суза. Ризалыгын белдереп ишарәле дип уйлап үреләм, ул бармак очы белән генә кулымны кирс этәрә.

— Ачкычыңны бир әле,— ди ул.

— Нәрсәгә?

— Кирәк. Кичә анда бер алкам төшеп калган... Аннары көт.

Бүлмәм ачкычын аерып алып, калганнарны аңа бирәм.

— Син көт, яме!

Ачкыч бәйләмен аның онлы учына салам. Ул баскычтан төшеп китә. Бауга элгән ак керләр арасында күздән югала. Эри.

## IX

Салкын җәймә кочагына кереп ятам. Алканы мендәр астына тыгып куям.

Гаебем юк — язмыш.

«Кемдә соң? Бу дөньяда нидер тиешенчә түгел икән, моңа кешеләр генә гаепле. Хәтта гаепсез кешеләр дә».

Кешелекнең синеке ише генә гаебе беләсеңме күпме?!

«Мине хәтта бу да акламый. Бөтен нәрсәгә сылтау табып була. Тик, нишләсә дә, үзе өчен һәркем иң элек үзе — ү з е! — җавап бирергә тиеш».

Үзе, Каһир, үзе генә.

Кичә...

Тынга динамо залындагы җылы май, сумала, сүс, түр идән капкачы астыннан — анда турбина — күтәрелгән су исе кушылмасы килеп бәрелде. Тәрәзәләрдән ай яктысы сирпелеп керә — залга ток нурланышы сеңеп калганмыни. Ишек катындагы зәңгәр буяулы динамо эчендә суына торган сумала чыртлый: динамо эшләп арган үгезгә охшап ята һәм, онытканда бер, хатыннар сагыз чартлаткан кебек итеп ала.

Кулымны ишек тоткасыннан алам да Кәүсәриянең сыгылмалы билен эзләп табам. Аңы белән үзен минеке итсә дә, уяулыгы белән ул табигатьнеке әле: җиңелчә генә алга этәрми торып, эчкәре атламады.

Шүрлекләренә чынаяк-тәлинкә тезелгән шкафны хәтерләтүче приборлар, реостат щитын узып киттек. Ампер һәм вольт үлчәгечләр миңа күз кысып куйды. Әллә соң, без узышлый, аларның сизгер уклары кан тамырларыбызда кайнаган киеренкелек, дулкынлану тогын үлчәп калдымы?

Әле генә безне үз күкрәгенә кыскан боз колонналары, имән субайлар башына басып барабыз. Без хәзер боз колонналары башында учак булып янган ике ялангач йөрәк.

Зал буенча кош очып узды — күгәрчен. Ай нурына ымсынган кош тәрәзәгә килеп бәрелде.

— Абау!..

— Курыкма, күгәрчен.

«Гөрр-гөр-гө...»

Мин Кәүсәрияне күтәреп алам. Кочагымда, дөнья авырлыгы кадәр булып, аның сыны гына калды.

Сәке. Кәүсәрия көлепме, елапмы — әллә сулый, әллә сулкылдый, муеныма уралган кулы хәрәкәтләремә комачаулый. Мин идәнгә тезләнгәнмен. Үбәм, ә ул — яшеннән курыккан ат күзе: бөтен җаны белән ачык. Мине, гүя, теземнән идәнгә кадаклап куйганнар. Елыйсым килә — тора алмыйм.

Шәлен ачып ташлыйм да бармакларымны чәченә батырам. Ул ыңгырашып куя, кулымны тартып алам, учымда — аның алкасы.

— Алкаң ычкынды,— дим мин.

— Куеп тор, соңыннан. Соңыннан...

Җылы алканы мендәр астына тыгып куям.

Боз колоннасы эреп, мин торган саен түбәнәям шикелле, әллә Кәүсәрия югарырак, буем җитмәс биеклеккә аша барамы? Кәүсәриянең инде шәле, чәче тузгып, жакеты чишелеп (әллә мин, әллә үзе) беткән, өстендә — айның зәңгәрсу парчасы гына. Туңмасын дип, юрган ябам — ачып ата һәм шул хәрәкәт җилкегән һава борыныма печән тузаныи, су томаны дымсулаган тун исен дыңгычлап тутыра.

— Мин сине — аннары... чистада, җылыда, яктыда... аннары, аннары...

Бездәй үтәли тишкән авырту мине сәке яныннан читкә алып ташлый — Кәүсәрия кулымны тешли. Исемә килгәнче, торып утыра, идәнгә баса. — Җүләр, җүләр!..

— Монда... Фәтхи йоклый,— дидем мин.— Монда чиста түгел.

Битен учыма алырга телим, ләкин ул, җиңелчә генә этеп, кулымны кире кага. Ни кылганымны үзем аңлап җиткәнче, ул инде шәлен яба. көтмәгән җирдән аркама салкын су коялармыни — бөтен аркам катып килә, телем бәйләнә.— Ә син... син... син чиста, саф...

Тирән итеп, үкенеч, кайгы, бәхетсезлек ташып торган тавыш белән:

— Ә-әйй!.. — Аннары соң баласын кыйнаган ана сыман ачу катыш кызгану белән: — Буялудан курыктыңмыни?

Тынлык. Ул инде жакетын да төймәли. Бетте. Ялгыш иттем. Ялгышлык кынамы? Гөнаһ белән ташып торган изгелек кылдым!

Гомеремдә беренче тапкыр учыма килеп кунган кошны куркыттым. Янәсе, кулым юылмаган. Ә аның өчен ул иң чиста, гомере буена көткән кул булган ләбаса. Әле генә күктә йолдыз кабынды, ә мин күрмәмешкә салыштым: имеш, кояшта тап бар! Гомеремдә беренче тапкыр үткән мизгелгә кире кайтып яшисе килү хисен татыдым. Әле моңынчы гел алга, алга дип яшәдем, бәхет чаты алда дип өметләндем. Иң зур бәхет артта да була икән. Кешеләр шуны вакытында күрмәү белән дә бәхетсез.

— Үпкәләттем,— дидем мин.

— Үкенмә.

Әле яңа гына ул үзен-үзе тояр хәлдә түгел иде бит. Әле генә аның өчен сөюбездән дә чынрак дөнья юк иде. Мин аны беренче кат аяк баскан бәхет дөньясыннан мәхрүм иттем. Чайкалып торган тубын аның аяк астыннан тибеп очырдым. Бу төннең бер мизгелендә мин бөтен гомеремнең барлык көннәрендә күрмәгәнне күрдем, белмәгәнне белдем.

— Баладан баш-аяк дидеңме?.. Кулак кызы белән буялып торганчы, әйеме?!— Һәм тагын баягыча үкенеч катыш кайгы белән: — Әй!..

Иңбашына кулымны салып:

— Карале,— дидем. — Һәм жакеты изүенә ябышып:— Сал.

Үземчә бу хәлдә моннан да хаграк, урынлырак кыюлык уйлап табарга мөмкин түгел, ул барысын да хәл итәрдәй гайрәткә ия кебек иде. Кәүсәрия тамчы да сүз дәшмәстән борылды да сәкегә иелде.

— Эзләш,— диде ул. Аңламый тордым.— Алкам юк.

Ышанмыйча:

— Кәүсәрия!.. — дип пышылдадым.

Ул эзли бирде. Ни туктатырга, ни булышырга белми торам. Әле ул янымда, кул сузарлык арада гына булса да, мин ялгыз, кирәкмәс, ә иң чыны — аның өчен юк идем инде. Аның диңгезеннән салкын дөнья ярына йомычка кебек чыгарып ташландым.

— Әй, ярар сәнә!— Кәүсәрия ишеккә таба китә, артыннан куып җитеп, гафу үтенәсем килә. Кәүсәрия язмышыбыз бишеге була язган станция ишеген ачып җибәрде. Ярсу белән кайнаган йодрыкларымны кесәгә яшердем.

— Кәүсә...— дигәнемне ишеткәндер,— ...рия!— диюем үз җаным бушлыгына төшеп китте.— Дөнья сафлыгы белән сәке исе арасындагы упкын уртасында калдым. Дөньяга чисталык кына дәгъвалаган уйларым әхлаксызлык булып эшкә ашты. Алтын идеяләр төсен җуйды, кырыс чынбарлык чәчәк атты. Ничә айлар буе үбәргә дә базмый кадерләгән җан иясен гөнаһсызга үпкәләттем. Кеше, ни хәтле генә тырышса да, кылган гамәленең нәтиҗәсен тулысынча татый алмый. Барысы да соңыннан, соңыннан...

Саташуга якын уйларым елгасына өндәге ярдан туфрак ишелеп төште: сәке ягында ниндидер кыштырдау, ыгы-зыгы. Саран ай яктысында әле генә Кәүсәрия башы яткан мендәр өстендә кайнашкан җәнлекләрне күреп алам. Икәү. Сызгырып, өннәрен аласым килде, тик бу уем төштәгечә көчсез ният кенә булып калды, тораташ хәлдә җәнлекләргә текәләм. Карашымны тойган кебек, алар да тынып, катып калдылар. Үземә читтән караш ташладым сыман. Ни күзәткәнемне чит кеше карап торгандагыча, оят булып китте. Шушында миңа күселәр тормышның тискәре ягын ачып бирде. Яманлык һәм яхшылык, сафлык һәм шакшылык, җир белән күк арасындагы бусагада калдым кебек. Мәхәббәт ялкынланмаган урынга хәшәрәтләр хуҗа; дөреслек курыккан төштә ялган кыюлык; кешеләр юк җирне дуңгызлар һәм күселәр яулый икән.

— Кешеләр юк җирне дуңгызлар һәм күселәр яулый икән,— дип кабатладым мин.— Әйеме, Каһир?

Шунда мин ишегалды капкасына таба күләгә кебек китеп баручы Сафинны шәйләп алдым.

Тик мин дәвам итәм. Инде сөйләп түгел, искә төшереп. Яңадан хәтерләп.

Бөтен сәкене пыр туздырып, җимереп атасым килде. Тик күселәрнең гаебе юк иде.

Үз-үземә булган нәфрәт авырлыгыннан картларча бөкрәеп, ишеккә таба юнәлдем. Укшыта иде... Аяк астында кар шыгырдый. Ап-ак кар.

Иртәгә мин Азамат Тархановларның гаиләсен кулак буларак законнан тыш дип белдерергә тиеш идем.

Сәерсенеп, капыл туктап калам: Кәүсәрия үзенә кагылмавымны шушының өчен дип белмәдеме икән? Ул чагында анда — станция эчендә минем хәлдә калудан да ахмаграк ни бар? «Кулак кызы белән буялып торганчы, әйеме?»

— Әй! — дип, тулы айга йодрык янадым. Айга өргән эттән дә мәгънәсез нинди җан иясе бар тагын?!

Кичкырын иртәнге аклыкның эзе дә калмады. Җир өсте, күлмәкчән печән чабучы кешенең аркасы сыман, тирләп чыкты, ала-колаланып калды: каймактай йомшак һәм җепшек кар элпәсен кояш белән җил ялап бетерде. Табигатьнең дәрте сүнеп калды. Көньяктан дымсу җил сузылып чыкты да күк йөзендәге болытларны тау артына куып алып китте. Кояшның соңгы нурлары тау башына алтын парчасын капларга өлгерде — аның өстенә зәңгәр шәүләсе сузылып калды. Ширәмәтовлар йортының ташландык коесында җил елый, ә төсе уңган кызыл әләм, шуны котыртып, шапы-шопы кул чаба. Агачлар, яз сулышын тоеп, каралып калган.

Бүлмәгә кайтуга, беренче эш итеп, мин өч тәрәзәнең берсен ачып куйдым, учакка өрәңге утыны яктым. Өстәлгә газета җәйдем, уртасына ике уч конфет чәчеп җибәрдем, буынтыклы шешә утырттым — гәрәбәдәй алтынсу шәраб эчендә учак ялкыны биеп тора. Бүген электр лампочкасын да, керосин лампасы да кабызмыйм: шешә янында мин чардактан табып, көл белән чистарткан өч җапле шәмдәлдә өч шәм

кукыраеп янып торачак. Шәмдәлнең як-ягына ике бәллүр рюмка куям. Аларын Ширәмәтовлар идән астындагы гөмбә, лайлалы мүк каплап бетергән черек агач мичкәдән табып алган идем. Мөгаен, аларга агызып, Ширәмәтовныкылар мичкәдәге ширбәтләренең өлгергәнлеген сынаганнардыр. Ул идән астын станция кирәк-яракларын саклар өчен чистартканда ат башы сурәтендәге көмеш көл савыты да килеп чыккан иде, ул да өстәлдә. Соңгы вакытта ялгыз үткәргән кичләрдә үзеннән-үзе тәмәке төрә башладым; каминнан күмер алып, биткә якынайту, тарткач, бармак битләреннән килгән тәмәке һәм жылы агач исе әллә кайдагы өебезнең әле ут эленмәгән кечке эңгер-меңгерен, әти-әни, ак мичне хәтерләттерә иде. Шушы хис һәм күренешне кабаттан кичерәсе килү белән үз-үземне алдалап, төнге тәмәке кабызулар санын да арттырганымны сизәм. Тыелсам, эч пошканга түзүе читен кебек. Кешеләр, бигрәк тә Кәүсәрия алдында тартудан тартынам әле анысы, ә бүген — тартачакмын: кичә станциягә бикләп калдырган малайлыгым белән мәңгегә хушлашуым шул булыр.

Ә иң мөһиме — агач караватымдагы мендәр тышларын, ак жәймәләрне Өрфәидә апа юып куйганнары белән алмаштырам. Алар көзге коры яфраклардай кыштырдап торалар, салкынчалар. Станциядәге сәкедән моннан да катырак үч алу мөмкинме соң?! Ачык тәрәзәне ябам. Пәрдәләрне тартып куйгач, искә төшереп, бер мендәрне бусага төбенә ташлыйм:

«Төкле аягың белән атлап кер, Кәүсәрия!»

Мин аны көтәм.

Кинәт кенә бөтен ачыклыгы белән үземне Кәүсәриянең ире рәвешендә күз алдыма китерәм. Кая әле, нинди икән ул — минем кыяфәтәге ир?

Агачтан уеп эшләнгән рамлы көзге каршына килеп басам — нәкъ шул мизгелдә, күмердәй кызарып, лампочка сүнә: көзгедә шәүләм генә каралып кала. Сәгать суга башлый — бер, ике... биш... Аның чыңы, учактан төшкән кызыл шәүләләргә кушылып, мине котырткан сыман биергә керешә. Сарык күзедәй акаеп калган көзге йөзендә кызгылт балкыш куера. Һәр әйбер, кара-кызыл пыяла аша күренгән кояш кебек, көзгедә ап-ачык чагыла. Ут шәүләсе, көзгедән кайтарылып, тәрәзәдә уйнакларга керешә. Көзгедә йөземнең һәр сызыгы пәйда була: очлы ияк, тулы ирен, уңга таба чалышрак борын, күз чишмәләре, артка тараулы калын, озын чәч... Чү... Мин учакка аркан басып торам лабаса — йөзем көзгедә һич кенә дә күренергә тиеш түгел! Тәнем эсселе-суыклы булып китә. Димәк, тәрәзәдән төшкән балкышны кире кайтарып, көзге минем йөзгә юнәлтә... Тәрәзәләргә карыйм: алар, кан белән юган шикелле, кызыл-кучкыл — авыл күгендә янгын әтәче канат кагына иде!

Чөйдә кулым тигән беренче өс киемен — күн пинжәкне эләктереп, ишеккә ташландым, бусага төбендәге мендәргә абынып, чак егылмый калдым. Коридорны йөгереп үттем дә, баскычны сикерә-атлый төшеп, урамга килеп чыктым.

Башымда әле сәгать чыңы, нәкъ тугызда станция уты сүнә, карашымны иң әүвәлтен станция ягына юнәлтәм, юк, балкыш ул турыда түгел.

— Аллага шөкер!

Кемгә шөкер, ә кемгә — битенә төкер.

Тархановлар яна иде.

Мин барып житкәндә, алланы каһәрли-каһәрли, каравыл өеннән килгән насосның бозын эретеп торалар иде.

Ут ярты каралтыны биләгән инде. Ике кеше, ут теленең юлын кисәргә исәпләп, түбәнең такталарын каерып маташа, ләкин бу файдасыз; тезмәдә дыңгычлап тутырылган печән. Тагын берәү лапастагы

карны ялкынга күри, ә бу мамык белән су ташкынын буган кебек кенә. Ут тирәсендә бүтән кеше күренми. Кемнәрдер — башлыча хатын-кыз — өйдән әйбер ташый, күккә үрләгән ялкын каршында алар йомыркаларын тешләп йөгергән кырмыскаларны хәтерләтә. Терлек-туарны чыгарып азапланалар: тик кайберләре абзарга кире кереп китә. Ишегалдын бетереп, беркемне якын җибәрмичә, шашкан ат дулап йөри. Хатын-кызларның берсе — олы киленнәре — капкадан бер кочак тавык күтәреп чыга, тик абынып егыла, ә тавыклары, кара печән учмалары бөтерелгән һавага күтәрелеп, утка кереп китә. Кайсыдыр корылманың түбәсе ишелеп төшә — кара күккә очкыннар ташкыны чәчри. Әсселеккә түзә алмыйча, түбәдәге кешеләр җиргә сикерешә.

Тирә-күрше йортларның салам түбәләренә кар һәм су сибәләр. Сәнәк, көрәк белән салам актарган, пумала белән су сипкән ул кешеләр җәһәннәм утына сумала өстәп торучы кара әрвахлар булып күренә. Ахыр заманмыни! Күктә печән көлләре оча — әнинең: «Таулар мамык булып очар, балаларның чәче агарыр, картлар акылдан шашар»,— дигәне искә төшә.

Тархановларның каралтылары тулысы белән диярлек утта инде, ә сүндерү гамәле юк.

Шунда гына халыкның тик торганын күреп алдым. Гүя Ширәмәтов куйган «Зәңгәр шәл» спектаклендәге хәзрәт йорты януын тамаша кылалар. «Аһ!» оралар, төрле киңәшләр коралар, ут пәрдәсе төшкәч, кул чаба башларлар һәм соңгы өлешне яңадан уйнауны сорарлар кебек иде. Иң кызык тамаша алда әле: ике катлы йортка күчкәнче, утның алты-җиде торык озынлыгындагы каралтыны йотасы бар. Халыкның тик торуы гаҗәпләндерде. Төенчек, сандык, чүпрәк-чапрак, савыт-саба тавы башында, утка ыргылган Гыйфритнең чылбырын култык астыннан күкрәгенә ураган, яланбаш Азамат карт басып тора иде. Гыйфрит, ырылдап, башын капылт-капылт төрле якка боргалый, кемнедер эзләгән күк.

— Этең малларыңнан кадерлерәкмени? — дип кычкыра берәү төркемнән.

— Эткә эт кадерле инде!

— Яп юшкәңне: Азаматны хурлаганың өчен телең корыр.

Чыелдык бер аваз, аның саен нечкәреп:

— Ә! Ут еланы йоткан бака хәлендә калдыларммыни? — дип тантана итте.

— Тарханнныкылар беркайчан да елан булмады.

— Аның каравы без бака! Болар йотам-йотам дип кенә тора!

— Бака! Дөрес! Баканың да таш астыннан чыкканы... Синең мич башыннан төшкәнең юк!

— Дөнья куып ни мәгънә! Әнә, яналар! Көл! Миннән дә хәерче болар хәзер!

— Мәгәр синнән дә ялкау булмас.

Ә Азамат картның карашы боек, битараф, әйтерсең, бакчасында бәрәңге тамырлары өеп яккан да ут тылсымына мөкиббән киткән. Шар ачык капкадан, җилгәргеч салынган чана сөйрәп, Бәдәмша белән Әмирхан, алар артыннан ат сбруе, сука, тырмалар өелгән арбаны тартып, кече Тархановлар чыкты. Чана белән арбаны мал тавына терәтеп куйдылар да, кулларын күкрәкләренә куеп, бер генә мәлгә Тархановлар да утка текәлде. Аннары, кабаланмыйча гына, тагын утка каршы киттеләр.

— Атларны, атларны, оланнар!.. Молотилканы да калдырасы түгел, карагыз аны!

Азамат картның гөлдерек тавышы мине уятып җибәрде сыман.

— Анда... чәчүлеккә дигән орлыклар...— Тамагым ертылганчы кычкырырмын шикелле иде — кайнар төер ирек бирмәде.— Тархановлар-



Т. Хажиәхмәтов рәсеме

ныкы түгел — колхоз орлыклары... Атларның ни гаебе бар? — дип янгынга каршы ташландым. Шул мәлне, тәртә башы төртелгәндәй, алга табан сөрлегеп киттем, егылмас өчен кисәк читкә атлап, артка таба борылдым: сызгырып һәм балта йөзедәй ялтырап, колагым төбеннән тыгыз, сыгылмалы су агымы чаптырып үтте. Ниһаять, насос телгә килгән, минем аркага шуның суы китереп бәргән икән.

— Утның үңәченә барып керсәң дә янмыйсың хәзер! — дип көлә-көлә, егыла язып брезент көпшә сөйрәгән Җәмлихан мулла ишегалдына кереп китте. Аңа халык ияргән иде инде! Ә мин, ул ташкынны ерып, кирегә ыргылам, Каһир Сафинны эзлим. Станцияне җибәрергә, авылга ут бирергә кирәк дигән фикергә киләм. Яр кырыена килеп, Таш чишмә сукмагы баскычыннан төшмичә, кардан гына шуып түбән очам, буа аша үтеп, шлюз чыгырына ябышам. Шыгырдап чыгыр әйләнә, бүрткән шлюз, пенал капкачыдай, тавышсыз гына судан чыга. Каузга бәреп кергән суның, чылбырдан ычкынган эт булып, станция тамагына ыргылуы күренми, әмма аның ярсуы бөтен корылманы калтырата башлый. Хәзер, станциягә кереп, турбина күчәрен тоткан ыргакны ычкындырасы да рубильникны гына тоташтырасы. Ишек ачык. Фәтхи, ачкычларны йозакта гына калдырып, ишекне бикләргә онытып, янгын чыккан җиргә йөгергән, күрәсең. Күчергеч касшның пышылдап әйләнә башлавына динамо чыелдавы кушыла. Янгын шәүләсендә каралып күренгән яр башында сирәк утлар кабына, гүя караңгыда мәче күзләре уйнаклап ала.

Станцияне бикләп кире йөгерәм.

...Йорт белән мунча гына утырып калды.

Утны басып, ялкын телләре җилфердәгән кара стена торыкларын тарата башлаганда, иңбашымда кемнеңдер кулын тоям — Каһир.

— Янамы? — диде ул, мыегын сыйпап.

— Кайда йөрисең? — дидем. Әллә арганга, әллә утны җиңгәнгә — мөгаен икесе дә сәбәпчедер — аң ничектер җиңеләеп, чистарып калды: дәһшәт чигенде, җанны тынычлык изрәтә иде. Гүя кар бураны белән тарткалаша-тарткалаша озын юл үткәнмен дә хәзер җылы мич башына менеп барам. Кәүсәрия янәшәсендә торганнан соң бөтен тәнне авырттырган киеренкелекне басар өчен Таш чишмәгә ятып су эчәм күк. Рәшәткәгә сөялеп, кемнәндер сорап алган тәмәке суырам, аның тәме кисәү һәм төтен исләрен басып китә. Яныбызга Идрис Ярмиев килеп баса.

— Каян чыкты икән?

Каһир иңбашымнан кулын ала. Әйтерсең мин — кызган мич.

— Саксызлыктан чыкмагандыр,— дим Каһирга.— Кешеләре ул түгел.

— Кеше төрткәндер дисеңме? — ди Каһир.

— Ихтимал. Үч итеп.

— Бәлки үзләредер?

— Юк. Үзләре төрткән уттан сука алып чыкмаслар. Алар үзләренә бүген кирәк әйберне түгел, ә иртәгә... үлгәнче кирәк әйберләрне ташыды... Иртәгә күпме кеше колхозга керәсен беләсеңме? Моның өчен Азамат картның молотилканы калдырасы түгел дигән сүзе җитә. Аннары соң минем чәчүлек орлыкларын коткарыгыз диюем. Инде колхоз орлыкларын.

Тыңлап торган диярсең — Азамат картның:

— Рәхмәт, олан,— дигәнен ишетәм.

— Нәрсә соң сез, Азамат абзый? Гыйфритне чылбырдан ычкындырасы иде,— ди Ярмиев.

— Ник?

— Шуннан файдаланган да инде ул. Ут салучыны әйтәм.

— Өрмәде дә ичмасам. Аннары гына...

— Беләсеңме, ник өрмәгән? — Каһир ике куллап минем җиңгә ябышты.— Беләсеңме?

Кулын ычкындырам. Әллә аның, әллә минем кул калтырый иде — игътибар итмәдем. Ә менә Каһирның ничектер җиңел сулап куюын... Багана башыннан төшкән сүрән ут яктысында аның юка иреннәрен җәеп елмаюын күрәм. Ул көйрәп яткан кисәүләргә ишарәли.— Азамат Тарханов! — ди ул картка борылып.— Эт гадәттә үз кешеләренә өрми. Гыйфрит бигрәк тә!.. Аңлашыламы? — ди ул миңа, хәтта кеткелдәп көлеп тә куя.— Үз хуҗаларына ничек өрсен! Үзегез төрткән сез утны, үзегез! — дип кычкыра кинәт Каһир. Безне кешеләр уратып ала.— Үзегез! Атларны, ашлыкларыгызны колхозга бирмәс өчен! Әйттем, әйттем! Ә син сүндереп йөрисең! — ди ул миңа борылып.

— Син сүндерешмәдеңмени?

— Минем әти белән әнине колчаклар ничек... Ә сеңелкәшне нишләткәннәрен беләсеңме?!. Мин байлар пожарын сүндерергә күнекмәгән. Киресенчә! Мин аларны беләсеңме күпме яндырдым?! Этләргә эт үлеме — куарга боларны! Авыру этләр шикелле... кеше күзеннән читкә. Кырылышсыннар!

— Безме эт? — ди Азамат карт. Бүреген салып, башын югары күтәрә. Бу хәрәкәтенең табигыйлегенә шаккатам: алла алдында да гаебем юк, бар икән — менә башым, кисегез, дигән сыман. Аннары карт, Каһирның битенә йөзен терәп диярлек, тирән сулыш белән: Кайсыбыз? — диде.

— Бугазыгызга аркылы бастыммы, кулак әфәнделәр? — Каһир, рәшәткәгә таба чигенде дә, аңа терәлеп, халыкка утлы күмердәй кайнар сүзләр ташлады: — Рамазанов башына кем җитте дип беләсез?!

— Кем? — дидем мин кинәт урнашкан тынлыкны бозарга кыймагандай пышылдап.

— Шушылар!

Халыкны ерып, уртага кече Тархановлар кереп баса. Дүртесе дә. Кайсы балта, кайсы багор, кайсы сәнәк тоткан.

— Кайсыбыз? — ди берсе. Бәдәмша тавышын таныйм.— Менә без— дүртәү. Хәзер җә син безне, җә без сине. Безне дә, сине дә бер генә нәрсә коткара.— Тынлык. Бәдәмша, артка һәм янгарак чигенеп, балтасын күтәрә төшә.— Ишетәсеңме, энем? Бер генә нәрсә — дыкажый!

Араларына кереп басам. Һәм дәшми генә Каһирга таба борылам. Аның яңак ите тартылып-тартылып куя, иягеи чөңкәйтеп, бармакларын изүенә тыга да күлмәгенең якасын тартып аера.

— Исбатлыйм! Хәзер үк!

Азамат картның тыныч күзләрен күреп алам.

— Кая шайтан кызыгыз? — дип пышылдый Сафин буылган шикелле.

— Ниса! — дип кычкыра Бәдәмша.— Кая олактың?

— Ну, кая?

— Ниса! — Бәдәмша үгездәй үкереп җибәрә.

— Ниса монда түгел ул. Станция астында. Бая ут салырга нелгән җиреннән люкка сугып төшердем. Әйдә, «дыкажый», күрсәтәм! Үз өегезгә ут төрткән булып — станцияне!.. Ахмаклар!

Каһир Тархановныкыларга каршы атлады. Елгыр башы як-якка боргалана, алдындагы дүрт әзмәверне күрми дә кебек. Күрәсең, ул үзенә ышана, аларны бетердем дип саный иде инде. Җиңүне ярата иде Каһир! Бүген Тархановныкыларны күрмәгән кебек, иртәгә ул миңа да карамаячак.

— Нәрсә, абый? — Бәдәмша каршына Ниса килеп баса.— Борчылма, акчалар миндә.

— Акча түгел, безнең баш синдә, Ниса,— ди Азамат карт.

— Син ничек монда?! — Каһир, кулын җәеп, бер адым артка чигенде.
— Ата нигезе янганда... караватта ятмам инде тагын!
— Каян килеп чыктың?! — диде Каһир.
— Бөтен кеше чыккан җирдән,— каян булсын ди тагын?
— Юк, люктан дим: ничек? Люктан...— Каһир куенына тыгыла.— Бу кем шәле? — ди ул пәрәвездәй нәфис чуклы ак ефәк шәлне таратып җибәрә.
— Кәүсәриянеке ич бу!
— Ә-ә, улмыни әле? — Сафинның ирене калтырый.
Мин аны аермачык күрәм. Аермачык. Багана башыннан төшкән ут яктысында. Ут? Кинәт йөрәгем өшеп киткәндәй була, Каһирның ниндидер коточкыч эш эшләгәнен сизенеп катып калам. Яшен тизлеге белән күз алдыма шлюз чыгыры пәйда була, зиһенем пәрдәсен кауз буенча ярсу аттай ыргылган су тавышы ертып керә. Кулымны кесәгә тыгам, ачкычлар көлешеп куя: «Ачкычыңны бир әле — нәрсәгә — кирәк, кичә анда бер алкам төшеп калган, аннары көт...»
Я, хода!.. Бая мин шлюзны ачып, авылга ут биргәнче, Кәүсәрия югалган алкасын эзләргә кергән, кеше күрмәсен өчен, янгын форсатыннан файдаланып! Ә Каһир аны...
...Ә мин аның өстенә су ташкыны җибәргәнмен...

Кәүсәрия үлде. Ике көннән соң. Үпкәләре шешеп.
— Күрдеңме инде? — диде ул.— Һәр әҗәтен кеше үлемгә түли.
Инде ышандым һәм ризалыгымны белдереп дәшмәдем.

...Турбина залының аркылы имән такта кыстырып бикләнгән капкачын ачып ыргытам. Шундук Кәүсәриянең башы калкып чыга. Тимер баскычка ябышкан көйгә ни гомер буе бозлы суда торган! Бил тиңентен. Кайнап, бөтерелеп, гел аска сөйрәп торган суда. Ул миңа кулын суза да аңын җуя. Өскә тартам. Авыр. Идрис абый килеп җитә. Кәүсәриянең йөзе ап-ак, иренен тешләгән; чәче, бар дөньясы юеш. Залның буеннан-буена ялгыз күгәрчен очып йөри. Кәүсәриянең аягыннан тәненә кисәк-кисәк көзән җыерган дулкын киерелеп уза. Менә ул күкрәге белән калкынып-калкынып куя, күзен һәм авызын ача, түшәм аркылы йолдызларга текәлә:
— Мин алка эзләдем... алка гына...— Тавышы бер ни булмагандай чиста, тыныч.
Станциягә кешеләр кереп тула. Идрис Ярмиев барысына да чыгып торырга боера.
Каһир:
— Шаһитлардан куркасызмыни? Мин барыбер әйтәм: кулак кызлары белән гыйш-гашрәт корып, колхоз төзим дисең икән — ялгышасың. Хә-тәр ялгышасың, иптәш Зәйнушин! Ут белән уйныйсың,— станция сәкесендә кызлар белән түгел.
— Серең шушымыни? — дим мин.
Кәүсәрияне чыгарып, кемдер сөйрәп китергән чанага төреп салалар да алып китәләр. Ул ыңгыраша, саташа иде.
Ярмиев сызгыруга охшаш тавыш белән Каһирга:
— Сөйлә! — диде.
— Мин аны Ниса дип белдем. Билләһи! — диде Каһир.
— Я, я.
— Карыйм: тәрәзәдә ут кабына-сүнә, кабына-сүнә. Шырпы сызалар. Ишек ачык. Керсәм — бу. Фонарь филтәсен күтәрәм — шул, Ниса. Сәке печәненә ут төртеп маташа. Печән бит юеш, турбина люгыннан

гел дым бәрә. Арттан килеп каптырдым да... Менә, кулны да тешләде, тәре!

— Каптырдың да — кая? — дип сорыйм.

— Шунда.— Каһир башы белән ачык люкка ишарәли.

— Шәлен салдырганда танымадыңмыни? — дип сорый Ярмиев.

— Караңгы ич! Фонарь сүнде, авып.

Идрис абый сәке астына иелә дә фонарь тартып чыгара.

— Әйтәм ич, караңгы иде дип.

— Ә эт? — дип кинәт аңа сорау бирәм.

— Нинди эт?

— Гыйфрит караңгыда сине таныймы?

— Моның ни катнашы бар?

Мин Бәдәмша абзыйга карыйм да карашымны ишеккә юнәлтәм: ул аңлый, бераздан чыгып китә.

— Гыйфрит мине җәһәннәмнән дә таный,— ди Каһир.

— Кычкырмадымыни?

— Кем?

— Ниса.— Юри шулай дим. Каһир нидер яшерә иде.

— Кәүсәрия диген!..

— Кычкырмадымыни?

— Пожар ич, кем ишетсен?.. Тешләде, каһәр! Мәйтәм, яхшылык белән...

— Яхшылык белән — нәрсә?..

Йөземне кисәк кенә сәкегә таба борам, ә күзем — Каһирда. Ул да нәкъ минем ишарәләрне кабатлый, аның йөз сызыклары карурманына кереп качкан икенче «мин»ен күреп алырга өлгерәм һәм — үземнең коточкыч дәрәҗәдә соңга калуымны аңлап алам!.. Бусага төбендәге кыштырдавык тышлы ак мендәремә Каһирның аяк сөрткәнлеген миннән дөньяның бер генә алдавы һәм мәкере дә яшерә алмый иде инде!

Кәүсәриянең алдына тезләнеп: «Соңардым, фәрештәм»,— дим. Кәүсәрия аркан борыла: «Ә мин — ашыктым».

Каһир да ахмак түгел, тиз төшенә:

— Ә көндез...— Ул мыек очын ялап ала.— Мин моннан алка таптым. Алтын. Кемнеке икәнен беләсең. Тәк шты...

— Соң?

— Мин дә риза. Чәнчелсеннәнр. Ул Бәдәмшаны дүрт баласы белән кая куып чыгармак кирәк инде, әйеме, Идрис абый?

— Хәшәрәт!

Фонарьне эләктерәм дә Каһирга томырам, әмма ул салкын канлылык белән читкә тайпылып кала.

— Кызганам мин сине!..— Ул кесәсеннән ачкычлар бәйләме чыгарып шалтырата.— Менә бу ачкычларның станция йозагына каян килгәнен исбатлыйсың бар әле, иптәш Зәйнушин! Бу ачкычлар минеке иде.

— Каһир, чык әле монда! — тыштан — Бәдәмша Тарханов кычкыра.

Идрис абый белән карашып алабыз. Ул да, мин дә Каһирны нигә чакырганнарын аңлыйбыз инде. Анда — дүрт агай-эне булса кирәк, Кәүсәрия өчен чакыралар. Идрис абый чыгып китә.

Каһир белән икәүдән-икәү генә калу мине җирәндерә иде инде. Кичәге күселәр белән кабат очрашкандай.

— Сиздем бит мин сезне, слушай! Әмма мин дә өлешсез калмадым... Кәүсәрия минеке булырга тиеш иде. Булды да!

Арабызда киң каеш әйләнә.

— Бәхетсез син, Сафин! Минем беркайчан да чәчәккә төкергәнем юк. Ишетәсеңме, Сафин?! Алла тарафыннан шушыны аңлау бирелгәнме сиңа?!

— Да?.. Син аңа... Каусәриягә... тимәгән идеңмени?

Идрис абый керә. Азамат карт белән.

— Мин Гыйфритне алып килдем, Каһир энем,—диде Азамат карт.— Анда бихисап халык, ә ул өрми...

— Ут төртүчене эзлисезме?

— Бәлки, син әйткәнчә, Каусәрия түгелдер? — ди аңа Ярмиев һәм миңа карап ала.

— Моны бер генә кеше — тфү, иманыңны! Гыйфрит генә әйтә ала... Тик бит... хы-хы... яхшы эт... үз хуҗасын сатмый!

— Ә сине?

Сафин күкрәген киереп барган җиреннән сөрлегеп киткән шикелле булды, йөзе ничә ел җир җылысын тоймаган сука калагы сыман күгәреп килде.

— Халык бихисап,— ди Азамат карт.— Сез генә юк.

Ишеккә юнәлдек.

Иң ахырдан Каһир күренә.

...Чылбырыннан ычкындыргач, Гыйфрит Каһирга ябышты. Аны икенче көнне алып киттеләр. Кичкә кайтып житте. Эткә ышанмаганнар — аңа ышанганнар.

Каусәрияне җирләгәч һәм аның өчесен үткәрүләрен дә көтмәстән, Тархановларны пристаньгача илтеп, пароходка утыртып җибәрделәр. Ләкин мин аларның һәр гаилә башлыгына, һәммә кешедән дә яшереп, әйбәт кәгазьләр язып бирдем. Авылдан читтә алар хәзер күчеп киткән кешеләр булып кына санала иде.

Язгы чәчү беткәч, мине Казанга, ә аннан Мәскәүгә чакыртып алдылар... Инде менә Днепрогэс, утлы Берлин, Братск, Усть-Илим, КамГЭСлар аша тагын шушында әйләнеп кайттым.

## X

Мин тау маңгаенда — гомеремнең иң биек ноктасыннан бераз гына түбәндәрәк басып торам. Вакыт кинәт туктап калды кебек. Икенче көнне, кичкырын, тегермәнне сүтә башлагач, вакыт кирегә таба әйләнергә кереште — мине шундый тойгы биләп алды. Тегермән түбәсенең инде кибеп саргайган мүкле такта түбәсенә ике кеше менеп басканы күренде. Аларны әрекмән яфрагында үрмәләп йөрүче кара кырмыскаларга охшаттым. Тегермән стенасындагы, кәрниз астындагы бихисап тишек-тошыклардан әллә нихәтле күгәрчен, чәүкә, чыпчык тузгып чыкты. Ә тегермән үзе яңгырлар каралткан салам кибәненә кунаклаган җиреннән очып китәргә җыенган тилгәнне хәтерләтеп тора иде.

Түбәдәге кешеләр беренче тактаны кубарып, аска төртеп төшерделәр.

Ә мин томан эчендә. Хәтер томаны. Такта кубаралар. Тешкә тиярдәй чыгырдау белән, кадак суырыла — истәлекләр капкасы шыгырдыймы? Вакыт кошының хәтерем ядрәсе йолкып алган каурые булып, җиргә түбәнең беренче тактасы килеп куна. Мин исә, томан аша кулымны сузам да, бу тегермәннең таш нигезенә тимердәй чыңлап торган ике имән өрлеген китереп салам. Дүрт почмактагы дүрт талир тәңкәгә. Аларны миңа Каусәрия биргән иде. Үз чулпысыннан. Көнчыгыш ягы почмакларына мин салдым, көнбатыш почмакларга — Каһир. Ул: «Безгә ырымнарның кирәге юк!» — дип караган иде, картлар күн-

дерде. Смоленскиның кремлен салганда, көянтә-чиләген күтәреп суга барган җиреннән тотып алып, диварга бер яшь кызны терелэй томалап куйганнар. Елата-елата. Ә без — Кәүсәрия чулпысын. Аны шатландырып. Хәтта горурландырып. Элеккеге тегермәннәрне тирә-күрше авылларда «Морза тегермәне» дип йөрткәннәр. Без салганы хакында «Кәүсәрия тегермәне» дигән сүз китте. Теге фаҗигале төнгә хәтле. Ул мактаулы сүзнең кан тамырын Каһир буганчы. Гади — «тегермән» дигән сүзе генә калды. Инде менә аны да сүтәләр. Әле дә таза бүрәнәләреннән ни корырлар икән? Беләсем килеп, берәүгә сүз каттым. «Утынга,— диде.— Пенсионерларга. «Монысын да ягарга!.. Җанны ягып төзегән нәрсәне тән җылытыр өчен утын итеп ягарга... Иске-москы бары тик ягарга гына ярый шул. Кешеләр искене тырышып яга. Үҗәтләнеп үк. Үткәннәрдән тизрәк арынырга, котылырга теләпме?

Инеш суы кирегә ага башлаган иде инде. «Аккан сулар кире кайтмый, яшь гомерләр дә шулай...» Кайта икән лә ич! Тегермән түбәсенең ярты ягын сүткәч, су буена, морзалардан калган, балчык, чирәм астыннан инде бары тик кырылып, кителеп беткән таш баскычка барып бастым. Юкса, тегермәнне сүтүләрен карап торуы читен. Кызганыч. Юк, үлем алды сагышы шикелле, тирән бер төшенкелек тойгысы басканга түзмичә бугай. Мин булсам, ул тегермәнне сүтмәс идем. Бернигә ярамаса да. Инде баштанаяк яңарган колхозга хаҗәте калмаса да. Һич югында берәр төрле ашлама саклагыч итеп тоту сылтавы белән. Элеккеге тормыш, бу авыл, колхоз тарихының җанлы шаһиты итеп. Яшьләр гыйбрәт алсын, өлкәннәр онытып ук бетермәсен өчен. Хәтер — бер нәрсә ул. Хәтерләр өчен бер этәргеч кирәк. Менә мин. Бу кадәр дә ачык итеп үткәннәрне уйлар өчен шушы кайтуым гына сәбәпче булды ич. Шушы су күтәрелү. Шушы тегермән.

Әйе, мин аны сүтми калдырыр идем.

Уемны кем беләндер уртаклашыр өчен урынымнан торсам... Түбәнең калган ягын, кайчылар башындагы үзәк матчасыннан бәйләп, трактор белән йолкытып яталар иде инде. Түбә, янтаеп, бирешмичә торды да тузан куптарып, җиргә килеп төште.

Тегермәннең ишелеп төшкән түбә такталары белән кайчыларын сүтеп, трактор арбасына төяделәр дә кайтып киттеләр. Башлагач, бетерергә кирәк иде, ярык-сурык ничек инде, болай бер көнне кабер казып, икенче көнне мәет күмгән шикелле...

Иртәгесен мин килгәндә, тегермән бурасын яртылаш сүтеп өлгергәннәр иде инде. Кеше күплегенә хәйран калдым. Сүтүчеләре әллә ни күп түгел, карап торучылар шактый. Тегермән тирәли тере койма ясап басканнар да, кычкырып, сүтүчеләргә киңәш биреп, эшләрен килештермичә, сүз катып торалар. Хәер, өч буынны диярлек туендырган икмәк хакына гомере буена калтырап он тарткан тегермәнне кызганып та җыелулары бик ихтимал, бу, бәлки, авыл халкының үзенчә саубуллашу тамашасыдыр, өметсез авыру янына мәңгегә хушлашу, соңгы сүзен ишетеп калыр өчен килгән ише бер йоладыр.

Мин үзем шуны телим, мин үзем монда шуның өчен.

Әмма җыелган халыкның бөтенесендә сәнәк, көрәк, күсәкләр булуы аңлашылып җитмәде.

Иң арттагыларының тыгыз рәте артына барып басам. Мине күреп, юл бирәләр, юк, эчкә үтәсем килми. Тегермән, чыннан да, төзәлмәс сырхау шикелле, ыңгыраша, сыкрый, сулкылдый, бөрешкәннән-бөрешә бара.

«Үлә»,— дип уйладым мин.

— Су монда да менәмени? — дип сорадым беркемгә дә мөрәҗәгать итмәстән. Кемдер ишетәчәк, бөтенесенә билгеле җавапны бирәчәк иде.

— Кем белә инде аны,-- диде миннән өченче кеше, борылып тормастан.

«Иртәгә я аяз була, я яңгыр ява...» Иң дәрес жавап. Крестьян аңының миңа таныш булмаган ягы. Мин белгән кешеләрнең иң гадәти җавабында да аларның китап сыман кулга алып укырлык ачыклык ята иде. Мин белгән игенче үзенә таяна иде, хәзергеләр башкаларга салынучан шул.

— Кая ашыгалар? — дигән булдым.

— Беркем ашыкмый, ник ашыксын,— диде шул ук кеше, күзен кыса төшеп, тырнагына хәтле төшеп җиткән папиросын суырып.

Аңа мыеклы җирән егет каршы төште.

— Йолкыгач, тамыры белән суырып чыгар. Күзне тырнап тормасын.

— Бетә, бичара. Тыны бетте. Ә торса, синең белән мине күмә иде әле — тегермәнне әйтәм, безнең гомергә дә җитәрлек иде.

— Күмде ди. Бульдозер белән бер як кабыргасына китереп кададың — ләхете-ние шул.

Тегермәнне яртылаш сүттеләр инде — ак тузан каплаган каушасы ачылып калды... Кайчандыр безгә кояшны салып, йолдыз итеп тартып булырдай тоелган кауша.

— Бер ташын сөйрәтеп алып кайтам әле мин моның. Урталай ярып, баскыч төбенә салам.

— Көчән, көчән, эчең чыксын. Каушасы җарый менә — бәрәңге базын капларга.

— Мин аны эт оясы итәрием.

— Соң сора, кемгә хаҗәт ул! Барыбер теткәләп ташлыйлар.

— Алайса, берсе сиңа, берсе миңа.

— Әй, аны сөйрәп азапланганчы...

Үлмәс борын, тегермәннең мирасын бүләләр иде. Сәерсенеп тыңлап һәм карап торам. Кызык: беркем дә боларны колхозга кирәк санамый, «колхозга» фәлән әйбер эшләп булыр иде», дими, үзләрен генә кайгырта. Ир-атның хуҗалыгындагы иң кирәкле, иң кадерле нәрсәләрен колхозга ташыган чаклар да бар иде бит... Вакланганнар! Вакланганнар... Тегермәнне уратып алган тере койма тирәли әйләнеп, алардан читкәрәк киттем.

Әй, тегермәнем минем, мине таныйсыңмы син, яшьлегем хәтирәсе булган тегермәнем!

Ә ул ыңгыраша да ыңгыраша, ыңгыраша да ыңгыраша, стеналары кимегәннән-кими, гүя тегермән үзен-үзе он итеп тартып ята иде!

Әнә инде каушаларын да машина краны белән тәненнән суырып алдылар. Авызынан күк йөзендәге йолдызлар санынча ашлык үткән чал кауша. Аны кран тросларыннан ычкындырып, сыртына аудардылар — кырын яткан алтын кыңгырау мыни! Каушалардан соң ташларны каплап торган такта касәләрне күтәреп чыгардылар, тегермән сәндерәсендә өсте-өстенә салынган дүрт таш ятып калды. Хәер, алар, кавышу язмаган бәхетсез парлар кебек, һичкайчан бер-берсенә орынып ятмаганнардыр: алар арасында бодай бөртеге генә сыярлык ара бар. Бөтендөнья тартылыш законы белән ташларның бодай бөртеге генә сыярлык арасы... шул ара зурайды исә, көрпә китә, ярма килә башлый; кысылды исә, онга үзен-үзе тарта башлаган ташларның комы кушыла.

Күк җисемнәре тартылышы законы белән тегермән ташларының бер-берсенә тигезләнештә торырга тиешлеге — дөньяның башы белән очын боларның кайсысыннан эзләргә соң? Кешелеккә Ньютон даһилыгы белән тегермәнче гадилегенең кайсысы кадерлерәк?

Җир шары белән Кояш арасында басып торган кешенең һәм тегермән ташлары арасындагы бодай бөртегенең тартылыш законын кем

ачкан? Ачмаганмыни? Әйе, формуласы юк. Ә аның кирәге дә юк лабаса. Яшәүнең формуласы яшәү генә, үлемнеке — үлем. Ничек яшисең һәм ничек үләсең бит.

Ташлар арасы тигез торса, яшәү дәвам итә. Ипиле, тук яшәү. Җир белән Кояш арасы (атом бомбасы, водород, нейтрон, плазма, нейтрино, гравитация... бомбалары җан ияләре яшәгән аралыкны тәмам бетерә торган көч түгелмени?!), әйе, Җир белән Кояш арасы якынайса...

Тегермәнчеләр кирәк!!!

Җир белән тегермән ташлары арасын хәвефсез тигезләнештә саклар өчен гади тегермәнчеләр кирәк!

Тегермән ташлары арасындагы бодай бөртеге.

Тегермән ташлары арасындагы кеше.

Тегермән ташлары арасындагы Җир шары.

Тегермән өстендә, зур бер янгынның төтене сыман, ялкау тузан баганасы басып тора. Ул яктан көлү, төчкерү авазлары ишетелә. Һавада әчегән он исе аңкый.

Кран тегермән ташларын бер-бер артлы күтәреп, беләк юанлыгы тимер күчәреннән суырып чыгарды да, табадан алынган юка коймак шикелле генә итеп, җиргә төшереп куйды. Без бу ташларны күпме кеше бергәләп урнаштырган идек. Махсус ике арба ясап, аңар әле тагын ничәмә өстәмә күчәр һәм көпчәкләр куеп, дүрт пар үгез җигеп,— нинди газаплар белән! — егерме сигез чакрымдагы пристаньнан алып кайттык. Кара көз уртасында. Билгеле, бүгенге ташлар аларның оныкларының оныклары инде. Безнекеләре чын граниттан иде! Икешәр тимер кыршау кидерелгән гранитлар. Менә алар тарткандыр онны!

Кран ташларның берсен сыртына бастырып куйды. Тросны ычкындырган арада, таш әкрен генә урыныннан кузгалды, ике егет, көлешә-көлешә, аны этеп тәгәрәтә башладылар. Ян-яктан тагын ике-өч ир-ат килеп кушылды.

Таш торган саен кызурак әйләнә башлап, үзәгеннән читенә таба кыйгачлап тешәлгән он юллыклары тоташ спираль булып әйләнергә кереште — галактикабыз рәсеме мени! Аңа, читкә тайпылып, юл биреп калдылар, ә ул, чак сизелерлек авышлыкны үткәч, тегермәнгә күтәрелгән суйкый юлны аркылы кисеп, сикелтәләр аша инешкә төшеп китте. Сөзәк ярдан болганчык суга төшеп, шартлаган снарядтай юк булды. Шул мәлдә йөрәгем кагарга кереште, уң колагым чыңлый башлады. Күкрәгемне чәнчеп, тәнем буенча гомерем узып бара иде. Тиздән мин дә, шул таш кебек, җир өстеннән югалуга дучармын лабаса.

Тик аңынчы нидер эшләп каласы иде. Ниндидер иң төп эшемне. Үзебезнең бу дөньяда яшәгәнлегебезгә дәлил булырдай эшемне.

— Әйдә тегесен дә тәгәрәтәбез! — дип кычкырды кранлы машина шоферы.

— Шундый малны әрәм итәләр димени!

Ул арада кран тегермән ташларының тимер күчәрен дә суырып чыгарды. «Ите» белән өзеп алган төймә кебек шартлатып кына. Ташны баскыч төбенә җәеп салырга теләгән егет, кранчы янына күтәрелеп, нидер әйтеп төште. Шуннан соң, тимер күчәр, таш турысына җиткәч асылынып торды да, түбән башы белән аны чокып куйды. Таш бирешмәде. Икенче тапкыр, югартынрак күтәртеп бәргәч кенә, таш йөзенә кыл урталай ярык кунды, хәзер аның кыршауларын салдырсаң, ул икегә аерылып китәчәк. Әйе, болдыр баскычы төбенә салсаң, шәп була инде бу. Бөтен тирә-як халкын, мал-туарын туендырган кытыршы таш аяк табаннары астында ятар, шомарыр, юкарыр, торган саен җиргә иңә барыр...

Кран, тегермән ташларының аста ятканнарын да чыгарып, өстеәстенә куйды. Болары да нindидер эшкә ярамый калмаслар, кешеләр бернәрсәне дә тик яткырмый ич.

Ә миңа ул ташлар кызганыч. Югыйсә, аларны һәйкәл итеп куйсаң да начар булмас иде. Уемда, күк капусы ачылгандагыча, ап-ак бер балкыш уйнаклап алды. Әйе, һәйкәл. Бу ташларны шушы урынга истәлеккә куярга иде.

Тегермән, жиргә иңгәндәй, кечерәйгәннән-кечерәя барды. Инде сәндерәләрен, күперчекләрен, басма, баскычларын сүттеләр. Тегермән сүтүчеләрнең куллары-кулга йокмый башлады. Аларга кызыксынып жыелышкан кешеләр дә барып кушылды. Кояш төшлеккә житкән, һава тын, жылы, зәңгәрсу бер аязлык белән тулып тора. Эшләүчеләрнең кәефе көр, тирләгәннәр, сүзләре жор. Эшнең ахыры күңелле шул. Нәкъ менә шушындый жанлылык белән һәм вакытны онытып, без тегермәннең түбәсен такта белән япкан идек. Хәзер дәртләнә-дәртләнә идәнен кубаралар.

Бу — тегермәннең үлеме иде, килешми хәлем юк. Авыр, әмма читкә дә китә алмыйм. Мин монда ялгыш кына килеп эләктем. Мин монда чит. Мине монда күрмиләр дә. Күзләремне тегермәннән алмыйча гына китәргә борылам һәм кемнеңдер карлыккан тавыш белән көлеп куюын ишетәм. Күтәрелеп карамасам да, аның Каһир Сафин икәнен беләм.

— Нигә көләсең? — дип сорадым.

(«Кызык,— дип уйлыйм, нәкъ әллә кайчан — шушы тегермәнне салган вакытлардан бирле аерылгысыз яшәгән чактагыча, без исәнләшеп тормыйбыз, гүя берниндн вакыт үтмәгән, ә тегермән кино төшерер өчен фанердан ясалган булган да, хәзер декорацияләрне алыштырып кына куйганнар, ә без бүтәнчә гримланган артистлар»...)

— Жыласаң да була,— дип жавап бирә Каһир.

— Нәрсәдән?

Иң кимендә ни гомер элек мәңгегә дип аерылышып та, бүген Каһир Сафин белән минем юлларыбызның башланган урынына кире әйләнеп кайтып, бер ноктада очрашуы гына да аның ни хакында уйлап көлүен әйтеп тора иде инде. «Нәрсәдән?» дип, Каһирдан битәр үземнән сорадым бугай. Үзем дә бу минутта көләргә дә, еларга да әзер идем ахрысы. Күз алдымда жимерелеп, сүтелеп бетеп ятучы һәм тиздән болганчык су астында калачак тегермән моңа сәбәп түгелмени? Безне жиңүгә китергән миллионнарча беренче жиңүләребезнең башы булган электр станциясе һәм тегермән үзе үлеп ята иде инде — моңа шатланып көлсәң дә, кызганып еласаң да ярый. Чын жиңүләр генә шундый! Әмма бу Эпир патшасы Пиррның римлыларны жиңгәннән соң, үзенең күпме сугышчыларын югалтуга дучар булуын күреп: «Тагын шундый бер жиңүдән соң мин гаскәрсез калачакмын!» — дип кычкыруы түгел инде. Күз алдымда беренче электр станциябездән калган чоңгыл белән соңгы бүрәнәләре сүтелеп яткан тегермән, ә тау артындагы урманның теге ягында шул чоңгылның меңнәрчә тапкыр зурайтылган туганы казылачак — атом электр станциясенең котлованы. Бездән калган чоңгыл белән ул котлован арасында, зурайткыч пыяла булып, Каһирның да, минем дә гомеребез үткән саф вакыт жәйрәп ята иде.

— Һәркем үзенчә үлә,— дидем мин. Ә эчемдә нindидер бер кылның шуның артыннан ук: «Һәркем үзенчә үлде»,— дип зыңлап куйганын ишетеп алдым кебек. Иртәме-соңмы бу киләчәк, тик аңынчы мин икебезгә дә тагылачак ул үткән заманда әйтелгән уйның Каһирга һәм үземә карата аермасын да ачыкларга тиеш. Ни өчен ул да, мин дә бер үк нәрсәдән бер үк төрле итеп көләргә дә, еларга да ихтимал соң әле?

— Ничек үлсәк тә, безнең каберләребезне бер төрле язмыш көтә...

Ул тегермәнгә, станция ягына карап куйды, ә мин карашымны сирәк болытлар күләгәләгән аръяктагы яшел тугай буйлап йөгертеп уздым.

— Бер төрле? — дидем мин үзалдыма сөйләнгәндәй, һичнинди хис белгертмичә.— Ә син шул иске тегермәннең биредә мәңгегә шыңгырдап торуын, ә кешеләрнең безгә асылташлар җемелдәве булып күренгән элеккеге зәгыйфь лампочкалар астында чекрәеп, тәбәнәк өйләрендә бөкерәеп йөрүләрен теләр идеңмени? Бәлки иске өеңдә дә шуны тансыклап калгансыңдыр?

Ул күзен кысып, миңа бер карап куйды да:

— Җүләр син,— диде.— Күрәсең, кешенең үзе үлгәч кенә башкаларга бирә торган соравы да була ахрысы.

— Үз сүзеңә исән чакта җавап ишетми үлгәч ни мәгънә?

— Аермасы юк.

Аермасы бар. Мин үз юлымның ахырына, нинди генә тозлы булса да, шатлыклы гомер кичереп килеп туктадым... Хәер, шатлыкны кем нәрсәдә күрә бит һәм ничек кичерә инде анысы. Тегермәнебезнең сүтелүендә сагыштан битәр шатлык күбрәк. Аның сүтелүенә көлсәм дә, еласам да, шатлык белән көләм, шатлык белән елыйм. Ә Каһир...

— Нигә аермасы юк, Каһир?

— Чөнки тереләрнең үлгәч бирә торган җаваплары бетте. Һәркем үзе теләгәнчә яши... Әйт, кешеләрнең үзләре теләгәнчә генә яшәүләре яхшы нәрсәме ул? Юк, начар нәрсә. Чик югала. Чик югалгач, очның мәгънәсе калмый. Ә оч беләсеңме ни ул? Синең белән мин. Синең белән минем мәгънә калмый, аңладыңмы? Теге елларны монда нигә тамырың өзелгәнче тартышканыңны беләсеңме?

Мин. Син дә тартыштың лабаса.

Ул. Җавап бир.

Мин. Әлбәттә. Миннән шул тартышуны тартып алсалар... Яхшы аңлыйсыңдыр.

— Без ышандык шул, Ислам туган,— диде ул беренче тапкыр исемем белән эндәшеп.— Шунсыз миңа үз чигәмә пуля чәпәве берни тормый иде. Ышанмаган кеше дошманым иде, шуңа күрә андыйларга пуля жәлләмәдем. Беләсем килә: син, менә син ул ышанычны югалтмадыңмы, ә юк — ташламадыңмы? — Сафинның сул күзе кысылып килде, ә уңы, дугаланып торган чал кашы астына яшеренгән браунинг көпшәсенең кара тишеге булып, миңа төбәлде.

— Кая? — дип сорадым мин.— Аяк астынамы?

Ул. Аяк астына түгел. Аяк астында ташландык нәрсәләр болай да күп... Каберә, каберә...

Мин. Мин әле үлмәдем.

Ул. Үлмәдең... Ә үлгәч? Кая китә синең ышанычың? Алып китәсеңме, әллә калдырасыңмы?.. Мин үлгәч, син җавап бирә алмый торган сорау менә шул инде, Ислам.

Мин. Җирдә мин үземнән табышмак калдырмыйм.

Ул йөзен читкә борып, тәмәке төтене карлыктырган калтыравык һәм күгәрек тавышы белән көлеп куйды.

Ул. Кешеләрнең дөньяга килүе табышмак түгел. Синең белән минем ник тууыбыз гына табышмак.

Мин. Без яңа тарих ясадык. Белмим, кем ихластан, кем...

— Ирексездәнме? — дип сорады ул карашын туп-туры маңгаема текәп.— Ә моның аермасы юк инде, Ислам! Без бер үк тегермәнгә су койдык. Мәгәр аннары син дә, мин дә шул тегермәннең ташлары арасында калдык. Ә ташлар әйләнә-ә-ә...

Мин. Бодайны тегермән ташлары арасына кертер өчен үстерәләр — менә мәгънә кайда.

Ул. Мәгънә үстерүчедә түгел — ашаучыда... Кем ашый, ничек ашый, ник ашый, күпме ашый.

Мин. Балаларыбыз, оныкларыбыз ашый. Рәхмәт әйтеп.

Ул. Рәхмәтне кем ничек әйтә бит аны: әллә ихластан, әллә ирексездән...

Мин. Монысы инде әйтүчеләр вөҗданында.

Ул. Шул-шул менә: синең белән минем ишеләрдән кала торган табышмак — әнә шулар вөҗданы. Алар «спасибо» ди. Әллә ихластан, әллә ирексездән. Ә кем ничек — бусы синең белән мин ясаган тарихта юк.

Мин. Анысы алар тарихында булыр. Безнекен алар дәвам итә — үзләренекен. Безнең проблемалар бетте, аларныкы башлана.

Ул. Таяк ике башлы... Аларныкы бетеп, безнеке башланмагае!

Мин. Таякны һаман үзеңә генә бөгәсең икән әле, Каһир... Әйе, алар заманы башлана. Җиңел заман димим, җиңеле беркемгә дә тимидер, мөгаен, һәр буынга үз өлеше.

— Буын, буын! — дип кабатлады ул бер мәл тегермән тирәсендәгеләргә карап торгач.— Буын ул кая бөксәң, шунда кәкерәя.

Мин. Алармы кәкере? Теге станция белән менә бу тегермәнне ничек төзегәнебезне хәтерлә дә, алар салып куйган яңа авыл белән чагыштыр... Исеңдәме, Тархановлар. Азамат карт, аның дүрт улы... Әлбәттә исеңдә!.. Кәүсәрия, Ниса...

Алар берәм-берәм күз алдыма килеп бастылар. Янәшәләрендә үзем: яшь, таза, көр күңелле, тик нигәдер күземне кысканмын да өске иренемне тешләгәнмен, кемнедер эзлим, эзлим...

Мин. Исеңдәме, берзаманны кешеләр аларныкы шикелле йортларда тора башласалар, коммунист буларак үз бурычымны үтәдем дип санар идем, дигәнем, исеңдәме? Бүген сүзем раска килү белән канәгатьләнергә рөхсәт итәсеңме?

Ул, тешен кысып, башын чайкады да:

— Кәкере агачны башка яктан карасаң, туры күренә,— диде.

Мин. Бөтенесе ал да гөл дияргә җыенмыйм, ләкин без беркайчан булмаганча көчле.

Ул. Кем инде ул «без» дигәнең?

Мин. Халык.

Ул. Халык? Кемнеке? Синекеме?

Мин. Минеке дә.

Ул. Мин — татар, ә татар капшап карамыйча ышанмый. Я?

Төшлеккә җиткән кояш бар нәрсәне әлсерәтү хәленә китергән: тегермән тирәсендәге кешеләр тавышы әллә кайдан, нинди дер калын пыяланың теге ягыннан сүлпәнләнеп ишетелә, түбәндәге комлыкка калейдоскоп пыялалары шикелле чуар көтү төшеп тупланды, аръяктагы зәңгәр бәрхет көзлектән кыр казлары күтәрелеп очты, җил исеп куйды һәм ул, гүя, аларның саллы канатлары астыннан җилпеп чыгып, йөзне сыйпап китте.

— Ашыгалар,— диде Каһир кулын селтәп.— Йөзләрен күреп булмый, кайсы өммәттән икәнлекләрен танырмын димә,— бар, капшатырлар яңак төбенә берне. Кул-аяклары тышаусыз, ә җаннарын мүкле таш баскан. Менә сиңа проблема, парин! Халык түгел, куузика алар — менә кем!

— Нигә куузика? — дип сорадым.

— Шалкан белән чөгендердән әмәлләнгәнгә. Боламык! Тиз үсәләр, кичтән өйләнеп, иртән аерылышалар, асларында да, өсләрендә дә техника, Акселерация! Гүпчим, пешеп житмәгәннәр,— диде ул.— Аларны син дә кәкере каенга терәтеп калдырган күк тоелмыймы? Менә мин тоям. Үз каберемнең нинди булачагы миңа билгесез, ә менә аларныкын аермачык күрәм, каһәр суккыры! Әкәмәт!

Мин. Нинди соң?

Ул. Сугыштагы ише.

Мин. Туганнар каберлегеме?

Ул. Ихтимал. Алай ук димим... Исемсез — менә нинди.

Мин. Каян алып әйтәсең?

Ул. Үзебезнеке шундый.

Мин. Картайгансың син, Каһир. Бавырың начар эшли икән.

Ул. Ник?

Мин. Үтең җыелып ята икән — теленә сеңгән.

— Әйе, шундый,— диде ул.

Мин. Әле һәркемнең шәхси кабере бар.

Ул. Формально шулай. Кабере бар, кадере юк. Тимер урлап, я, ярый.... рөхсәтсез алып, чардуган куялар, таш утырталар да вәссәлам!.. Син белмисең, кайгың ул түгел. Син бит — оһо! — биектә! — Ул йөзен җыерып, кемнедер, нәрсәнедер бик кызганган кыяфәт белән бармагын күккә каратып торайтты.— Биектән күренми. Биектән тормышның... җирнең өске катламы гына күренә... Син шуның белән бәхетле дә, бәхетсез дә... Шәхси кабер яхшы инде ул анысы. Миңа бит барыбер. Сиңа да. Үлгәч дим. Кабер ул... җирдә калганнар хәтере өчен. Ә алар ашыга, кабалана. Менә, зират булып, зиратны күчерделәр. Беләсең килсә, авылда калганнардан битәр (аларның да бөтенесе түгел) үзләренең ата-энкәләре, әби-бабайлары каберен кая, ничек күчерүләрен сирәк кеше сорашты, кайтып белеште. Гаепләмим, юк... Мин уйлыйм гына. Уйлыйм. Фараз гына кылам. Тыңламасаң, тыңлама, Ислам... Тик менә бу төш авырта,— диде ул йөрәген тотып.— Ата-ана каберләрен кадерләү урынына, бүтән нәрсәләргә табыналар... Әйе, безнең әүвәлге зиратка кара: шәрә!.. «Халык»! дисең. Халыкны мин зиратына карап беләм. Чиркәвенә, мәчетенә... «Без көчле!» дисең. Ни ул — көч? Пулямы? Снаряд? Ракета? Ну бит алар, парин, складта ятканда... аннары соң очканда гына пуля, снаряд, ракета. Килеп төшкәч, берни түгел — бетәләр. Үлем бетсә, кеше кеше булудан туктар иде. Мин менә кеше үлеме белән үлемсез дип уйлыйм. «Үлемнән курыкмаган»,— дип язалар... Үлемнән дуңгыз да курка, парин! Халык хәтерендә үлүдән куркырга кирәк, халык хәтеренең үлеменнән... Шәхси каберен булу — чепуха! Менә бит кайда арбаның кендеге... Халык, парин, үткәне белән генә халык, үткәненнән аермасалар гына...

Ул корыган үлән сабагы өзеп, иренenә кыстырды да тагын читкә, еракка карап тынып калды. Аннары үләнне ирен читенә шудырып, авыз эченнән генә бер җыр көйләде:

Алга килми, белеп булмый,
Башның ни күрәчәген.

Кинәт (әйтерсең лә башыма китереп суктылар) артка борылып карадым. Тегермән турысында соры тузан баганасы гына, җил юк. Тузан баганасы, ниндидер борынгы җимереклектән торып калган килбәтсез колонна сыман, шул ук вакытта ниндидер цивилизациянең җирне ташлап, үзләре хакында бернинди хәбәр, эз калдырмыйча, очсыз-кырыйсыз тирәнлеккә менеп котылган бердәнбер ракетасы артыннан сузылып калган, инде вакыт җиле таратырга керешкән төтен баганасын хәтерләтеп тора. Үземне башка бер вакытка һәм урынга килеп эләккәндәй тойдым. Тизрәк үзем күнеккән, белгән, яраткан урыныма әйләнеп кайтасым килеп китте. Әле кичә генә мин бу тарафларга моннан нибарысы йөз илле чакрым ераклыктагы, соңгы агрегаты тагын утыз биш көннән соң җибәрелергә тиеш булган ГЭС аша чыгып киткән идем. Сокланып, горурланып, куанып, эчтән елар дәрәҗәгә җит-

кәнче моңаеп; яшьлегемне сагынып һәм битемдә мәңгелекнең ләм, балык, цемент, су исе аңкып торган салкынча сулышын, кочагымда тәкәббер һәм шаян елганың сыгылмалы, тыгыз, кайнар билен, йөрәгемдә станциянең йөгерек ток кудыручы агрегатлары тибешен тоеп. Гүзәл елганы, дөресен әйтергә кирәк, без көч белән дә буйсындырабыз. Мин утырган кара «Волга» плотина буенча чаба, графикка сыяр өчен бирәдә көчәйтелгән бригадалар эшли, техника гаять күп, шуңа күрә бүтән транспорт йөреше вакытлыча тыелган, бөтен юл тасмасы җәяүлеләр белән тулган. Плотина чакрымнар белән үлчәнә, җәяүлеләр чыга-чыга арып бетә, йөклеләр туктап-туктап хәл алгалый. Кыска гына бер тукталыш вакытында мин машинадан чыгып тордым да култыксага таяндым. Аста акчарлаклар гына очып йөри, тирән ургым айкалышканда балык тоталар. Суга кошлар оча торган биеклектән карап торам. Җитмәсә, бу якта су өслеге теге яктагыга караганда унбиш метрга түбәнрәк, җиңелчә генә башым әйләнеп китте. Янәшәдә ак күлмәгенә кызыл галстук таккан, ә пинжәген беләгенә салган озын буйлы яшь кенә, интеллигент кыяфәтле егет, зәңгәр култыксага таянып, сигарет тартып тора иде. Янында кара «дипломат» портфеле. Тартмаган арада, муенын сузып, аска төкерә дә, төкерегенең ком бөртеге хәтле генә калып кара, күләгәле суга килеп төшкәнен карап тора.

— Нигә суга төкерәсең, агайне? — дип эндәштем мин аңа.

— Кызык,— диде ул һәм тагын суга төкерде.— Сез төкерекнең ничә эмсекунд тизлек белән төшкәнен белмисезме?

— Кызганычка каршы, юк, агайне. Ә нәрсәгә ул?

— Плотинаның биеклеген белергә.— Ул портфелен алды да, билен турайтып, плотинаны күзеннән кичерде.— Гран-ди-оз-но!

— Гран-диоз-но! — дидем мин аныңча әйтергә тырышып.— Кая барасың?

Ул ияге белән генә кагып, сөзәк, биек яр буйлый Кремль кебек сузылган көмеш шәһәрнең тоташ йортларына ишарәләп алды.

— Соңга калгансың түгелме соң? Синең кебекләр монда ун ел элек шәрә җиргә килеп төште. Башкалар агачын утыртты, ә син җимешен ашаргамыни?

Башын аска иеп, тыйнак кына елмаеп куйды да, урыныннан кузгалып, каршыма килеп туктады.

— Тыйнак ук булмаса да, сезгә әйтәм. Нервыгызны бозмагыз. Ун ел элек алар арасында мин дә бар идем.

— Качтыңмыни? — дип сорадым мин, аның кояшта алтын булып янган чибәр йөзен күрәсем килмәгәнне сиздерергә теләмичә.

— Мин сезгә үпкәләмим. Кәефем шәп, бозасым килми... Ун ел элек безнең көчебез кирәк иде. Ә хәзер акылга чират житте... Мине бригада укырга җибәрде, биш ел буена стипендия түләп торды.

— Гафу ит,— дидем мин әкрен генә.— Шәп укыдыңмы соң?

— Ахрысы. Төкерек очканын да эмсекундлап санагач, артыгракка да китмәгән микән әле!

— Суга төкерергә ярамаганны әбиең өйрәтмәдемени?

— Алар ярамаганны үзләре эшләп туйгач әйтәләр ич!.. Кешелек ярамаганны эшләп арыган инде, иң соңгысы гына калган...— диде ул кузгалып киткәч, башын гына борып.— Ә ун ел элек мин менә шушы ГЭС төзелешендә башладым. Сезне дә бая ук таныдым... Кечкенә генә бер киңәш бирергә рөхсәтме?

Мин, күземне йомып алып, «рөхсәт» дигән ым бирдем.

— Сез патша түгел, керфек белән боермагыз, мин кол түгел.

— Рәхмәт,— дидем мин ачуым килә башлавын яшерергә тырышып.— Әйт киңәшеңне.

— Киләчәктә миңа «син» дип түгел, «сез» дип дәшәргә киңәш итәр идем.

— Кем соң син?
— Сезнең галәмәт күп вәзирләрегездән берсе, коллега. Иртәгедән. Планеркада мине сезгә тәкъдим итәрләр.
— Иртәгә планерка юк.
— Алайса, очрашканга кадәр! — диде ул җиңелчә генә башын иеп.
— Хуш...— Аның авызын чак кына кыегайтып йомшак елмайганын күреп, мин: — Хушыгыз,— дидем.
Ул, кырт борылып, бик таныш моңлы бер җыр көен сызгыра-сызгыра китеп барды. Әллә ничек, җилгә каршы төкергәнмен дә, шуның тамчылары үз битемә кире чәчрәгәндәгечә, кинәт тирләп чыккан маңгаемны кулъяулыгым белән сөртеп калдым...
Каһирның бер сулыш белән, ләкин гаять тыныч тавыш һәм ышаныч белән сөйләгәннәре мине шул егет белән очрашкандагы хәлдә калдырды.
«Халык ул, парин, үткәне белән генә халык».— Каһир Сафинның сүзләре аңыма чайкалып торучы асылмалы тар басма сурәтендәге фикер булып сузылды. Басма астында чоңгыл. Аста су түгел, кичәге «кол» булмаган егетне һәм минем үземне чагылдырып торган түгәрәк көзге җәеп куелган кебек. Егет теш арасыннан шунда «черт» иттереп төкерә дә (үткәненәме, киләчәгенәме?!) көлә-көлә басманы чайкалдыра башлый. Троска чытырдап ябышам, ләкин егылып төшмәс өчен түгел, ә басма шартлап өзелмәсен өчен... Үземнең мондый тотрыксыз хәлдә калганымны хәтерләмим. Һәм моның сәбәбе Каһир Сафин сүзләрендәмени, шайтан алгыры?! Кичерешемнең кайчандыр бер күргән төшемнән килгәнен исемә төшердем — бары тик шул гына. Ике ярны — үткәнне һәм киләчәкне тоташтырган басманың зыңлап өзелергә житешүен тою әзмени? Нигә элек моны искә алмаганмын? Каһирның фәлсәфәсеннән борнап, миемә ниндидер шик үләне тамыр җәя башлады ич, башлады... Кичә мин басып торган, гомеремнең киләчәккә (үткәнгә булуы да ихтимал) мирасы дип саналган ГЭС плотинасы бәлки беркем кичә алмаслык сират күперeдер ул? Мин омтылган мәңгелек мәнә шушы буш кырлар, тын үзәннәрдер ул, һәм мин аны су белән күмдергәнмендер? Бу минем бәхетем, ихлас яшәү мәгънәмме, әллә ирексездән кылган эшемме? Шикләнәм, сизәм, аңлыйм, беләм — мин салдырган ул ГЭСны урталай чабып өзәр өчен кайдадыр җәһәннәм утлы балта да кайрап, күтәреп куйдылар ич инде... Дөнья кешеләрнең күчәнә бәйләнмәгән, ә һәркемгә туу кебек үк бер генә мәртәбә бирелә торган үлем алдындагы фаҗигале көчсезлеккә эленеп тора ахрысы. Каһир кебек, үз халкыңның исән-имин̨леген яки үлемен генә кайгырту аз. Әллә соң һәркем үз учагы утын сакласа гына яшәүнең, тынычлыкның гомуми казаны тулы тора микән? Океанда артык тамчы, туфракта артык бөртек, кеше сулый торган һавада артык катнашма юк. Һәммәсе дә бер бөтен яшәү икмәгенең оны, суы, аксымы, тәме. Бөтен кешеләргә дә бер дәрәҗәдә кирәк, барлык халыкларга да.
Чыннан да, син туры дип санаган агач башка ноктадан караганда кәкере күренә мәллә соң? Гомуми рух икегә бүленгән — бер ягында хакыйкать, икенче ягында ялган. Яшәү мәгънәсе ике яр арасындагы сират күперенең кылыч кырында чайкалып тора. Кемдер яшәүнең сират күпереи кулларын, тезләрен каната-каната, йөрәген урталай яра-яра узарга тырыша, ә кемдер түбән төкерә-төкерә... Тырышканың ничә эмсекунд та, төкерек тизлеге ничә эмсекунд? Кайсысы тизрәк уза? котыла? коткара? Кемне? Артта калган гүзәл Кәүсәриянеме? Әллә алда көткән... Кемне? Кемне...
Төш сүнде һәм Каһирга:
— Хәтерлисеңме, Сафин: теге чакны изгеләр зиратын күмдергән идек,— дидем.
— Истә, чәрсә аны.

— Без аны ник кучермәдек икән?

— Вакыт әз иде. Ә аның, карт тәренең, күп чагы булмый да икән... Ул зираттагыларның кем булганын беләсеңме?

Мин иңбашымны җыерып куйдым.

— Изгеләр! — диде ул тамак төбеннән сызгырып чыгарган пышылдау белән.— Алар безнең хәтеребез булган. Оныттык... Үзебез оныткач, бүтәннәргә ни кала? Кеше булсак та, безне маймылдан туган диләр... Шуңа күрә безне дә онытачаклар. Без пулемет лентасына патроннар итеп тыгылган. Бер учерыттан соң... Ә буш гильзаларны эретәләр... Без менә шундый буын вәкиле, Ислам Имамович!.. Маймыллар түгел, мамонтлар!.. Проблема калсын ул, калсын. Алар бетсә, ми шиңә. Анда инде кем ашый, ничек ашый, ник ашый, күпме ашый — ике чабата бер кием! Анда инде ташны ничек көйлисең: ачкычны кысасың — өске таш төшә дә улактан он ага. Тегермәндә дим. Ә ачкыч кемдә? Тегермәнчедә, парин. Менә кайда хикмәт!.. Ә тегермәнченең онытылып китүе дә ихтимал, парин, ташларны бер-берсенә кирәгеннән артык кысып җибәрүе. Ул чагында бодай гына эштән чыга дисеңме әллә?..

«Ул чагында таш үзен үзе кыра»,— дип уйладым мин.

Һәркайсыбыз үз уен үзе уйлап бетерде.

Ул үргә таба — үз өенә таба менеп китте. Үрнең кояшлы бите буенча көтү-көтү вак болыт күләгәләре агылып төшә. Каһир Сафин шул күләгәләр агымына каршы бара иде.

## XI

Каһир... Каһир гаяр кеше иде. Сирәк очрый торган кеше. Мәсәлән, станцияне салып бетергәч. Ачар алдыннан. «Хәтерлисеңме?» — дип сорыйм мин үз-үземнән. Әлбәттә!

Ничәмә-ничә буа белән буылып, кысылып, кысрыкланып беткән инеш бер көнне тыеп, буйсындырып булмаслык көч-кодрәт белән, чүпрә салынган камыр кебек, ярларыннан ташып чыкты. Башта иң өске буа киткән, аннары икенчесе тулып ташыган... безнең плотинага дүрт-биш буа суы берьюлы килеп төште — чыда гына!

Тып-тыныч, инде күнегелгәнчә, һәркем үзенә кушылганча эшләп ята идек. Игеннәр урылган, халык ашлык суга, станция төзелешендә иң алыштыргысыз кешеләр генә. Мин үзем, районга китми калган Идрис агай, мулла-мәэзин дә Ширәмәтов. Бүген беренче тапкыр станцияне эшләтеп карау көне. Өйләргә чыбыклар сузылган: хәзер авыл урамнары тараеп калды кебек: кыл уртада имән баганалар, аларга сузылган ак алюмин чыбыкларны көтү-көтү сыерчык яки карлыгач сырып алган. Биш баганага бер кызыл флаг кадап чыктылар, станциянең әле бүртмәгән кауз һәм турбина идәне такталары, субайлары, шлюз агачлары су саркып каралды инде; шлюз ачык, су ага да ага, корыч улак тирәли су ургып, күбекләнеп тора, аннан инешкә сузылган ак балчыклы һәм вак ташлы канау торган саен җебеп ишелә, киңәя, ә астан өскә таба тирәнәя бара. Буа артындагы аллы-шәмәхәле сасыган сулы тобага җил мендәр-мендәр җирән күбек куып кертте дә туктаусыз әйләндерергә кереште; буага су җыелган арада астагы буаларда хәрәкәтсез һәм ач яткан балыклар инеш агымына каршы күтәрелеп, станция астындагы тыгыз ургымга җыелды. Ә бина үзе тау астына килеп туктаган пароход шикелле — якты, ак, җиңел. Ширәмәтов балалар белән аңа керә торган басма култыксаларын чыршы, имән, кызарып чыккан җимешле миләш ботаклары белән бизәп чыкты. Буа бурасы да кара-

лып, зәңгәрсу бака үләне, су төбеннән калыккан куе яшел суүсемнәр ябышып ямьсезләнде, алды тирес, чыбык-чабык, йомычка, чүп агач кисәкләре белән тулды.

Станцияне кабул итәргә районнан гына түгел, республика башкаласыннан хөкүмәт вәкилләре дә килергә тиеш иде, олы юлда тузан-фәлән һәм атлы яки машиналы күренмәде.

Мин иртәдән станция эчендә. Динамоны, реостат, приборлар щитын, маховикны, ремень, аны тотып торган сыгылмалы элмә таяклары тартылышын карап йөрим. Эшләтә башлауга ук ременьнең эчке ягын сумалалыйсы бар, дулкынланудан онытылмасын өчен сумала кисәген тимер чыбыкка кадап, күзгә чәчрәп керерлек урынга — маховикны турбинага тоташтыра торган вал тәгәрмәче тоткасына элеп куям. Станция эче гөжләп тора, салкынча, су, юеш, агач, механизмнар исе белән тулы, түр стенада Ленин белән Сталинның ылыс белән бизәлеп, көрән рамга куелган төсле портретлары. Тыш стенага — динамо һәм киләчәктә йон тегермәне булачак залларның ишекләре өстенә зур кызыл комачка Ленинның коммунизмны, совет властен һәм илне электрлаштыруны тигезләп күрсәткән бөек формуласы язып эленгән.

Қаһир килеп, Идрис абыйны кичекмәстән районга дәшүләрен житкерде, аның йөзендә ниндидер борчу бар иде, тик аны-моны әйтмәде, минем янга — станциягә кереп, кулын иңбашыма салып:

— Қәефләр ничек? — диде.

— Әйбәт.

— Бетәме инде?

— Бетте.

— Ышанасыңмы?

— Қат-кат тикшерелгән.

— Алайса, кич белән?

— Эңгер-меңгер төшүгә. Халык шаккатсын. Электрик өйдәге выключательләрне тикшереп йөри — бөтен авылда берьюлы кабынсын. Шуңа өстәп, станция өстенә биш прожектор куйдым: биш якка карап.

— Яхшы! Қайберәүләр шартласын әле!

Ул тарантасына Идрис абыйны утыртып китеп барды. Атын гадәтенчә, жайлы гына, үз дәрәжәсенә килешле санаган саллы биетү белән тотып бармыйча, кузгалганда ук баш очында дилбегә очын болгап кушаяклап жибәрде.

Ник икәне ике сәгатьтән соң гына ачыкланды.

Бездән астагы Борым авылында чуалыш купкан. Без моны соңыннанрак — ни эләкте шуның белән кораллаңган урыс крестьяннары аңлаешсыз һәм сәбәпсез коткыга бирелеп, безнең станциябезне жимерергәме, ут салыргамы исәпләп, авылыбызга бәреп кергәч кенә белдек.

Ул көнне искә алу аякларымның жегәрен алды. Ахыр килеп, станцияне ничек итеп салганбыз — барыбер түгелмени соң! Салганбыз — баста!.. Ләкин бит сүткәннәр дә инде, бераздан эзе дә калмый. Шаһитлар кимегәннән кими, башлаганмын икән, тәгәллим инде, кайдадыр мине әһәмиятлерәк эшләр көтә, шулай да, кайсысы әһәмиятлерәктер бит әле: төп жаваплылык миндә булса да, алланың кашка тәкәсе түгел ич, әле, ярдәмчеләр күпме, эшләсеннәр, алыштыргысыз кеше хәзер юк, ә мена истәлекләргә килгәндә... монда инде мин чыннан да алыштыргысыз, комачауламагыз, шайтан алгырлары, мин хәтерлим, үземнән битәр, бу сезнең өчен. Әйе! Ничек булган — шулай искә төшерәм. Үз телемә, ягъни үземә ничек кирәксә, шулай итеп түгел. Хәтта сөйләшүләрен дә русча бирәп. (Хәтеремдә татарчалаштырып утырмам бит инде, әйеме?!)

Шулай итеп, түбәнге авылда фетнә чыккан. Кайнар сулышлы котлы үз эшен эшләгән, күрек белән өреп җибәргән дә кызган тимерне сандалга салып тукмарга керешкәннәр, тыгып суындырыр өчен су куярга гына онытканнар. Ахырдан ачыкланганча, махсус рәвештә онытканнар.

Кыскасы, әле әвеннәренә ташып, күпме иген чыгасын, күпмесен дәүләткә тапшырып, күпмесен сатып, күпмесен үзенә алып каласын ачыклап бетергәнен дә көтмәстән, Борым крестьяннарының әвеннәре, ындырлары борынча авыл советы председателе һәм активистлары камчы тотып походка чыккан. Билгеле, мондый түземсезлек күпләрнең ачуын кубарган, аларга тапшырасы урынга, ашлыкларын йөк-йөк төяп, спирт заводына илткәннәр. Үлчәп алганнар, акчасын алырга иртәгә килегез дигәннәр. Иртән килсәләр, акча бирергә уйлаган кеше дә юк, амбар ишекләрендә потлы йозак, берданкалы сакчы, директор сөйләшергә дә теләми: «Властьлар шулай кушты! — дип кенә җибәрә.— Бәлки продналог хисабына китәр әле»,— дип тә өсти. Крестьянның власте кем — авыл советы, шунда китәләр, ә председательнең сүзе кыска: «Тапшырган икмәгегез — дәүләткә. Ә менә минем кулымда — өстәмә, ягъни встречный план: шуны үтәми торып, көннең якты чыраен мыскыллап йөрмәгез дә!.. Совет власте сезгә уенчык түгел, понятно?»

— «Какой-такой стричный план?»

«Кого стричь?

«За что?»

«Мужики! Слыхали? Стригут!»

«Подчистую! Под метелку!»

«Лучше палить! Пропади оно пропадом!»

Тозлы тир күзләрен томалый, шома сабынлы сүзләрдән авызлары күбекләнә, һавага бөтерелеп-бөтерелеп ярсу тузаны күтәрелә.

«Братцы! Дадим им драть свою шкуру? Али драться будем?»

«Не так страшен черт, как его малюют! Пошли на анбары! Свое берем, чужово нам не надоть!»

«Нужон вождь, мужики!»

«А пускай кажный вошь сам себе и вождь!»

Һәм шуннан китә. Спирт заводы амбарларына кичә тапшырылган ашлыкларын кире ташый башлыйлар, тик ераккарак: базларга, идән асларына, кайсыберсе йөге-ние белән — тауларга — Петр патша заманыннан соң Пугачев вакытында гына искә төшкән, ә хәзер инде ни гомер кеше аягы басмаган бакыр шахталарына ук.

Безгә боларны соңыннан Идрис Ярмиев сөйләде. Каһир аны вакыйганың нәкъ шушы өлешендә утыртып алып киткән икән. Берни әйтмәде бит, таш йөрәк. «Районнан куштылар»,— дип акланган булды. Имеш, бу хәбәрнең таралуын теләмәгәннәр, шул очкынны гына көтеп, кызып яткан урыннар булмагае, янәсе.

Директор Булганин тимер рәшәткәле контор тәрәзәсеннән бу тамашаны ишеген бикләп карап торган. Инде складларны кырып себереп, таралалар дигәндә генә, үгезнең күзен кыздыргандай, аның: «Подвалдагы спиртка кагылсагыз, атам!» — дип кычкырганын ишеткәннәр. Инде тынычлана башлаган кырмыска оясы колакларын торгызып, аягүрә баса, тыелгысыз кызыксыну белән һава исни-исни, подвал ишеге төбенә сузылалар. Булганинның сүзе аларны өскортып кына җибәрә. Тәмугтан качкан шайтанны җәннәт белән куркыталармыни соң?! Ач эт өеренә сөяк ыргыту ич инде бу. Алар исләрендә дә булмаган табышка яңа көч белән ташланалар. Ике потлы чүкеч тотып, каршыларына саескан шикелле аклы-каралы киемдәге демобилизацияләнгән бер матрос төшә:

«Провокация, братва!»

«Ә ни ярамый тагын?»

«Бүгенге көндә корабльдә бунтмы? Менә ни ярамый. Бөтенегезне вне закона куячаклар! Иптәшләр, таралыгыз!»
«Хуже не будет — не трусь, мужики!»
«Ябыгыз авызыгызны! Пренья бетсен! Паскуда подкулачная! Кем беренче — миегезне чәчәм!!»
«Будя, мужики, шаярдык, хатыннар көтә. Чыннан да, баштан сыйпамаслар».
«Мыекны да чылатмыйчамы? Крой яво!.. Берәр уймак җибәрми торып, синнән хатыныңа нинди мәгънә бар, кода?»
«Кан белән костырмагайлары!»
«Оно и хочется и колется...»
«Безнең ашлыктан кайнаган спирт ич инде ул, шайтан алгыры!»
«Бугазыгызга аркылы тормас әле, мужикны мужик костырсынмы?!»
Авыл өстендә чиркәү кыңгыраулары кага башлый, мужикларның нәфесләре артканнан-арта, ни таралырга, ни матросны читкә алып ташларга белмиләр.
«Сатканнар сезне, бетле этләр, утыз көмешкә сатканнар!» — ди матрос, трубкасына ут элеп.
«Кем?»
«Үзегез! Совет власте моны кичерер дип беләсезме?»
«Без әллә влачка тел тидерәбезме?»
«Сезне монда спирт бар дип кем котыртты? Бурда гына монда».
«Юк микәнни? Ах, эт койрыгы!»
«Үзе әчсен! Монда өстерәп алып килергә кирәк мөртәтне!»
«Сөйрә монда йонлач гадны! Я ему кендюх вспорю!»
Бер төркеме директор кабинетына ташлана.
Йөгәнләп диярлек, директор Булганинны алып киләләр.
«Ач әле, спиртың колмаклы микән?» — Аны тимер тасмалар белән аркылы-торкылы тышланган имән ишек төбенә төрткәләп кертәләр.— Дегустация!..»
«Ачкыч миндә түгел, завхозда.»
«Завхоз кайда?»
«Эзләп кара хәзер борчаны тары көшеленнән!»
«Телең белән ач, директор. Үз ачкычыңны өзеп кулыңа тоттырганчы, ач!»
«Җавап бирәчәксез!»
«Телеңне чарлама, иптәш директор. Син ачкан өчен безне җавапка тартырлармы?»
Матрос арага кермәкче була, бескозыркасын тузанга салып таптыйлар, кувалдасын тартып алып, директор кулына тоттыралар, йозакка күрсәтеп:
«Читкәрәк китегез, каны чәчрәмәсен!»
Әйтергә кирәк, директор артык ялындырып тормый. Подвалга депутация кертеп җибәрәләр. Көтәләр, көтәләр — тегеләр юк. Бераздан подвалның салкын авызыннан:

Где болит, чего болит —
Голова с похмелья-а!
Нынче пьем, завтра пьем —
Целая неделя-а! —

дигән кайнар җыр бәреп чыга. Шикәргә ябырылган кырмыскалар кебек, подвалга ташланалар.
Районнан өч милиционер (Идрис Ярмиев тә) килеп төшкәндә, алар инде мичкәләрне тышка тәгәрәтеп менгереп эчәләр. Теге ике потлы чүкеч белән төбен бәреп төшерәләр дә мичкә кырыеннан гына чөмерәләр. Җирдә — спирт күле. Баскычтан подвалга, шарлама булып, ауган мичкәдән спирт ага. Директорның авызына ашлык көри торган калай

соскыдан аракы коялар. Ул инде исерек, ләкин чалшайган күзе белән завод капкасыннан йөгерешеп кергән ак фуражкалы милиционерларны күреп ала.

— Тартырга бармы? — ди Булганин манма френченнән чыланып беткән пачкасын мичкәгә ыргытып.

— Харлампий! Кәҗә сыйрагыңны каптыр!

Каптыралар — сүнгән. Харлампий шырпы кабы чыгара, директор аны үз кулына тартып ала да, кабызып, спирт күленә ыргыта...

— Ба-тюшки!..

— Ивикуация, мужиклар! Кем аякта — кач!

Директор, биле сынган эт шикелле шыңшый-шыңшый, читкә, баскыч астына сөйрәлә.

— Янабыз, братва! Отдай якорь!

— Милиция, милиция төртте, егетләр!

— Менә нинди ылтиматум?!

— Харлампий! Үкчә пешә, тайыйк!

Ут мичкәләргә күчә, ыгы-зыгы, милиция белән буталышып, алар кысрыклаганга түзмичә чигенә, подвал ишегеннән чалбар балакларына ут капкан мужиклар атылып чыга башлый, капка төбенә хатын-кыз, карт-коры, бала-чага өелешә, чыга да, керә дә алмыйлар. Тар басмадагы кәҗә тәкәләре сыман, ике өер маңгайга маңгай терәшеп акыра, елый, ялвара, көлә.

— Христос ярлыкасын, Борисыч... Син бит юри, кабәхәт!— һәм кызыл битле крестьян директорның эченә баскыч астыннан үрелеп алган сынык сәнәкне батыра.

Подвал эчендәгеләр идәнне тутырып килгән зәңгәр ут елгасыннан качып, тимер рәшәткәле ике тәрәзәгә килеп буыла, подвал тәмуг уты белән тулган шешәгә охшап кала, ә бөкесе урынында — тимер рәшәткә. Лом белән каералар, лом бөгелә генә. Форсаттан файдаланып, үзенең исән-имин әйләнеп кайтканын спирт белән билгеләп алган матрос формасын салып ата да, тәрәзә чокырына төшеп, шул ике потлы чүкече белән рәшәткәгә суга башлый. Колак төбеннән кирпеч ярчыклары оча, чүкеч сабы шартлап сынганда. подвалдагыларның битләренә тимер рәшәткә дә ишелеп төшә. Аста ут телләре биешә, кешеләр акырыша.

— Җылындыгызмы, бирәннәр?! — дип шашып көлә матрос, аларны, шалкан шикелле итеп, чәчләреннән өскә сөйри, сөйри.— Эшче-крестьян каны шулай өтә ул!.. Сал ыштаныңны, хатыныңа тәбәсе генә кала ич, падла!

Идрис абый моны безгә менә шулай сөйләде. Подвалда ике кеше янып үлгән. Ә Булганинны, эченә кадалган өч җәпле сәнәкне суырып чыгарырга азапланган килеш, баскыч астыннан табып алганнар.

— Матрос... чәнчеде!..— дип ыңгыраша ул үзенә иелгән милиционерга, канлы иреннәрен көчкә ачып. Һәм, исереклектән чайкала-чайкала, сул кулы белән эченнән тырпаеп торган күгәрек сәнәкнең чәрдәкләнеп сынган сабын учлап баса да, куен кесәсеннән маузер суырып чыгарып, халыкка ата башлый. Барысы да (милиционерлар да) читкә сибелә. Көйрәгән тельняшкасын киң йонлач күкрәгеннән умыра-умыра һәм давылда чайкалган палубада баргандай аягын аерып, матрос кына Булганинга каршы китә.

— Хрулю, лярва! — йөзеннән корымлы тир ага.— Планетаны буямакчы буласыңмы, сволочь?! Айга саңагыңнан киптерергә әләм!..— Һәм кинәт йөрәге турысыннан ургып чыккан кара канны учы белән басып: — Амба, братва... лево на борт...

Директор ата да ата, аяклары тотмыйча, тезенә сыгылып төшкәч тә ата. Бөтен пулясын аңа — үзе иң кўралмаган формага — матрос формасына.

— Кўралмыйм!.. Кўрал...

Шуның белән демобилизацияләнгән матрос та, Булганин да...

Уттан качкан тараканнар шикелле, кайсы нинди ярыкка кача башлаган мужиклар каршысына аскы урамнан хатын-кыз улап менә:

— Әвеннәрне су басты!..

— Көтү ага!

— Каравы-ы-ыл...

Спирт мичкәләре зәңгәрләнеп яна әле, бәхеткә, подвал баштанаяк таш, ялкын үрләмәс кебек. Әвеннәре, ындырлары исән-имин торган югары оч кешеләре дә, әвеннәрен су басканнары да елга буена агыла. Ап-аяз көн, ә елгада гомер күрелмәгәнчә болганчык су ургый, инеш, ярыннан ташып, бәрәңге, яшелчә бакчаларын баскан, кабык түбәле мунчаларны, келәтләрне агыза, сугылган саламны, ашлык көшелләрен, сугылмаган көлтәләрне алып китә. Уттан, шау-шудан куркып, көтү көтәргә ялланган көтүче татар малайлары (безнең авылныкылар) сарык-сыерларны авылга куган — өстеннән су ага башлаган агач күпергә килеп кергән маллар суга егылып төшәләр, йөзәләр, баталар, һәм менә күпер камыр кебек өскә күпереп чыга, чатный, ярыла, тарала, мал-туар авырлыгыннан бата да борылыштагы бәрәңге, кәбестә бакчаларына килеп керә.

Ә көн аяз, бары тик инешнең югары башындагы авыллар өстендә генә ямь-яшел болытлар тавы өелеп тора. Сунның каян килгәнен беркем белми, көтүче малайларның берсе генә:

— Безнең станциядән җибәргәннәрдер,— дип сала.

Шул җитә кала.

— Ах, татарва гололобая! Әйттем мин сезгә, станцаларын туздырып ташлыйк дип әйткәниемме?

— Бөлдерделәр-р!..

— Таз тәреләр!..

— Башлары белән бергә түбәтәйләрен салдырып төшик, ә?!

— Православныйлар!.. Әйдәгез минем арттан!

— Сәнәкләр белән эчләрен тишеп агызмый торып...

...Ничәмә-ничә буа белән буылып, кысылып, кысрыкланып беткән инеш тыеп, буйсындырып булмаслык көч-кодрәт белән ярларыннан ташып чыкты. Пугачев явымыни! Сунның күтәрелүе кинәт, ярсу башланды.

Безнең авыл өстендә көне буе кояш торды. Ә Карнаухово урманнары, Ырга үзәннәре турысында яшелле-зәңгәрле болыт өере асылынып, өзлексез яшен яшьнәп, күк күкрәп торды. Бөрку җил безнең якка иссә дә, болытлар якынаймады, аяз күктә кабарынган япа-ялгыз болыт бүрекләре генә узып киткәләде. Башта без моңа тамчы да игътибар итмәдек, ә бер заманны, станциядәге сәкегә хәл алырга дип утырсам, турбина залына төшә торган капкач астан һава өргәндәй калтырап куйды. Ачып карадым — ул-бу юк. Сунның төсе үзгәргәнгә генә игътибар иттем: яшел түгел, болганчык.

Мулла-мәзин күренде.

— Бәла, кем...— диде ул тыныч кына.

— Ни булды, Җәмлихан?

— Әле булмады.

— Ни бар?

— Су. Буа суы күтәрелә.

— Шлюзны ябарак төштем. Кичкә су күбрәк җыела торсын — кимегән иде.
— Су күтәрелә,— диде ул һаман тыныч кына.— Башта Йөзен чиркәвендә кактылар, аннары Карнаукныкында да... Ә Борымда аракы заводы яна.
Мин тәрәзәгә капландым:
— Күренми ич.
— Анда да чиркәү кактылар.
— Алайса, шул янгынгадыр.
— Анда янгынгадыр. Ә өстә... Аллаһы тәгалә каргышы белән бәлаказа чыкмагае. Өстә ярты көн кара болыт тулгана.
— Безгә җитеп яумаса ярый. Станцияне ачар көнне генә.
— Ябар сәгатең җитмәгәе, су күзгә күренеп калка. Бер төшкә яуганнан иман көтмә инде ул.
Буага таба йөгердем. Су, тирән сулыш белән йоклаган кеше күкрәгедәй, бер төшә, бер күтәрелә. Бер субайга су биеклеген үлчи торган киртекләр уелган иде, буаның һәр сулышы саен, су белән киртекләр арасы үзгәреп кала. Ник икәнен уйлап бетермәдем, зират башындагы борылышта күбекле дулкын күренде, әйтерсең лә сай судан авызлары күбекле һәм яллары тузган ат көтүе томырылып килә!
Сәер, борчылмадым. Буага моннан гына һичнинди зыян килми; язгы ташуларга исәпләнгән. Төп һәм ярчен шлюзлар бар, җитмәсә, зират туры тәбәнәк булганга, мунчала күле чокырыннан аерып, дамба өелгән иде, кирәк шәттә аны ачарга була, ләкин ул чагында кайбер өйләрне су басуы ихтимал.
Ә хәл афәтле икән!
Юкә йөгән кигезелгән ябык атта авыл советы дежурные «Оборот-минут» Сөләйман килеп җитте.
— Ептәш Зәйнушин, ептәш Зәйнушин! — Кырт туктаткан атыннан чак мәтәлеп төшмәде.— Минутка өч мең оборот белән килеп җиттем.— Ул атыннан шуып төште.— Кан кайный. Җөрәк — чистокровный ат тоягы!.. Тилехренграм сиңа, ептәш Зәйнушин.— Тезенә төшеп җитә язган киндер ыштанын иягенә кадәр тартып менгерә дә тезе турысындагы кесәсенә башы белән диярлек кереп китеп, кәгазь чыгара, аны атның ыңгырчак кырып чиләндереп бетергән җиренә җыелган вак чебеннәргә чәпәп алгач, миңа суза: — У-у, иксприприаторлар!.. Бер полк җыелышып, ат канын эчәсез! — дип, пыр тузынган чебеннәрне куа.
Кәгазьгә карыйм — сытылган өч чебеннән гайре берни юк.
— Ни сузасың син?
— Тилехренграм-м! — ди ул мөгердәп.— Ептәш Сафин өйдә жук, сиңа китердем, стансыга карый чөнки.— Кәгазен атының бу як ярасына ябыштырып куям. Ул аны күзен кылыйландырып әйләндереп карый да атының авызына тыкмакчы була.
— Эчкәнсең ич син, агудан баш миең черек бәрәңге боламыгына әйләнгән.
— Тучны, агу...
— Кем шалтыратты?
— Иптәш Сафин.
— Я, ни диде?
— Бик хәтәр җангыр җауган, өстәге буаларны агызган, дип.
— Ник аны кәгазьләп маташасың соң?
— Тилехренграм язылган булырга тиеш, законы шундый. Ликбез үттем, беләм.
— Язмагансың бит! — Инде көлә башлыйм.
— Алла телне ник биргән? Бушка тел асрап җатырга миндә Әндри казнасы жук... Ну, мин киттем.— Ул атына үрмәләп менде.— Биш мең оборот-минут белән, но-оа! — диде ул атының касыгына тибеп.

Станция кыегына эленгән рельс кисәген кагарга тотындым. Барлык тыкрыклардан да кешеләр йөгерешеп килә иде инде...

Каузларны, шлюзларны ачып бетердек. Атына атланып, Каһир Сафин кайтып төште.

— Телефонограммаңнан алданрак йөрисең икән,— дидем.

— Нәрсә?

— Әле генә «тилехренграм»ын китереп тоттырдылар.

— Тоттырам мин аңа, тоттырам! Каз кияве!.. Мин шалтыратканга...— Ул куен кесәсеннән капкачлы көмеш сәгатен чыгарды.— Мин шалтыратканга ике сәгать тә чирек булып узган инде, имансыз! (Сүгенү.) Идиот! Күземә генә чалынсын — бәрәңге кук, тиресен әрчим! (Сүгенү.)

Безне кешеләр урап алды.

Ниндидер гөжләү ишетеп, зират ягына борылып карадык: карт каеннардан кара карга көтүе күтәрелде, этләр өрүдән туктады. Безнең буага ташкын ишелеп килә иде. Салам, агач, чыбык-чабык, абзар-кура калдыклары, арбалар, мичкәләр, сыер үләксәләре... Буадагы су күбенгән сыер эче кебек күперел килде, хәтта ухылдап та куйды бугай.

Кешеләрне бүлеп-бүлеп, шлюзларга тыгылган чүп-чарны чистартырга тараттык. Ә станция шлюзын ябарга боердым: аның алдындагы сусаклагычка, каузга һәм турбина залына чүп тыгылса, каузның, чыдамыйча, җимерелеп үк төшүе ихтимал.

Буа тулды, су шарлап, плотина өстеннән ага башлады, алдында чүп-чар тавы хасил булды. Буталыш, айкалыш, мунчалага дип салган юкә кабыклары бәйләме, үлгән эт, кабык бишек, чана... Мужиклар бүрәнәләрне, тамырларыннан кубып аккан агачларны багорлар белән я ярга сөйриләр, я плотина бурасы аша түбән төртеп төшерәләр.

— Җәмәгать, карале, самагун аппараты! — дип сөрән сала пеләш Фәтхи.— Аллам орсын, самагун аппараты!

— Суда тимер йөзәмени, зәңки күз!

— Әнә ич, мунча ләүкәсенә кагылган. Мунчада самагун куып яткан бит, тәре тамак!

— Мунча ләүкәсендә нәрсә кагып, нәрсә куганнарын хатыныңнан сора, җәме?

— Ха-ха-ха...

— Прых!..

— Әти, көймә тоттым!

— Тартып чыгар соң.

Иң авыры — плотина өстендәгеләргә. Буа чыдыймы, чыдамыймы — билгеле түгел, сынау үтмәгән, тик купкан тактасы, чатнаган бүрәнәсе юк әле. Миңа үзем төзегән «күпернең» астына кереп, үз өстемнән «поезд» үткәреп җибәрү җае да чыкты менә — багор алып, мин дә шунда менеп басам. Ташкын көчле, аяктан ега. Чүп-чар эченнән саплы чалгы чәчрәп чыга да, сабында бер әйләнеш ясап, чак кына минем муен тамырына кадалмыйча кала. Хөрәсән Шәйдулла аңа үз багорын аркылы куярга өлгерә. Шул мәлне тез астына буш мичкә тәгәрәп керә, чалкан егылган Шәйдулланы ташкын түбән очыра. Башы Тәкәрлек тобасында калкып чыга, артыннан йөгергәннәр аны багорыннан өстерәп чыгаралар — теше тешкә тиеп, пулемет шикелле тыкылдый.

— Шәйдулла абый, ботың каный.

— Чепуха! Көзән җыерды да багор очы тыгып чыгардым.

Каһир тупылдагы тимер чөйгә бәйләнгән аты янына йөгереп барып, крокодил тиреле яссы портфеленнән көрән сөргечле шешә алып килә:

— Йотып куй, Шәйдулла абый!

Шәйдулланың аяк астына хатыны килеп ава:

— Җиде балаңны ташлап, кайларга гынай йөзмәкче булдың, бәлеш авыз?

— Борым марҗалары янына — кая булсын тагын... Бар анда эк-

земпляртлар!.. Кайда Рәчәй, кайда Порт-Артур икәнен оныттырырдай экземпляртлар, парин! — дип, Шәйдулла шешәнең яртысына төшеп җитә дә янадан плотинага кереп китә.

— Пляртларың белән ябышып кат, җәме? — дип елый башлый Фәтхелбаян апа, аның авызыннан тартып алган шешәне алъяпкычы астына яшереп.

Пеләш Фәтхинең йөнтәс кулы да шул алъяпкыч астына кереп китә һәм яңак төбенә Фәтхелбаянның кайнар кабартмадай уч төбе килеп төшүгә карамастан, шешәне яулап алуына чиксез куанып, Шәйдулла янәшәсенә менеп баса.

Кара бура ничек чыдагандыр — белмим. Әмма шунысы ачык — әгәр дә ул елганың туры бер җиренә корылган булса, түзмичә чалкан яткан яисә икегә аерылып таралган булыр иде. Инеш таш кыяны сөзгәч юашланып, авылга таба борылган җирдә урынны сайлап ялгышмаганбыз: бар басымны иң элек шул кыя ала. Агып килгән нәрсәләр башта аңа баш иеп, аның тобасында әйләнеп, куәтләрен сүрелдергәч кенә плотинага юнәлә. Гүя арып эштән кайткач, арыш чумары ашаган җиреннән генә караватына янтаеп йокыга түнгән авыл агае. Минем кара исәп белән, язгы бозлар да шунда бер-ике кат әйләнеп, көчләрен югалткач кына буага якынаерга, аның ике шлюзыннан үткәч, кыйгач салынган бүрәнәләрдән шуып кына түбән агарга тиешләр иде.

Бушаганрак арада халыкка күз аткаладым. Хатын-кыз яр читендә өелешеп, ах-вах килә, бала-чаганың кайсысы таш кыя башына ук менеп кунаклаган, кайсысы этләре белән янәшә су буенча йөгерешә, озын саплы җәтмә белән балык сөзә, аталары сөйрәп чыгарган бүрәнәләрне читкә тәгәрәтә. Мин Кәүсәрияне күзлим — ул да, атасы белән туганнары да өстәге дамбаны ера. Ә Ниса, таш баскычның урта бер басмасына утырган да, хәтта ерактан ук ике керәшә оясын хәтерләтеп торган кара күзләрен төтенгә урап, папирос көйрәтә — тимер холыклы хатын да соң, әй! Хәер, ике ел сугышта йөреп, ни генә күрмәгәндер, бәлки нәкъ шушындый тыелгысыз елга булып, аның күз алдында кеше каны аккандыр? Хәзер ул гамьсез, җансыз, әмма сүнмәгән, сүрелмәгән... Иң башында чуклы шәл, шуны җилпеп, менә-менә очып китәр кебек. Ялан баш, кара чәчен толымлап үреп, күкрәгенә салган. Аның кайсы якка очасын мин бик яхшы күзаллыйм.

Ширәмәтов атасы яшереп калдырган асылташны авыл советына тапшырган көнне, дөресрәге, төнне (без аның акчасына — ул без уйлаганнан да галәмәт кыйммәт торган икән! — төзелешкә кирәкле бик күп нәрсә сатып алдык, иң мөһиме: Фордзон тракторы, җиде ат, тегермәнгә электр двигателе, ике пар таш, тик соңгыларын әле алып кайтмаган, ә станция җиһазларын Казаннан безгә ссудага бирделәр; тагын яңа мәктәп салырга уйлыйбыз. Кышка колхоз оештырырга исәп бар, мине председатель булырга үгетли башладылар инде) ...әйе, Ширәмәтов асылташны безгә тапшырган кичне Ниса аны ташлап, бер карчыкка төште, шуның белән аралары суынды...

Ә бер төнне...

Станция мине үзенә йотты диярлек. Ашавым — ашау, эчүем — эчү, йокым йокы булмады диярлек. Иртә таңнан кояш баеганчы, туктаусыз аякта. (Шәһәр ботинкалары эштән чыкты, кирза итек киям, аны да икенчене туздырам инде, әле ярый эш кораллары гына түгел, эш киемнәре дә кайтарттым.) Кайбер көнне яңа сауган сөт кенә эчәм дә йокыга түнәм, ә кайвакытны, бигрәк тә озаклап иртәгә эшлисе эшләрне барлап утыргач яисә Каһир белән кара төнгә хәтле сөйләшеп, хыяллаunion утыргач, йөреп керәм, төзелеш арасында буталам, тау башына менеп китәм.

Шундый кичләрнең берсендә, тиргә батып, башымда кырмыска оясы кебек мыжгып торган саннардан, сүзләрдән, исәпләүләрдән тәмам әлсерәп һәм колак төбендә безелдәгән озынборыннардан алҗып, тышка чыгып киттем. Айлы төн. Чалт аяз. Бөркү. Кайбер өйләргә ут алынган. Инеш ягыннан су, без актарган, казыган үзле балчык, йомычка исләре аңкып килә.

Тугай тобасына җитәрәк, комлы сөзәк ярда ак шәүлә күреп алдым: суны ярып (җаенмени!) берәү ярга чыгып килә икән. Эт чиясе куагы артына постым, карап торам. Чыкты. Ялангач. Ап-ак. Хәер, зәңгәрсу-яшькелт, ай нурында йөзә. Тәнендә эре тамчылар җемелди. Чәчен сыкты да, кулын артка каерып, баш артына төйнәп куйды... Ниса иде ул!

Каршы очраганда аның яныннан тыныч кына узып китә алмый идем. Дулкынланам, Кәүсәрияне уйлаган йөрәгемне үтәли күрәдер шикелле. Кәүсәрия бүтән. Ә Ниса янымнан бу авылда бер хатын да узмаганча үтеп китә, артыннан каерылып карыйсымны, хәтта иярәсе килгәнемне сизә микән? Тыштан сап-салкын калырга тырышсаң да, эчтәге иярле атның тимер чылбыр тышавы чыдамас, шартлап өзелер сыман. Әллә нинди — сихерле иде ул.

Ләкин бик тиздән, Нисаның бу авылны кузгаткан уртак эшкә салкын битарафлыгын тойгач, ул минем өчен өрәк белән бер дәрәҗәдәге чит затка әйләнде. Озакламый, ялгыз очраткан чакларымда күрмәгән дә кебек үтеп китә башладым: тәкәбберлеген куралмый идем. Менә шул чагында ул ,үчләнде ахрысы: Каһирның үземә ачуны китергеч мөнәсәбәтен күрсәткән чакларын да аннан гына күрәм шикелле, Кәүсәрия белән тел ачып йөргән чагым иде — ул да ачык түгел. Күрәсең, Ниса мине яманлап сүз ката, араларны бутарга тырыша иде. Тора-бара аны күрмәмешкә салынудан туктадым, чыгырыннан чыгарырга кирәк иде — башта үчекләп, аннары шаяртып йөрдем. Ул ни әйтергә дә белми, күркә кебек кабарынудан узмый.

Һәм менә бер төнне...

Дөресен танырга кирәк: хатын-кызны бу кадәр дә гүзәл зат итеп күзаллаганым юк иде әле. Хыялланганым бар. Ул гынамы — әйтсәм әйтим инде — Мәскәүдә үзебез йөри торган ашханәдәге бер повар хатын күземә караган килеш ашыма арттырыбрак ит сала башлаган иде. Күзенә багарга кыймыйм, ә итнең чамадан артыграк төшкәненә тәмам нәләндем, ашаган җиренә мал түгел, кеше дә нәләшүчән икән ул. Бер заманны үзенә иярттеп алып китте ул мине. Бар кыюсызлыгымны кием-нәрем белән бергә салдырып ташлады... «Итне юкка гына яратмыйсың икән!» — дип, тук көлүен генә хәтерләп калдым. Яныннан хатын-кызны үземә якын җибәрмәскә дигән төшенке канәгатьсезлек кенә алып кайттым. Ә ашханәдә байтак гомер аш бүлегендә туктамыйча, икенче-микенчеләр тирәсенә ашыктым, ә бер туктагач, ул пилмәнне әүвәлгечә чүмече белән генә тондырмыйча, иренен дога кылгандай кыймылдатып, кашык белән санап кына салды...

Ә Ниса, чыннан да, шайтан кызы белән бер икән. Чәченнән, бөтен тәненнән су ага, авыз эченнән генә ниндидер танго көенә бирелеп, билен дә уйнатып ала.

Аннары ул киенде дә, тугай ярында тезен кочаклап бераз утыргач:

— Аллага тапшырдым! — диде.

Авылга борылыр дип көткән идем, ә ул су буенча аска таба төшеп китте. Шул чак Булганин өендә торган караватъ башындагы чулпы чыңын яңадан ишеткәндәй булдым. «Менә ничек!» Аңлашылды. Тәгаен, ул шунда бара, айлы төндә тәне зәңгәрләнеп янган хатын өчен ике чакрым ара ни тора!

Аның шулай түбән төшеп киткәнен ике-өч тапкыр шәйләдем. Беренче кат шул төнне, калганнарын соңыннан. Теге кызыл күзле кара эттән ничек курыкмый икән? Хәер, ул аңа өрмидер дә! Бәлки эт аны та-

нып, каршы ук чыгып аладыр, хуҗасы үз иткән кешегә юмалану ялгызлыкта яткан этккә тансыктыр. Билгеле, Ниса киләсе төнне (ә бу хакта алар алдан ук сөйләшеп куялардыр һәм ул көнне Булганинга хатынын авылда калдырыр өчен әллә нинди хәйләләр уйлап чыгару кирәкмәстер дә: «номенклатур» кеше ич, кая бармас!), әйе, ул киләсе төнне зирек агачлары артындагы өйнең тәрәзә капкачлары ябык, әмма ишекләре ачык каладыр.

Ниса кыланып:

— Боңсуар, моң вие! Комман ки са ва[1] — дигән буладыр.

Кызык — ут кабызып торалар микән? Минемчә, Булганин аны тышта ук көтеп торып, зур куллары белән күтәреп аладыр да караңгы өйгә алып керәдер. Мондый чакта караваты турысындагы тәрәзә (бигрәк тә айлы төндә) капкачы ачып җибәрелергә тиештер. Ниса чыклы үлән чылаткан аякларын тизрәк җылы юрган астына яшерергә тырышадыр, ә күшеккән озын бармаклары Булганинның йөнтәс күкрәгендә адашып йөридер, ә төн уртасында шундый юл үтеп, ни өчен килгәнлеген икесе дә бик яхшы аңлыйлардыр. Ах, Булганинның ак эчке күлмәге Нисага үзенең тәвәккәл кызыл командирын никадәр сагындырып искә төшергәнен белсә иде бу — үбешкән чакта сакалы белән бөтен битне, бигрәк тә иякне чәнчеп бетергән йөнтәс битле ир!.. Ул, Ниса килгәнче, үзенең күлекә кереп чыга ахрысы. Ә ай нинди, ай, ай!.. Тәрәзә төбендә эт шыңшып, стенаны тырный, аратада ат пошкырып куя, тәнне куырып, ябалак кычкыра, күлдә балык ухылдый һәм төне буе — чикерткәләр чыңы... Аннары Булганин керосин лампасын кабызадыр. Суык карп ите, тозлы уылдык, куырган гөмбә һәм, әлбәттә, дүртпочмаклы утлы шешә.

Этнең Нисаны күралмавы да ихтимал, ул килгәндә ярсып өрүе дә бар. Булганин аны я келәткә бикләп куяр, я өй буенча сузылган чыбыкка чылбырлар. Теле булса, эт биредәге хәлләрне хуҗабикәсенә сөйләп бирер иде микән? Хәер, хуҗабикә үзенә генә таныш билгеләрдән бу хуторга читләр иянләшкәнен сизенер. «Минем чәчем мондый кара һәм озын түгел, озынлыгының гомумән әһәмияте юк... әйе, минем чәчем мендәр астыннан килеп чыккан бу чәч шикелле кара түгел»,— дип уйлыйдыр ул, ләкин иренә әйтергә кыймыйдыр. Бердән, графиня горурлыгы ирек бирмәс, икенчедән... Хәер, нинди графиня, я хода! Барысын да ниндидер томан йотты, әле дә ярый теге чакны Ростовта, сорау алган һәм тентегән булып, үзен чишендерә башлаган өч матрос янына полкның разведка начальнигы иптәш Ярослав Борисович Булганин килеп керде. Яхшымы, яманмы — ир, яхшы заманалар да килеп җитәр, пресвятая богородица рәхмәтеннән генә ташламасын, Ярослав Борисович бу якларга Новороссийскида очраткан татар баеның яшергән асылташын тапканчы гына. (Нибарысы бер асылташ, ләкин нинди бит!) Хәер, алдалавы да бардыр: аның өчен иң мөһиме — бераз кеше күзеннән качыбрак тору. Яхшы заманнар җиткәнче. Ә биредә алай ук начар да түгел сыман. Табигать. Завалишиннарның, Макашиннарның имениеләре — яп-якын. Ах, әйе, әүвәлге, инде берни калмаган имениеләре... Завалишин? Кайсы Завалишин? Таныш исем. Ә! Декабрист Завалишин!..

Ә бер төнне хуҗабикә кадерле ире Ярослав Борисовичны чит хатын белән тотар. Төн уртасында шәп-шәрә калышып, күлдә су коенган чакларына килеп төшәр. Ярослав Борисович соңыннан ярсыган һәм чәчләре тузгыган, Трезорны кочаклап елаган графиняга ул татар ха-

---

[1] Хәерле кич, кадерлем. Эшләр ничек? (франц.)

гынын теге татар бае малаеның хатыны дияр, тик инде ул «малайның» ике ай элек асылташны советларга тапшыруын Ярослав Борисович сөйләп тормас: нигә чүп белән хатынның кәефен төшерергә.

...Аннары Булганин торып тозлы кыяр суы эчәр, аның сакалына ябышып калган яшел әнисне күреп, Нисаның күңеле болганыр. («Туктале, нинди күңел болгану ди ул? Алла сакласын!.. Алай да кемнән булыр?» — дип уйлап куяр Ниса Тарханова.) Ә тегесе юрганны кайтарып, Нисаның шома эченә салкын чулпы ыргытыр: «Артыңнан җыеп йөр, дура!» Аннары Ниса чыклы үлән ерып, су буйлата авылга менеп китәр, ә Ярослав Борисович, баскычка утырып, алтын язулы папиросын тартырга керешер...

Морзалар паркына төшә торган, яртылаш туфракка күмелгән һәм тузганак, чирәм, бака үләне каплап бетерә язган баскычка утырып, Ниса ни уйлый икән?

Ширәмәтов Нисаның үзеннән китканенә кайгырмады ахрысы. Ул асылташ белән бергә аны да югалтасын бик яхшы аңлады. Өйләнүгә, шәһәргә китәбез дигәч кенә чыккан иде ләбаса. Әйе, байлыклары байтак гомер кайгы-хәсрәт күрми яшәргә житәрлек иде. Әмма Ширәмәтов башкадан курыкты: иртәме-соңмы шәһәрдә сагыш басачак иде, аннары карта, иске дуслар, хатын-кыз... Әйе, асылташның гомере кыска иде. Штабс-капитан аны тынычлыкта калдырырмы соң? Дөрес, аның кулында да Булганинны бәйдә тотарлык тышау бар: Рамазанов. Теге төнне ул Рамазанов бүлмәсендәге камин төннегендәге яшерен кирпеч астыннан асылташны алып яткан мәлдә Ширәмәтовның нишләгәнен тәрәзә каршындагы агач ябалдашыннан Булганин карап тормаган һәм шулчакны Рамазанов кайтып кермәгән булса иде дә бит.

«Хәерле кич, Юныс Йосыпович!»

«Мине көтәсезмени?»

«Сүз бар иде...»

Шулчак ишектән Булганин килеп керде:

«Сүз? Менә аларга безнең сүз!» — Ул, киң селтәнеп, Рамазановны идәнгә сугып екты. Рамазанов, револьверын чыгарса да, атмады. Булганин аңа ташланды. Әүмәкләшкәндә ялгыш атылган пуля Булганинның яңагын кисеп үтте, тик ул тартып алган револьверны Рамазановның чигәсенә терәп өлгергән иде инде. Ату тавышы яңгырады...

«Бүлеш, Ширәмәтов!»

«Мине каян беләсез?»

«Контрразведка, поручик!»

«Бүлешер нәрсәм юк, тайник буш».

«Артыңнан биш ай күзәтәм, поручик. Иртәме-соңмы син бирегә керергә тиеш идең, сәүдәгәр атаңның кабинетына».

«Ул барысын да үзе алып киткән».

«Юк, поручик: юлда әллә талыйлар, әллә нәрсә,— кире борылып кайту бик ихтимал, ә ул чагында иң затлы нәрсәнең монда калып торуы мәгъкуль... Аннары соң... картның поручик улы да бар бит, аңа да ход калдырырга кирәк, я?»

«Логика бар, тик...»

Алар янына ату тавышын ишеткән Ниса килеп керә. Ул — избачитальняда мөдир, бая гына «Шәрык хатын-кызлары һәм пәрәнҗә» дигән темага лекция укыды. Рамазанов — үлгән... Ширәмәтов Нисаны сөйрәп алып чыгып китә, дөресен сөйләргә хәленнән килми. Ә Булганин үзен-үзе аткан кешенең ни рәвешле ятарга тиешлеген бик яхшы белә...

Хәтеремә нинди эзлеклелектә килсә, шулай сөйлим. Моны ташуның икенче көнендә — Булганинның үлемен ишеткәч — Ширәматов бәян кылды.

«Ник элегрәк әйтмәдең?»

«Һәркемгә үз өлеше, Ислам Имамович. Һәркем үзе өчен җавап бирә».

«Буталчык».

«Безне революция бутады».

Борым хәлләре бөтен авылны тетрәндерде, тик һәркем станция һәм кара буралы плотинаның исән калуына шатлана, горур, сөйләрлек нәрсә күп, кооператив кибете төбендә дә, өйләрдә дә көне буена, аннан төнгә һәм таңга хәтле тынмадылар. Шатлык хакына хатыннары да тыярга базмады. Өйләр гөлт итеп тора, Ильич уты астында нигә утырмаска — гомерләре буена көттеләр, мать честна! Алар да төшеп калганнардан түгел икән ләбаса, сукыр лампа астында күз чекрәйтеп утырмыйлар, гуляй!.. «Открой шибер, проверь тягу, кода!» — «Ә Сафин молодец, ут җегет!» — «Ә иптәш Зәйнушин?!» — «Ә Сафин?! Сәнәкчеләрнең артына карболканы шәп кыстырды да соң!» — «Ә оборот-минут?» — «Монда хикмәт — стансы. Үзебезнең стансы! Рәсәй зур, ә без бәләкәй идек, үз каныбызны үзебез эчеп тик ятканбыз шунда». — «Ә хәзер без — не трогай, әйе!»

Әйе, сәнәкчеләр.

Башта алар безне куркуга салдылар, ләкин үзләренең дә котлары үкчәләренә төште. Алай да «сәнәкчеләр» дигән кара тамганы алар муеннарына үз ирекләре белән такты, байтагы курку белән генә калса да, кайберәүләренә бу тирәләр белән саубуллашырга туры килде. «Каждая вошь сама себе и вождь» булса да, кайсыдыр алдан барырга, беренче тешләргә мәҗбүр, һәм алар, ирексездән, «вождь» дип аталды, ә һәммә «вошь» үз ярыгына посты.

Мин үзем күргәнне генә сөйлим, бары тик үзем кичергәнне. Бездә укытучы кызларны көчләү, совет биналарын ут төртеп яндыру, активистларны үтерү булмады. Спирт заводы директоры Ярослав Борисович Булганинны искә алмаганда. Әмма эткә — эт үлеме.

Хәер, кем белә: шул хәвефле кичне станциягә үтеп керә алсалар, сәнәкчеләр аны тәгаен җимерергә, бәлки яндырырга ук тотынырлар иде, ә сакларга, якларга ташлаганнарны... Кем белә: һәркайсында дип әйтерлек сәнәк, чалгы, балта я читән казыгы, ә «Кара күмер» кушаматлы үгезнең киң маңгаен чәрдәкләгән кургашынның минем күкрәгемне теткәләве ихтимал түгел идемени? Яки Каһир Сафинның бавырын. Янсә Кәүсәриянең гөнаһсыз йөрәген... Ничек кенә ихтимал иде әле! Ләкин, күрәсең, тарихка безнең үлемебезнең хаҗәте чыкмаган, кемдер безгә ул көнне янаган пуляны читкә юнәлдергән. Кем ул? Яки нәрсә? Язмышмы? Әмма станция — ул язмыш түгел, ул — без үзебез идек! Юк, ул безнең идеябез һәм ышанычыбыз иде. Без йөрәкләребезгә төбәлгән пуляны чынга ашкан идеябез яктысы белән сукырайттык. Ә үзебезгә атасы кешенең күзен ачтык.

Болай булды.

Кайнап торган тобадан аерылып, плотинага таба сәер бер нәрсә ажгырып якыная башлады. Аны су агызган күпер басмасы этеп килә. Шул рәвешчә плотинага килеп керсәләр, ай ярым буралган бураның мизгел эчендә гаип булуы шиксез. Бәлки тоелган гынадыр, бәлки кара бура бирешмәс тә иде әле?..

Плотинага таба өстәге авылларның берсендә киселеп, яр буена ташланган мәчет манарасы якынаеп килә иде. Манара очы су яра, күпер басмасын сал шикелле тартып килә.

— Вәссәлам буа!

— Җә тишә, җә ишә — тучны!

— Эчәгесен агыза хәзер.

— Шәйдулла, Фәтхи! Иптәш Зәйнушин! Таегыз — миегезне чәчә!

Шәйдулла белән Фәтхи ярга йөгереп чыктылар. Берсенең чабатасы төшеп калган, икенчесенең ыштаны кендектән умырткага хәтле аерылган. Һәр ботында бер балак, ул аларны бөрмәсе буенча чаршау шикелле җыерып куя: алдан җыера — арттан ачыла, арттан җыера — алдан ачыла.

Мин дә плотинадан йөгереп килеп, станциягә кердем дә, сүс баулар сөйрәп чыктым, ирләр чуалган төргәкне сүтеп бетерер-бетермәс үк, очларын авызыма кабып, суга ташландым, ике күнитегем ике якка очып, юеш чолгауларым гына таралып калды. Кәүсәрия килгән икән, кулларын күкрәгенә кушырып, бөрешкәнен генә күреп калдым. Агым көчле, алай да өлгердем: бауны манараның үзәк нарат баганасына бәйләдем дә пошкыра-пошкыра:

— Тартыгыз! — дип кычкырдым.

Бауны тарттылар, үземне кырт борылган манара чак кына күпер басмасына китереп кысмады. Икенче бау белән күперне арканладым. Мин чыкканда, манара, үлгән чуртан сыман, үги ана яфраклы сай суда сузылып ята иде. (Соңыннан ул шунда таралып череде — язгыннан куркып, мәчет манарасын хәтта тол карчыклар да утын итеп ягарга теләмәде.)

Авыл күгенә, кеше башына төшкән бәхетсез мәхәббәт шикелле, болытлар тавы ишелеп төште. Хатын-кызлар, эгузеләрен әйтешеп, өйләренә таралышты, бер-ике ир-ат тегермән салырга кайтарылган, әле каезланмаган һәм тәмәке төпчекләредәй тәртипсез таралып яткан бүрәнәләр арасыннан бәрәңге бакчаларына таба юл алмакчы иде — Каһир юлларына аркылы төште. Җил чыкты, плотинадан шарлап аккан суны тузганак урынына очырта башлады. Өермә ике өйнең салам түбәсен хатыннар итәге кебек кенә кайтарып салды, корымлы моржалары гына тырпаешып калды. Тауга чартлатып коры яшен бәрде, кыядан ташлар ишелеп төште. Болытлар битне тырнап узсалар да, янгыр яумады, күрәсең, өстә идән мунчаласы кебек борыла-борыла сыгылып, теткәләнәп, коп-коры булып калгандыр.

Урам башында «Оборот-минут» күренде: җәяү генә йөгерә, артын камчылап килгән чабата бавына буталып, ике тапкыр егылды, баш очында кәгазь болгый. Чабатасын баганаларга сузган тимер чыбык калдыкларыннан үрде ул: «Мәңгелек һәм ашарга да сорамый!» Каһир янына килеп җиткәндә генә, кәгазе кулыннан ычкынып, яфрак шикелле очып китте, артыннан ташланган иде дә, Каһир чабата бавына басып туктатты:

— Кая шуышасың?

— Тилехренграм.

— Атың кая?

— «Кара күмер» аның эчен тишеп агызды, иблис!

— Ычкынганмыни?

— Фордзонны сөзеп аударды да магнитосына басып, чәпрә итте. Чакматаш Дәмине койрыгына, Тәртә Гәптрафигы мөгезенә барып җабышканые — тыялмадылар. Эче киткән булган икән, шүре җибәрде. Дәмин бака төсле ямь-яшел, Гәптрафикның өч бармагын таптап издe...

— Яп юшкәнне, житте!.. Кәгазьдә нәрсә иде?

— Тилехренграм...

— Ни язылган?

— Борым урыслары менеп килә дип.

— Ни калган?

— Тилехоннан әзерләнеп торырга диделәр, белмим. Сәнәкләр күтәргәннәр, балта... Ярдәмгәдер инде, безгә булышырга... Прлетәреләр, соединәечь!.. Сыйнфый туганлык, гупчым. Алла да юк, бог та! Попларны сөннәткә утыртырга, муллаларны чукындырырга — текущий момент шундый! Җөрмәсеннәр дөнья бутап... Прухыр ахири менә микән? Атна кич кенә карт әтәчкә алмашып, бер чирек самагунын апкайтканыем — карачин булып чыкты, зимагур!.. Икенче көнне йокыдан торып тышка чыксам, карт әтәчебез күрше тавыгын куып йөри... Прухырның Праскувьясы белән минем абыстай арасында шундый дагавар икән, мутлар... Прухыр да менсә, кунакка алырыем, атны чалдым бит... Ну, киттем, иптәш Сафин. Прухыр знакум килеп җиткәнче, атның бавырын гына булса да куырып өлгертергә кирәк.

Кычкырып көлә калдык. Нинди руслар килә, кая килә, нигә? Бәлки безгә булышыргадыр, әллә станцияне ачу тантанасына микән? Кая монда тантана!

Су тынычлана, төшә башлады, чүп-чардан арынды. Кояш баеган икән инде. Җил дә тынды.

Шунда сәер тавышлар ишеттек. Ир-ат кайсыдыр алып төшкән чәйнектән әчегән бал эчеп, алма, помидор капкалап утыра иде — алар да башларын күтәрде. Авыл ягында ул-бу юк.

Ширәмәтов аска — тугай ягына төртеп күрсәтте:

— Карагыз әле! Әнә!

Тугай борылышыннан иске тун кебек сәләмә, тузгыган халык төркеме килеп чыкты.

— Дулыйлар түгелме соң?

— Ат карагы тотканнар диярсең!

— Әллә безнең көтүче малайлар берәр ярамаган эш кылганмы?!

Төркем әле кысылып йомыла, әле таралып җәелә. Мин аны хәзер карт керпе белән тиңлисем килә, ул вакытта исә шом басты, ниндидер яманлык сизендем, йөрәгем сулкылдап тибә башлады. Каһирга күтәрелеп карадым, ул агарып килгән, муен тамырлары бүртеп чыккан, күзе сөзеп, килүчеләрнең йөзләренә түгел, ә аларны үтәли тишеп, каядыр артка карый, туңгандагы кебек, иңбашы калтырана. Хәтеремдә кулы белән чак кына сизелерлек хәрәкәт ясавы уелып калган: баш бармаклары буынтыклары агарганчы йодрык булып йомарланган бүтән бармакларына ятып кысылды — үз уендагы пулемет гашеткасына басуына шикләнмәдем. Димәк, хәл яман иде булса кирәк.

Килүчеләрнең кыяфәтендә иман заты аз иде шул. Әйе, нәкъ керпе: баш очларында сәнәкләр, чалгылар тырпаешкан.

Каһир белән минем тирәгә ир-ат җыелыша башлады, кайберәүләре багорларына үрелде, ирексездән без дә алга таба атлый идек бугай инде. Әмма без арыган, хәлдән тайган, бер-беребезгә карашып алдык та маңгаебызга бәреп чыккан салкын тирне сөрттек. Бер Каһир гына үтә тыныч күренә иде.

Ак атына атланып, аргы якка милиционер килеп чыкты — Идрис Ярмиев. Аты шарламалы плотинага керергә курыкты, ул аны ташкынга каулап кертте дә безнең якка йөзеп чыкты.

— Бунт! — дип кычкырды ул астагы төркемгә ишарәләп. Өстеннән шарлап су ага.— Сәнәкчеләр! — Килеп җитте; сулышы капкан, авызы-борыны кара кан, яланбаш, башындагы ярага тузан ябышып каткан.— Берьюлы өч авылда. Иң хәтәре — Шүмкәдә, Йөзендә, Үтереш... Станцаны сакларга! — Кобурасы корсагы турында чайкала, буш.— Кулачье эше. Өлгерми калдык... Булганин, кабәхәт!.. Өлгермәдем-м!

Каһир, йөгереп барып, атының ияренә аскан портфеленнән револьверын алып килде, Ярмиевкә сузды.

— Үзең,— диде Идрис абый.— Берәр нәрсә чыкса — рөхсәт.

Безнең арага Кәүсәрия килеп керде. Зәңгәр күлмәктән, бите янып тора. Безнең ертык, юеш, кылка киемнәребез арасында ул курчак кебек. Идрис абыйга карап алгач, югалып торды да ак чүпрәк тасмалар җилфердәтеп килде.

— Бәйлик, Идрис абый!

— Булышма, Кәүсәрия! Мин ичмасам исән... Шүмкәдә милиция начальнигын үтергәннәр. Анда мәхшәр!

— Идрис абый, бәйлик.

— Җә инде, тилчә булдың бер...

Безнең тирәдәге кешеләр кайсы-кая таралышты. Аннары тагын укмаштылар. Бу юлы аларның баш очындагы багорлар куерак иде инде.

Борымныкылар адымнарын сүрелдерде. Аның каравы тавышлары көчәйде. Әмма ни кычкырганнарын аерырлык түгел.

— Ни кирәк аларга? — дип сорады Кәүсәрия миннән.

— Атаң башы түгел,— диде Каһир теш арасыннан.— Карга күзен карга чукымас.

Кәүсәрия беләгемә ябышты, тирләгән кайнар кулын кыстым. Ирләр арасында Азамат картның таза уллары бар иде, башлары калкып тора. Бәдәмша ау мылтыгы тоткан.

Өйләрдән кешеләр атылышып чыкты. Кайсылары бабаларыннан калган турылыклы крестьян кораллары — сәнәк-чалгылар тоткан, кайсысы чүпрәккә аскан икешәр кадаклы түгәрәк герләрен йомарлый.

— Хәрби обстановкада иң кирәге — шабер! — дип сөйләнә Шәйдулла. Шаберның нәрсә икәнен сүзсез аңлатып, Фәтхинең артына шапылдатып ала.— Оторви да брось — асларына җибәртәбез!

— Бәлки лименация ясаргадыр? — дип сорый миннән Фәтхи абый.

— Ни ул?

— Станцияне җибәрәбез, прожекторларны төбәп куябыз да — кинәнеп дөмбәслибез!

— Аллага тапшырдык, җәмәгать! — ди берсе учына төкереп.— Мәфтуханың ашы суынмас борын, кикрикләрен шиңдерик.

— Үзеңнең эштиеңне суытмасыннар!

Без бер карыш та алга атламадык, тегеләр генә якынайды. Ара утыз-кырык сажиннар гына калып бара. Көтәбез.

«Оборот-минут» Сөләйман күренде — аягы тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк. Ә артыннан, юеш җирне сулышы белән көйдереп, «Кара күмер» томырылып килә. Мөгезендә «Оборот-минут»ның каеш табанлы «мәңгелек» чабатасы, шуның ат кылыннан ишкән бавына сөртенеп, инде үгез абына.

Сөләйманга тегеләр якынрак иде, ул сыңар чабатасына ябышкан пычракны өстерәп, туп-туры Борымлыларга таба элдерә. Менә хәзер сәнәкләренә эләчәкләр дип, тын да алмый көтәбез, кычкырабыз, ул колагына да элми, безне хуплап тора дип белде ахрысы.

— Әй! Дорогу-у! — дип кычкырды «Оборот-минут». Үгез аны куып житте, ләкин ул җиргә ятып калды, үгез кире борылган арада тагын торып йөгерде.

Без генә түгел, борымнык лар да «Оборот-минут»ка кычкырырга, киңәш бирергә тотынды инде.

— Стой — не шевелись! Упал — пропал!

— Тылыңны сакла, тылыңны!

— Тю-тю-тю!..

— Прухыр Савате-е-еч! — дип кычкырды Сөләйман тегеләр төркеменә житкәндә.

— Чаво тябе?

— Здаруф, лысый мозга!
— Салямалейкум, шайтан бесхвостый!
Сөләйман төркемгә бәреп керде, аңа аерылып юл бирделәр, артыннан юл ябыла барды. Төркемне ерып үтеп, тагын унбиш адымнар буш лыкта йөгергәч, кире борылды. Без дә егылып көләбез, тегеләр дә.
«Кара күмер» ике арада потлы тояклары белән җир актара, үкерүенә станция тәрәзәләре зыңлый.
— Прухыр, где ты, аднаполчан?
— Тута, Сулейман!
— Айда ко мне — кунак будешь!
— Чего хай поднял? Вот счас устроим вам кунак! — ди берсе.
— Закрой кляп! — дип кычкыра Прохор дигәне аңа каршы.— Ето ж кореш мой закодычный. Мы с им казакам усы накручивали!.. Вали сюда, Сулейман! Разомкни перед моим корешом брюхи червивые!
Сөләйман белән Прохор кочаклашып күрештеләр ахрысы, алар турысында хуплау авазлары яңгырады.
— Кумышка есть? Гулять будем!
— Сперва нам вашу станцию сжечь надоть под едреный корень.
— Хычаму стансы жечь, дурак твоя башка?
— Чтоб глаза не мозолила, ахири.
— Хычаму стансы, аднаполчан? Нада... энта самая... глисты жечь в пузе самагуным.
— Кончай брататься с курвой басурманской?!
— Не чихай, Хфедорыч, зубы отхаркаешь, понял? Ето ж Сулейманка — первая шашка в кавалерии эркака-а!
Без инде көләргә дә, еларга да белмибез. Каһир «Оборот-минут»-ның шәхси танышлыгын файдаланып калыр өчен әле үгезгә, әле кара төркемгә карый-карый алга атлады.
— Барма! — дип кычкырды Идрис абый ирен читендә күренгән яңа канны җиңе белән сөртеп.— Пычранма контраларның йонын уңайга сыйпап! Аларга бер генә дару — Себер!
— Сәнәккә — сәнәк, балтага — балта! — дип кычкырды Бәдәмша абзый.
— Нинди контра, нинди контра? Ыштансыз чабаталар, тавык мие эчкән нәрсәләр. Яшәүләре тәмуг, өметләре җәннәт,— диде Каһир.
Каһирга иярмәкче идем, әмма кире куды:
— Станцияне сакла,— диде ул. Күзләре арыган, тавышы карлыккан, ә йөзенә кан йөгергән иде инде, ә сулышы иркен. Елмаеп күз кысып куйды.— Саклангнны алла саклаган, Ислам Имамович!
Караңгылыктан да каралыбрак торган үз төркемебезгә, йолдыз кебек агарып торган Кәүсәриягә таба чигендем һәм кинәт, күңелемнең бөтен барлыгы, гомеремнең үткәне һәм киләчәге белән ташып, басманы дөбердәтә-дөбердәтә станциягә кереп киттем, маховикны тотып торган юан чылбырлы корыч ыргакны ычкындырдым да валны күтәрттем: пышылдап кына, иркен сулап җибәргәндәй, киң каеш әйләнә башлады, динамо нечкәргәннән-нечкәрә барган сызгыру белән әйләнергә керешге. Киредән ишек катына — реостат һәм приборлар щитына барып, чынаяк тоткалы рубильникны аска тартып төшердем. Яшькелт очкын балкып китте — һәм авылда беренче тапкыр үзебезнең йөрәкләребездән тамчылап саркып чыккан хыял кошының йолдызларны сискәндергән иксез-чиксез киң һәм якты канаты җәелеп китте. Электр балкыды. Электр уты.
Дөньяны «ура!» авазы басар дип көткән идем — ату тавышы яңгырады.
Үз-үземне белештермәстән, тышка атылып чыктым: станциянең дүрт почмагыннан дүрт якка һәм югарыга — күккә (биш нур — биш почмаклы йолдыз) биш нур сузылган, бер якта чагылган күзләрен җиң-

нәрсе белән каплаган безнең төркем — төзүчеләр, икенче якта — җимерергә яки яндырырга дип килгән, ләкин инде моны оныткан кешеләр, алар уртасында — аякларын җәеп яткан «Кара күмер» һәм кочаклашкан Каһир белән Прохор. Прохор кулында обрез, ул ут кабынгач, шашып Каһирга ташланган үгезне атып еккан икән.

Ике якта — чабаталы ике төркем, аяк асларына коелышкан сәнәк, чалгы, балта, килсапларны, багорларны таптап, кешеләр бер-берсенә якыная, бая гына коточкыч ерак булган ара тарайганнан-тарая. Әйтерсең лә бер-берсеннән башка яши алмаган ике тегермән ташы үткән, хәзерге һәм киләчәк заманнарны кысып, безнең инде беркайчан да буш булмаячак өмет капчыкларыбызны чинга ашкан хыял оны белән тутыра. Кәүсәрия көлә-көлә Идрис абыйның канлы битен сөртә, ярасын бәйли, Идрис абый исә елый-елый аның чәчен сыйпый.

Мине бер генә мәлгә онытып тордылар, миңа беркем карамады. Бераз үпкәләдем дә бугай. Үземне чөя башларлар дип көткән идем. Юк, иң әүвәл тегеләр төркеме «Оборот-минут» Сөләйманны, безнең төркем Прохорны чөйде. Аннары соң гына — Каһир белән мине.

Өйләрнең ишекләре тупсаларыннан каерылып ачылды, урам һәм тыкрыклардан халык инешләре агып, безнең станция уты булып җәйрәгән дәрьяга килеп кушылды.

«Оборот-минут»тан да гарьрәк тузан туздырып килгән машинаны без тып-тын калган көенчә каршы алдык. Идрис Ярмиевнең куллары калтырый башлавына игътибар иттем, Каһирның очкын чәчеп торган күзе кысылып килде, мин кинәт бөтен күкрәгемне тутырган кызгану хисе белән халыктан бер башка калку Прохорга карап алдым. Машинада милиция килгән дип белдек, иң әүвәл Прохорны алып китәселәренә шикләнмәдем шикелле, мин аны шуңа күрә кызгандым. Ахыр килеп, аларның гаебе барлыкка бар, әмма тимичә, тыныч кына яшәүләренә ирек куйсаң, алар бүген үзләре кылган иң оятлы фигыльне кабатлау түгел, искә алырга да читенсенерләр иде инде.

Халык, урталай ярылып, машинага юл бирде, аның «Кара күмер» күзе инше калкып торган фараларыннан сирпелгән ике ут көлтәсе минем һәм Каһирның өстенә ябырылды. Бер мәлгә сукыраеп калдым, кара ишекнең ялтырап ачылуын, аннан ак фуражкалы бер кеше чыгуын күземне каплаган учымның бармак араларыннан гына күреп тордым. Һәм ул, халыкка борылып, нәкъ Прохор Саватеевич каршында басып калды! Болай да сәерсенеп калган халыкны тынычландырырга теләгәндәй, башта кулларын югары күтәрде, аннары... иң башлап Прохор белән кул биреп күреште. Юк, ул милиционер түгел иде. Дөресрәге, милиционер гына түгел. Ә югарырак дәрәҗәле булса? Без белмәгән берәр катгый тикшерү органыннан түгелме? Кемнәндер нәрсәдер сорашты, аңа җавап бирделәр ахрысы, кисәк кенә борылды да башын янтайтып һәм кулын козырегына куйган килеш (безнең яктан да аңа ут көлтәсе төбәлгән иң) бу тарафка карады. Артында торган чалыш йөзле Гайсә Зәйналовны танып алдым, аннары — аны. Әйе, бу мизгелдә саллы адымнар белән үзебезгә каршы атлаучы кешенең халык комиссары икәнен күзне сукырайтырлык яктылыкта гына түгел, җәһәннәм караңгылыгында да таныр идем.

— Исәнме, энекәш! — диде ул гөлдерек, мул тавышы белән коендырып.

Алга атлап куйдым, әйтерсең, егылам дигәндә каршымдагы юан һәм нык агачка тотынып калырга теләгәнмен.

— Исәнмесез! — дидем мин аның җитди йөзенә карап.

— Менә хәзер сөйләшергә була! — диде ул, Каһир белән күрешкәндә дә минем белән сөйләшүен дәвам итеп.

Каһирны нарком белән таныштырдым, алар тагын бер кат кул кысыштылар.

Нарком белән бергә райкомнан да килгәннәр булып чыкты.

— Әйттем бит мин! — диде нарком.— Исәндәме, Ислам Имамович! «Ильич лампалары кабыза алсак, бөтен крестьян коммунизм өчен жанын-тәнен кызганмыйча утка керәчәк» дигәнемне онытмадыңмы әле? Фетнә булып, фетнә сүрелгән! — Ул, фуражкасын салып, маңгаен сөртте. Бөтен өсте-башы — ак чалбар, костюмы — пычранып беткәнен күреп алдым. Карашымны тоеп, кул гына селекте: — Яңгыр астында калдык. Яңгыр гынамы?! Зилзилә! Батып яттык. Әй!.. Ә халык, халык! Ышанган лабаса, ышанган! Хәер, үз кулы белән үзе корганга кем ышанмасын?..

Аннары ул, фуражкасын йомарлап тотып, халыкка болай диде:

— Иптәшләр!.. Туганнар һәм кардәшләр!.. Без сезнең тарафка көн батышы ягыннан чыгып киттек, кояшка каршы. Инде менә килә-килә төн житте, кояш безнең артыбызда баеды. Аның көн чыгышы ягыннан яңадан тулып чыгарына кадәр җирне төн басты, кешеләр караңгылыкта калды. Ләкин сез түгел, иптәшләр! Сезнең хәзер үз кояшыгыз бар! Үз иманыгыз, үз гамегез — электр станциягез. Сезнең ярлылык һәм газап белән тулы күкрәкләрегез, өмет белән тулы йөрәкләрегез бар иде. Сез шул йөрәкләрегезнең барысын да бергә җыйдыгыз да бөтен авылыгыз өстенә яңа кояш итеп балкыттыгыз. Караңгы күкрәкләрегез эчендә һәркайсыгызның үзе өчен генә типкән йөрәгендә хәзер беркайчан да баемаслык Ильич кояшы балкый. Сезнең станциягезнең уты күзләрегезне генә ачмыйча, йөрәкләрегезне дә җылытуын мин беләм. Мин шулай ук күктәге йолдызларның чаткысы безгә, безнең күзләребезгә кадәр килеп җиткәнче миллионнарча, миллиардларча елларга сузылган юл үтүен дә беләм. Сез бүген кабызган җир йолдызлары — Ильич лампалары да дистәләрчә, йөзләрчә еллардан соң шушы җылы туфракта туачак балаларыгызның, оныкларыгызның күзенә нур бирсен, йөрәкләрен җылытсын, каннарына — гайрәт, аңнарына изге акыл биреп торсын. Дөрес, алар үз электр станцияләрен чиксез дәрьяларны иңләп корыр, үзләренең киләчәкләрен яктыртыр өчен алар диңгезләрне эшкә җигәр, яшеннәрне иярләр, кояшны буйсындырыр, ләкин алар язмышының чыбык очына бүген сезнең шушы станциягез тогы йөгерде. Сез аларга үзегез кабызган Ильич утлары белән бергә халкыбызның йөрәгеннән ургып чыккан канын, әманәтен, иманын тапшырдыгыз. Котлыйм сезне, иптәшләр!.. Котлыйм сезне, кардәшләрем, туганнарым! Бәхетле булыгыз!.. Бәхетле бул, энекәш! — диде нарком һәм, иңемә кулын куеп, йөземә карап торгач, мине кочаклап алды. Мин аны тагын танымас булдым. Бу юлы күземне каршы ут сукырайтмыйча, күз яшем әлҗе-мәлҗеләткән иде инде.— Рәхмәт сиңа, Ислам Имамович, партия һәм Татарстан республикасы исеменнән зур рәхмәт... Рәхмәт сезгә, иптәшләр,— диде ул тагын халыкка борылып,— партия һәм Татарстан хөкүмәте исеменнән бик күп рәхмәт яусын сезгә!

Елганың болганчык суы кайдадыр якты кояшлар астында яткан зәңгәр диңгез һәм океаннарга таба инде торган саен тына һәм тона барып ага да да ага иде. Күк йөзе дөм караңгы, бары тик җирдәге утларга күзләре камашкандай, мең еллыкларның аргы ягыннан йолдызлар гына җемелдәшә. Станция каузында су ургып шаулый, аның тыгыз көче, меңнәрчә елларны кыл урталай бүлеп, чиксезлекнең математикадагы билгесе сыман, авыш сигезле булып бөтерелгән шкиф каешын әйләндереп ята иде.

Тарихны бөек шәхесләр ясый. Ә мин менә хәзер тарихның чын иҗатчылары «мәңгелек чабата» турында хыялланган, нәкъ кирәк минутында тарих күчәренә, үзенең кан тибеше, пульсы белән үлчәп, тиешле «оборот» бирә белгән Сөләйманнар, Прохорлар икәнен беләм, бу хакта теләсә кайсы парламент трибунасына менеп сөйли алам һәм үземә кул чабучыларның ачык, җитди, теләктәш йөзләрен күрәм.

Мин тегермәнгә якынрак килеп бастым. Ярты гасыр буена меңнәрчә кешеләрнең аяк астында он белән бер-берсенә чартлап ябышкан тегермән идәне такталарын кубаруны бу минутта әллә кайчан яшәгән кеше каберенең ләхет такталарын ачу кебек итеп күзалладым. Әллә кайчан яшәгән ул кеше — мин үзем, һәм аның каберен, археолог булып, хәтерем ачып ятамы әллә? Йөрәккә тиеп һәм үзәккә үтеп, күгәргән кадаклар суырыла, кадактан гайре бер-берсенә әллә ничә җирдән буй чөйләр белән дә куылган идән такталары ачыла барган саен, тегермәнне уратып алган кешеләр бөҗрасы бөтенләй бөрешеп бетте, әйтерсең лә идән астыннан чыгачак ниндидер гайре табигый җан иясе һөҗүмен кире кагарга әзерләнеп калдылар!

Түземем бетеп, бүтәннәрдән кысылып чыгып, читтәрәк сөйләшеп торган ике ир-атка дәшеп:

— Ни бар анда? — дип сорадым.

— Күселәр,— дип җавап бирде озынча няклесе.

— Шуларның чыкканын көтеп торасызмыни?

— Алтын чыкканынмы әллә? — диде аларның сипкелле йөзлесе.

— Алтын булмаса да, дүрт почмакта дүрт талир тәңкә бар,— дидем.

Озынча иякле «и, мескен!» дигән кыяфәт белән аралы зур тешләрен ыржайтып елмаеп җибәрде:

— Почмак саен берәр олимпийский тәңкә ятсае ул! Тагын бер тәңкә юнәтеп өстәсәң, Шәмсия егерме биш тиен әҗәткә генә җибәрер ие дә бит...

— Кем ул Шәмсия? — дип сорадым.

Әңгәмәдәшем мәсхәрәле караш ташлады да таянып торган сәнәген җиргә кадады.

— Тьфү,— диде ул төкермичә, сүз белән генә.— Кибетче Шәмсия, кем булсын инде тагын. Шул җирән биянең каршына бармас өчен бер ярты бирер иең дә... үзебездән артмый шул, бирән тамак. Әме, Шәмгун?

Шәмгун дигәне — шул сипкелле йөзле, тиресе купшакланып торган кызыл борынына бер пыяласы чәрдәкләнеп ярылган күзлек кигән какча ир — муенын тартып куйды.

— Әйтәм җирле кыяр түтәлен таптаганың өчен ун тәңкә ыштраф түләтте,— диде ул күкрәгән кашып.

— Мин аңа папирос кабызырга шырпы сорап кына кердем ич!

— Кабызган утыңны хатының ничә атна сүндереп йөрде әле, Надир абый?

— Кеше барында тартәгә тибенмә, җәме? Югыйсә, минем дә тышау ычкынгалый, беләсең!..

— Ул күселәрне нишләтәсез соң?

Озынча иякле авызын күккә чөеп көлеп җибәрде, йөзе кешнәгән ат башын хәтерләтеп куйды.

— Каклыйбыз, әме, Шәмгун...

Үз соравыма үзем җавап бирергә калды. Билгеле, алар тегермән идәне астындагы күселәрне үтерергә җыелышканнар бугай. Менә бүген, хәзер. Бөтенесе берьюлы, кумәкләшеп. Элегрәк, әйтик, әле кичә генә моны эшли алмаган булырлар иде. Күселәр белән алар арасында моңа кадәр шушы тегермән торган. Инде хәзер, ул сүтелеп беткәч, әле кайчан гына тоттырмаган, мал корыткан, тәңкәгә тигән күселәр кешеләрнең күз алдында бар дөньялары, оялары, көл төсендәге мүк шикелле төк белән капланган кызыл тәнле, йомык күзле балалары, көн яктысы бөрештергән тәннәре, кояш сукырайткан, куркудан акайган күзләре белән көчсезләнеп калырлар һәм үзләренә төбәлгән көрәкләр, сәнәкләр астында вак тешләрен ыржайтып чинарлар, бәләкәй аяк-кул-

ларын болгый-болгый җан бирерләр. Аларны шәфкатьсез төстә, сүгенә-сүгенә һәм җирәнеп сытарлар, имгәтерләр, дөмектерерләр, тончыктырырлар. Алар камырлы һәм онлы ояларына качкан булырлар, тик аларны казып чыгарырлар.

Бу котылгысыз иде. Моны кайчандыр күрдем дә шикелле. Без ул соры күселәрне нәкъ шулай урап алгач, Сталинград янында юк иттек. Курскида алар безгә каршы броняга төренеп чыкты — «пантера» һәм «юлбарыс»лар... Мин ул күселәрнең «кара пулеметчы» Каһир Сафинга каршы тезелеп һәм сыңар тешләрен штык итеп ыржайтып килүләрен күз алдыма китерәм.

— Юкка маташабыз,— диде озынча иякле.— Монда калдырдык ди,— әллә яңа авылда яралмаслар дисеңме?

— Алары аның үзебезнеке, ничек тә җаен белербез. Менә болары куәмәсен. Кеше калдыгы үзеңнекеннән яманрак,— диде җирән егет.

— Мин алардан җиңел котылу әмәлен беләм... Нитәсең... Теге «җен уләне» бар ич әле? Менә шуны чәчәк атканда җыеп, кая кирәк — өй тирәли; базга димсең, келәткә димсең төнгә каршы таратып чыгасың. Эзләре дә калмый, табан ялтыраталар. Шуның исен өнәмиләр, хәерсезләр.

— Алар ерак китмиләр ич инде алайса — күршеләргә хәтле генә. Миңа, ахмак! Әле син шулай миңа күсе өстереп яттыңмыни?!

— Ысулын гына әйтәм.

— «Ысулын», «ысулын»!..

Җирдә тегермәннең өрлекләре генә ятып калган иде инде. Кояш астында озак ятып, агарып беткән хайван скелеты төсле.

— Тайганнар ич алар, җәмәгать!

— Хәшәрәтләр, сызганнар!

— Сизгәннәр!

— Актарырга кирәк. Кая китсен алар, ояларындадыр.

— Тотарсың хәзер койрыкларын! Алар кораб батасын да алдан тоеп кача. Кача да океан кичеп җиргә чыга.

— Кичә сутәсие, тоташтан сутәсие, сиздермәстән! Әйттем, тыңламадыгыз, кишер башлар!

— Кая элдерде икән суң алар?

— Кая булсын? Авылга!

Халык үкенә, гаҗәпләнә, шакката, үзен-үзе битәрли, яманлый, сүгенә иде. Мин инде аларның нишләгәнен карамыйм, талгын гына искән җилнең үләннәрне, тегермән чокырындагы кычыткан, әрем башларын таравын, тупыл яфракларын лепердәткәнен карыйм. Көн кояшлы, ялангач тау яры яктырып тора, әүвәлге су канауларын картайган сыер кукысы, каты билчән тутырган, буа дамбаларын чирәм баскан, ул чирәмдә, җил көйрәткән кумерләр булып, усак яфраклары калтырана. Кешеләр тегермән астын актара иде ахрысы,— һаваны тагын әчегән он исе тутырды.

— Җәле, җәмәгать, бульдозер актарып салсын әле, тешегезгә кысылган итне чокчынасыз, кишер башлар! Газуй, Хөсәен!

Тегермәннең он чаларткан нигезенә җирән бульдозерның ялтырап торган көрәге якынлашты.

— Туктап торыгыз әле,— дидем мин әкрен генә һәм аның каршысына атлап, кулымны күтәрдем.

Трактор, пычагы белән нигез ташына терәлеп, туктап калды.

— Ни кирәк, абый?

Озынча иякленең тавышын ишетеп борылдым.

— Дүрт почмакта дүрт көмеш таңкә бар диген идем, исеңдәме? Башта шуларны алыйк әле, энем.

— Каян беләсең?

— Шулай тиеш иде.

— Берәр ярты куештан булмаган ичмаса.
— Андый гадәт юк.
— Хәзер бар. Былтыр әрмәннәр шулай итте, Культура йортына. Берәүләрнең бәхетенә чиртәчәк инде.
— Бәхетенә? Сутәргә дип салдыгызмыни?
— Кешедән артмый инде ул. Бүген — тегермән, иртәгә... Ә иртәгә әллә бар без, әллә юк... Кешедән артмый... Каяле алайса... Егетләр, күтәрик әле!
Яшел мүкле дүрт ниргәне дүрт якка таратып җибәрделәр. Аларның асларыннан алтын черек оны сибелеп калды. Әйләндерә-әйләндерә карагач, Надир минем учыма көмеш тәңкә китереп салды.
— Ялгышкансың, абый, өчәү генә.
Көтмәгән идем. Оялып киттем.
— Кайсы почмактан чыкмады?
— Теге,— диде ул, төньякка ишарәләп.
— Шундадыр, яхшылап кара әле, энем.
— Менә инде, миннән шикләнмисездер ич? — диде ул бу юлы «сез»гә күчеп.
— Рәхмәт,— дидем.
— Үзегез куеп калдырдыгызмы әллә?
— Әйе, үзем.
— Кайчан? А-а, хан заманында!
— Юк, үзебезнең заманда, энем, үзебезнең заман башында.
Читкә киттем.
— Газуй, Хөсәен!
Ташка барып утырдым да учымдагы каралган талир тәңкәләргә текәлдем. Кире әйләнеп кайту өчен, диңгезгә вак акча ыргыталар. Ә мин үземнең үткәнемә әйләнеп кайттым. Бу акчалар да менә шунда... аның янына алып кайтса икән лә ул!.. Хәер, мин ул талир тәңкәләрне хәтерем диңгезенә ыргытырга өлгерәм әле.
Бульдозер, карт кеше башындагы чал чәчне күтәргән сыман, тегермән урынын юнып кына алды да чокырга эшереп төшерде. Киләсе ел кары эреп, җир җылынгач, биредә ямь-яшел чирәм үсәчәк.
Күселәр чыкмады.
Үрдән түбән агылган болыт күләгәләрен таптап, югары менеп киттем. Каһир янына. Ә ул...

## XIII

...Ә ул, кече капканы япканчы, беравык тышка карап торды. Әллә ул үзе контузияләнгән кебек, әллә дөнья үлгән — саңгырау тынлык хөкем сөрә. Әйтерсең лә ул бик биек манара башында. Каенлыктан авылга таба бер көтү саескан очып узды. Аның өе әүвәлге авылның иң югары очында иде, хәзер исә яңа авылның иң түбәнге ягында. Элеккеге авыл урынында өере белән этләр йөри, үзләренең тир исләре сеңгән урыннарындагы ояларын сагынышып төшкәннәр, күрәсең. Төшлеккә җиткән кояш, томансуланып торган юка ак болытлар астына кереп, тарау яктылык сибә башлады. Кояш күз уртасын узып бара иде инде. Тешләре сынган таракка охшап калган койманың теге ягындагы груша агачыннан яшелле-көрәнле йомшак җимешләр коела. Ул аларның җиргә төшкәннәрен җыймый инде, шунда — агач төбендә тимгелләнеп чери баралар, балалар да җыймый. Кышка киптерергә менә дигәннәр югыйсә. Тик күңеле юк. Аның яңа өе авылда инде. Дөресрәге, квартиры. Икенче кат, су, газ, канализация. Ниса инде бер ай шунда яши. Каһир кунарга гына кайта. Буш вакытта гел шушында әле. Гомер кичкән куышын ятим калдырасы килми. Бу аның оясы. Биредә аның җаны,

тәне. Эчкән суы, ашаган ризыгы, авыз иткән җимеше, торган хатыны, үстергән балалары. Бирелә ул көн күрерлек хезмәт итте, эшләп тапкан акчасын санады, китап укыды, телевизор карады, күршеләреннән көнләмәде, үзен мактамады, хатынын хурламады, җәберләмәде. Үткәннәр күләгәсеннән качмады, киләчәк рәшәсенә алданмады. Кешеләрен дус күрде, әмма пычак кебек туры сүзле булды, ачу тотмады, кичерә белде. Үзен балаларына бәйләмәде, такмады, тулы азатлык бирде. Алар аның үз көнен үзе күрүенә ышана, ярдәмнәре белән бимазаламыйлар. Кирәкми. Азатлыкка ни җитә! Әлегә алар аңа мохтаҗрак. Шулай ышанычлы. Әнә, кызлар. Авыл күчәсен ишетүгә, талымсыз сыер кебек кайтып төште дә йорт бүрәнәләрен кызыл тырнаклы бармаклары белән чиртә-чиртә елаган булды. Яһүд ире дәшмәде, эсседән таш астына качкан гөберле бака сыман, җәймә җәеп, кызыл «Волга»сы астына кереп ятты.

— Ник елыйсың, кызым?

— Сине жәлләп, әти. Без дүрт бүлмәлегә дә көчкә сыябыз, яңа өегездә нишләп кенә ятарсыз икән?

— Яшәрбез, кызым.

— И-и, бу иркенлеккә җитәме соң инде! Мунчасы, келәте, базы, бакчасы... Ничек утын итеп якмак кирәк?

— Безгә утын кирәкми инде.

— Соң, нишләтмәкче буласың инде бу хәзинәне?

— Кабергә сыймас инде.

— Йөрәгемне бозмале, әти. Анау тукмак борын күрсәткәннәрдән дә гарык.

— Шүмкәдәге бер знакум урыс мәгәричен алдан ук тотып килеп киткән иде килүен...

— Синең, әти, авыл саен знакум булыр инде. Йорт кызганыч. Бакчы, бүрәнәләре — скрипкә!

— Үз дачагыз да моннан ким түгел бугай. Хәер, күрсәткәнегез юк...

— Сатканыек шул инде, әти җаным!.. Ә минем Шумахерыма саф һава кирәк.

— Шулай. Авылга ешрак кайтыгыз. Машинагыз үз кулыгызда.

— Ә бензин? Театрга чакыру кәгазе белән генә йөрсәк тә, бер барып күренү өчен дә биш тәңкәлек бензин кирәк.

— Йөрмәгез соң...

— Ирең кибет директоры булып торса, барырга да кирәк икән шул. Үзең генә йөрү димәгән, кунак ашы кара-каршы ич, безгә дә чакырырга туры килә. Ә кая чакырасың — театрга... Дача юк инде хәзер. Менә, яңа җир алдык әле.

— Җәяү йөрисезме?

— Машинада, әти, ник җәяү булсын ди?! Кеше көлдереп...

— Ә бензин?

— Бензины чәнчелсен лә! Агач кыйммәтләнде әле, әти җаным. Бакчы безнең өй бүрәнәләрен — скрипка инде менә!

— Безнең заманда агач кыйммәт кенә түгел, гупчым юк иде әле. Теш казырлык агач тапмый тилмерә идек.

— И-и, әти! Бәя күпертәм дип, тузга язмаганны сөйләмә инде, яме? Колхоз салдырган өй бит бу. Сугыштан кайткач, председатель булдың да салып бирделәр.

— Кайдадыр торырга тиеш идемдер ич мин, кызым? Сез дә шундук тордыгыз, әллә алла куенындамы?

— Шулай инде, әти... Бакчы, бүрәнәләре — скрипка! Тик үз кызың күк күрсәң дә, чит кан — чит кан икән шул инде. Үз атам сугышта үлеп калмаса, бу хәтле ялындырып тормас иде.

— Әле бит, кызым, бернәрсә дә сорамадың? Тел төбеңне аңламадым да.

— Нәрсәсен аңлыйсың инде аның? Бакчы бүрәнәләрс — скрипка!..
Аңлаган иде Каһир, ник аңламасын. Колагына мамык тыкмаган ич, ишетте. Миенә дә йон үсмәгән — аңлады. Шумахеры белән кече яктә таң тишегенә тиклем шухер-мухер килештеләр дә иртәгесен әнкәләре ягып керткән мунчадан соң, калган ромнарын әләктереп, кайтып киттеләр.

— И-и-и, эти! Бакчы бу мунчаңның бүрәнәләрен! — дип мактады Исламия әнисе ягып керткән мунчаны.

— Мунчаны Таһир сораган иде шул.

— Бәй, ир башы белән апасыныкын талыймы?

— Таламый — сорый. Апасыныкын түгел, атасыныкын.

— Миңа да бирәр нәрсә тиештер ләбаса инде, эти!

— Ярый, мин үлгәнче өен дә, мунчасын да алып китегез соң.

— Син үлгәнне көтеп ятабызмы соң, эти җанашым!

— Үлгәнне көтсәгез дә тамаша инде. Менә, ничек җирләрсез икән, карарбыз.

— И-и, эти җаным! Тамчы да кайгырма ичмасам, кеше алдында ким-хур итмәбез, әйтте диярсең!..

Исламия шулай дигәч, Ниса елап җибәрде. Еламаска: алар терелэй күмәргә күп сорамаслар!.. Исламия ялгыш ычкындырганын сизде-сизүен, тик сүз бозау түгел шул, тышаулап булмый.

«Һе, үл генә икән алайса! — дип көрсенде Каһир. — Юк, үлгәнче эшем бар әле минем», — дип уйлады ул тегермәнгә таба төшеп киткән алмачуар җигүле атка кем утырганын танырга тырышып. Бүген чәршәмбе, шимбә аның йортын сүтеп алып китәргә Шумахерлар кайтасы. Әгәр дә инде бер атна буена үҗәтлек белән башлаган, җирәнү белән дәвам иткән һәм, һичшиксез, ләззәт белән тәгаллисе эшен бүлдерсәләр, алар бу юлы да буш китәчәк әле. Хәер, аңынчы өлгерә әле ул. Нишләгәнен ул Нисага әйтми, белсә, чукындырып әрләп ташлый инде, һәм хаклы булыр иде, чөнки Каһир Сафиннан гына калыр идемени. Гомумән, Ниса хаклы. Дөрес, гөнаһысы кирәк түгел. «Эчәсең» дип бәйләнә икән, авызыннан иснәттермәде, кулыннан тартып алмады, иртәгесен баш авыртканны төзәтергә китереп куя белде. Берзаманны «Йөрисең» дип тын бирмәгән иде, өстендә тотарга дип сагаламады, аның эчендәге иярсез айгырның басынкы эш атына әйләнүен сабыр гына көтте. Көтмичә ни! Ул үзе дә теге чакны үз оясына гына сыймыйча һәм өлешенә үзе сайлап алган көмеше белән генә туймыйча, Булганин янына йөрмәдеме әллә? Белә Каһир, барысын да белә. Исламияне үз кызы күк карап үстерүгә карамасын, бала ич, урамга чыгарып атасыңмыни. Белсен, атасын Ширәмәтов дип белсен... Ә Ниса... Ул сөйләде, яшермәде. «Уналты яшемнән лазаретларда яралы кызылармеецларны карап, тотып тышларга хәтле чыгарып тордым. Инде яшәргә вакыт... Яши башлаган идем яшәвен!.. Бер канторда секретарь булып тордым. Начальник кулын озынайта башлагач, битенә кара сиптем дә, урындыгымны аударып чыгып киттем. Урамда элеккеге лихой командирымны очраттым, күкрәгенә ятып җыладым, тинтәк... Әйбәтләбрәк карасам, — джентельмен! Кибет тота икән, зараза! Кибетенә чакырды. Киттем! Барысы да көл булып күккә очты. Казанда яшәрлегем калмады, эти аягына кайтып егылдым... Аннары поручик Шереметьев... Сөләгәй! Җебегән...» — «Ширәмәтовны әйтәсеңме?» — «Шереметьев. Ши-ре-меть-ев! — дип төзәтте ул башын горур чөеп. — Инде менә син, җан көеге»...— «Сөләгәй булгач, ник чыгасың?» — «Сер! — диде ул күзләрен кыса төшеп. — Белерсең әле, әйтермен. Бөтенләе белән синеке, синеке генә булгач... Бывший поручик хатынына түгел, ә хан кызы Ниса Азаматовнага ия булырсың». — «Алайса, ия булмыймдыр. Мин хан түгел. Алайса, син миңа ия булырга чамалыйсың икән». — «Убы-

токта калмассың, кикригәнне салындырма!— диде ул сак кына хәрәкәт белән билен сыйпап.— Аитова мәктәбендә юкка гына ми черетеп ятмадым. Хоть урысча, хоть французча... Белсәң икән син, Каһир, йөрәк парәм минем, белсәң икән!..» Аннары ул, гадәтенчә, елый-елый, үзенең сузыйкы, күкрәк төбеннән күтәрелеп чыккан тавышында тибрәтеп, туктаусыз сөйләнә-сөйләнә, әллә артистланып, әллә табигатенә йөгәнсез буйсынып, буталчык, зәңгәр хыялларында йөзә иде. Һәм йөздерә... А-а, андый вакытта алиһә иде ул! Күзләре — көлтә-көлтә ялкын сибәрлек икe чакма ташы. Ә карашы? Яшелле-зәңгәрле болыт өере астыннан бәреп чыга торган аҗаган сирпешемнен! Ходай тәгалә борын белән бүлеп куймаган булса, аның күзләре арасында яшен чаткылары уйнап торыр иде шикелле. Нисаның күңелендә кыя башындагы бөркет оясыдай яткан сере ачылды. Ширәмәтов үз бриллиантын бөтен авыл каршында колхоз нигезенә беренче таш итеп китереп салгач, Нисаның төнге ябалак сурәтендә бар аулаганы шул булган икән. Икенче көнне үк Ширәмәтовтан аерылып китте, Каһирга да кияүгә чыкмады.

Берничә елдан соң, томанлы бер көзге иртәдә Каһирны авылдан алып чыгып киттеләр. Тырышканы өчен. Артыграк тырышканлыгын соңыннан гына белде, шуңа күрә үз гаебен авылдашлары алдында маңгай тире белән юарга тырышып яшәде. Кабат ышандылар. Ышанычларын аклады бугай, аны яратмаган кеше күп булмады. Сугыштан соң бер ел үткәч, Каһирның хатыны үлгәнен ишетеп, Ниса кайтып төште. Уналты яшьлек кызын ияртеп. Күкрәгендә орден, медальләр...

— Үзеңнекеләрме?— дип сорады Каһир.

— Юк, базардан сатып алдым!— диде Ниса мыскыллап.

Яшәделәр. Яшиләр...

Ул капканы шыгырдамасын өчен күтәребрәк япты да лапас астындагы карама бүкәнгә килеп утырды, папирос кабызды, эч пошып көрсенгәндәге шикелле, тирән суыра-суыра тартты. Ак балчык түшәлгән җиргә лапас җирдалары буй-буй күләгәләр булып яткан; мөгаен, өстән караганда ул читлектә утырган кебек күренәдер. Читлектә утыра торган кош булыпмы, әллә мәктәп дәфтәре битенә тамган шәмәхә кара табы булып микән? Аның ул дәфтәр битен ертып алып, учында бөгәрлисе, утка атасы килеп китте. Үзе белән бергә. Хәер, аның гомере бозылган дәфтәр бите түгел. Сызыклары артык туры, калын, кисешмиләр — сыза башлаган да дәфтәр бите кырында өзелеп калган. Һәр сызыгы ни белән тәгәлләнгәне күренми, анысы читтә, билгесез. Ә менә ноктаны куясы бар әле, бар. Соңгы нокта гомер каләме очыннан тамган кара түгел әле, соңгы нокта — алда, нинди икәнен ул үзе генә чамалый. Кайчандыр аның пулеметыннан пунктирлап чәчрәп чыгып, дошманнарына барып кадалган пуля-бал кортлары үле инде. Алар чагып, укларын кадап калдырганнан соң үлгән бал кортлары кебек, дошман тәннәрендә суындылар. Каһир дошманнарын ул чагында артык күп кырган икән — үз гомере дәвамына берсен дә калдырмаган. Ислам Зәйнушин? Теләсә дә, ул Зәйнушинны дошманы итә алмады. Аның тормышы да (әгәр ул да үз гомерен дәфтәр бите рәвешендә күз алдына китерсә), нәкъ Каһирныкы сымак, буй-буй сызыклы лабаса. Әмма сызыклары гына бүтән юнәлештәдер. Әгәр ул икe кәгазьне бер-берсенә капласаң, менә дигән шакмаклы дәфтәр бите килеп чыкмас идемени? Тик менә кайсысының гомер юлы буйлый да, кайсысыныкы аркылы?.. Ә бу барыбер бугай! Шакмаклы биткә язуы җайлырак. Аларның гомер битләрендә бүтәннәргә язуы (димәк, яшәве? Әйе, яшәве!) җайлырак. Әйе, алар кешеләргә әз бирмәделәр. Анысы хак. Тик әз алдылар бугай. Анысын да бер-берсеннән. Ислам Кәүсәрияне тартып алды. Ә Каһир Сафин Тархановларны җәһәннәмгә олактырды. (Дөрес, сугыштан соң Азамат карт үз иленә кайтып үлде, уллары сугышта һәлак булган, оныкларының һәм киленнәренең аны җирләгәннән соң кайтып күзгә

чалынганнары юк.) Ахыр килеп, алар икесе дә хаклы иде, икесе ике яктан бер суканы тартып бармадылармыни?)

Аның аяк астында, гильзалар кебек, өч папирос төпчеге ята. Келәт кыегы астындагы буш карлыгач оясына ялгыз чыпчык килеп кунды. Алда кыш. Хәер, Каһирны да җәй көтеп тормый иде... Кош оя кора... Ә аның бу йортын кияү сүтәчәк. Җәрсңгәгә карлыгачлар ояларын тапмас. Моңа ул гаепле түгел.

«Мин үзем дә шул карлыгачлар хәлендә, чыпчык»,— дип уйлады ул.— Канатым булса, мин дә очар идем. Канатым булса, аннары соң... шул күселәрнең башына житсәм...»

Аны уеннан бүлеп, келәттә тимер чыкылдап куйды, аңа бик яхшы таныш чыелдау кушылды да тонык, йомшак бәргәләнү ишетелде.

— Җаның җәһәннәмгә ашсын, бәдбәхет!— диде ул, сүзләрен теш арасыннан сөзеп чыгарып. Аскы ирене калтыравын басар өчен өске тешләре белән тешләргә мәҗбүр булды. Күкрәгән алты төрәнле сука белән ертып килгән ярсуны ничек кубарып атарга белмичә, аяк астында яткан балтаны киң селтәнеп келәт стенасына томырды. Келәтнең нечкә, каптагы папирослар кебек тигез һәм шома нарат бүрәнәләре зыңгылдап торган коры күкрәү белән җавап бирде дә, тәненә батып калган балта җәрәхәтенә чыдый алмыйча тавышсыз елагандай, ишеге ачылып китте. Чыпчык юкка чыкты, карлыгач оясы ишек төбендәге ташка төшеп чәлпәрәмә килде. Балта белән бәрү келәтнең эчке стеналарындагы тузан һәм онны туздырган күрәсең, ишеккә кыйгачлап кергән кояш яктысы, иртәнге күл өстендәге томандай, көйрәп тора иде. Шундук чылбыр шылтырап куйды да тынды... Ул эт оясына сөяп куелган тимерче келәшчәсенең озын түгәрәк сабыннан эләктереп һәм аңа таяна төшеп, бусагага күтәрелде.

Ул үзенең ерак яшьлегендә шәм кебек сүнеп калган психик атака күренешләрен оныткан иде инде. Аларны Бөек Ватан сугышының салкын окоплары, бигрәк тә ару — муенга һәрвакыт тегермән ташы асып йөргәндәй ару тойгысы алыштырган иде. Хәзер ул дөньяның алтмыш еллык кабыгын кубарып ыргытты да тагын кылганлы далалардагы, карлы чүлләрдәге урынына — ашыгыч төстә жиргә сузылып яткан отряд тезмәсенең, рота траншеяларының алдына чыгып, пулеметы белән бер тән булып, өн-тавышсыз янсә барабан сугып килгән, күзләрен үлемгә битарафлык, ә йөрәкләрен нәфрәт баскан катлы-катлы ак гвардиячеләр тезмәләре алдына чыгып ятты кебек. Күселәр... Тормышта үзе очраткан һәм эченнән күселәргә тиңләгән кешеләрнең аның аңындагы күләгәләре.

Ул күселәрне үз өенә үзе әйдәп китерде. Авыл күчәнә башлагач (ә аның үзенә, ике сугыш ветераны буларак, таш өйдән яздан ук бер бүлмәле фатир бүлеп куйганнар иде инде, тик ул Ниса белән соң чиккәчә иске өендә торып торырга булды — ни әйтсәң дә, һәр нәрсәгә җан кунеккән, кул ята, күз ияләшкән, тау аръягындагы авыл кибетенә көндәлек ипи, чәй-шикәр кебек нәрсәләргә йөрү авырыксындырса да)... әйе, урып-җыюдан соң бөтен авыл дәррәү кубып күчәнә башлагач, бер айлы төнне ул капка төбендәге утын кузласына папирос тартырга утырган иде. Иске сазлык мүге, торак, мунча төтене исләре бөркеп калдырган автомашиналар, арбалы тракторларның иң ахырдан ут яндырып барганнары берәм-берәм тау сыртыннан түбән төшеп киткәннән соң (ул аларны төн караңгысында елга аша күпер салырга киткән сапер ротасына охшатып калды), тыныч һавага таралып калган коры тузан басылгач һәм болганчык төтен исе таралгач, ул ялтырап торган шәмәхә юлда вак шәүләләр хәрәкәтенә игътибар итте. Ул тезләренә таянып торып басты һәм шундук үз алдында җәһәт кенә читкә елышкан күләгәләрне шәйләп алды һәм аңлады: күселәр — юл буенча ат тизәкләре, резин, коелып калган мүк һәм бүрәнә оны исе буенча яңа авылга күче-

нәләр. Башта әллә ни исә китмәде. «Күселәр, имеш. Бәламени ул? Җир йөзендә алардан да зуррак корткычлар, бәлаләр бар. Шөкер, хәзер муллык заманы, басуларда бер карыш буш җир юк, игеннең чирегә кырда кала, ындыр табагында кыза, элеваторда чери. Былтыр әнә, элеваторда күпме иген янды тирә-күрше колхоз малларына ашаттылар да күпме хайван агуланып, үләксә базлары өстендә җәй буе фосфор ялкыннары биеште, күселәрдән генә ни зыян; күрәсең, тормыш булгач, алар котылгысыздыр, юлларына аркылы тимер киртә корасыңмыни? Тимер киртә белән генә арынырдай әмәл бар икән, кешеләр арасындагы кеше чырайлы күселәрне әллә кайчан... Юк инде, кеше белән күсә һәрвакыт янәшә, араларын аермалы түгел. Тик тере тән, кайнар кан белән, атакада йөрәк белән пуля йотып, бугаз белән минага тончыгып, танк чылбыры астында үз гранатаңда шартлап, җир ашап, таш кимереп... кенә аерып була. Көрәш брустверың каршындагыларын шулай итеп аерып була, ә синең гомер кичкән өеңнең җылысын онытып, үзләренең салкын ояларына сөйрәүче Исламия кебек кызларыңны ничек итеп аерырга соң? Баштан чит язулар белән чуарланган кием киеп, «Мальборо»лар көйрәтер дәрәҗәгә җиткәнче кем тилебәрән ашаткан ул ни шалкан, ни чөгендер — куузика башларга? Үзләренең тамырларына нинди чылбыр белән бәйләнгән соң алар? Резина беләнме? Кая телисең, күпме кирәк — сузыла, тартыла, тавышы юк; гаеп итә, артык күрә башласалар, кире кайтара... Кем ирек биргән? Үзебез түгелме соң? Без күргән дә җиткән, дөньяның рәхәтен күреп калсыннар дип. «Ә ни ул — рәхәт?»— дип уйлады ул бөрешеп килеп, бөтенләй бөкрәеп бетеп, кире үз бүрәнәсенә барып утыргач. Юлга башка карамый иде инде, әмма эчендәге борчу, ярсу, көчсезлек, төшенкелек артка гына бара, чөнки күченү ыгы-зыгысына тартылган, шуңа сөенгән, көенгән авыл халкының киләчәк тормышына һич кәтмәгән яктан бишенче колонна — мәкерле, явыз, астыртын, хәшәрәт, шакшы, ямьсез, җирәнгеч күселәр кереп бара иде. Ул дөньяга колак салды — көзге төн тыныч кына җирне сөя, сыйпый, иркәли. Кызык бит тормыш: зәңгәр күзле, җиңел гәүдәле, наян холыклы көн җирне читтән генә сокланып ярата, ә кара күзле, авыр сулышлы төн җирне бар куәтенә үзенең йөнтәс күкрәге астына ала. Каһир җирнең басынкы сулышын, шома хәрәкәтен сизеп, торып утырды, дөнья битендәге төн пәрәнҗәсен алып ташлап, җирнең биленә көмешсу каеш булып уралган юлга кояшны тәгәрәтеп җибәрәсе килеп китте. Аларның юлында ниндидер киртә булырга, кемдер аларның тәгәл юнәлешләрен бутарга тиештер ләбаса? Югыйсә, бөтенесе азат, бөтенесе дә тук һәм рәхәттә. Бөтенесе дә бер-берсенә яхшы, дус, мәрхәмәтле. Бөтенесе һәм бар нәрсә ирекле, шул исәптән яхшылык һәм явызлык та. Бүре белән сарык янәшә. Сарык печән ашый, тик бүрегә ит кирәк, әлегә тамагы тук, әмма иртәме-соңгы ул, һичшиксез, тагын ачыгачак...

Һәм шунда Каһир караңгыгаияләшкән күзе белән күселәрнең капка астыннан үз өенә җыелуларын шәйләп алды. Явыз һәм шакшы булсалар да, кайберәүләр шикелле, иң җиңел һәм кыска юлны сайладылар. Каһир аларны үз каралтысыннан иртәгә үк юк итә торган бер әмәлне белә: берсен тотып, бензин сибеп ут төрткәч, ирекка җибәрәсең дә... чыелдау һәм көек, тере ит исеннән өннәре качкан ыругдашлары күз бәйләнү белән юкка чыгып бетәчәк! Бензин бар, кияве белән кызы багажникка иске самавыр, күмер үтүге, дуга, олы җиз кызгырау, үлчәү көянтәсе, иске чынаяк-тәлинкә ише нәрсәләрне тутыргач, ике канистр бензиннарын икенче кайтканчыга хәтле калдырып торган, ә карт аны хәвеф-хәтәрдән ераккарак — келәттәге салкын таш базга — төшереп куйган иде. Берсенең авызы ачылып киткән иде, ул аны караңгыда капшанып кына ябып куя алмады, ә кире өскә күтәреп менәргә авырыксынды, ярар санә, пычагым булсынмы, тик авып түгел-

мәсен генә... Әйе, бензин бар, күсегә ике кашык сипсәң шул җитә ана, ә тотыйм дисәң аю түгел, кыр куяны тотарга дип кышка хәстәрләп куйган өч капкынының берсенә тәгаен кабачак, ачлык җәһәннәмгә кертә.

— Картагызны бутыйм әле мин сезнең! — диде папирос көлен кагып.

«Дошман барында яшәү ачыграк,— дип уйлады ул.— Дошманы булган кешегә җиңмичә үләргә ярамый... Исемем дә ич — көрәштә җиңеп чыгучы, өстен булучы... Менә кем ул — Каһир...»

Язмыш аның үзенә күп капкыннар корып карады. Ләкин ул, сизгер җәнлек кебек, аларның һәрберсен читләтеп яши белде. Гомер үтеп, күпме таш ком булып уалды инде, күпме агач корыпауды. Коры һавада да булган су пары һәм иртәнге кояш нурында да җемелдәгән тузан бөртеге — черү һәм җимерелүнең күренмәс орлыгы — аның тәненә дә кунса кунгандыр, ләкин тамыр җәймәгән әле. Һәрхәлдә, вакыт-вакыт авыргаласа да, бирешергә исәбе юк. Үз сукмагындагы соңгы капкыннан — үлемнән берниндп сизгерлеккә һәм житезлеккә исәп тотып котылып булмавы белән ул күптән килешкән иде инде килешүен.

Ә менә үз каралты-курасын бер көтү күсе басу белән аның һич кенә дә килешәсе килмәде. Дөньяда берничек тә бетереп булмый торган яшәү белән үлем бар. Ә бетереп булмый торган явызлык юк. Моны ул яхшы белә. Шуңа күрә ул күселәрне җиңәчәгенә ышана иде. Дөрес, ул аларны үз каралтысыннан куып чыгару юлларын күп белә. Ләкин аның теләге күселәрне куып чыгаруда түгел. Аларны үз хуҗалыгыннан бер карыш та чыгармыйча бетерергә кирәк. Һәм ул аларны үзе белгән әмәл белән көче һәм вакыты җиткәнче кырырга карар кылды. Пулеметчының уйлары яктырып китте.

Каһир мунчага кереп, тәрәзә төбендәге фонарьны чайпалдырып карады: керосины житәрлеген барлагач, филтә күмерен чыра телгеч пычак белән кырып ут элде: электрны өзгәннәр иде инде. Келәт матчасындагы итле төшен кияү кеше юнгалап ашаган каклаган каз мае белән капкыннарын корып, берсен өйалдына, икесен келәткә чылбырлап куйды...

Аннары өйгә керде һәм, фонарен күтәреп, көзгедәге үз чагылышына караш ташлады: йөзе тыныч, күзе арыган, салынкырак аскы ирене әкрен генә дерелдәп тора иде.

Иртән өч капкын чылбыры да аның аяк тавышын чылтырап каршылады.

Ә кичә, яртылаш сүтелгән тегермән тирәсеннән кеше өзелгәч, ул шуннан бирле хәтле кичкырын бодай сипкән иде. Иске авыл белән тегермәннән менә торган юл нәкъ аның өе турысында кисешә, һәм юлларның һәрберсеннән тезелешеп менгән күселәр, комулятив гранатаның бер ноктага җыелган шартлау көче кебек, аның өенә килеп төртелде.

— Хәзер — бетте. Хәзер мин сезне — бәдрәф гуланчы! — диде ул өзек-өзек сулыш алып. Маңгаена салкын тир бәреп чыкты; эссе, кояш агач ябалдашларын эретә, җиргә вак-вак алтын тамчылар гына тама һәм яфраклар коела. Җиз тынлык, әче әрем һәм әрекмән исе килә, койма өстеннән баш калкыткан чия ботагы аермасындагы гәрәбә сагыз эчендә зәп-зәңгәр чаткы катып калган. «Миңа хәзер алла, шайтан, фәрештә — бөтенесе булышчы. Ул тишек бадья төбеннән чаптырган нечкә су агымыннан кулын, битен юды, болдыр тәрәзәсе төбенә тезгән поми-

дорлар арасыннан күзе кирәк тапканны алып чыгып юды да ипи белән помидор ашады.

Ашаганнан соң бүкәндә уйсыз-нисез тагын бер папирос тарткач, аның ишегалды тарлыгыннан һәм чикләнгәнлегеннән арынасы, котыласы килеп китте. Ләкин бүкән утырырга бик җайлы, ишегалды ышык, һәрнәрсә аныкы, һәм ул үзе дә һәрнәрсәнеке, аны ялгызлык талдырмый; хәзер ул сүзсезлекне якын күрә: сөйләшкәндә вакыт тиз уза, күбесенчә бер-берең күптән билгеле нәрсәләрне сөйлисең бит, ә яңа хәбәрне һәркем үзенә яраклаштырып сөйли, бәя бирә, алдаша; алдашканың белсәң дә, дәшмисең, бәхәсләшмисең, чөнки син аның ялганын сизүеңә канәгать; үзеңнекен генә уйлап тыңламый башлыйсың, тик ул да сине тыңламый. Ул да сине үзе кебек алдаша дип белә, имән шаулаганны — усак, усак калтыраганны — имән аңламаган шикелле була; шуңа күрә, дәшмичәрәк күзәтеп йөрүе артыграк, тулырак; нигә үзеңнең таш икәнеңне комга уалып, пүлән икәнеңне утынга вакланып, акыллы икәнеңне бәхәсләшеп, эшлекле икәнеңне ыгы-зыгыланып исбатларга — сандугач аулакта сайрый, бөркет ялгыз аулый, иң акыллы нәрсә — табигать: сүзсез генә кабул итә, сүзсез генә озата; кеше мәңгелек сүзсез тынлыктан пәйда була, мәңгелек сүзсез тынлыкка китеп бара, теле барында катырак кычкырырга, кулы селкенгәндә көчлерәк, ераккарак селтәнергә, аны эшләгәндә күбрәк уйлап чыгарырга, күзе һәм күңеле күргәндә арттырыбрак сокланырга тырышуы бәлки шуңадыр да. Ә вакыт ага да ага, ага да ага. Әгәр алла бар икән, ул кеше дә, шайтан да түгел, ул — вакыт, чөнки ул гына очсыз-кырыйсыз, ул гына дәшми, катнашмый, көнләми. Аңа бар да тигез: кеше дә... күсе дә.

«Аның каравы миңа тигез түгел,— дип каршы төште карт үз-үзенә.— Ә ник үчләнәм соң әле мин аларга? Миңа ошамаганнары өчен генәме? Тик миңа байтак нәрсә ошамый. Ә бәлки мин... сагынамдыр?» — Ул «яшьлегемне» дип ачыкларга базмады. Сагынудан ни мәгънә, кайтарып булмый. Арада тимер киртә дә юк. Кайтарып булмый, ә кабатлап... «Әйе, ул туктаган ахрысы инде, ә вакыт, ташны аралап аккан су кебек, инде аның тирәли әйләнеп ага, һәм менә аның әйләнешендә ул яңадан аларны күреп алды. Үлгәннәр җиде мең елдан соң гына җиргә кайта, имеш, ә болар... Ул аларны үз каршына иртәнге болын үләнен ертып килгәндә дә, ак кар ерып якынлашканда да, чүл комын туздырып, атта томырылганда да күселәргә охшата иде, һәм менә ул юраганының юш килгәненә куанды. Ул шуларга үчләнгән икән ләбаса, ул алар барында яши алмый — бары тик шул гына. Әле ул үлмәгән, алар тончыкмас борын, аңа үләргә ярамый, югыйсә, алар аның аша үтәчәк, алар аннан җирәнеп үтәчәк, ә ул моны теләми. Хәзер аннан: «Яшьлегегезнең кай вакытына кайтыр идең?»— дип сорасалар, ул тәгаен унтугызынчы елны — үзенең ун мең сум торган уналты яшьлек чагын атар иде. Кешеләр хәтерендә ул — башына ун мең вәгъдә ителгән кара пулеметчы. Ул шул хактагы зур-зур хәрефләр белән язылган белдерүнең бер нөсхәсе (бердәнбер нөсхәсе) Куйбышев музеенда саклаганын белә иде. Аны шунда чакырганнары бар. Тик ул бармады. Кешеләргә хәзер инде үзенең ун мең тормаганын күрсәтергәме? — Шул — ун мең торган кара пулеметчыга соклансыннар, егерме дүрт сумлык колхоз пенсионерына түгел.

Каһирның арысланныкыдай зур башы салынып төште, кызгылт каймалы күзеннән ике бөртек яшь сытылып чыкты да, ашка салган кызыл борычтай, шундук вак җыерчыкларга таралды.

Өй эчендә сәгать сукканын ишетте. Калтыравык, ниндидер зур куе кызыл күбәләкне хәтерләткән тавыш бер канаты белән калын сызгыру, икенчесе белән нечкә тимер чыңы таратып кагына-кагына, өйнең ачык ишегеннән өйалдына, өйалдыннан такта верандага, аннан һавага чыгып сүнде.

Һәм ул сәгать астындагы яшел тумбочкада кияввен сыйларга дип алып кайтып та ачылмый калган бодай аракысы барлыгын исенә төшерде.

«Бәлки... бер... ярты стакан җиб-бәрәседер, парин? — дип уйлады ул ике көн кырынмаган битен учлап.— Ну да... Помидор бар...» Ул келәт базында август уртасында ук тозлап куйган гөрәҗдә гөмбәләрен исенә төшерде. Кырык көннән ашты, өлгергәннәрдер, шәт. Ул кызыл эчле калушын салмыйча гына өйгә кереп, түргә узды, тумбочкада аның колхоз председателе, аннан ревкомиссия председателе чагында язган доклад кәгазьләре, мәктәптә хезмәт укытучысы булып эшләгәндәге дәрес планнары, завхоз, склад мөдире булып торгандагы амбар кенәгәләре саклана иде, шуларга аударып куйган шешәне ике бармагы белән генә муеныннан тотып суырып чыгарды да ватык тәрәзәле шкафтан стакан алды һәм шешәне дә, стаканны да үзе утырган букәнгә бастырып куйды. Аннары келәткә керде, уң аягы очы белән генә яссы пружинага басып, эре тоз сибелгән һәм тузан кунган, эреп, үтә күренмәләнеп калган каз мае бәйләнгән тәлинкәнең чәмәген капкынның теленә эләктереп куйды да кулы тигән урыннарны керосинлы чүпрәк белән сөрткәләгәч, баз капкачын ачып җибәрде. Битенә салкын туфрак, дымсу таш, чери башлаган кычыткан (кары эремәсен өчен май ахырында, тагын июнь урталарында чабып җәйгән иде), бензин исе килеп бәрелде. «Тиккә!» — дип үкенде ул канистрларны монда төшергәненә.— Ризыкларга исе сеңсә?» Биредә Ниса тозлаган бер мичкә кыяр, бихисап банка помидор, җиләк вареньелары тора иде әле. Ниса, таш өйдә кая куярга булыр инде дип уфтанып утыргач, Исламияләре Шумахерына карап:

— Гаражыбыз базында урын калдымы әле? Әз-әзләп кайтарып торыр идек, әрәм итеп булмый ич инде!— дип маташты.

«Тотсын менә, кышка баз казырлык кына әмәл бар әле»,— дип уйлады Каһир ачу белән һәм ухылдый-ухылдый агач баскычтан түбән төшеп китте, нигәдер, күнегелгәнгәдер инде, электр кабызгычын чертләтеп карады; күзе һичнии аермады, ничәмә-ничә банка, кайсысында гөмбә икәнен капшанып кына белерлек түгел. Чүгәләгән көйгә генә чалбар кесәсеннән кап чыгарып ачты да шырпы кабызып җибәрде...

Каһир:

«Чә! Электр тогы!» — дип гаҗәпләнергә генә өлгерде, баз эченә кояш килеп төште. Юк, бу аның баш очында таралып, кайнар офыккача җилфердәгән канлы байрак (хәтта эрегән кургашындай тамчылары аны баштанаяк чылатып та бетерде) иде бугай. Ул аның артыннан омтылды, тик пулеметының көпчәкләре урынында тегермән ташлары, бар куәтенә сөйрәсә дә, кузгата алмады, ә байрак ерагайганнан-ерагая, кызыл атларның тояк тавышы сүрелгәннән-сүрелә, аның алардан каласы килми, җан ачысы белән пулеметын сөйри, ниһаять, ул авыр кузгала, һәм аны уздырып якынайганнан-якыная бара да күк йөзен томалап, кызыл үгездәй үкереп, аңа үрмәли башлый. «Алла хакы өчен!» — дип ялвара ул җиргә тезләнеп. Ә байрак ерагайганнан-ерагая, ерагайганнан-ерагая...

## XIV

Каһирны шулай югалттым. Фронтташ дустымны — бер окопта, бер блиндажда яшәгән, бер атакада йөргән дустымны югалткандай булдым. Алай гынамы соң! Сугышта югалткан дусларның искитмәле күп булуын күтәрүе авыр иде. Ә Каһир Сафин белән без бу тормышның коточкыч кыска юлында һәрвакыт иңгә-иң барганбыз лабаса. Аны югалту

миңа фаҗигалерәк. Ул минем бераү генә булган икән! Бүтән юк. Мин шул хәтле дә яраткан һәм күрәлмаган кеше. Аның кеше буларак кыйммәтен үземә нисбәттә генә үлчәсәм, мин үз-үземнән оялырга лаек. Каһир Сафиннар күп түгел иде!

Үкенеч басты. Үземне гаепле тойдым. Нинедер ачыклап өлгермәдем. Аңа әйтәсе килгән ниндидер гап-гади сүз йөрәгемдә, горур күңелемдә бикләнеп калды. Хәзер шул кыйммәтле, иң затлы, Каһирга әйтергә кирәк булган бердәнбер сүземне үкенеч кимереп ята.

Үлем үкенечсез булмый ди татар кешесе. Ни бу? Үлгән кешегә карата тере кешенең теләсә нинди гаебен ярлыкар өчен чыгарылган тәкъбирме, әллә яшәүнең мөхтәрәм фәлсәфәсеме? Теләсә нинди ялгышын ярлыкар өчен...

Үлем үкенечсез булмый.

Бер заманны, әле Братск ГЭСын төзеп бетермәстән, главкка, министрлыклар, хөкүмәт тә ачыкламас борын, хәтта күбәүләрнең каршы торуына карамастан, Усть-Илим су электр станциясенә урын сайларга баргач, бер аучының тайгадагы йөзләрчә чакрымга бердәнбер өенә төн куна кергәч һәм туңган буыннарны спирт белән таратып, Себер чәе белән эретеп җибәргәч, бәхәс купкан иде. Бәхәс тә түгел — сүз. Яхшы, кирәкле сүз. «Кешенең бәясе нәрсәдә? Әгәр ун ел гомерең бәрабәренә үткән гомереңнең бер генә сәгатен кире кайтарырга мөмкинлек бирсәләр, кем нәрсә сайлар иде? Гомумән, кешенең үткәнендә ун ел гомергә торырлык минутлар бармы?» Артык сайланып тормадык: һәркемнең үзенә генә газиз минутлары бар икән, һәм ул минутлар алдында ун ел гына түгел, бөтен калган гомер дә берни тормый икән!.. Озак сөйләштек, ахырда үз фикеремне уртаклаштым: һәрберебезнең сайлаган үз минутлары гомеренең иң кадерле, иң асыл, иң бәхетле вакыты түгел, ә калган гомере өчен үкенечле мизгеле икән! «Үлем үкенечсез булмый, дип шуңа әйтәләр икән. «Кешенең үлеме тере кешеләр өчен үкенеч белән тулы. Якын кешеңне югалтуның әче авырлыгы, кабатланмас фаҗигасе нидә? Минемчә, үлгән кешене терелтеп, аңа иң кирәкле соңгы сүзне әйтә алмауда.

Тегермәнне урап алган ир-атлар янгынны бик тиз сүндерсә дә (баз авызыннан ургып торган ялкын келәткә генә кабарга өлгергән иде, ләкин баз эче...), минем җанымдагы үкенеч утын сүндерердәй кодрәт кешелеккә бирелмәгән иде шул. Шуңа күрә мин «Хуш, Каһир!» диясе урынга, «Кичер, Каһир...» дидем.

Әй минем соңгы сүземә аның җаны нинди сусаган булгандыр! Мин моңа аның соңгы сүзенә үземнең җаным гаять сусаган икәнен сизгәч кенә төшендем.

Яры-ы-ый... Ярый. (Уфтанудан ни мәгънә?)

«Кара «Волга»ның һәммә ишекләре, капоты ачык. Ул канатларын җәйгән һәм каурыйларын тырпайткан көртлекне хәтерләтә. Кердем дә шалтыраттым:

— Үзендәме?

— Хәзер, Ислам Имамович!.. Тыңлыйм, Ислам Имамович.

— Карале, килеп чык әле...

— Срок шул килеш кала. Өзсәң, бер ни белән дә аклана алмыйсың!

Озын тынлык.

— Кыям Сөләйманович...

— Юк, үтенмә, сорама. Кстати, шатландыра алам: рапорт раслануырга китте. Аңлагансыңдыр дип уйлыйм,— диде ул тавышы белән булдыра алганча мәгънәле ымлап.

— Рәхмәт.

— Уңышлар телим.

— Кыям Сөләйманович, әйтергә бир. Карале... Килеп чык әле.

— Нәрсә булды?

— Бернәрсә булмады.

— ...

— Сагындым. Сине сагынырга хакым бәрмы минем?

— Карале, син бит миңа валидол каптырасың, Ислам ага! Әйт тизрәк.

— Тизрәк? Озаклап, тәмләп әйтимме соң?

— Әллә үпкәләттемме?

Чигәм буенча «Үп-кә-ләт-тем-ме...» дигән авыр поезд составы узып киткәнне көтеп тордым.

— Исән чакта үпкә нәрсә ул!— дидем мин.— Көн кызу шул, көз димәссең,— диде ул кыштырдап. Әллә чыннан да валидол кабамы? Юк, эфир кыштырдавы бугай.

— Көн?

— Кызу капкан сиңа бүген, Ислам Имамович!

— Көтәм.

— Бәлки син килерсең? Холодильник эшләп тора...

— Бушка эшләтмә. Бушат та — әйдә.

— Ярый. Бер... егерме биш-утыз минуттан килеп җитәрмен.

— Өлгермәссең дип уйлыйм.— Мин аңа үземнең кайда икәнлегемне әйттем. Ул сызгырып куйды.

— Нинди шайтан ташлады сине минем авылга?

— Кузгал, кузгал.

— Ярый, бер... егерме биш-утыз минуттан килеп җитәрмен.

«Вертолет чакырта»,— дип уйладым мин.

— Холодильнигыңның эчтәлеге белән бергә көтәм,— дидем мин.

— Кызган инде әзрәк, аңлат...

— Килгәч.

— Алайса, хуп мәйле.

Шофер миңа сәерсенеп карап куйды да сәгатькә күз төшерде.

— Яратса, ике төн генә түзәр — чәпчемә... Яле, Нәүрбәковны тот әле.

Утыргычның мәче кебек йомшак зәңгәр япмасыннан җиргә төшеп бастым. Җир бирегә тырналып, шадраланып беткән: әүвәлге алма бакчасы урыны. Кабинеттан күренми торган җирләр. Үз күзең белән күргәч, бөтенләй башка. Су астында калган җир хакында мин журналистларга күп интервьюлар биргәнем бар. Братскида безга гаепне әз якмадылар: күпме урман утырып калды. Урманчыларның графикка сыймавына ачу гына килә иде, ә бүгендәй кызгану хисе... юк, кичермәдем. Электр энергиясен ялтыравыклы упаковкаларга төреп кенә сатып алып булмый шул, җан кисәкләрем!

Биредә, менә, безнең аркада җиде йөз гектар алма бакчасын су күмә. Иң югарыда — үр башындагылары гына калган. Ә астагыларын... төбе-тамырлары белән йолкып алып, зур-зур күчләргә өеп куйганнар. Ягарга. Ә якмыйча берәр эшкә тотсалар, ихтимал, яңа бакча салырлык акча эшләп булыр иде. Мебель. Алмагачыннан ясалган мебель. Иң киме чәч тараклары. Дөресрәге, тарагы. Аны миңа кем ясап биргән иде әле? Хәзер, хәзер... «Оборот-минут» ласа! Шома, бизәкле. «Имянной!» дип сузган иде ул аны миңа. «Имәннән юндыңмыни?» — «Имәннән дураклар ясасын... Мәйтәм, имянной! Менә, полный антураж: бояваму командиру пярвой еялектростанции коммунистического образца 1929.»

Исемле тарак... Мин хәзер ике мәртәбә Социалистик Хезмәт Герое. Туган җиремдә миңа бюст куелырга тиеш икән.

Ә һәйкәл кирәк иде. Каһирга. Кәүсәриягә, «Оборот-минут» Сөләйманга, Идрис абыйга, Прохорга... Әйе, Прохорга да. Тегермәнне Борым авылы кешеләре дә төзеште. Бәйрәмне бергә үткәргән идек бит. Бездә дә, аларда да колхоз оештырып.

һәйкәл кирәк иде. Рамазановка, Җәмлихан муллага, Пеләш Фәткигә, Хөрәсән Шәйдуллага, Наркомга... Мин аны бервакытны эзләгән идем. Табалмадым. «Фаҗигале төстә. 1939 елда...» дигән хәбәрен генә ишеттем.

һәйкәл кирәк иде.

Бетончылар бригадиры Нәүрбәков миңа шуның өчен кирәк иде.

Бер автокран, бер үзбушаткыч (цемент төяп килсен), ике «К-701» тракторы кирәк. Ихтимал, эретеп ябыштыручы. Алар биредә дә бар, билгеле. Ләкин моны мин эшләргә тиеш. Теге елны биредән киткәндә вәгъдә иткәнемчә. Соң булса да, уң булсын. Лаек кешеләрнең җирдә һәйкәлләре калырга тиеш. Дөресрәге, һәйкәл булып — эшләре. Ә эшләрен вакыт инвентарьдан сызып аткач? Менә монда инде һәйкәл кирәк тә кирәк. Хәзергә генә ышанып булмаганын беләм мин. Кешеләр оны тучан. «Кем ашый, ничек ашый, күпме ашый...» Белеп ашасыннар әле! Чагыштырып!

һәйкәл кирәк. Мөмкин кадәр гади... Бер бөтен ипи кебек. Ике тегермән ташы... Берсе аска — пьедесталга. Аннары теге — турбиналы корыч улак. Аның өстенә тагын тегермән ташы. Ә аның өстенә — тузган динамо. Ул шунда, станция чокырында ята... Менә шул. Туган елы — 1929 дип язылыр. Үлгән елы юк. Шуннан аның үлемсезлеге аңлашылып торыр. Мәңгелеге. «Сүнмәс ут бирүчеләргә мәңгелек дан!» Шулай дип язылыр. Тиңе булмаган яңа шәһәрнең һәм автомобиль заводларының беренче комиссары Кыям Сөләйманович Сөләйманов, һәйкәлне ачканда, шулай дияр. Әйтә белә ул.

Нәүрбәков белән сөйләшкәч, җәяүләп кенә ташландык бакча буенча киттем. Кайбер агачларны кан тамчыларыдай вак алма сарган. Кыргый алма. Кыргый әче алма. Кайберәүләрнең язмышы кебек әче алмалар. Теге һәйкәл янына да шушындый бер агач күчереп утыртмаска микән? Ихтимал.

Бакчадан янтаеп, үр сыртыннан түбән төшеп киттем. Ярына кадәр тулып торган, ә кайбер урыннарда инде суы ташып җәелгән елга буенда шалаш утыра. Янына кәбестә өйгәннәр. Яшелчә бакчасы икән. Алюмин торбалар. Каралып калган помидор, кишер, кыяр кишәрлекләреннән узам. Борынны салкында киптерелгән кернең исен хәтерләтүче кәбестә исе ярып керә. Күч янында тукталып, көрәк алам да, чирәмгә сөрткәләгәч, пычагын кәбестәгә якынайтам: әллә тиде, әллә юк, кәбестә башы шартлап ярылды. Яфраклары тыгыз һәм сусыл, тешкә тиярдәй салкын. Саф су кебек туеп булмастай тәм. Күч янында ак мичкәләр тора, аларга кәбестә тозлыйлар икән, берсе яртылаш тулган килеш, кишер турап, тыгызлап тапталган, өстенә күбекле су чыккан. Чеметеп кенә кабып карыйм: кәбестәсе төче, суы тозлы — төкереп атам.

Куышның авызы кечкенә генә, анда мүкәләп диярлек керәсе икән. Иөземә коры җир, печән исе килеп ягыла, күземә караңгылык сирпелә. Кереп, иске тунга сузылып ятам. Сул кул якта йомарлап куелган керле юрган, аяк очында төрле кәгазьле өч шешә — монда, билгеле, сайланып тормыйлардыр, ялгызыңа ни дә ярыйдыр, бигрәк тә салкынча кичләрдә. Куыш авызы турысында — учак урыны, аркылы таякта корымлы чәйнек. Кыям Сөләйманович белән тотарга да кунарга шушында! Мин аңа атасы — «Оборот минут» турында сөйләрмен. Тынлык тыңлап утырырбыз, учак телләренең чигән кызларыдай биешүен карап. Учакка карап утырганда кеше күңелендә озак яшисе килү хисе уяна. Учак янында утырмаганга мең ел инде. Ә ул җылыныр өчен генә түгел, яшәрер өчен дә. Уйлар өчен. Уй яшәртә. Яшәтә.

Күземне йомам. Ә ачканда мең ел үткән булыр шикелле. Минем урында кем ятыр икән? Җир кешесеме? Күктән төшкән затмы? Инде күптән читкә күчкән бу авыл кешеләре сыман, күккә күчеп, җиргә кайт

кан кешеме? Минем кебек, учакка карап уйланып ятаргамы? Җирдә кәбестә үсәр микән? Әллә ул туласмы белән учак урынына әйләнерме?

Уйлар кыска — бер мизгел. Уйларның арасы озын — мең ел.

Кем булыр икән ул — мең елдан соң куышта чалкан ятып, күзен йомган зат? Кайчандыр атом электр станцияләре салып йөргән адәмнәтларның соңгы могиканымы? Куышы кипкән үләннәрдәнме, әллә гравитация вакуумыннанмы?

Мин аның Җир кешеләренә һәйкәл куярга дип кайтуын телим. Менә ул унар-егермешәр метрлы эрем, тигәнәк, аксыргак, тилебәрән басып киткән, кометалар, метеоритлар тузаны каплаган АЭСка якынаер. Кесәсеннән шырпы кабы кадәрле генә бер нәрсә чыгарыр, йөзендәге төрле төймәләргә бармак битен тидергәләп, нидер хисаплар да аны төгәл рәвештә корылмаларга юнәлтеп, куян күзедәй кызыл нурын кабызыр... Һавада сабын куыгы шикелле аллы-гөлле үтә күренмәле ярым шар күрәм. Ул аяз көндәге эссе рәшә сыман калтыранып, дулкынланып, станцияне каплап алган һәм кысыла башлый. Ярымшар кечерәйгәннән-кечерәя, рәшәсе әкрен-әкрен генә төссез ялкынга әверелә бара. Аның астындагы тимер, бетон, пыяла — һәммә нәрсә гармун күреге сыман тартыла, сузыла, җәелә һәм җыерылып кысыла, эри, башта кызыл үт, аннары алтын, көмеш төсе алып, ниһаять, үтә күренмәле булып кала. Ярымшар төссез учакка әверелеп бии, кечерәйгәннән-кечерәя, эчендәге тыгыз, йөгерек сыеклыкны кыса. Мин моны нигәдер көзгедә күрәм шикелле. Нәрсәнеңдер чагылышы. Үткәннеңме? Киләчәкнеңме? Бернинди тавыш ишетмим, ис тоймыйм. Үтә күренмәле капкач белән ябылган ризык (солянка, өчпочмак, илле грамм әрмән коньягы?), тавышы сүндерелгән телевизор (нинди марка?) — ни бу?

Ярымшар яңадан пәйда була башлый, төссез ялкын рәшәгә, рәшә, киңәеп, аллы-гөлле сабын куыгына әйләнә бара, һәм, тавышсыз гына юкка чыга, ә җирдә һәр кыры салават күперенең төсеннән һәм тагын санап, күреп бетергесез хәтсез ярымтоннардан торган алмаз багана басып кала. Алмаз багана җиргә таянмаган килеш басып тора, һәм иң могҗизалысы,— аның аста да, өстә дә очлары, ягъни башы һәм ахыры юк. Ул чагында нәрсә соң ул? Матдәме, әллә рухмы? Вакыт якисә пространствомы? Формуламы яки эшме?

Ә мин ни кыяфәтен, ни киемен хәтерләп өлгермәгән кеше, инде шырпы тартмасы хәтле генә булып калган электр станциясен кесәсенә салгач, баганага таба атлый да, аңа кереп юкка чыга. Шунда гына төсләрнеңниндидер мәгънә белән балкуын тоеп алам. Ул мәгънә ни томанлы, ни болытлы димәслек сүрән күктә күренмәгән, әмма барлыгы сизелеп торган кояшны хәтерләтә.

«Аңнары вакытта чикләнеп,
пространствода кысылып,
кәрәштә янып
алмазга әйләнүчеләргә»,—

дип баганада балкыган төсләр әллә гимн уйный, әллә реквием җырлый, әллә сагышланып елый.

Һәйкәлгә без менә шундый язу язарбыз.

Уйлап карасаң, без үз-үзебезне шулкадәр дә рәхимсез һәм аяусыз төстә эш белән кысабыз, вакытны ашыктырып, шулкадәр дә соң чиккәчә кыздырабыз ки, безнең рухыбыз күптән алмазга әверелергә тиеш!..

Һушыма килдем бугай инде: чалкан яткан җиремнән йөзтүбән әйләндем дә, кулыма һәм тезема таянып, куышның төнге су кебек агарып торган тишегенә таба мүкәләп киттем.

Күчәнендә утырган кәбестә башлары арасыннан кызыл күзле көрән куян карап тора иде.

*Беренче китап тәмам.*

## Нәби Дәүли

### Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар

Яңадан яз килдә яңгырап,
Тынлыктан ташкыннар уяна.
Елгада бозлар да кузгала,
Минем дә йөрәгем куана.

Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар,
Сез кабат чыктыгыз юлларга.
Кар суын кояшта җылытып,
Дөньяның йөзләрен юарга.

Ә дөнья сусаган сафлыкка:
Корымга, төтенгә буялган.
Чәчәкнең шиңгәнен күргәндә,
Мин дә бит яшәргә оялам.

Оялам, үләннән, бөҗәктән,
Балыктан оялам күлләрдә.
Нигә мин яшәргә тиешмен,
Ник алар тиешле үләргә?

Мин кеше, мин көчле, мин хуҗа —
Хаклымы мин шушы исемгә?
Йөрәгем сагышлар тоймаса,
Өзелгән бер яфрак өчен дә!

Уйланам, сызланам шул хакта,
Җир дә бит кайгырып интегә.
Болыттан яңгырлар явармы,
Агулар тамармы ипигә?

Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар,
Уянсын кешедә кешелек.
Ни булыр кап-кара бушлыкта
Калдырсак балалар үстереп?

Аларның телендә нинди сүз,
Нинди сүз буласын мин беләм,
Хәтергә алганда бервакыт
Мин туган, мин үлгән көн белән,

Әйтерләр: «Яшәгән безнең карт,
Каенны кискәләп яндырган.
Ә безгә мираска ташны да
Бары тик зиратта калдырган...»

Уйларың хата, дип әйтегез,
Ялгышып хәсрәткә табынсам.
Хатамнан шатланып калырмын.
Бу сүзләр тудылар сагыштан...

Көннәрем яшәүләр китерсен,
Үләннәр сау-исән калсыннар.
Кайгыны агызып күңелдән,
Шаулагыз, гөрләгез, ташкыннар!

### Яхшы сүз турында

Резервлар эзләп кайберәүләр
Әллә кая барып чыгалар.
Кайберәүләр тыныч кабинетта
Күзләр йомып уйга чумалар.

Югарыдан указ килер диеп,
Телефоннан хәбәр көтәләр.
Моңланалар, авыр уфтаналар,
Урындыкта арып бетәләр.

Яз килгәнме, әллә көз булганмы,
Әллә ярсып давыл исәме?
Ә кешеләрнең йөрәкләре нишли?—
Юк аларның анда исәбе.

Ә йөрәк ул кеше агрегаты,
Атомнардан бәлки көчлерәк.
Йөрәк белән кеше тау күтәрә,
Аңа бары яхшы сүз кирәк.

Ул яхшы сүз утлы сугышларда
Канат бирде солдат күңеленә.
Окоплардан безне кузгатты да
Алып китте җиңү көненә.

Яхшы сүзне оста докторлар да
Кулланалар дару урынына.
Ул сүз тиеш безнең төп законда
Язып куйган канун булырга.

Ул яхшы сүз — бөек энергия,
Өшеп калган җанны җылыта.
Шатлык белән сине көчле итә,
Күзләреңнән яшьне корыта.

Ул резерв яши үзебездә,
Ник йөриләр эзләп еpактан.
Беркем, беркем бурычка да
бирмәс,
Яхшы сүзне телдән югалтсаң.

Сусаганда чишмә суы тәмле,
Зур шифалы бәлзәм тәслерәк.
Картаймаска, чәчләр агартмаска,
Безгә, дуслар, яхшы сүз кирәк.

Җиерчыклар йөздә азрак булыр,
Ә йөрәкләр булыр көчлерәк.
Озак, озак гомер итәр өчен
Безгә, дуслар, яхшы сүз кирәк!

## Син — миңа, мин — сиңа

Мин бер чыбык ташлыйм учакка,
Син бер чыбык китер учакка.
Яктылыгы балкыр еракка,
Нуры белән охшар кояшка.
Без әйтергә хаклы шул чакта:
— Син — миңа, мин — сиңа!

Бер бүрәнә алып куйганда,
Мин бер очтан тотып торганда,
Син бер очтан күтәр кулларга,
Күпер салып барлык юлларга,
Тир тамчысы йөзне юганда,
— Син — миңа, мин — сиңа!

Мин кайгыдан янып йөргәндә,
Язмышымны авыр дигәндә,
Шатланырмын сине күргәндә.
Бер тамчы су миңа бирсәң дә,
Матур хәбәр алып килгәндә.
— Син — миңа, мин — сиңа!

Үрләр аша барган чагымда,
Син дә булсаң минем янымда,
Корал тотып көрәш явында,
Атакада танк алдында,
Бергә барсак җиңү алырга.
— Син — миңа, мин — сиңа.

Яралансаң әгәр син элек,
Коткарырмын, сиңа кул биреп.
Ярчык екса кинәт, бер тиеп,
Күтәрерсең мине син килеп.
Без әйтәбез моны ант диеп!
— Син — миңа, мин — сиңа!

Изге канун бар бит дөньяда,
Гадел өлеш — сиңа, миңа да.
Бер телемне бүлсәк уртага,
Күзгә карап кеше дус таба,
Йөрәкләргә — йөрәк юл сала!
— Син — миңа, мин — сиңа.

Шушы канун — яшәү шатлыгы,
Тормышның ул ахак сафлыгы,
Күңелләрнең керсез аклыгы.
Тоткан чакта бөек атомны,
Без булырга тиеш ак куллы.
— Син — миңа, мин — сиңа!

Әгәр миңа яхшылык итсәң,
Мәрхәмәтне бурычка бирсәң,
Миннән дә син бер «калым» көтсәң.
Кара хурлык йөзләргә төшәр,
Безнең ара өзгән дә, кискән,
— Син — миңа да, мин — сиңа,—
дисәң.

## Синең туган көнеңә

*Жыр*

Әллә язмы, әллә көзме,
Болытлымы әллә көн,
Әллә җилләр исәме?
Әллә син күрше йорттамы,
Әллә ерак җирдәме?

Котлыйм туган көнең белән,
Бу иртәдә, бу көндә.
Бәлки кемдер оныткандыр,
Сиңа чәчәк бирергә.
Ә мин җыр бүләк итәм.

Мәхәббәтең сине тапсын,
Кичекмәсен юлларда.
Шушы минем теләгем.
Чәчәкләр китермәсә дә,
Алып килсен йөрәген.

Котлыйм туган көнең белән,
Сине бит дөнья көткән.
Зәңгәргә төнне бизәгән,
Таңнарны алсу иткән.
Ә мин җыр бүләк итәм.

Кайгыңны белер дусларың,
Йөзеңә карап күрер.
Туган ил сиңа бәхетне
Үз кулы белән бирер.
Ә мин җыр бүләк итәм.

## Мин — бередә, син — арыда

*Жыр*

Син килдең дә, бер күрендең,
Йөрәгемә үрелдең.
Бу дөньяда син булганда,
Мин дә ялгыз түгелмен.

Мин — бередә, син — арыда,
Ерак юллар арасы.
Юллардан әллә барасы,
Әллә бармый каласы.

Очрашулар көттек, көттек,
Яки язын, я көздә.
Бер бәхет тә җитәр иде
Гомергә икебезгә.

Икебез ике тарафта,
Ишетмәссең сүземне.
Язлар узды, көзләр килде,
Җиргә яфрак сибелде.

Көннәр уза, сине уйлыйм,
Янам да, һаман көям.
Кайсыдыр ерак шәһәрдә
Минем дустым бар диям.

●

Хатыннар яшәр иде,
Йөз яшькә кадәр.
Балалары сугышларда
Үлмәсә әгәр,

Ирләре дә азып-тузып
Йөрмәсә әгәр,
Йөрәкләрен кайгылары
Өзмәсә әгәр,

Хатыннар яшәр иде
Йөздән дә артык.
Алар дөнья нужаларын
Баралар тартып.

## Бер этюд

Әйтерсең боз кисәкләре —
Болытлар йөзеп йөри.
Кайсылары эри,
нигә эри?
Җиргә төшәргә тели.

Җир аларны кочып ала,
Бишегенә илтеп сала.
Кешеләр әнә шул бишектән
Кулларына икмәк ала.

## Кеше белән бүре нинди?

Бүре урманда
Кеше баласын назлап үстерде.

Кеше бүрене
Урманда күреп атып үтерде.

## Бакый ага Урманчега

*Автограф*

Син кояштан нурлар алдың,
Чәчәкләрдән таптың буяуны.
Синең куллар тиеп китсә,
Таш та уянды,
Таш та уйланды,
Таш та җырлады,
Таш та моңланды.

●

Тормыш безнең куллар аша
Орлык булып җиргә күчә.
Алтын чәчсәң — алтын үсми,
Тирес сипсәң, алтын үсә.

## Мирас

Ул яшәде, үлде. Варисларын
Беркемгә дә васыять итмәде.

Кулдан-кулга алып бүлешергә
Безгә калды аның икмәге.

●

Дошманнар шатланмасыннар,
Без кайгы кичергәндә.

Ал байрак үбеп елыйбыз,
Илгә ант китергәндә.

*1981—83*

# Афзал Шамов

# БЕР ҖАМАЯК СӨТ

хикәя



Бу хәл 1944 елны фронтта булды. Алгы кырыйга бик ашыгып барганда, Глубокое шәһәрендә машинабызның берьюлы ике камерасы тишелде. Мине, тагын ике корреспондентны утыртып алып баручы шофер — азербайҗанлы Али Бала ләпшерәгән көпчәкләргә аягы белән типкәләп карады да, башын чайкап, бик өметсез сызгырып куйды:

— Бәла өстенә бәла!

Безнең белән бергә баручы майор Игнатов сәгатенә карап алды:

— Моны аяклы итәр өчен күпме вакыт кирәк?

— Ким дигәндә бер сәгать.

— Ярты сәгать эчендә рәтләп булмасмы?

— Юк, булмый, иптәш майор,— диде Али Бала, чем кара бөдрәләрен селкеп.— Бер сәгатьтә өлгерсәм бик яхшы. Камераларымда ямау өстендә ямау. Теләнче капчыгы диярсең. Яңаларны һаман бирмиләр.— Шул сүзләрне әйтә-әйтә ул инструментларын җиргә сибеп салды да машина күтәртү өчен домкратын кулына алды.

Бу бер сәгатьне без бик әрәм уза торган вакыт итеп санадык. Чөнки бу көннәрдә бөтен фронт буйлап һөҗүм сугышлары бара, ул вакыт эчендә безнең гаскәрләрнең шактый ерак китүләре мөмкин. Ә редакциягә яңа хәбәрләрне, репортажларны, әгәр мөмкин булса, кичерәк бер очеркны телеграф беләнме, кыр телефоны беләнме яисә башкачамы, бүген үк тапшырырга кирәк. Шунсыз ярамый.

Без өчәү, өч хәрби корреспондент, аягүрә баскан хәлдә генә киңәшеп алдык. Нишләргә? Виллис төзәтелгәнне көтәргәме, әллә алгы кырыйга таба баручы берәр машинага утырып, хәзер үк, шушы минутта ук китәргәме? Китсәк, Али Бала безне ничек табар?

Бик тиз бер карарга килдек. Мин машина белән калам, ә иптәшләрем сәфәрләрен дәвам иттерәләр. Озакламыйча алар, снарядлар төяп баручы бер студебеккерны кул күтәреп туктаттылар да, ящиклар өстенә менеп утырып, китеп тә бардылар.

Мин Али Бала янында калдым, эшне тизләтү өчен аңа ярдәмемне тәкъдим иттем.

— Юк, иптәш капитан, пычранмагыз,— диде ул.— Сезнең эш түгел бу — минем эш. Тик онытмагыз, бер сәгатьтән минем янда булыгыз.

Мин, газета өчен берәр кызыклы материал табып булмасмы икән дип уйлап, шәһәр урамы буйлап китеп бардым.

Шәһәр зур түгел — район үзәге. Халкы биш-алты меңнән артык бул-

мас. Бәлки аннан да кимрәктер. Таш йортлар үзәк урамнарда гына, ә калганнарында — күбесе бер катлы агач өйләр.

Фашистлар коллыгыннан әле ул кичә генә азат ителгән. Егерменче гасыр варварлары үз эшләрен эшләгәннәр, шәһәрне яндырып, ватып, җимереп чигенгәннәр.

Мин бара торган урамда уңда да, сулда да ватык, җимерек таш йортлар, янгыннан соң кара булып ыржаеп торган тәрәзә, ишек урыннары, хәсрәтле, кайгылы нигезләр. Агач йортлар янып көлгә әверелгәннәр,— кайчандыр монда тормыш булганлыгын белдереп, корымлы морҗалары гына, мескен булып, тырпаеп торалар.

Без менә ничә ел инде мондый хәрабәләрне, дәһшәтләрне һәр көнне, һәр сәгать күреп киләбез, ләкин яннарыннан беркайчан да гамьсез күңел белән узып китә алмыйбыз. Җаныбыз әрни, йөрәкләребез ярсый, боларның барысы өчен дә, барысы өчен дә фашистлардан, котырган ерткычлардан үч алырга, изге, мөкатдәс үчкә ашкынабыз.

Бөтен әйләнә-тирә шомлы, дәһшәтле, куркыныч... Янгыннар сүнгән булса да, кайбер йортлар әле һаман төтенләп, пыскып яталар. Шәһәрдән төтен исе, дары исе, үлем исе килә.

Урамнар әле җыештырылмаган. Таш, ватык кирпеч өемнәре, күмерләнгән бүрәнәләр, чүп-чар, немецлар ташлап качкан техника белән тулы.

Урамда шәһәр кешеләре очраштыргалый. Алар, безне күргәч, ерактан ук сәлам бирәләр, җиңүебез белән котлыйлар, шатлыгыбызны уртаклашалар. Без дә, бу дәһшәтле сугышта тоткан урыныбызны, дәрәҗәбезне белеп, сәламнәрен алабыз, сәлам кайтарабыз.

Мәйдан шикелләрәк бер җирдә, башка йортлардан аерым утырган ярым җимерек бер бина игътибарымны җәлеп итте. Фасады, җимерелмичә калган өлеше, тәрәзәләре, тәрәзә өсләре, болдыры — барысы да шәрык архитектурасын хәтерләтәләр. «Нинди йорт икән бу? — дип уйладым мин.— Монда бит руслар белән белоруслар, поляклар, литвалылар гына яши. Шулай булгач, монда шәрык стилендәге йортның булуы бик гаҗәп».

Шундый уйлар белән мин ул йорт янына бастым, берничә минут аңа гаҗәпләнеп карап тордым, аннары тирәле әйләнеп чыктым. Әйләнә-тирәсе таш, кирпеч ватыклары белән тулы. Шулар арасында калҗайган, бөгәрләнгән, теткәләнгән калай кисәкләре сибелеп ята... Тукта, нәрсә бу? Гөмбәз түгелме соң? Иелеп, аның өстендә яткан кирпеч ватыкларын, калай кисәкләрен, чүп-чарларны алып ташладым. Чыннан да, гөмбәз, мәчет гөмбәзе! Өч гөмбәз. Берсе зур, икесе кечерәк. Очында алтын йөгертелгән ае да бар. Сынмаган, ватылмаган, тик янчелгән генә. Нинди халык мәчете бу? Ник салганнар аны монда? Ялгышмасам, монда яшәүче халыкларның берсе дә ислам динен тотмый шикелле. Шулай булгач, бу мәчетнең монда ни кирәге булган? Башка берәр бина түгелме икән? Ялгышмыйммы икән?..

Урамнан узып баручы бер белорус картын туктатып, бу җимерек йортның нинди бина икәнен сорадым.

— Мәчет,— диде ул.

— Мәчет?.. Нинди мәчет? Кемнәрнеке?

— Татарларныкы.

— Нинди татарларныкы?

— Польша татарларыныкы [1].

---

[1] Польшада һәм Белоруссиянең көнбатыш өлкәләрендә яшәүче татарлар. Аларның борынгы бабалары, Җәләлетдин хан җитәкчелегендә Алтын Урдадан килеп, 1410 елда, поляк-литва, рус гаскәрләре белән берлектә (Литваның союздашы булып), Грюнвальд сугышларында катнашканнар, немец Тевтон ордены рыцарьларын тар-мар иткәннәр. Шулай итеп, рыцарьларның көнчыгышка таба ябырылып килүләренә чик куелган. Шул сугышларда катнашкан татар атлы сугышчылары Польша һәм Литва җирләрендә гомерлеккә урнашып калганнар. **Автор.**

Алар турында тарих битләреннән укыган булсам да, үзләрен күргәнем юк иде. Тиз генә сәгатемә карап алдым. Әле вакыт бар. Мөмкинлектән файдаланып, аларны күреп китәргә кирәк. Нинди кешеләр алар? Ничек яшиләр, ничек көн күрәләр? Культуралары ни дәрәҗәдә? Гореф-гадәтләре?..

— Күпме алар монда, сезнең шәһәрдә?

— Кем белгән аны, кем санаган,— диде карт, кулын селтәп.— Шулай да шактый булса кирәк... Бер урамны тутырып торалар диярлек.

Ул урамның кайдалыгын сорагач, агай кулы белән көньякка таба күрсәтте:

— Әнә тегендә, шәһәр читендә. Моннан ерак түгел. Бу урам белән китеп, сулга борылсаң...

Мин, аның сүзен бүлеп:

— Ә бу тирәдә торучылар юкмы?— дип сорадым.

— Ник булмасын, бар. Әнә теге машинаны күрәсезме?— дип, ул безнең виллиска таба төртеп күрсәтте.— Бер солдат нәрсәдер эшләп маташа анда... Әһә! Күрсәгез, менә шул турыда, сул якта янмый калган өч йорт бармы?.. Бар. Шул йортларның өчесе дә татарларныкы.

Поляк татарларының тормышлары, гореф-гадәтләре турында бераз сораштыргалаганнан соң, карт миңа киңәш итте:

— Әгәр аларның берәрсен күрергә теләсәгез, иптәш офицер, ул чакта сез Абдулла Мусинский дигәне янына керегез. Русча яхшы сөйләшә ул. Башкалары кебек түгел.

— Кайсы йортта тора ул?

— Шул өч йортның уртагысында. Сары капкалысында.

— Нинди рәк кеше соң ул?

Белорус агай соравымны аңлап бетермәде булса кирәк, төшендереп бирергә туры килде:

— Баймы, ярлымы дип әйтүем.

— Ә-ә-ә, шуны соравыгызмыни? — диде ул, бераз көйләбрәк сузып.— Ничек дияргә инде аны сезгә... Бай да, ярлы да түгел ул. Кыскасы, рәтле хуҗа... Рәтле кеше.

Мин, киңәше өчен аңа рәхмәт әйтеп, сары капкалы агач йортка таба киттем.

Рәтле хуҗа?.. Рәтле кеше?.. Ни дигән сүзе булды икән аның? Моның белән ни әйтергә теләде икән ул? Хуҗалыгы рәтле, тәртипле дип әйтүе булдымы, әллә башка берәр мәгънә ятамы икән бу сүздә?.. Ярар, күз күрер, тик өйдә генә туры килсен.

...Берничә минуттан мин инде Абдулла Мусинский өендә, түрдә, өстәл янында сөйләшеп утыра идем. Ул мине бик ачык чырай белән каршы алды:

— Әйдәгез, рәхим итегез, пан капитан, түрдән узыгыз,— диде.— Бик кадерле кунак сез безгә. Өч ел көттек без сезне...

Чигә чәчләре шактый агара башлаган, илле-илле биш яшьләр тирәсендәге, озын буйлы, какча гәүдәле, кысык күзле кеше иде ул. Бер караганда монголга, икенче караганда казахка охшый. «Кара әле, Идел буе татарларына бер дә охшамаган лабаса бу»,— дип уйлап алдым мин.

Хуҗа сөйләвендә дәвам итте:

— Рәхмәт сезгә, бик зур рәхмәт! Коткардыгыз. Чынын әйтәм, валлаһи менә, эшләр харап иде безнең. Фашистлар, муеннары аска килгере нәрсәләр, кешегә санамадылар безне, хайван урынына йөрттеләр... Килеп керәләр дә: «Бир!» Килеп керәләр дә: «Бир!» Атыңны да, сыерыңны да бир! Ыштаныңны да салып бир. Оятсызлар, хатыныңны да алып чыгып китәргә әзер торалар. Татар икәнебезне белгәч, бигрәк котырындылар. Имеш, без кеше түгел — татар... Аларча әйткәндә, кыр-

гый халык, түбән халык, дөньяда яшәргә хакы булмаган халык... Менә бит ул ничек, пан капитан, әгәр белсәгез иде сез...

Белорус карты дөрес әйткән икән, хуҗа русча яхшы сөйләшә иде.

Бүлмәсенә күз төшереп алдым. Бернәрсә юк, буп-буш, җилләр уйный диярлек. Берничә гади урындык, шундый ук гади өстәл. Өстәл өстенә дә берни җәймәгәннәр. Түрдә, ике тәрәзә арасында, бик борынгы стильдәге савыт-саба шкафы. Ул да буш, тик берничә чынаяк белән берничә тәлинкә генә тора. Кием-салымнары да күренми. Яшергәннәр, фашистларның талап чыгуларыннан курыкканнар булса кирәк. Әллә инде талап чыгып киткәннәр дәме?

— Шәһәребез сугышка чаклы бик матур иде безнең, пан капитан,— дип, Абдулла Мусинский сөйләвендә дәвам итте. Ул үзенең туган-үскән шәһәрен бик ярата иде булса кирәк, чөнки аның матурлыгы, төзеклеге турында сөйли башлагач, карасу күзләре ничектер җанланып, чаткыланып киттеләр, үзе дә урыныннан кузгалып, урындыгы-ние белән каршыма килеп утырды.— Әгәр сез аны элек күргән булсагыз иде, пан капитан, валлаһи, исегез-акылыгыз китәр иде. Гөл бакчасы сыман иде ул. Урамнарны тутырып агачлар шаулап үсеп утыра: каеннар, юкәләр, карамалар... Бакчаларда алмагачлар, грушалар, чияләр. Башка төрле җиләк-җимешне әйтәсе дә юк. Менә шундый шәһәрне алар, муеннары аска килгере нәрсәләр, ватып, җимереп, яндырып, харап итеп киттеләр...

Зарлары урынлы булса да, мин сүзне икенче темага күчерергә теләдем. Минe, барыннан да бигрәк, аларның тормышлары, гореф-гадәтләре кызыксындыра иде.

— Шәһәрегездә татарлар күпме, иптәш Мусинский?

— Әллә ни күп түгел,— дию белән генә чикләнде ул.— Польша белән Литвада күп алар. Йөз меңнән артык.

Мин аңа ничек көн күрүләре, нинди кәсеп белән шөгыльләнүләре турында бер-ике сорау бирдем.

— Ничек дип әйтергә икән аны сезгә, пан капитан,— дип ул, башын кашып, бераз уйланып торды.— Төрлебез төрле кәсеп белән маташабыз шунда... Элегрәк сәүдә итүчеләр дә бар иде. Аннары, кайда туры килде шунда эшләүчеләр дә юк түгел. Әйтик, май заводында да, консерв заводында да. Нишләрбез инде, белмим. Заводларны каһәр суккан фашистлар шартлатып киттеләр. Ә болай татарларның шактый өлеше тире иләү, күн эшләре белән шөгыльләнә. Мин дә шуның белән тамак туйдырып торам. Ат сбруйлары ясыйбыз, камыт, ыңгырчак, эшлея, йөгән, башка шуның кебек кирәк-яраклар дигәндәй. Ата-бабадан килгән һөнәр, күнегелгән эш...

Мин аның тамырланып торган кулларына күз төшереп алдым, алар дегет белән, төрле химикатлар белән каралып, яргаланып беткән иде.

— Татарча сөйләшә беләсезме?— дип сорадым мин.

— Юк, белмибез. Борынгы бабалар гына белгәннәр, ә безнең ата-бабалар инде татарча сөйләшмәгәннәр, үз телләрен онытканнар. Без полякча сөйләшәбез. Балаларым да полякча сөйләшәләр, поляк мәктәбендә укыдылар. Ә мулла белә иде.

— Кайда соң ул хәзер?

— Кайда булсын, немецлар белән качты. Алар җырын җырлый иде ул.

Мин аңа үземнең татар икәнемне әйтергә кирәк таптым. Мусинский моңа бик гаҗәпләнде, әмма ышанмады,— ышанмавы йөзенә чыкты. Шуның белән бергә аның кысык күзләрен: «Шаярма, егет, мине тиз генә алдалый алмассың, мин бик үк төшеп калганнардан түгел»,— дип тә әйтеп тора иде.

— Юк,— диде ул, башын чайкап,— юк, пан капитан, шаяртасыз булса кирәк. Татар түгелдер сез... Болай гына, юри генә әйтәсездер. Дөрес, минем Казан татарларын күргәнем юк...

— Чынлап әйтәм, нигә шаяртыйм,— дидем аңа. Татар икәнемне шуннан артык исбатлап торуымны кирәк тапмадым. Теләсә нәрсә уйласын, татармы, русмы, чувашмы, марими — барыбер түгелмени! Тегеянсә бу милләт кешесе булудамыни эш!

— Туктагыз әле, күршебездә Әхмәт исемле кеше бар безнең. Герман сугышы вакытында ул Казанда хезмәт иткән. Аны чакырыйм әле. Ул, урыныннан торып, ишек алдына караган тәрәзәләрнең берсе янына килде дә, аңа башын тыгып, тыштагы кешеләрнең берсенә, әллә балаларына, әллә хатынына полякча нәрсәләрдер әйтеп кычкырды. Мин аның Әхмәт дигән сүзен генә аңладым.

Сәгатемә күз төшердем, урамга да карап алдым. Али Бала әле эшен бетермәгән иде.

Хуҗа яңадан каршыма килеп утырды, мондагы татарларның тормышлары, көнкүрешләре турындагы сүзне дәвам иттердек. Бераздан ул миннән һич көтмәгәндә:

— Пан капитан, бисмилла әйтә беләсезме?— дип сорады.

Мин чак көлеп җибәрмәдем. Ул әле һаман тынычланмый, «ялганымны» фаш итәргә тели. Бәлки фаш итәргә теләве дә түгелдер, бары минем белән, Казан татары белән кызыксынуы гынадыр.

Мин бисмилланы гына түгел, әгузыны да беләм. Сабагын яхшы белүче малай кебек, һич тотлыкмыйча әйтеп бирдем. Хуҗаның шиге кими төште. Шулай да тынычланмады, мине имтихан кылуында дәвам итте.

— Сез мине, пан капитан, гафу итегез. Намаз укый беләсезме дип сорыйсым килә минем сездән. Тик, зинһар, ачуланмагыз. Бисмилланы белгәч, анысын да белә торгансыздыр дип әйтүем.

— Беләм, нигә белмәскә,— дидем бусы турында да.— Биш вакыт намазның бишесен дә беләм.

Шөкерләр булсын, намаз укып күрсәтүемне таләп итмәде. Хәер, таләп итсә дә, укымас идем. Яшермим, намазларның исемнәре белән рәкәгатьләре генә исемдә калган, ниятләү догаларын һәм башка шуның кебекләрен онытканмын. Бөек Октябрь революциясенең башыннан бирле мәчеткә барганым, намаз укыганым юк.

Мусинский инде миңа ышана сыман тоелса да, шиге бетмәгән икән әле. Ул, бик бирелеп, карта уйнаучы кеше кебек үҗәтләнеп, күземә туп-туры карап, иң соңгы «козырен» чыгарды. Әгәр бу сорауга җавап бирә алсам, татар икәнемә генә түгел, чын мөселман икәнемә дә ышаначак, ә җавап бирә алмасам — юк. Ул, бик җитди итеп:

— Коръән дә укый беләсезме?— дип сорады.

Ничек белмәскә! Бала чакта мин иске мәдрәсәдә укыдым. Авылча әйткәндә, мәдрәсәгә йөреп, чабата туздырдым. Коръәнне безгә анда таяк белән дә, тал чыбык белән дә, камчы белән дә укыталар иде. Белмәсәк, дөрес укымасак,— барысын да татыдык. Хәлфәләремә рәхмәт, тал чыбыгы миңа ул чаклы эләкмәде, тырышлыгымны, һәвәслегемне искә алдылар, бары шәрикләремне сабакларын өйрәтмәгән өчен генә, идәнгә сузып салып, кыйнаган чаклары булгалады. Әмма менә мәкам белән укуга килгәндә, анысын яшермим, көйгә, моңга осталыгым юк, табигать мине андый сәләттән мәхрүм иткән.

Хуҗа, уңай җавабымны ишеткәч, нигәдер бераз уйга калды, аннары, ниндидер бер фикергә килгән кешедәй, урыныннан торды да, мин хәзер керәм, гафу итегез, дип әйтеп, өйдән чыгып китте. Бер минут та узмагандыр, кулына коръән тотып, килеп керде. Бисмилла әйтеп, аны өстәл өстенә, минем алга бик тантаналы итеп китереп куйды (бисмил-

ланы ул шулчаклы ватып, җимереп әйтте ки, әгәр мин бу өйнең кунагы булмасам, кычкырып көлеп җибәргән булыр идем). Коръән укытыр дип уйламаган идем, моны көтмәгән идем. Нишлисең, укып күрсәтергә туры килә.

Яшел сафьян белән тышланган тулы коръән иде ул. Титул битен ачам. 1898 елда Казанда, брадарән Кәримовлар матбагасында басылган. Санкт-Петербург цензурасының басарга биргән рөхсәте дә күрсәтелгән.

— Кайсы сүрәне укыйм?

— «Кол һу алла»ны.— Бу өч сүзнең өчесен бергә кушып әйтсә дә, аңладым.

Коръәннең ахыргы битләренең берсендә иде ул сүрә. Мин аны циркта фокус күрсәтүче иллюзионист кебек тиз таптым. Әгузы-бисмилла әйтеп, көйләп укып бирдем. Ул чакта әле мин бу сүрәне яттан да белә идем, хәтерем яхшы иде. Тагын бер-ике кыскарак сүрәне укып күрсәттем.

Мин коръән укып маташканда, бүлмәгә, безнең янга, агач аяклы бер карт килеп керде һәм, минем нәрсә белән шөгыльләнүемне күргәч, шунда, ишек төбендә таштай катып калды. Хуҗаның да, әле генә өйгә килеп кергән агач аяклы, базык гәүдәле картның да бу минутта гаҗәпләнүләреннән карасу күзләре шар ачылган иде.

Башта хуҗа аңына килде, мин сүрәләрне укып бетерү белән үк ул, аксак картка карап:

— Әхмәт, таныш бул, бу пан капитан — мөселман офицеры!— дип рухланып кычкырып җибәрде. Аннары мине мактарга керешге:— Пан капитан, сез безнең мулладан да яхшырак укыйсыз икән! Валлаһи, яхшырак!..

— Үзегез укый беләсезме соң?— дип сорадым мин аның үзеннән.

— Юк, белмим. Мулла белә иде.

Мин коръән битләре кырыена гарәп хәрефләре белән язылган рус сүзләрен күрсәттем. Анда сүрә исемнәре янына «В пятницу читать», «В четверг читать», «В понедельник читать»... дигән сүзләр язылган иде.

— Ә боларны кем язды?

— Эти мәрхүм язган аларны. Ул гарәп хәрефләре белән укый да, яза да белә иде.

— Кайда укыган ул?

— Вильнюста. Хәзер дә мулла бар анда. Үзен күргәнем юк. Әмма күргән кешеләр әйтәләр: бик галим, бик белемле мулла, диләр...

...Бераздан өй эче кеше белән тулды. Араларында хатын-кызлар да, бала-чагалар да бар. Казан татарын, коръән укый белүче офицерны, пан капитанны күрергә кергәннәр алар. Күрәсең, алар өчен кызык кеше идем мин. Кем белә, бәлки мин алар йортына аяк баскан беренче совет офицеры да булганмындыр. Чөнки шәһәр 1939 елның сентябренә чаклы буржуаз Польша территориясендә булган, безнең гаскәрләрнең Көнбатыш Белоруссияне азат итү өчен алып барган походлары вакытында гына Советлар Союзына кушылган. Ә кырык беренче елны аны гитлерчылар басып алганнар. Кичә аны фашистлар коллыгыннан коткарган безнең гаскәрләр, монда туктап тормыйча, сугыша-сугыша узып киткәннәр. Хәтта икенче эшелоннар да туктамаганнар, алар да сугышлар дәвам иткән җиргә юл тотканнар. Шуның өстенә әле шәһәрдә совет власте урнашып җитмәгән, халык арасында политик аңлату, совет властеның тоткан юлы белән таныштыру эшләре дә башланмаган. Кыскасы, мин Казан татары гына түгел, Совет власте вәкиле дә идем алар каршында. Шуңа күрә алар мине төрле сораулар белән күмделәр. Илебез тормышындагы бөтен мәсьәлә — иң зурысыннан алып, иң кечкенәсенә хәтле — барысы да кызыксындыра иде аларны: халкыбызның көн-

көреше, материаль хәле, культурасы, колхозлар, завод-фабрикалар, андагы эш шартлары, әйбер бәяләре, сәүдәләр, Коммунистлар партиясе һәм Совет властеның милли политикасы, дингә булган мөнәсәбәте һәм башкалар, һәм башкалар...

Сорауларына мөмкин чаклы ачык, аңлаешлы итеп җавап бирергә тырыштым.

Без сөйләшеп утырган арада кырык-илле яшьләр чамасындагы, яланаяклы бер хатын, хуҗа хатыны булса кирәк, өстәл өстенә чигешле ап-ак ашъяулык кертеп җәйде, зур агач җамаяк белән сөт китереп куйды. Күптән сөт эчкәнем юк, бик тансык иде ул миңа.

— Эчегез, рәхим итегез, пан капитан,— диде Абдулла Мусинский.— Тамагыгыз ачыккандыр. Юл кешесе, сугыш кешесе бит сез.

Мин, рәхмәт әйтеп, җамаякны кулыма алдым. Каршымда кешеләр басып тора, күзләре миндә. Бала-чагаларның да күзләре миндә. Минем дә шундый матур, шундый кечкенә балаларым бар. Кайчак, алар искә төшкәндә күңелем тула, бер-ике бөртек күз яшем үзеннән-үзе тәгәри, тыя алмыйм, иптәшләремә күрсәтмичә генә сөртеп алам. Оят булганга түгел, юк, ә солдат чыдам булырга, нык булырга, күңел хисләренә бирелмәскә тиеш булганга яшерәм. Балаларым еракта, Казанда, ә хатынымның алар турында язган хаты якында, кесәмдә генә.

Кечкенәбез дүртне тутырып, бишенче белән бара. Ә хатыным аны әле һаман имезә икән. Күкрәгендә сөт булмаса да, имезә икән бәгырем. Сөт сатып алырга хәле булмаганга имезә ул аны.

Күптән түгел генә бер иптәшем Казанда булып кайтты. Шул әйтте: квартираңда булдым, хатыныңны да, балаларыңны да күрдем, бик ябыкканнар, диде. Уртанчы кызың шәм кебек эреп бара, диде, йөрәгемне өзеп алды. Беләм, балаларымның сәламәтлеге яхшы түгел. Мин сугышка киткәнче үк әле врачлар миңа аларны яхшы ашатып-эчертеп, сөт белән майда гына тотарга киңәш иткәннәр иде. Сөт белән майда?.. Каян алсыннар алар аны!.. Хәзер, менә монда, кулымда бер җамаяк сөт. Белорус орнаментлары белән бизәп-сырлап ясалган җамаяк. Мөлдерәмә булып тулып тора... Нигәдер кулым калтырый, теләмәсәм дә, ничаклы тыярга тырышсам да, күңелем тулып килә. Каршымда балалар басып тора. Пычракта, тузанда йөри-йөри каралып, ярылып беткән ялан тәпиле балалар. Күзләре миндә...

Абдулла Мусинский кыставын дәвам итә:

— Рәхим итегез, пан капитан, эчегез, эч, яңа сауган сөт.

Мин, аның сүзенә буйсынып, сөтне авызыма алам, эчәргә телим, ләкин, ни гаҗәп, йота алмыйм, никадәр тырышсам да, көчәнсәм дә, тамагымнан узмый. Тамагыма нәрсәдер, ниндидер каты төер килеп тыгылды, шул җибәрми, шул үткәрми... Кешеләр миңа карап торалар, ялан тәпиле балалар да миңа карап торалар, ә мин бер йотым сөтне йота алмыйча азапланам... Ничек эчим, ничек йотыйм мин аны? Еракта балаларым сөткә мохтаҗ, бер йотым сөт өчен тилмерәләр. Минем балалар гына түгел, меңнәрчә, миллионнарча балалар мохтаҗ...

Җамаякны өстәл өстенә кире куйдым, ә үзем, ачык тәрәзәләрнең берсенә барып, авызымдагы сөтне урамга төкерергә мәҗбүр булдым.

— Гафу итегез, эчә алмыйм,— дидем мин кунакчыл хуҗага.— Алып куегыз, зинһар. Рәхмәт!

Хуҗа гына түгел, каршымда басып торган кешеләр дә моңа бик гаҗәпләнделәр.

— Нигә эчә алмыйсыз, пан капитан?— дип сорады Мусинский.— Әллә ярамыймы? Я булмаса, чирканасызмы? Чирканмагыз, пан капитан, эчегез, пакь сөт. Әнә Хәдичәмә карагыз, бик чиста хатын ул. Ашамлыкка беркайчан да кулын юмыйча, бисмилла әйтмичә орынмый. Шулай бит, Хәдичә?.. Нигә авызыңны йомып басып торасың?! Шулай диген, әйт...

Хәдичә, сөтне эчә алмавымны күреп, хуҗаның үзеннән дә битәр гаҗәпләнгән, хәтта сүздән калган иде.

Абдулла Мусинский сөйләвендә дәвам итте:

— Бу сөтне без сезнең алга чын күңелдән куйдык... Бик кадерле кунак сез безгә... Туган илебез турында сез безгә бик яхшы сүзләр сөйләдегез, һәркайсы йөрәгебезгә май булып ятты... Әгәр эчәргә яраса, пан капитан, эчегез сез аны...

Мин аңа ни өчен эчә алмавымның сәбәбен әйтергә мәҗбүр булдым.

— Менә нәрсә, Абдулла абзый,— дидем мин аңа. Абзый дигән сүзне татарча әйттем, мәгънәсен русча аңлатып бирдем.— Үзегез беләсез, бу көннәрдә без бик күп авылларны, шәһәрләрне илбасарлардан азат иттек. Азат итүне дәвам итәбез. Шундый авылларның, шәһәрләрнең кайсына гына аяк басма, барысында да ачлар, ялангачлар. Бигрәк тә балалар, әти-әнисез калган меңнәрчә ятимнәр. Бер телем ипигә, бер йотым сөткә тилмерүче балалар... Шундый ачларны, шундый балаларны үз күзем белән күреп торганда, бу сөтне мин ничек эчим? Ничек ашыйм?.. Тамагымнан узмый, йота алмыйм мин аны. Сез мине гафу итегез,— дидем. Үз балаларым турында бер сүз әйтмәдем, аңламаслар, аларны күз алдына китерә алмаслар дип уйладым.

Өйдәгеләр тынып калдылар.

— Дөрес, дөрес әйтәсез, пан капитан,— диде Абдулла Мусинский, минем фикерне җөпләп.— Ач-ялангачлар бик күп хәзер. Бик күп! Каһәр суккыры Гитлер, кабәхәт дуңгыз, бөтен дөньяны канга, күз яшенә батырды...

Ул арада Али Бала килеп керде, машинабызның төзәлгәнлеген әйтте. Мин, урынымнан торып, зурлар белән кул биреп саубуллаштым. Ишек төбенә җитәрәк, түзмәдем, өч-дүрт яшьлек кечкенә бер кызны күтәреп алып, иркәләргә, сөяргә керештем. Нәрсәсе беләндер ул минем кечкенә кызымны хәтерләтә иде. Күңелем тулган иде, бер-ике бөртек күз яшемнең тәгәрәве мөмкин иде. Моны күрмәсеннәр, сизмәсеннәр өчен баланы идәнгә бастырдым да, үзем, берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, эндәшмичә, зур-зур атлап, машинага таба киттем.

Өйдәгеләр, безне урамга чыгып, озылап озатып калдылар, дошманны тизрәк җиңүебезне үтенделәр.

Машинабыз шаулап, гөрләп кузгалып китте.

Сугыш беткәннән соң берничә ел узгач, бу вакыйганы мин танышбер психиатрга сөйләдем,— бу турыда аның фикерен беләсем килде. Танышым сүземне игътибар белән тыңлады да миңа берничә сорау бирде, тик шуннан соң гына үзенең хөкемен чыгарды.

— Гаҗәп бит ул кеше дигән нәрсә!— дип башлады ул сүзен.— Бик гаҗәп! Аның организмы, психикасы, бөтен торышы, яшәеше бик гаҗәп, бик серле. Син дә табигатьнең шундый серле бер йомгагы. Мәсәлән, син Абдулла Мусинский өендә сөтне кулыңа алгач, бер йотым сөткә мохтаҗ булган балаларыңны күз алдына китергәнсең дә, их, бу сөтне аларга эчерәсе иде дип уйлагансың. Шулаймы?

Ризалашып мин башымны гына селкедем.

Танышым сөйләвен дәвам итте:

— Аннары тагын бер нәрсәне ачыклыйк,— диде ул, миңа текәп карап.— Сугышка кадәр син ничек, һәр тәмле азыкны башта балаларыңа бирә идеңме? Әгәр табында берәр ашамлык аларга җитәрлек булмаса, аны ашамый идеңме? Шулаймы?

Җавап бирәсе урынга мин пырхылдап көлеп җибәрдем.

— Күрәзәчеме әллә син? Әллә шайтанмы? Кешеләрнең ни ашаганын, ничек ашаганнарын күзәтеп йөрисеңме?

Ул, елмая төшеп, җавап кайтарды:

— Күрәзәче дә, шайтан да түгел, ә врач, психиатр. Ярый, максатка кайтыйк. Менә син балаларыңа шундый мөнәсәбәттә булганга, аларны

бик сагынганга, кызганганга, сөтне кулыңа алгач, истериягә бирелгәнсең.

Мин, аның шундый нәтиҗәсен ишетеп, гаҗәпләнүемнән чак кычкыры җибәрмәдем.

Моны сизеп, ул:

— Сабыр ит, сабыр ит, ашыкма,— диде.— Фикеремне аңлап бетермәдең шикелле. Алайса, игътибар белән тыңла. Син үзең истериягә бирелмәгәнсең, ә тамагыңа истерик спазм булган. Тамак сеңгерләрең кыскарып, җыерылып, азык үткәрә торган юлны буган. Азыкны йотарга ярдәм итүче нервларың эшләүләреннән туктаганнар. Шулай итеп тамагың сөтне үткәрмәслек хәлгә килгән. Менә шуның аркасында син сөтне йота алмагансың. Төшендеңме инде?

— Төшендем.

— Әгәр Абдулла Мусинский сиңа шулвакыт сөт урынына су биргән булса, син аны һич тоткарлыксыз эчкән булыр идең. Нечкә хисләргә бирелмәс идең. Менә шулай, дускай, кеше организмы ул бик серле, бик катлаулы.

Бу гаҗәп хәлнең медицина телендә ничек атала икәнен дә әйткән иде, грек сүзе иде. Кызганычка каршы, оныттым, берничек тә исемә төшерә алмыйм. Әмма сугыш елларында немец-фашист коллыгында газап чиккән меңнәрчә-меңнәрчә ачларны, ялангачларны, бигрәк тә бер телем ипи белән бер йотым сөткә тилмергән гөнаһсыз сабыйларны, аларның аяныч күз карашларын, зәгфыраңдай сары, ябык йөзләрен, сөяккә генә калган кулларын, аякларын беркайчан да, беркайчан да онытачак түгелмен. Онытырырга мөмкин түгел аларны!

................

# Шәүкәт Галиев

## Очты яфрак...

Күзен кошлар тезелешеп
Очтылар җылы якка,
Аларга ияреп китте
Иманнән бер яфрак та.

Канатлылар юл алдылар,
Ә яфрак җиргә кунды,

Иң беренче очуы да,
Соңгысы да шул булды.

Яфрак бер дә көрсенмәде,
Ул рәхмәт әйтте җилгә:
«Язын кайтып торасы юк —
Мин инде туган җирдә!»

## Юлдагы таш

Таныш түгел юлдан бара —
Бабай миннән алда бара,
Алга-юлга карап ала.
Күрсә шунда яткан ташны,
Ала да ул читкә ташлый.

— Үзеңә эш таптың, бабай,
Таш җыясың нигә болай?

— Юлчылар, дим, абынмасын,
Машиналар кагылмасын.

— Моннан бүтән үтмисең бит,
Ул ташларны чүплисең ник?

— Син киләсең минем арттан,
Кемдер килер синең арттан...

...Таныш түгел юлдан барам,
Мин бабайдан алда барам,
Алга-юлга карап алам...

## Бабамның уң кулы

Бабамның фронтта алган
Бүләкләре ничаклы!
Орденнарга кысып мине
Бер кул белән кочаклый.

Уң кулы калган сугышта...
Калган сугыш туктатып!
Сул кулына балта алып,
Агач юна тук та тук.

Белмәгәне юк ул кулның;
Бар эшне дә булдыра.

Тик кул гына чаба алмый —
Булмастае шул гына...

Кирәк чакта, мин янында,
Бергә җаен табабыз:
Бабай кулы+минем кулым=
Икәүләп кул чабабыз!

Булышкач, бабай сөенә:
— Егет булган улым,— ди —
Синсез эшем бармас иде,
Син минем уң кулым!— ди.

## Исәнме, дус!

Салкыннан мин
Төн эчендә
Качып барам,
Бирмим аңа —
Учка җылы
Кысып барам.

Күрдем, юлда
Салкын үткән
Минем дуска...
Кулны суздым —
Җылы салдым
Учтан учка!

## Дуслык балы

Дустым миңа алып килгән
Күчтәнәчкә «Башкорт балы»,
Мин дә аңа бал утыртам —
Җыйган татар бал кортлары.

Гәрәбәдәй якты икән,
Икесе дә татлы икән:
Синең бал да кәттә икән,
Минем бал да яхшы икән!

Кысташабыз алмаш-тилмәш,
Макташабыз алмаш-тилмәш,
Очрашабыз алмаш-тилмәш —
Бик күңелле дустың килгәч!

Кыр-болыннар янәшәләр,
Гөл-чәчәкләр янәшәләр,
Бал кортлары әрле-бирле
Шәт кунакка йөрешәләр?

Синеке дип, минеке дип,
Чәчәк-ара чикләр юк бит,
Кәсаләре көнгә ачык,
Гел дә ачык — бикләр юк бит.

Синең балкорт, минем чәчәк
Күптән инде кушылгандыр,
Синең көйме, минем җырмы —
Җан уртаклык шушындадыр?

«Сезнең бал шәп!»,
«Сезнеке!»— дип,
Туганнарча сүзгә килеп,
Тойсак тойыйк бал әчесен
Сезгә барып, безгә килеп.

Бозылмый да, картаймый да
Безнең татар-башкорт балы —
Гәрәбәдәй якты булсын
Халыкларның дуслык балы!

## «Икмәктер!»

Яңа костюм белән бераз
Мактанасы да килә,
Класс алдында күренеп
Шатланасы да килә.

«Үзем эшләп алдым!» — дигәч,
Ышанмыйлар нишләптер.
Карганып әйтүем түгел:
Үзем алдым, икмәктер...

...икмәктер аңа сәбәпче —
Авылда мин, бабайда,
Комбайнда эшләдем бит,
Абзаң хәзер ул бай ла!

Кайчан тагын җәйләр җитәр,
Эшләр идем иплэп бер,
Кайтам, дигәч, кайтам инде,
Бусы менә — икмәктер!

## Нахак бәла

Мәсьәлә чишкән чакта
Тәрәзәдән карадым —
Пыялага кунган да
Тора энә карагы.

Ник ул энә урласын,
Нәрсәгә аңа энә —
Кушканнар да бер исем,
Онытылмый шул, менә...

Охшаш үзе энәгә —
Тәгәл исем тапканнар.
Әмма нигә «карак» дип,
Нахак бәла якканнар?

...Чишелмәде мәсьәлә,
Өлгереп лә булмады —
Энә карагы әнә
Вакытымны урлады!

## Буш вакыт

Буш вакыт — буш савыт түгел,
Савыт кына буш тора —
Буш вакытын һәрчак кеше
Ни беләндер тутыра...

Бер малай буш вакытына
Трай типкән дә, туп керткән.
Берсе кызыгып укыган
Китаплар тезеп киткән.

Телевизор белән тулган
Бик күпләрдә буш вакыт...

Кемнәрдер әле үткәргән
Бушны бушка бушатып.

Ә берәү буш арада гел
Нәрсәдер әмәлләгән —
Бүтәннәрнең әрәм калган
Вакытын да җәлләгән...

Эшчәннәрнең буш ара юк —
Бар күңелгә хуш эше.
Ялкауның буш вакытыннан
Үсеп җитә буш кеше!..

## Кесәле баш

1

Бу малайның блокнотын
Күрсәң исең китмәле:
Формулалар, саннар белән
Чуарланган битләре.

Түш кесәсе, эчке кесә
Нигә димсең кабара —
Шыгырдавык кәгазь белән
Шыгырым алар бар да!

2

Күршесенең кесәсе дә
Һич кенә дә тын тормый:

«Без монда!»— дип
тавыш биреп,
Тимер-томыр шылтырый.

Анда калай төймәләрдер,
Шөрептер дә кадактыр,
Үзе дә ул әйтә алмый —
Кайсы нигә яраклы?

3

Бер партада әнә шундый
Ике малай утырган.
Һәркем башка сыймаганын
Кесәсенә тутырган...

## Көч

Тра-та-та, тра-та-та —
Пулеметтан кем ата?
Урамны калтырата,
Мускулын ялтырата —
Бер абзый асфальт вата!
— Түгел йомшак гөмбә!
— Менә ул көч кемдә!

Тра-та-та, тра-та-та...
Чү, гөмбә ничек чыккан,
Шып-шыпырт килеп чыккан,
Асфальтны тишеп чыккан,
Җимереп, ишеп чыккан!
— Менә сиңа гөмбә!
— Менә ул көч кемдә!

## Сагыну

Әй, сагынып кайткан тургай —
Сайравыннан карлар эри!
Суалчан эзләгән булып,
Тыңлый-тыңлый карга йөри...

## Куркыныч тешләр

Үткен, усал тешләр барын
Урман күптән төшенгән —
Бүре теше берни түгел,
Курка пычкы тешеннән!..

## Туйган икән...

Күрәсем килми конфетны,
Тизрәк олактырыгыз,
Күзне йомам, күрсәтмәгез —
Авызга каптырыгыз!

## Ак күлмәк

Бәйрәмгә миңа текteләр
Ак чалбар да ак күлмәк.
Ни утыра, ни яталмыйм,
Йөгерә алмыйм юньләп...

Малайлар балчыктан өеп
Нинди плотина корган,
Ә мин буялудан куркып,
Шәм кебек басып торам.

Киңәш бирсәм, тыңламыйлар:
— Өйрәтергә бик оста —
Күргәзмә әсбап шикелле
Кукрай да тор син чиста!

«Ә шулаймы!»— дип ачудан
Балакларны сызганып,

Пычрак ерып кереп киттем,
Эчтән әзрәк сызланып...

Җиңем төшсә, күтәрәмен
Бик сак чеметеп кенә,
Чеметемләп бетергәнмен
Тәмам җебетеп кенә...

Башта борчылган идем дә
Акка төшкән тапларга,
Тора-бара күз күнекте —
Булды тоташ кап-кара...

— Ыспайланып тормадың,—
дип,
Иптәшләрем мактады,—
Аксөяк түгелсең икән,
Ышанычны акладың!

## Укол

— Шигырь сөйләп бирәсеңме?
— Сөйлим, сөйлим, апаем!
— Әллә бии дә беләмсең?
— Биим, биим, апаем!

Уйнап-җырлап та карадым,
Кыланмаган калмады.
Барыбер искә алмады —
Апа укол кадады!..

## Рафис Сәлимҗанов

# ЕЛАН МӨГЕЗЕ

хикәя



Төнне борчылып үткәрде карт. Икенче көнне таң белән түбән очтан Сәлимә әбине чакырырга кеше җибәрде. Ул кергәч, торып мендәренә утырды. Ютәлли-ютәлли сүзгә кереште.

— Әҗәлдер бу, Сәлимә... Буа... Кыса... күкрәкне... Сиңа сүзем бар. Кеше җибәргән идем шуның өчен. Бәхиллисем килә минем сине... Күптәнгеләр өчен. Үпкәләмә, би-ик күптәнгеләр өчен. Әйт әле, ни өчен син теге чакта... Яшь чакта ук инде... Ни өчен син мине... Мин бит сине бер күрергә зар-интизар идем. Шахтага да синең аркада чыгып киттем. Егерме ел буе авылга кайтмадым. Кһым... кһым...

Шәрифҗан карт буыла-буыла ютәлләргә тотынды. Сәлимә әби йөгерек кара күзләре белән аның агарган йөзенә, чир белән бөрешкән гәүдәсенә чын җәлләү белән озак кына карап утырды. Ютәлләү тынгач, сүз башлады.

— И, Шәрифҗан абзый, ник сөйлисең инде шуларны, әллә кайчан онытылып беткән нәрсәләрне...

— Сөйлим әле, Сәлимә... Сөйлим. Ярты гомерем сине уйлап үтте. Ярты гомерем... Калган яртысының, кем әйтмешли, дүрт аяклап, таякка таянып йөри торганының әллә ни кирәге дә, мәгънәсе дә юк.

Тынып калдылар. Аермачык булып стена сәгатенең «келт-келт» йөргән тавышы ишетелде. Саный да саный. Ни саный торгандыр — алла белсен...

Шәрифҗан карт сүзен дәвам итте.

— Шахтадан кайтып, сине күргәч... күз алларым караңгыланып китте. Егылам дип торам. Яшь чаклар диген... Инде ярәшергә йөри идем мин сине. Ә син?.. Гел котелмәгән хәл булды ул, аяз көнне яшен суккандай булды. Берәрсе яман сүз ишеттергәндер инде. Ничек ялындым шул чакны, алларыңа килеп тезләндем бит. Яшь чаклар, яшь чаклар...

Сәлимә әби як-ягына каранды, аннары елмаеп куйды.

— И, карт тиле! Хәле ничек... һаман шуларны уйлап ята икән әле. Үзе үйга калды. Әйе... Заманында Таһир-Зөһрә, Ләйлә-Мәҗнүннәргә тиңләп сөйлиләр иде шул аларның исемнәрен.

Хатын-кыз аркасында кичерергә мөмкин булганнарның бөтенесен дә күрде Шәрифҗан. Сәлимә кияүгә чыккач, тәмам исәрләнеп йөрде.

Төннәр буе бакча артларында, су буйларында «Таһир-Зөһрә»не кычкырып җырлап йөрер иде. Аның өчен күпме кыз саргайды. Ә ул һаман— Сәлимә дә Сәлимә.

— Әйт әле, Сәлимә...

— Бәхилләшик соң, Шәрифҗан абзый. Дөньяныкы дөньяда калсын. Шуңа аптырап утырам әле — әллә кайчан булган хәлләр бит,— онытмагансың. Гел исем китеп утырам.

Шәрифҗан карт, мендәренә кырын яткан килеш, яшьлек чорларына кайтып китте.

— Яшьлек юләрлеге, Шәрифҗан абзый... Бик гөнаһлы мин синең алда... Әниең Нурҗамал түти вафат булган елны мин сезгә май язарга гөбегә кергән идем. Нишләп сезнең очка җиткәнмендер — анысын хәтерләмим. Сезнең күршедә минем ахирәтем Камилә яши иде, аларда булмагач, сезгә кергәнмен, күрәсең. Кайтарып бирдем гөбене әнигә. Ә ул, юарга дип, төбен каккаласа, килеп төшкән моның алдына бер әйбер. Әни шундук танып ала моны. Миңа бер нәрсә дә әйтми, әйбәтләп кенә җыеп куя тегене. Эшен бетергәч, миңа буш гөбе биреп җибәрә.

— Нәрсә булган соң ул?

— Елан мөгезе!

— Их, чукынганнар! — дип, кинәт җанланып китте карт.— Эт булгансыз икән! Әни мәрхүм үлгәч, бөтен дөньяны бетереп эзләп маташтык бит без аны. Актармаган җирне калдырмадык. Бер гөбене без гел тотмый идек, тик ята иде. Шунда яшергән икән, мәрхүм.

— Ие. Күптәннән даны йөри иде инде ул елан мөгезенең. Гәрәйнекеләр шуңа бик рәхәт яшиләр алар, дип. Ул елан мөгезенә әллә ничә йөз ел икән, дип. Аны өендә тоткан кеше бик бай була икән, дип. Синнән яучы килгәч, әти белән әни шуңа күрә кире бордылар. Минем дә колакка киртләп куйдылар: онып ул егетне, үз бәхетеңә үзең төкерәсең килмәсә, диләр. Бәхет дигәнең әз нәрсәмени ул кыз балага... Байлык дигән сүзе дә бар бит әле аның. Безнекеләрнең ничек яшәгәнен беләсең бит инде син...

— Сөйлиләр иде... Кияргә ыштаннары юк дип.

— Ә син кабат-кабат яучылар җибәрттең... Бер көнне Мәгъри Нурдидәсе булса, икенче көнне Әүхәди абзый килеп җитә... Үзең дә килеп карадың. Әтиең белән дә килдегез. Мин әйтәм: нишлим? Чыксам, барыбер тора алмабыз, дим. Әхмәтхан мәрхүмгә ябышып чыктым шуннан соң.

Шәрифҗан карт Сәлимә әби сөйләгәннәрне телсез калып тыңлап утырды. Хәйран гына тынып торганнан соң сүз башлады.

— Вәт син аны! Шту такуй койрыкны тиз борды дип аптыраган идем аны... Болай тату тордыгыз бугай Әхмәтхан мәрхүм белән.

— Тату тордык та, Шәрифҗан абзый... Тату тордык та... Болай тату тордык инде торуын — бәхет дигән нәрсә генә булмады. Мәрхүм үпкәләп ятмасын — ишегалдына чыгып китсә дә сөенә торган идем. Синең хәлләрне сораштыра торган идем гел. Исемең чыкса, сүз бетмичә китми торган идем кеше яныннан. Әллә нигә рәхәт булып китә иде синең исемне ишеткәч... Шулай... Бәхет булмады инде минем, Шәрифҗан абзый. Үзем сине ташлап кияүгә киттем, үзем гомер буе сине уйладым... Бәхет тә булмады, балалар да булмады, дигәндәй...

Сөйләшмичә тагын байтак гомер утырдылар.

— Теге... елан мөгезе кайда соң?

— И-и, Шәрифҗан абзый... Әздән генә эрәм булмады ул синең елан мөгезең. Сугыштан бит үле хәбәрең килгән иде: шул вакытны еладымеладым да, мин әйтәм, тормасын әле күз алдымда йөрәгемне яндырып дип, тоттым да утка аттым мин аны.

— Яндымыни?

— Ю-ук. Кире алдым. Беләкләрне пешереп бетердем... Ике ай буе кулга бер нәрсә дә тота алмыйча йөрдем шуннан соң. Аннары сезнен нигезегезгә илтеп күмдем. Мин әйтәм, файдасы тимәсме, исән кайтмасмы, дим.

— Шундамыни ул хәзер?

— Ачулансаң ачулан, Шәрифҗан абзый, аннан да алдым мин аны. Бер төнне малларны эзләп йөргәндә, тәрәзәгезгә күзем төште дә, Мәрфуганы күрдем. Бер баскан җиргә өч баса... Урын җәеп йөри. Мин әйтәм, Әхмәтханнар тегендә үлеп ята, син монда сөенеп йөрисеңме әле, дип, кулга таш алдым, чүттән генә тәрәзәгезне бәреп ватмадым... Сикереп кердем дә коймагыздан, казып алдым елан мөгезен. Ул вакытта әллә нигә бик холыксызга әйләнгән идем мин...

Сәлимә әби урындыктан төенчеген алып чишә башлады.

— Алып килдем мин аны, Шәрифҗан абзый... Менә...

Сәлимә әби, төргәк эченнән соргылтрак сөяккә охшаган бер нәрсә алып, картның кулына тоттырды. Әмма, картның кулы калтыранып киттеме,— әлеге нәрсә идәнгә тәгәрәде.

Икесе дә «аһ» иттеләр.

Сәлимә әби өстәл астына, аннан соң карават астына кереп, эзли башлады. Аңа Шәрифҗан карт та кушылды, әмма елан мөгезен таба алмадылар.

Шулай шактый гомер эзләгәннән соң, Сәлимә әби кайтып китте.

Менә шул көннән башлап, әҗәл кайгысы китте Шәрифҗан карттан. Ул хәзер көндез дә, кич тә, караңгыда да, яктыда да, шырпы яндырып та, яндырмыйча да, көненә әллә ничә тапкыр елан мөгезен эзли. Сайгакларны сүтеп, актарып бетерде инде. «Кулга тоткач бит. Кулга тоткач!» — дип, кайвакыт үз-үзен сүгеп утыра карт.

Һәм яңадан эзләргә тотына...

# Фәннур Сафин

## Безнең гомер

Юк, тиңләмим кырны диңгезләргә,
Диңгездә су, монда иген бит.
Тозлы суны ничек
Иген белән,
Изге ипи белән тигезлик?!

Юк, тиңләмим иген бөртекләрен
Алтын белән, асыл таш белән.
Икмәк — яшәү,
Икмәк — безнең гомер,
Уйлап караганда баш белән!

## Дәвам

*Әткәмә — Шәйхенур Сафинга*

Сүзсез генә дәшәм мин җилләргә
Я давылга шомлы өн салам:
— Барыбер бит Аның һич берни ди
Хәбәре юк фани дөньядан...

Әмма үзем тыңлыйм урман шавын
Һәм Син булып кайчак моңланам.
Ялгышамдыр гына бәлки үзем
Хәбәрең юк диеп дөньядан...

Синең җан бит шушы басуларда,
Ашлык тулы ындыр янында.
Синең дәвам — миндә, кечкенәдән
Бу дөньяга гашыйк канымда!..

## Егетлекне сынау өчен...

Куркыныч ул кайчак дөнья:
Кара төндә кем күрер? —
Караңгылык куерганда
Эт өрер, бүре йөрер.

Өстеңә бүре килгәндә,
Араларга кем керер?
Ялгызакны талыйм диеп,
Эт өрер, бүре йөрер.

...Араларбыз!
Егет кеше
һәммәсенә әлгерер.
Егетлекне сынау өчен,
Эт өрер, бүре йөрер...
Эт өрер, бүре йөрер..

## Тиң чагыбыз

Эзләү... Табу... Югалтулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...
Әле бар да алда диеп,
Бер-береңне юатулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...

Яр буенда сары комда
Яланаяк йөргән вакыт...
Ул гөнаһсыз чакны бездән
Алды икән кемнәр тартып?

Үзебезне үзебездән
Урладыкмы соң әллә без?
Атлыйбыз тагын бергәләп,
Моңсу елмайган хәлдә без.

Суләр һаман ургый, кайный,
Әйтерсең лә нидер сөйли.
Дулкын бөдрә талны кыйный,
Тынлык бер үк җырны көйли:

«Эзләү... Табу... Югалтулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...
Юанулар, юатулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...

Ашыгулар, ялгышулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...
Кабат табу, кавышулар...
Инде хәзер тиң чагыбыз...
Тиң чагыбыз!..»

## Бары шул...

Чүлдә йөрсәң — булдым күләгә,
Күлдә — әйләндем мин көймәгә.
Чәчләреңнән актым су булып,
Алларыңа яттым юл булып.
Сине уйлап беттем сулыгып,—
Хак булдыммы сиңа юлыгып?!.

...Синең киткән якка күз ату,
Сиңа бары җилләр озату,
Эзләреңә генә сүз кату —
Төш түгелме сине югалту?!
Тик хәзер хет яңабаштан ту —
Мөмкин түгел мине ярату.
Чөнки мин бит сиңа бары шул:
Тын күләгә, көймә, юл һәм су...

## Төн кызына

Син — күзге төн.
Нурлы ялардан мин.
Очрашырга икән соң ничек?



Т Хажиахматов рәсеме

Бу — тилереп кенә йөрү мәллә,
Барлыгыңны синең ишетеп?

Табигатең юкса башка синең,
Үзгә дөнья, үзгә гадәтләр.
Сине эзләп, сиңа табыныпмы
Үземнән ваз кичкән сәгатьләр...

Минем өчен тоташ яктылык син,
Үзең бер төн кызы булсаң да.
Тоям, тоям!
Җаннар якыная
Чакырсаң да мине, кусаң да...

...Төнне телгән кызлар көлүедәй
Эрисең дә — юк син, төн кызы.
Әйләнәсең якты хатирәгә,
Атылгандай өмет йолдызы...

## Бер мәхәббәт хакында

Сулар кереп карый бер кыз,
Йөрәк суынмасмы дип.
Су кызына әверелә,
Әллә бу да азмы дип.

Тик хисләрен сүндералмый
«Сүндерергә тиеш» су.
Үзе ялкынга әйләнә
Инеш булган килеш бу.

Кыз сөюен Аңа әйтми —
Бар дөньяга аңлата.
...Каеннар гына тирбәлә:
«Ярата иде...
Ярата!»

## Тузга язган сүзләр

— Шундый да томан иде ул кичтә...
Томан бәйләде чәчләрен чәчкә!..
Егет шаяртып сорады кыздан:
— Әйт әле, сеңлем, син ничә яшьтә?

Кызый кимсенгән булып кыланды,
Һәм әйтте яшен байтак арттырып.
Ә егет исә «яшәреп» китте,
Күренмәс өчен артык карт булып.

Гомерләр узар, балалар үсәр,
Шаяртып әйткән сүзләр онтылыр.
Тик шул илаһи ялган кичәнә
Бәхетле яшьлек рәхмәтле булыр...

Шундый риваять сөйләде агай
Янда утырган шаян бер кызга.
Кызның үзеннән сорамый гына
Күңеле язып куйды ак тузга!

## Сине эзлим

Бөтен гомрем буе көттем сине,
Гомер буе сине эзләдем.
Әллә кайдан, әллә күңелемнән
Чакырып торды назлы күзләрең.

Шундый көттем, кеше шул кадәр үк
Һичбер нигди бәхет эзләмәс.
Көне-төне һаман юлда булдым,
Сине сагынуга түзмәгәч.

Сине эзләп йөрдем далаларда,
Таптым дигәч, тагын югалттым.
— Син туктама, кабат табарсың,— дип
Таң җилләре генә юатты.

Сине эзләп менәм тау башына,
Ерак офыкларга күз атам.
Ничек түзәр икән инде йөрәк,
Сине табып кабат югалтсам?..

## Наз

Ышанырсың микән, очрашырбыз,
Күрешербез әле без икәү.
Күзеңдә — тол сагыш...
Синең бәлки
Мине моңдаш итмәү, үз итмәү?

Без бит бер үк моңнан яралганбыз,
Бер үк якка безнең юл яткан.
Безгә дигән сихри чишмә суы
Аккан гүя бер үк улактан.

Алда көтсен безне хәр шатлыклар,
Серләшүләр тулы тәм-ләззәт.
Синең назлы һәрбер йөз сызыгың
Йомшак нурлы бәхет-сәгадәт!

## Гашыйк

Гашыйк идем, шундый гашыйк идем!..
Синдә күрдем Бәхет, таң төсен.
Карурманны кичтем, Иделләрне,
Өзгәләнеп синең җан өчен.

Шулхәтле хис Ләйлә-Мәҗнүндә дә
Булмагандыр диеп уйладым.
Көнләдем бит хәтта күбәләкнең
Синең янда очып уйнавын!

Йөрәгеңне тыйсаң, яратмасаң,
Төшенә алмасаң серенә,
Мәхәббәт ул нинди була дисәң,
Үзең күз сал җаным түренә!

## Ике яр

И шыбырдый бер өрәңге,—
Сүз кушмакчы тупылга.
Ә тупылкай бер сүз дәшми,
Уфылдама — уфылда.

Күңел уйлый: «Болар мәңге
Аеры торыр микәнни?
Бер-берләрен аңламыйча
Ялгыз корыр микәнни?»

Өрәңге белән тупылны,
Я, кавыштырып кара.—
Өрәңге белән тупылкай
Икесе ике ярда!

## Максат өчен

Узганнарга яңа хисләр өстәп
Омтылабыз тагын яңага.
Зур яңалык җанны алгысытып
Дөнья уртасында ярала.

Уйланабыз барлап хис, аң көчен
Алга куйган чакта максатны:
Аны әле, тотып карау өчен,
Чынга әйләндерү ансатмы?

Һәр үләндә, тереклектә — максат —
Буразнада, урман иле ндә.
Олы максат — ирләр йөрәгендә,
Хәтта сылу кызлар иңендә.

Максат өчен алтын куллар кирәк,
Максат өчен — кыю, саф йөрәк
Иркен, нурлы һава, яшел юллар,
Максат өчен яңа җыр кирәк!

## Харрас Әюпов

### Өй өмәсе

Җәйләр җитсә, авыл өмә әйтә,
Шау-гөр килеп өйләр күтәрә;
Нигезләргә таңкә сала картлар:
Бәхет бирсен гомер итәргә!..

Бөтен авыл кереп биесә дә,
Бирешмәслек имән өрлекләр,
Өйне түгел — илне күтәрерләр,
Ир-егетләр өрлек кебекләр.

Җеге-җеккә килеп кенә тора,
Ятып бара нирга-ниргәгә;
Кул да тими кала бүрәнәгә,—
Нидер булган бүген ирләргә.

Мүге белән бергә ниргә саен
Шаян сүзне түши мул итеп,
Яктылыгын сала күңелләрнең, —
Гомер буе торсын җылытып!

Җайлап тезә түшәм такталарын,
Ипле итеп сала матчасын:
Елларына-чорларына түзәр, —
Кайгы-хәсрәт кенә ятмасын!

Почмакларның тигезлеген карый,
Балталарын асып, осталар,
Бәхетне дә тигезлисе алар,
Тиң итәсе, әгәр кушсалар.

Өмә белән өй күтәрә авыл:
Кыз төшәсе, туйлар буласы...
Гомер кичерәсе... картаясы..
Бәрәкәте җитсен шуңарчы!

### Исәнлек

Кичләремә: «Хәерле кич!» — диләр,
«Исәнмесез!» — диләр иртәмә.
Көннәремнән хәл белешә дөнья,
Уйга салып йөртә-йөртә дә...

Һәр теләге ләкин кабул булмас,
Хәл белүдән дәрман табылмас:
Илгә-җиргә тоташ ирләр җаны
«Сау бул!» — диеп кенә сау булмас.

Ир саулыгы — ил тынычта гына,
Бәхет белән көннәр хәерле;
Исәнлекме — үксез сабыйларның
Күз яшьләре телсә бәгырьне?!

Явызлыклар өстен чыкса әгәр,
Егылып калса сафлык, тапталса...
Җинаятьтер — җирдә хаксызлыкны
Күрә торып, җаның сау калса!

«Исәнме?» — дип хәл сорыйлар дуслар,
Дөрес булыр икән ни дисәм?
Илләр имин чакта — бәхетле мин,
Бәхет барда җирдә — мин исән!..

## Гали углы Мөхәммәтдин

Алдымда — таш. Язуы бар:
«Гали углы Мөхәммәтдин».
...Учка кысып, көрешер идем,—
Кулларың юк, ни хәл итим?

Ел язуын вакыт юган, —
Кайсы гасыр улыдыр син;
Дөнья буйлап кичкән чакта
Ни хәлләргә юлыгырсың?

Гали углы Мөхәммәтдин!
Сак була күр алга табан:
Хәзер җирдә «эһ» дигәнче
Ташлар эреп төшәр заман...

Әле синең бар белгәнең
Ук-җәядер... Сөңге-калкан...
Тизрәк уз безнең чордан,—
Ниләр булмас соңга калсаң?!.

Киләчәккә барып өлгәш,
Гали углы Мөхәммәтдин! —
Ни әйтсәң дә үз халкымның
Үткәндәге улы бит син...

...Басып калдым башым иеп.
Иске зират. Җәйге иртә.
Алдымда — таш, тирәсендә
Чикерткәләр кубыз чиртә...

## Җыр булып калыккансың...

*Туган авылымда, безнең өй урынында үсеп чыккан яшь каенга*

Талпынасың, тартыласың, —
Җанмы бер, каенмы син?
Кабатланмас шатлыгыммы,
Әллә бер кайгыммы син?

Безнең гөнаһсыз чакларны
Күтәреп алдыңмыни?
Тирәннән алып чыктың да,
Уйларга талдыңмыни?

Яктырып басып торасың, —
Карлар сарылдымы әллә?

Әбием-бабамнар җаны
Шулай ак идеме әллә?

Без монда кичергәннәрне
Син генә беләсеңдер,
Шуларны бөтен дөньяга
Күрсәтим дигәнсеңдер...

Туфрак-дымнан гына түгел,
Еллардан, халыктан син! —
И каен! Чорлар төбеннән
Җыр булып калыккансың...

## «Кара тартма»

*Һава лайнерлары бортына махсус җайланма — «кара тартма» куела. Очкыч бәхетсезлеккә очрый калса, һәлакәтнең сәбәбен шул тартма язып барган язмалар аша ачыклыйлар.*

Без очышта, очышта без бүген...
Беләм шунсыз тынгы тапмасым да.
Гомерләрнең һәрбер тирбәнеше
Бу очышның «кара тартма»сында.

Бөтенесен язып бара хәтер...
Үткәннәрдән — минә бүгенгәчә
Барысы шунда. Сабыр савытлары
Түгелми лә икән түгелмәсә!

Кайгы, шатлык, сөю, нәфрәтләр дә
Язылалар җуелмаслык булып;
Кире кайтып, тарихларны яза,—
Җир сулышы кала сулык-сулык...

Әгәр бер көн хәтәр һәлакәткә
Очрый калса кинәт газиз Җирем,
«Кара тартма» сыман чәчрәп төшеп
Калыр кебек бу йөрәгем минем.

Кемнәр табып алыр киләчәктә,
Кемнәр укыр, сабырлыгы җитеп?
...Бөтенесен язып бара хәтер,
Бер сулыш та эзсез китми үтеп...

## Аккош күлендә

Аккош күле. Ак каеннар...
Беренче яз Туфансыз.
Күке елый: «Юк-юк, юк-юк!..»
Ничек яшәр ул ансыз?

Көннәрдә — аның яктысы,
Җилләрдә — аның назы;
Терелә Аккош күлендә
Гөлләрдәй җанның язы.

Аккош күле. Ак чәчәкләр...
Аһ, гөлләр ятимлеге!
Күбәләк аларга соңгы
Сәламен әйтим диме?

Аның өчен түгел ахры
Бу дөньядан китүләр:
«Юк-юк, юк-юк... Ул китмәде!» —
Ышанмыйлар күкеләр...

## Чулпылар

Чылтыр-чылтыр чыңгылдыйлар чулпылар...
Тавышына колак салмый кем чыдар?—
Ниләр шулай сибеләдер еллардан,
Кем йөрәге, кемнәр җаны чыгарган?
Чулпыларда — зәңгәр-зәңгәр асылташ:
Күз яшьләрең тамып калган, и туташ!
Ирексезләп кемнәргә соң бирделәр?
Ничек шулай соңга калдым мин юләр!
Чылтыр-чылтыр чыңлый көмеш чәчкәләр...
Үткәннәрдән килми димә хат-хәбәр:
Сылу кызлар бик борынгы иллэрдән
Моң-зарларын чулпыларда җибәргән!
Тимәсәң дә, чыңлап тора чулпылар...
Мәхәббәтен юксынмыйча кем чыдар?
Әй, асыл яр! Кирәкми лә еларга,
Болай да бит моңсу әле елларга:
Дөнья буйлап инде әллә кайларга
Сибелгәннәр чулпыларың, җырларың!
...Ник тыңладым? — Чулпылардан җаныма
Күз яшьләре тамды кебек чорларның...

## Зәңгәр күкләр, каурый болытлар...

Тып-тын калып, кемне юксынасыз,
Зәңгәр күкләр, каурый болытлар? —
Зәңгәр дәфтәр... Ап-ак каурый каләм...
Кайсы шагыйрь сезне оныткан?

Нинди җыры калган язылмыйча,
Баш очымнан нинди сер ага?
Җавап бирә кебек күкләр миңа:
— Шагыйрьләрнең хәлен сорама!

Каурый болыт! Буйсын кулларыма,
Язганымны сеңдер, зәңгәр күк! —
Бу дөньядан җирнең шагыйрьләре
Әйтәлмичә киткән сүзләр күп.

Языйм әле сезгә мин шуларны, —
Агылсыннар, дөнья гизсеннәр;
Сизмәгәннәр, әйдә, сизмәсеннәр:
Яшен дисен, шәфәкъ дисеннәр!..

Җәмит Рәхимов

# ШӨГЕРНЕҢ ИКЕНЧЕ ЯШЬЛЕГЕ

Бирәдән, авылның күрке булган Җандур-тау башыннан бөтен тирә-юнь аерым-ачык күренә, бигрәк тә тауга сыенып утырган Иске Шөгер уч төбендә кебек. Шушма елгасы җәйрәп ята. Авылны иркәләгән, назлаган, бәллүләгәндәй кырый йортларга тәрәләп үк диярлек, бормаланып-бормаланып ага ул. Елга кебек үк булырга тырышкандай, асфальт өслекле олы юл уза. Аның ике ягында да янбакчалы, алты почмаклы гүрничәләр, түбәләре — калай да шифер. Шулар арасында — культура йорты, канлы көрәштә ятып калганнарга һәйкәл, авыл Советы, колхоз идарәсе, балалар бакчасы, медпункт, кибет биналары. Салынып ята торган мәктәп. Карашыңны ераккарак күчерсәң, «Шушма» колхозы машиналары өчен төзелгән ап-ак гараж һәм тимерче алачыгын да күрергә мөмкин. Тагы да арырак тулы бер шәһәрчек булып терлекчелек фермалары калыккан.

Елганың аръягында — Яңа Шөгер. Аның янәшәсендә үк тагы бер шәһәрчек — колхозның машина-трактор паркы, ябык ындыр табагы, бөртек саклау складлары...

Монда әле узган гасырда ук эшли башлаган битум заводының яңа цехлары, культура-көнкүреш объектлары, эшчеләрнең тораклары төзелгән. Завод халык хуҗалыгы өчен бик кирәкле продукцияне күпләп чыгара. Шушыннан көнен-төнен машиналар ташып торган битум Уренгой — Помары — Ужгород кебек континентара газ һәм нефть үткәргечләр сала, Кама автомобиль заводы кебек гигантлар торгызырга булыша.

Шулай да Җандур-тауга беренче аяк баскан кунаклар авылның күркәмлегенә дә, аның таш пулатларына да, абруйлы заводына да игътибар итмиләр сыман. Аларның карашы — Шөгерне бөтен яклап урап алган, бер карасаң, талпынып очып китәргә торган аккошларны, икенче карасаң, борчак җиренә төшкән торналарны хәтерләтүче скважиналарда. Һай, күпме алар монда! Ялкау гына тирбәлеп торучы сиртмәле насослар Шөгер суы буйлап та, Зобай инеше кырыйлап та тезелгәннәр, яраткан язучыбыз Абдулла Әхмәтне «Серләр» пьесасын язарга илһамландырган Бизмән-тау, Киле-тау, Очлы тау итәкләренә дә, Тәкә-тау, Карабыл тавы, Озын тау, Чат-тау өстенә дә менеп басканнар, исемле һәм исемсез дистәләрчә чагыллар өстендәге урман ешлыкларына кереп сыенганнар.

Шөгер кунаклары шуларга сокланып карый, бораулау вышкалары белән хозурлана. Ләкин моннан кырык ел гына элек (тарих өчен бер мизгел) Шушма буйлары тып-тын иде, бу кырларда фәкать тук башаклар кыштырдый, үзәннәрдә буйга котырган киндер исеннән хушланучы чыпчыклар гына чыркылдаша иде.

Гасырлар тынлыгы моннан нәкъ кырык ел элек бозылды, нәкъ кырык ел элек бирәдә, «Партизан» колхозының алма бакчасы янындагы беренче скважинадан, Татарстанда беренче булып, ташкүмер катламыннан промышленность нефте алын-

ды һәм ул шунда ук, бөек Җиңүне якынайту өчен, сугыш хаҗәтләренә озатыла башлады. Республикабыз тарихында тәүге нефть промыселы барлыкка килде. Шөгер исеме теллэрдән төшмәде ул чакта.

Канлы елларда туган бу промысел, хәзерге белән чагыштырганда, бик зәгыйфь иде. Техникага ярлы булуына карамастан, ул скважиналар да бораулый, аларны үзләштерә дә, эшләтә дә иде. Техник яктан көче чамалы булганга, буровойлар айлар буе монтажланды, нефть коелары еллар буе казылды. Шулай да ишәя тордылар алар. Акбур тавы башында да, Мукшы суы буенда да, Яңа басу түрендә дә скважиналар пәйда булды. Алардан беренче товар паркына, аннан инде Келәүле тимер юл станциясенә беренче нефть үткәргечләр сузылды, янәшәдә генә «Зеленая роща» эшчеләр поселогы калкып чыкты. «Шөгер» сүзе җырларда җырланды, сәхнәләргә менде, калын-калын журнал битләренә керә башлады.

Беренче нефть хакындагы шау-шулы хәбәрләрдән соң биш ел узуга, разведчиклар Шөгердән егерме чакрымдагы Тимәш авылы янында, Чияле тау итәгендә, девон катламындагы искиткеч бай хәзинәгә тап булдылар. Соңрак әле аннан, әле моннан берсеннән-берсе куанычлы хәбәрләр килеп торды: Зәй-Каратайда да бик күп нефть табылган, Суркинода да, Миңлебайда да, Әлмәттә дә... Болар Шөгердәге сыман ун-егерме тонна гына ягулык бирүче скважиналар түгел иде инде.

Нефтьле яңа мәйданнар гөр итте: Тимәш тә Әлмәт, Карабаш та Азнакай...

Күп кенә ир-егетләр, нефтьче осталар Шөгерне ташлап киттеләр. Машиналар шавы, ыгы-зыгы сүрелде, авыл ятимләнде, әмма таралмады. Тәүге скважиналар калды, Шушма буйларына гашыйк егетләр калды, хәтта нәни генә бер промысел да эшләп калды. Тик ул инде Лениногорск, Әлмәт якларындагы кебек көчле хуҗалык түгел, конторасының тышкы кыяфәтеннән үк аның юаш предприятие икәнлеге беленеп тора иде. Промыселның җитәкчеләре дә Шөгер тирәсендәге «карт» коеларны эшләтүгә караганда, Федотовка, Елховой якларына йөз тотуны, андагы яңа нефть мәйданын үзләштерүне мәгъкуль күрәләр төсле, планны да яңа мәйдан исәбенә генә үтәп баралар кебек иде. Шулай да «карт гвардия» сафтан чыкмады, тәүге скважиналар аз-азлап булса да нефть бирә тордылар. Ленин ордены кавалерлары Галим Сәйфуллин белән Гатаулла Насыйбуллин, соңрак Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булган Зиннәт Шәрифуллин, Рәүф Мәүлүдов, Шәрип Гаязов кебек ветераннар аларны карыйлар, майлыйлар, көйләп-чөйләп дигәндәй эшләтә килделәр. Шөгер нефте уртак агымга кушылудан туктамады.

Алай да берләшмә һәм идарә җитәкчеләренең һәр гамәлендә тәүлеккә уңунбиш тонна нефть бирүче алтмышлап скважина белән чиләнәсе килмәүләре сизелеп тора иде. Бераздан Шөгердәге промысел Яңа Елховой нефть мәйданына күчеп китте, мондагы скважиналар «Лениногорскнефть» идарәсенең 5 нче промыселы карамагына бирелде. Хәзер инде алар участок мастеры Галим Сәйфуллин һәм биредәге операторлардан башкаларга кирәкми дә кебек иде. 1972 елда исә аларны битум заводы карамагына бирделәр. Аларның хәле тагын да мөшкелләнде. Соң инде битумчылар нефть чыгарган халыкмы? Көннәр, айлар үтте, Шөгер скважиналары акрын-акрын ташландык хәлгә килде.

Бу вакыт инде «кара алтын»га бай коелардан девон нефте суыртучы промыселларда да хәлләр үзгәрә башлаган иде. Туган илебезгә инде ике миллиард тонnадан артык җир мае биргән скважиналар акрынлап суланды, алар барысы да диярлек механикалаштырылган юл белән эшләтелә. Төп фонд бораулап бетте диярлек. Нефтьчеләр теле белән әйткәндә, республикабызда нефть чыгару стабильләшеп җитте. Бер караганда, инде көннән-көн саега барган «кара алтын» чишмәләрен мулландыру юллары юк та кебек. Менә шул чак геологлар һәм инженерлар төрле җыелыш-киңәшмәләрдә өске катламнарны — нефтькә саранрак ташкүмер һәм бобрик катламнарын ешрак телгә ала башладылар. Сүздән эшкә күчәр чак та җитте. 1100—1200 метр тирәнлегендәге коелар борауланды, корыч пәһлеваннар кабат Шөгер якларына әйләнеп кайтты, Шушма буйлары, Шөгер суы һәм Зобай инеше ярлары буровойлар чыңына күмелде. Алар артыннан исә

аккошлар булып сиртмәле насослар тезелеп калды. Шөгер тирәсендә күзгә күренеп ишәйгән скважиналардан файдалану инде битум заводы кулыннан гына килерлек түгел иде. Шөгердә өр-яңа промысел булдыру мәсьәләсе килеп басты.

1979 елның октябрь башында, узган гасырда ук килмешәк Шандор нефть хәзинәсе капшанып йөргән урыннан ерак та түгел,— Шөгернең Чаган багана тавы итәгенә өч күчмә вагон китерделәр, алар тирәсендә таныш булмаган кешеләр күренгәли башлады. Бу — яңа туган предприятиенең нигезе һәм яңадан туган Шөгер промыселының хуҗалары иде.

Мәшәкать дигәнең олавы белән иде аларга. Шөгер һәм Зобай сулары буйларына, Яңа басуга һәм Акбур тавына сибелгән йөз сиксәнләп скважинаның алтмыш бише, әлеге дә баягы, моннан кырык-утыз ел элек бораулапып, инде ташландык хәлгә килгән скважиналар. Бөтен промыселга өч группалы үлчәү җайланмасы: нефть шуларга җыела һәм искереп беткән Спиридоновка термохимик җайланмасында эшкәртелә. Җитмәсә, юллар да начар, катлам басымын саклау, скважиналарны электр энергиясе белән тәэмин итү, нефтьне судан һәм тоздан арындыручы химик реагент бирү системалары ышанычсыз. Автоматика һәм телемеханика дигән нәрсәләрнең эзе дә юк.

Еоларын, тырышканда юлга да салыр идең — кешеләр юк. Дөрес, утыз елдан артык шул хезмәттә булган Татарстанның атказанган нефтьчесе Мәхмүт Мөхәммәтҗанов, Гата Минһаҗов, Рәшит Хәйретдинов кебек яшь промыселның умыртка сөяген тәшкил итәрлек ветераннар бар. Әмма алар гына җитми. Хуҗалыктагы скважиналар саны арта, нефтьче-операторлар кирәк. Аларны шушы төбәктәге Шөгер һәм Керкәле авылларыннан тиз арада тупларга, мәшәкатьле һөнәргә өйрәтергә кирәк иде. Ашыгу-кабалану аркасында коллективка очраклы кешеләр да килеп эләкте, элкен-селкен, кыеш-мыеш йөрүчеләр күренгәли башлады — хезмәт дисциплинасы ике аягына да аксый иде. Башлангыч партия оешмасы кечкенә, профсоюз әһелләре дә эшләрен җайга салып җиткерә алмый, промысел җитәкчеләренең әледән-әле алышынып торуы да аякка ныгытып басарга комачаулый. Әнә шундый кыен, әле генә тернәкләнеп килгән вакытында, яңа промыселны аның үзе кебек үк яп-яшь инженер Разиф Галимов кабул итте.

*

* *

Без килеп төшкәндә, промыселда борчулырак көннәр иде. Эш күрсәткечләре экранындагы саннар инде шактый көннәр буе шомлы минус билгесе белән бара икән. Кичә дә минус, өченче көн дә, аннан алдарак та... «Ни булган? Айның аенда, кварталның кварталында дәүләт планнарын һәм социалистик йөкләмәләрне арттырып үтәүче промысел коллективы нишләгән? Айлык план үтәлерме?..» Әлеге экранга күз салуга, күңелне әнә шундый шөбһәле сораулар биләп алды. Әмма нефтьче-операторларның да, инженер-техник работникларның да кәефе начар түгел, хәтта, киресенчә, ниндидер шатлык, күңел күтәренкелеге, канәгатьләнү кичерәләр сыман. Промысел мөдире Разиф Галимовның кыр сыман иркен кабинетына кергәч тә, без шуны сиздек.

— Әйе,— диде Разиф, безнең әлеге шикле сорауларыбызга каршы, һич тә исе китмичә,— әлегә минус белән барабыз шул. Язгы ташу сулары чорында Шөгер һәм Зобай елгасы буендагы, үзәнлекләрдәге кайбер скважиналарны туктатып торырга туры килде. Нефтьче-операторларыбыз «Шушма» колхозына караган чәчүлекләрне тимер-томыр калдыкларыннан арындыра тордылар. Иген кырларының, елгаларның чисталыгы барыннан да мөһимрәк ич... Ә планны үтибез аны! Безнең резервлар бар, көч-куәт җитәрлек.

Промыселның эше һәм тормышы белән танышкач, мөдир сүзләренең коры шапырыну түгеллеге ачыкланды. Яңа коллектив менә инде күпме вакыт «Лениногорскнефть» идарәсенең йөзек кашы кебек. Ул айның аенда, елның елында үзенә алган бурычны уңышлы үтәп бара. Өч ай эчендә генә дә, алдан билгеләнгән 445 тонна урынына, 865 тонна (бу еллык йөкләмәнең яртысыннан артыграк)

«кара алтын» чыгарылды. Үзләренең мөмкинлекләре хакында уйлап-исәпләп карагнннан соң, нефтьчеләр РСДРПның II съездына 80 ел тулу хөрмәтенә күтәренке йөкләмә кабул иттеләр, быелгы социалистик йөкләмәдә күрсәтелгән 1700 тонна урынына, 2110 тонна сыек ягулык бирергә булдылар.

Аларның сүзләрендә торачакларына ышаныч нык. Чөнки промысел тәмам эзгә төшеп житте. Теге еллардагы өч будка урынында яп-якты булып зур ак йорт калкып чыкты. Аның коридоры, кызыл почмагы, бөтен кабинетлары зәвык белән бизәлгән. Ишегалдында чәчәкләр үсеп утыра. Якында гына илле эшчегә исәпләнгән ашханә салынган. Ашлары тәмле. Нефтьчеләр монда бушлай өстәмә туклану да алалар.

Бүген инде хуҗалыктагы скважиналар саны биш йөздән артып китә. Алар исә һаман ишәеп тора. Былтыр гына да бораулаучылардан 52 скважина алып, аларны эшләтә башладылар. Якын елларда исә Шөгер төбәгендә меңнәрчә яңа скважиналар бораулау планлаштырыла. Хәзер инде чыгарылган нефтьне җыя һәм үлчи торган группалы җайланмалар саны да унсигез. Промыселда алынган барлык сыеклык, ахырынача чистарту өчен, Куакбашка озатыла. Спиридоновка авылы янындагы искереп эштән чыккан термохимик җайланманың эзе дә юк. Аның урыны тигезләнеп, тәртипкә китерелгән. Катлам басымын саклау, промыселны электр энергиясе белән тәэмин итү, нефтькә химик реагент бирү системалары камилләштерелгән. Нефтьчеләр инде, элекке сыман һәр юк-бар өчен дә телләрен салындырып чабып йөрмиләр, телемеханик система һәр хәвефле хәлне промысел диспетчерына җиткереп тора. Дежур операторлар шунда ук туктап калган скважинага ярдәмгә чыгып китә.

Шөгер промыселының кабат яшәрүе могҗиза түгел, әлбәттә. Бу уңайлыклар, камиллекләр, уңышлар күктән төшмәде, аларны моннан утыз-кырык ел элек нефтькә беренче юлны ярган ветераннарның уллары һәм кызлары барлыкка китерде. Чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә монда чикләвек төше сыман таза, ныклы коллектив барлыкка килде. Аның нигезен шушындагы Шөгер һәм Керкәле авылы егет-кызлары тәшкил итә. Очраклы кешеләрне күрмәссең хәзер. Инде менә ничә квартал рәткә коллективта хезмәт һәм җәмәгать тәртибен бозу очраклары юк. Бу исә администрациянең, технолог Зөһрә Шәймәрданова, Александр Мурзаев җитәкчелегендәге партия һәм профсоюз оешмаларының гаять зур оештыру эшләре башкаруларын сөйләп тора.

Өченче участокны гына алыйк. Моннан утыз-кырык ел элек бораулангаи алтмыш биш скважина шушындагы бригада карамагында. Коелар искереп эштән чыкканга, бирәдә эшләр хөрти иде. Участок айның аенда, планны үтәмичә, хуҗалыкны артка сөйрәде. Шушы кыен бригадага яшь, энергияле, сәләтле мастер Владимир Сидорин билгеләнде, өлкән оператор итеп алдынгы эшче Сәгыйть Гаязов куелды. Участок Гата Минһаҗов, Виктор Петров, Рәшит Хәйретдинов кебек нефть осталары кулына тапшырылды. Хәзер мондагы скважиналар саны йөздән артык. Аларның яңа бораулангаиннары гына түгел, «борынгылары» да туктаусыз нефть бирә, план һәм йөкләмәләр үтәлә. Хәтта моннан кырык ел элек тишелгән беренче скважинадан да тәүлек саен ике тонна ягулык алына.

Карамагында сиксәннән артык скважина булган икенче участокта да мастер Николай Николаев, Ильяс Гаязов, Әсгат Йосыпов кебек операторларның тырышлыгы нәтиҗәсендә нефть мул килә.

Икенче классны мастер, республиканың атказанган нефтьчесе Мәхмүт Мөхәммәтҗанов җитәкчелегендәге участокның, монда эшләүче комсомол-яшьләр бригадасының эше аеруча мактауга лаек. Мастер үзе нефть промышленностенда утыз өченче елын эшли. Хәтердә: аңа инде моннан өч ел элек үк пенсия билгеләнгән иде. Ул һаман — промыселда. Чәченә чал кунарга да өлгермәгән пенсионерны (нефтьче-ирләр пенсиягә 55 яшьтә чыга) комсомол-яшьләр бригадасы башында күрү башта сәерсендерә, әлбәттә. Әмма эшләре белән танышып, уйланып йөргәннән соң, моның нәкъ шулай кирәк икәнен инанасың. Бригадада — комсомоллар һәм яшьләр. Аларга күз-колак булып, эшкә өйрәтеп торучы бер остаз да кирәк ләбаса. Мәхмүт Мөхәммәтҗанов — әнә шундый остазларның берсе инде.

Бригада Зобай суының ике ягы буйлап тезелеп киткән йөздән артык скважи-

нага, җиде группалы үлчәү һәм промыселның бөтен нефтен җыеп кудыручы җайланмаларга хезмәт күрсәтә.

Егетләр тәүлек саен 1300 тонна нефть алып, бригадалар арасындагы социалистик ярышта квартал саен беренчелеккә ирешәләр. 1982 ел йомгаклары буенча коллектив нефть чыгаручы комсомол-яшьләр бригадаларының Бөтенсоюз ярышында да икенче урынга чыкты. Аңа ВЛКСМ Үзәк Комитетының Почет грамотасы һәм премия бирелде...

Әнә шундый уңган егетләр җиң сызганып эшләгәнгә, промысел һаман үргә күтәрелә. Әнә шундый тырыш нефтьчеләр, маңгай тирен агызып юллаганга, Шәгер икенче яшьлеген кичерә.

## Изаил Зарипов

# ПАР КАНАТЛЫ ЯКТАШЛАРЫМ

ОЧЕРК

Мин аларны атналарга сузылган сменаларыннан соң Себердән Бөгелмәгә самолетта очып кайтканнары өчен генә пар канатлыга санамыйм. Әүвәл аларның бу ерак араларда ни белән шөгыльләнүләре турында сөйләргә кирәктер, мөгаен. Канатларның сере шунда ачылыр...

Ленин орденлы В. И. Ленин исемендәге «Нижневартовскнефть» идарәсенең баш геологы Юрий Свищев миңа Самотлор нефть һәм газ җитештерү осталары алдында торган яңа бер мәсьәлә турында сөйләде.

— Без бик катлаулы юл белән табыла торган нефтькә тотынмакчы булабыз,— диде.— «Божыр» дигән кушамат та тактык инде үзенә. Шундый кошны беләсезме? Кечкенә генә, канатларында вак кына кара таплары бар. Ике мең метр тирәнлектән чыккан, божыр кадәре генә балчык йомарламындагы кара төрткеләр безгә катламда нефть барлыгын хәбәр итте.

Юрий Свищев хәлнең бөтен җитдилеген аңлатып бирде. «Божыр» нефтенә олы юл ачу, нигездә, бораулаучыларның иҗади хезмәтенә бәйле икән.

— Бөтен документлар әзер, эшне кайсы төштән башларга кирәген дә билгеләдек,— диде.

— Кемнәр бораулаячак?

— Бөгелмә егетләре! — Юрий, бу хәбәрнең мине шатландырганын белгән кебек, өстәп тә куйды.— Татарстаннан килгән Анатолий Фоминга тапшырабыз, эзләп-тикшерү бораулаучыларының Норлат идарәсеннән ул. Беләсездер?..

Белмәгән кая?! Бораулаучыларның Бөгелмә идарәсендәге өр-яңа баш геолог Себер нефте турында шактый мәгълүматлы кеше иде. Әмма әкияттәгедәй мул нефте дә, табигатенең серлелеге дә аны әллә ни кызыктырмады. «Тайга!», «Сазлыклар!», «Илле градуслы суык!»... кебек сүзләргә дә аның әллә ни исе китмәде. «Булыр, булыр...» — дигәндәй, ваемсыз гына тыңлап тора да үз эшен дәвам итә иде. Татарстанда да геологка эш — муеннан. Бигрәк тә бораулаучылар алдына: «Нефть скважиналарын — тоташ агымга!» дигән яңа бурыч куелгач, эш артканнан-арта гына барды. Кызыклы, мавыктыргыч һәм өметле яңалык иде бу. Шуңа күрәдер дә инде, Себергә китәргә өндәүләр никадәр көчле булса да, Анатолий Фомин беркая да кузгалырга уйламады.

Берсендә «Татнефть» берләшмәсе хезмәткәрләренең зур киңәшмәсе җыелды. Докладчы тагын бер яңалык хәбәр итте.

— Без тиздән Төмән өлкәсенә самолетта кайтып-китеп йөри торган бораулау предприятиеләре оештырачакбыз,— диде.— Вахтадагылар иң җайлы лайнерларда очып йөриячәк...

Гомер ишетелмәгән бу оешманың төзеләчәгенә кем ышанды, кайсы көлеп кенә карады. Көлүчеләр арасында Фомин да бар иде.

Әмма, озак та үтмәде, Себергә очып китәчәк бораулаучыларның яңа идарәсен туплау да башланды. Аның штабы Бөгелмәдә булачак икән. Бу шәһәрдә нефть предприятиеләре юк, шунлыктан яңа идарәгә килгән кеше, вак-төяк сәбәп табып, тиз генә башка эшкә күчеп утыра алмый. Тәвәккәлләгәнсең икән, басылып кына шушы яңа идарәгә хезмәт күрсәтергә тиеш буласың.

Кадрлар табу шактый кыен иде. Хәтта бораулау эшләре идарәсенең начальнигы вазифасына да кеше чыкмый торды. Гадәттә, белгечне башка якка, яңа урынга билгеләгәндә, аны берәр баскычка күтәреп куялар. Бу очракта исә яшь хезмәткәрләр икешәр, хәтта өчәр мәртәбәгә үстерелде. Бәхеткә каршы, безнең гади һәм өлкән инженерлар да, геологлар да, энергетиклар һәм механиклар да әлеге эшнең зур материаль керем китерәчәгенә түгел, ә иҗат өчен киң колачлы мөмкинлекләр тудырачагына кызыктылар. Ун еллар буе тыныч кына эшләп яткан оешмаларда үз осталыгын, нигә сәләтле икәнен белә алмый аптыраучыларга Себер ягы гаҗәеп тәҗрибә мәйданы иде. Чын нефтьче икәнсең, бар шунда, рәхәтлән, күтәр профессиональлек дәрәҗәңне! Табигатенең бинһая четерекле булуы исә синең чыдамлыкны, егетлегеңне дә сынаячак. Замананың иң алдынгы эш алымнарын үзләштерергә һәм шул юлда өр-яңа күрәшкә әзерме син? Чамала!

Моңарчы Норлат тикшеренү-бораулау идарәсенең өлкән геологы булып эшләгән Анатолий Фоминны, яңа оешманың баш геологы вазифасына ризалашканда, мәсьәләнең әнә шул ягы кызыктырды. Коллективның баш җитәкчесе итеп Казанның «Татнефтегазразведка» трестында, баш механик буларак, зур тәҗрибә туплап өлгергән Семен Багрий билгеләнде.

Кичекмәстән эшчеләр җыярга тотындылар. Ашыгыч белдерүләр таратылды! «Бораулау осталары кирәк! Тиз арада!..» «Татнефть» берләшмәсе дә һәр идарәнең бу яңа оешмага ярдәм итүен сорап торды. Әллә ни көттермичә, Себергә очып йөрүче коллективка кабул итүләрен үтенеп гаризалар агыла башлады.

Нижневартовскида бөгелмәлеләргә өр-яңа мәйдан бирделәр. Баш геолог Анатолий Фомин «Урьевка» участогына беренче очып килде. Шаккатты — моңарчы телдән-телгә күчеп йөргән сүзләрдә нефтьчене монда көткән кыенлыкның чиреге дә булмаган икән! Алар, әле Татарстанда чакта ук, башта эш кирәк-яракларын җайлап куярбыз, кыш кергәч, иркенләп, бораулаларга тотынабыз, дип өметләнгәннәр иде. Татарның буыннан-буынга килгән: «Чанаңны җәйдән әзерлә!» — дигән мәкале дә Себер өчен ярап бетми икән шул. Монда чанаңны да, арбаңны да бары кыш көне генә әзерли аласың, чөнки җир-су бозланып катмыйча, берни дә эшләп булмый.

Октябрь иде инде. Бөгелмә егетләре җайланмалар куярга да мөмкин булмаган җирдә бораулау эшләре алып барырга тиешләр. Баткаклыкның өсте генә туңа башлаган. Насосларны, ташпулат биеклеге авыр корылмаларны анда ничек урнаштырмак кирәк? Кимендә ике айсыз эшкә тотынырлык түгел. Димәк, бу елда алар бер метр да бораулый алмаячаклар. Киләсе елның икенче кварталына гына өмет итәргә кала.

Себернең үзендәге бораулау идарәсен җитәкләүчеләр арасыннан берәү Мега елгасының аръягына ишарәләп:

— Май аенда без анда әзер участокны ташларга мәҗбүр булдык,— дип куйды.— Язгы ташкын куып чыгарды, бораулап бетерә алмадык, бригаданы күчерергә туры килде. Шатлана-шатлана киттеләр, хәзер аларны анда көчләп тә китермен димә инде. Башкаларга да яман атын таратып бетерделәр, бишенче төбәккә берәүнең дә барасы килми...

— Әзер участоккамы? — Фоминның сөенече эченә сыймый иде.— Бораулаучы өчен моннан да зур бүләкне кайдан табасың!

Хуҗалар, бер-берсенә карап, елмаешып куйдылар.

— Рәхим итеп алыгыз гына! — диделәр.

Яңа гына Бөгелмәдән очып килгән Сельсков бригадасы, әллә ни озакка сузмыйча, бораулауны башларга да тиеш иде. Бу урындагы сигез скважинаның дүртесе әзер икән инде, калганнарында ун мең метрлап бораулларга кирәк булачак. Тик мондагы станокның җегәре калмаган, аны, өр-яңадан диярлек, монтажлау

таләп итеп. Кызганычка каршы, Бөгелмәдән килгәннәр арасында монтажчылар юк. Фомин үзе дә:

— Менә сиңа бүлә-ә-әк! — дип офтанырга мәҗбүр булды.— Ачудан, барын да ташлап, кире кайтып китәрсең, валлаһи!

Юк, монда егетләрнең башлаган эшне ташлап китә торганнары җыелмаган иде. Мега елгасы юка боз элпәсе белән капланугa, алар кирәкле җиһазларны аргы ярга чыгару җаен эзли башладылар. Әйберләрен үзләре ясаган чаналарга төяделәр дә, аны төрле тарафтан арканнарга бәйләп, боз өстенә таралыштылар. Тарта башладылар. Чаналарда эш өчен кирәкле һәммә нәрсә, хәтта электрик двигательләр дә бар иде. Һәркем бик сак хәрәкәтләнергә икәнен тоя иде. Себерлеләр татар егетләренең, кыш җитәр-җитмәстә елга кичүенә хәйран калып карап торды...

Бу вакытта алдан әзерләнгән дүрт скважина инде нефть бирә башларга тиеш иде. Әмма мондагы бораулаучылар, метр артыннан куарга, ә нефть тапшыру хакында әллә ни баш ватмаска өйрәнгәннәр икән. Өзлексез бораулап кына тору аларны, үтелгән метрлар санына карап, моңарчы ишетелмәгән рекордларга китергән. Билгеләнгән төштәге бөтен скважиналар бораулангач кына, нефть җитештерүчеләр эш башлыйлар. Шулай итеп, илгә байлык китерүче төп хуҗалар, тулаем, бораулаучылар карамагына, алар хөкеменә тапшырылган.

Үзләштерү цехы начальнигы Рем Ильясов белән Анатолий Фомин үзләренә бирелгән урындагы дүрт скважинадан нефть суырта башларга мөмкинлеген чамалыйлар, шул ук вакытта калган дүрт скважинада бораулауны да дәвам иттерергә була. Идарә начальнигы Багрий белән киңәшәләр...

Нефтьче һөнәренең кыйммәте нәрсәдә? Җир куенындагы байлыкны мөмкин кадәр тизрәк кулга төшерүдә, әлбәттә. Нефть ала алмыйсың икән, меңәр метр аска төшүеңнән ни файда?! Уртак фикергә килеп, әзер скважиналардан нефть алу бригадасы оештырырга хәл кылалар.

1979 елның көзендә бишенче төбәктәге эшләр ике юнәлештә алып барыла башлады: үзләштерү бригадасы беренче дүрт скважинага тотынды, ә бораулаучылар үз эшләрен дәвам иттерделәр. Себер нефте тарихында беренче тапкыр, бораулау түгәрәкләнеп җитмәгән төбәктә, кыйммәтле ягулык фонтаны бәреп чыкты.

Татарстан нефтьчеләре теленә «тоташ агым методы» дип телгә кергән бу алым Бөгелмә егетләре өчен яңалык түгел иде. Әлмәттәге бораулау мастеры Социалистик Хезмәт Герое Дамир Нуретдинов тәкъдиме белән җайга салынган бу ысул бездә күптән үзен аклаган, хупланган иде инде.

Себердә исә бораулый башланган төбәк, бораулаучыларның эше бетмичә, нефть бирми. Кайбер скважиналар айлар, хәтта еллар буе бөкеле килеш утыра бирә. Мәгълүм ки, башланып та соңгы нәтиҗәсен күрсәтмәгән һәр эш дәүләткә зур зыян китерә. Башлангыч өчен билгеле күләмдә чыгым тотылган, файдасы күренми. Казылган коелардан нефтьне суыртмый торуның зыяны тагын да зуррак. Андый катламның сыйфаты начарланганнан-начарлана бара.

Гаделлек өчен шунысын да искәрик, Себердә тоташ агым ысулыннан нәкъ Татарстандагыча ук файдаланып та булмый, аны мондагы шартларга җайлаштырырга кирәк. Мега аръягындагы бишенче төбәк бу юнәлештә дә беренче тәҗрибә иде...

Бөгелмә егетләре, уңышлы беренче адым үрнәгендә, «Урьевнефть» өчен унҗиде төбәктә бораулау һәм үзләштерү эшләрен берьюлы алып бардылар. Аларның һәрберсендә — сигезләп скважина. Шул коелар санынча минем якташлар үзләрен ут астына куя килделәр, чөнки мондагылар, алда әйтелгәнчә, нефть алырга ашыкмыйлар. Бораулангaн метрлар гына булсын, аннан сыек ягулык чыгамыюкмы, бусы — башка мәсьәлә, янәсе. Бары метр артыннан гына куучылар рекорд арты рекорд бирә, графиклары алдан үтәлә, хезмәт хакы, премияләр артканнан-арта.

Бөгелмәлеләрнең эш алымы, халык әйтмешли, үз өстенә үзе бүре китерүчеләр хәле кебек күренә. Һәр скважинадан мөмкин кадәр тизрәк нефть алырга тырышу бораулаучыларның кулын тота, тизлекне киметә, хезмәт хакына да шактый начар тәэсир итә, премиясез калу куркынычы тудыра.

Себерлеләр иң беренче күрсәткеч итеп бораулаган метрларны санарга өйрәнгәннәр. Бөгелмә бригадаларында мондый караш — ят нәрсә. Бораулаучы белән нефть чыгаручы кулга-кул тотынып эшләмәсә, хезмәтнең кызыгы да юк кебек. Монда үзләштерү бригадаларына да оста белгечләр бирергә, аларны яхшы техника белән коралландырырга тырышалар. Әлмәтнең бораулаучылар әзерләү мәктәбендә, Бөгелмә үтенече буенча, скважиналарны үзләштерү осталары да әзерләнә. Бөгелмә идарәсенең баш геологы карамагында махсус скважиналар үзләштерүче РИТС булдырылды...

Әлбәттә, Бөгелмәдән очып йөрүче бораулаучылар, Себердә очраган бу каршылыкка кул селтәп, җип-җиңел юлдан да китә алалар иде. Бораулаган метрлар гына кирәк икән — әйдә, тиш тә чык! Тик Бөгелмә егетләре хезмәт нәтиҗәсен соңгы этапта күрергә өйрәнгәннәр. Нижневартовск нефть районында, алар казыган коелар арасында нефть бирмичә утыручылары бик аз. Кызганычка каршы, Себердә бу чын җиңүне тиешенчә бәяләргә өйрәнмәгәннәр әле. Информацияләрдә бары тик бораулау нәтиҗәләре яктыртыла.

Бөгелмә идарәсе исә миннән Рем Ильясов җитәкчелегендәге үзләштерүчеләр бригадасының хәлләре турында язуымны үтенде. Ильясов белән әңгәмә сәеррәк башланып китте.

— Сез циркны яратасызмы? — дип сорады ул.

— Яратам. Анда кешенең нәрсәләргә сәләтле икәнен беләсең. Арена барын да ап-ачык күрсәтә дә бирә!

— Арена — чепуха! — диде Рем.— Сез менә минем егетләрнең ничек эшләгәнен белсәгез иде! Бервакыт, һич көтмәгәндә, өскә язгы ташкын ябырылды. Мондагы яз сәер икән: сабырсызланып, шашынып килә. Безгә, скважинаны үзләштереп бетерү өчен, күтәрткеч җайланма куярга кирәк. Кичтән китереп калдырдык, суык иде әле. Иртән су һөҗүм итә башлады. Йөз яшәр эрбет агачлары ыңгыраша-ыңгыраша чайкалырга тотындылар. Коточкыч. Төбәкне дә менә-менә су басар кебек. Минем егетләр — манара башында. Нәкъ циркачлар, тик алар тамаша күрсәтмиләр. Кулларында — ун-унбишәр килограммлы ачкычлар, болтлар, күтәрткечне ныгыталар. Аларга биеклектә уйнаучы гимнастлар хәленә керергә дә, кыл өстендә биюче артист ролен башкарырга да туры килде. Мин белән, циркачка, егылып төшкәч, трюкны кабатларга да рөхсәт ителә. Безгә исә кабатлау мөмкинлеге бирелмәгән иде. Ник дисәң, бер яктан су кысрыклый, икенчедән, шушы скважиналардан алыначак нефтьнең югалу ихтималы куркыта.— Ремның йөзе балкып китте.— Нәкъ минутында өлгерделәр. Су һөҗүме алдыннан берничә генә минут элек нефть фонтаны бәреп чыкты...

Ильясов бригадасына егетләрнең иң уңганнары җыелган. Күтәртү җайланмасы машинисты Мөкътәсим Шакирҗанов, мәсәлән, дизель тавышыннан чамалап та, җир куенына ничә торба төшерелгәнне төп-төгәл итеп әйтеп бирә. Мөкътәсим осталыгының бөтен нечкәлекләрен, шушындый катлаулы шартларга очрамасаң, кайда ачып бетерер идең әле?

Машинист Шәрәф ага Фәхретдинов та — бригаданың төп терәкләреннән берсе. Аның озак еллар бөртекләп җыйган тәҗрибәсеннән тулысынча файдалану өчен дә Себернең мең мәшәкатьле нефте кирәк булган икән!

Рем Ильясов бригадасының яшьләре өчен Мөкътәсим белән Шәрәф кебек өлкәннәрнең үрнәге гаять шифалы. Төрлесе төрле яктан җыелган егетләрне бердәм гаилә итеп тоту өлкәннәрдән башка мөмкин дә түгел кебек. Үзләре булдыклылар алар, авырлыклардан курыкмыйлар, туган җиргә безнең хакта яман хәбәр ишетелә күрмәсен, дигәндәй, җан-фәрманга тырышалар. Фәндүс Гыйлаҗев белән Иршат Мөдәррисов — Азнакайдан. Анда аларның һәр адымнарын белешеп торучы дуслары күп. Кайткан саен сорашалар. Фәндүснең һәр яңалыкка бик теләп алынуын да беләләр. Бригадир Ремның бер күрсәтүе җитә — Фәндүс шунда ук эләктереп ала, кабатлап торуның һич кирәге юк. Өйрәнергә, күбрәк белергә тели Фәндүс. Егетнең дуслыкка тугрылыгы да, оештыручанлык сәләте дә, туган яктан еракта эшләгәндә, аеруча кирәкле сыйфат.

Иршат, эшен яхшы башкару өстенә, спортны да бик ярата. Ул, Азнакай якла-

рында, сабан туе мәйданнарын тота иде. Бөгелмәгә барып, аннан да, иң көчле көрәшчегә, дип билгеләнгән бүләк сарыкны алып-алып кайткалады...

Хәзергесе көндә монда бары да бер максатка, нефтьне күбрәк алуга юнәлдерелгән. Шул изге максат хакына алар, көч-куәтләрен һәм намусларын пар канат итеп, бөтен авырлыкны өсләренә алып, бораулаган скважиналардан нефтьне тизрәк чыгару ысулын алга сөрәләр. Бораулау метрларын гына арттырып, рекорд куу һәм... нефть алмый тору аларның әхлагына сыймый. Бу омтылыш безнең ил, дәүләт, халык, партия мәнфәгатьләренә дә туп-туры җавап бирә. КПСС ҮКның һәр күрсәтмәсе халык хуҗалыгын эффектлы, файдалы һәм экономияле юлдан алып барырга кирәклекне искәртеп тора.

Бер карасаң, бөгелмәлеләрнең эш алымы турында бәхәс бөтенләй урынсыз кебек. Казылган коедан, беренче мөмкинлек туугa, нефть ала башлауның, белгечләр теле белән әйткәндә, нефть чыгаруны тоташ агым ысулына күчерүнең, һичнинди бәхәс кузгатуы да мөмкин түгел кебек. Тәкъдиме дә, тәҗрибәсе дә бар — җиң сызганып эшлә генә! Татарстанда, чыннан да, шулай. Бөкеләнгән скважиналар юк дәрәҗәсендә. Казып туктадыңмы — нефть чыгара башла! Татарстан нефтьчеләренең бу ысулын, гаҗәп отышлы булганга, бөтен ил нефтьчеләре куллана башлады. Урта Обь елгасы буендагы промыселлар гына моны күрмәмешкә салышалар. Меңнәрчә әзер скважиналар тик тора. Тоташ агым методы нәкъ менә Урта Обьта зур отыш китерер иде. Монда бит колач башка! Димәк, нәтиҗә дә ифрат эффектлы булачак.

Гаҗәпкә каршы, шушындый мул байлыкны бикләп яткырганнары өчен, берәүнең дә җавап биргәне юк. Ник? Бәлки, монда нефть алуны тоташ агым ысулына күчерү бик катлаулыдыр? Бу сорауга Рем Ильясов бригадасы үрнәгендә җавап бирү урынлы булыр. Гыйлаҗев һәм Ханмедов вахталары бораулау дәвам итә торган төбәкләрдә нефть алуны да тып-тыныч җайга салып баралар. Бөгелмә егетләренең бу ысулдан Себердә дә файдаланырга мөмкин икәненә бер генә мизгелдә дә шикләнгәннәре юк. Омтылышың гына нык булсын да акыл һәм көчеңне эшкә җигә бел! «Бел!» дигәне шул — скважиналарның җайланмасын, үз карамагындагы мәйдан мөмкинлегеннән чыгып, дөрес урнаштырырга кирәк. Техника куркынычсызлыгы кагыйдәләренең таләпләренә дә җавап бирсен, бораулаучыга да иркенләп эшләрлек булсын, әзер скважинаны үзләштерергә дә мөмкинлек табылсын!

Бөгелмәдән очып йөрүче коллектив Себер шартларына ияләшеп үк җитмәде әле. Тиз бораулау серләренә дә, сыйфатны яхшыртуга да өйрәнәсе бар. Әмма үзләренә тапшырылган төп бурычны, илгә күбрәк нефть бирү, дип тану — аларның изге ышанычы. Аларны нефть бирми утыручы коеларга ишарәләп кенә кызартырга мөмкин булыр иде, бу төп мәсьәләне чишүдә аларның йөзе ак.

Татарстан бораулаучылары алга сөргән тоташ агым ысулын себерлеләрнең әле һаман кабул итәселәре килми. Семен Иванович Багрийның бик тәфсилләп аңлатуыннан соң алар шактый сагайдылар. Карашларында, бу ысулны безгә көчләп такмагайлары тагын, дигән шик-шөбһә дә чагылды. Шул арада ялкаулыкка ярдәм кулы сузучылары да табылды. Нижневартовскидагы тау техникасы инспекциясе хезмәткәрләре Бөгелмә егетләренә дә тоташ агым ысулы белән эшләүне катгый тыйдылар. Инспекция кулында, шактый искергән булса да, инструкция бар. Шулай итеп, Бөгелмә идарәсенең, Себергә алып килеп, шактый киң колачлап файдалана башлаган яңалыгы өр-яңа каршылыкка очрады.

Унҗиде төбәктә йөз кырыкка якын скважина үзләштерелгән иде бит инде! Хәвеф-хәтәр дә булмады, нефть тә шаулап килә торды! Ирешелгәннәрне ныклап өйрәнеп, бөтен Себер тирәлегенә ярардай бер отышлы алымны законлаштырасы урынга — мә сиңа, эш туктатылды! Бөгелмәлеләргә өр-яңадан экспериментлар уздырырга, хаклыкларын раслап күрсәтергә кирәк иде.

Яңа алым тыелгач, Бөгелмә идарәсе начальнигы Семен Багрий махсус киңәшмә уздырырга мәҗбүр булды. Уртак фикергә килергә кирәк иде. Иң соңыннан:

— Кемдә нинди фикерләр бар? — диде ул.

Берәү гомуми теләкне белдерде:

— Бораулаганда ук, үзләштерү эшләре өчен, әзерлекне башларга кирәк! — диде.
Начальник кырт кисте.
— Бораулау һәм үзләштерүне берьюлы алып бару катгый тыела, дидек бит инде. Нигә кабатлап торырга?!
— Мин бит, «үзләштерү», димәдем, сүз әзерлек эшләре турында гына бара. Үзләштерүчеләргә әзерлек ясап торсак та, нефтьне, кимендә, егерме-егерме биш көн алданрак кудырта башларга мөмкин булачак.
— Әзерлек ясау өчен дә шул ук эшләрне үтәргә кирәк бит инде, башны катырмыйк, булмый! Манара куючылар кисәтелгән, алар безне якын да китермәячәк...
— Алар көндез эшли, төн — безнеке!
Кемдер кыю иптәшенең сүзенә куәт бирде.
— «Белозернефть»тә дә безне яклаучылар бар, тәвәккәллик!
1981 елда Бөгелмә егетләре бораулау, манараларны сүтү һәм нефтьне үзләштерү эшләрен берьюлы алып барып, отышлы алымнарының хаклыгын кабат расладылар. «Белозернефть» идарәсеннән тиешле белешмә дә алдылар. Бары да тәртиптә, рәсмиләштерелгән. Кирәксә, төбәкләрнең тәртип санын да күрсәтергә мөмкин: 320 нче һәм 315 нче төбәкләр...
Хәзергә шуннан артыгын әйтергә ярамый. Көрәш дәвам итә әле. Рәсми кәгазьне кем язып биргәнне дә, бу юнәлештә тырышып йөрүчеләрне дә, камилләштерүне кәтә-кәтә искереп беткән инструкциягә туры килмәгәнлектән, әйтми торыйк әле. Сер икән, сер булып калсын! Әмма төн карасында башкарылган ул операцияләр һәм төгәллекнең, һәм тәвәккәллекнең, һәм бердәмлекнең сокландгыч үрнәгеннән саналырга хаклы. Хәрби операция диярсең! Егетләрнең аны тел-теш тидергесез итеп очлап чыгулары — чордашларыбызның чираттагы каһарманлыгы ул.

*

* *

«Нижневартовскнефть» идарәсендәге әле күптән түгел генә булып узган бер утырышта 1983 елгы эшләрнең сүлпән баруы турында сүз кузгалды. Сәбәпләрнең берсе итеп бораулаган скважиналарның нефть бирми утыруы танылды. Карар проектын укыдылар. Партком секретаре В. Н. Гуриненко:
— Кемдә, нинди өстәмәләр бар, иптәшләр? — дип сорады.
Фомин сүз алды.
— Нефть җитештерүдә артка калуыбызның иң төп сәбәбе — үзләштерү эшләренә игътибар җитмәү,— диде.— Бу юнәлештә Бөгелмә егетләренең ифрат файдалы тәҗрибәсе бар. Карарга: «Самотлорда да бораулау белән үзләштерү эшләрен берьюлы алып барырга рөхсәт бирүләренәирешергә!» дип өстәргә иде!
Яздылар бит, әй, өстәп яздылар! Бусы — бөгелмәлеләрнең тагын бер җиңүе иде. Килер бер көн: нефтьчеләр эшен тоташ агымда алып бару ысулын Себер промыселларының төп кагыйдәсенә әйләндерерләр! Ул чагында төнге тәҗрибә үткәрүчеләргә ярдәм кулы сузган кешеләр турында да тәфсилләп сөйләргә мөмкин булыр.
Шушындый катлаулы хезмәттә дә Фомин геологлары эзләнү эшләрен дәвам иттерделәр. Көнбатыш Себер җиренең тирәндәрәк яткан яңа байлыкларына юл ярдылар. Геологның омтылышы очучыныкына охшаш, тик ул биеклеккә түгел, тирәнлеккә тартыла. Нефть җитештерү предприятиесенең баш геологы Владимир Репин белән киңәшкәч, Фомин егетләре 765 нче скважинаны тагын йөз дә ун метрга тирәнәйтергә тәвәккәлләделәр. Яңа җиңү килде — скважинадан тәүлегенә 75 тонна нефть бирә торган фонтан бәреп чыкты. Икенче, өченче скважиналарның нефте исә Юра катламының «Урьевка»дагы язмышын хәл итте.
Бөгелмәлеләр үрнәгендә, Мега буенда да шундый ук катламнан нефть ала башладылар.
«Бөгелмәлеләр» дигән сүз ешрак кабатланганга аптырап, проект институтларының берсендә сорарга мәҗбүр булалар:

— Кемнәр соң алар?

Егетләрнең, чагыштырмача, яшь оешмадан икәнлеген аңлаталар. Соңгы вакытта аларга, институт әзерләгән схема буенча борауларга, дип, яңа мәйдан тапшырганнар икән. Әмма бораулаучы егетләр проектны кабул итмиләр, ди. Институтныкылар:

— Яңа чакта була ул, аңламаганнардыр,— дип, котылырга чамалыйлар.— Килсеннәр, консультация бирербез, төшендерербез!

Баксаң, Бөгелмә бораулаучыларына бернинди консультация дә кирәк түгел икән. Алар проектта җитди кимчелекләр тапканнар. Эшне гади генә итеп тә үтәп чыгарга була икән бит! Фомин үзенең «Урьевнефть»тәге коллегасы Д. М. Усков белән яңа схема тәкъдим итәләр. Нефть бирәчәк скважиналарның саны сакланган хәлдә төбәкләрне алтмыштан кырык җидегә калдырырга һәм чыгымнарны сигез миллион (!) сумга киметергә мөмкинлек табалар. Нефтьче геологлар иҗат иткән проект, отышлырак булганга, дәүләт комиссиясе тарафыннан раслана.

Инде Себердә иҗади эзләнүләр алып баручы һәм илнең ягулык байлыгын арттыруда армый-талмый хезмәт итүче якташларымның, чыннан да, пар канатлы икәне ачыклангандыр, дип уйлыйм.

*Әлмәт — Нижневартовск*




Рахмай Хисмәтуллин

# РЕСПУБЛИКАНЫҢ КӨНЧЫГЫШЫННАН ХАТЛАР

## Гадәттән тыш кызыклы чор

Мин, махсус кайтып, ике атна буена туган төбәгемнең тарихын, табигатен яңадан өйрәнү бәхетенә ирештем. Азык-төлек программасы яраткан шөгылемне бермә-бер актуальләштереп, аерым бер мәгънә бирде сыман. Һәм шул нигездә борынгы һәм бүгенгенең контрастлары уйларымны тирәнәйтеп җибәрде.

Актаныш, Мөслим, Минзәлә районнарына караган бу төбәк кешеләре белән очрашып, көндезләрен һәм кайчак төннәр буе да юлларда һәм кырларда, кыр станнарында, өйләрдә булып, борынгы һәм бүгенге көннәр турында гәпләштем, һәр көн яңача балкыган тормышның яңа төсләрен күзәттем.

Башта — тарих турында. Авыллар арасында төрле яшьтәгеләре бар. Инде беренче бабаларның зиратлары сөрелеп, басу-кырга әверелгәннәре дә, замана күрке булып торганнары да, борынгы авыллардан күченеп ясалган, әмма аз гомерле булып, бүген инде урыннары гына торып калганнары да бар. Ни генә булмасын, шайтан таягы, кычыткан һәм алабута баскан элекке авыл һәм йорт нигезләрендә басып торуы аерата моңсу һәм шомлы икән.

Авыл тарихы — җир өчен көрәш тарихы ул. Бу төбәк авыллары үз тарихларын Казан ханлыгы таркалган чорлардан, уналтынчы гасырдан алып исәплиләр. Күз алдына килә: әнә алар, ханнар һәм морзалар тарафыннан алданып, өметләре сүнгән, кайда җәяү, кайда атларга атланып, авыр йөкләр күтәренеп, елгалар, карурманнар кичә-кичә, хуҗасыз җирләр эзләп, көнчыгышка таба күченәләр. Зур югалтулар аша, яшәргә өмет итеп. Берни дә мәңгелек түгел икән: патша да, дәүләт тә, сүзләр-вәгъдәләр дә, әмерләр дә. Бары тик яшәргә теләү генә мәңгелек икән...

Ә хәзер кыр-басулар юк. Карурман да карурман. Һәм алар хуҗасыз карурманда тукталып, аны агачлардан арчып, иген игә башлаганнар. Бу җир аларны бар иткән, юкка чыгудан саклап калган. Дүрт гасыр буена монда бабаларның бик күп тире тамган, шушы хәләл җир өчен бик күп каннары коелган.

Биредәге татар авыллары мари авыллары белән аралашып утырган. Кайбер татар авыллары һәм туган авылым Әнәк янында борынгы мари зиратлары да бар. Мин тирә-яктагы бөтен мари авылларында да йөреп чыктым. Тарих белүчеләр барысы да бер авыздан бабаларының бу якларга татарлар белән бер үк чорда килүләрен әйттеләр. Хәтта кайдан, кайсы бабалары килеп утыруларын да бик әйбәт беләләр икән.

— Татар халкы белән без әүвәлдән, борынгыдан дус яшәгәнбез,— дип сөйләп китте Мәскәүдән ялга кайткан отставкадагы полковник Имам Җамалиев.— Чиста, эшчән халык бит ул татар халкы. Мин милләтем буенча мари. Ләкин гомерем буе «Казан утлары» журналын яратып укыдым. Татар теленә, әдәбиятына гашыйкмын.

Шулай ук татар авыллары утырган төбәкләрдә Баҗана, Кыпчак, Сарашлы, Үркә, Ык («ак» сүзеннән үзгәртелгән икән) кебек географик атамаларның да төркичә аталуы минем шикләремне бөтенләй таратып җибәрде. Бабаларым, марилар белән уртак язмышлы кешеләр буларак, аралашып яшәгәннәр, зиратлар да шуның бер билгесе булгандыр. Димәк, бабаларым берәүне дә рәнҗетмәгәннәр, бу кара урманнарны чыннан да үзләре төпләп, яшәргә яраклы җир иткәннәр.

Соңга таба шушы җир өчен, француз һәм герман сугышлары кебек зур яуларда, бик күп асыл ирләр һәлак булганнар! Шушы җир өчен...

## Заман башка, китү барыбер моңсу...

Бабаларыбыз, әтиләребез тире һәм каны белән сугарылган әнә шул меңләгән гектар җирләр өчен хәзер кеше белән кеше, авыл белән авыл сугышмый. Заман башка...

Киресенчә. Бу җирләрне әнә теге урман арчыган бабаларның оныклары «берни дә булмагандай, бик җиңел генә» ташлап китә алалар. Дөресрәге, калганнар «бик җиңел ташлап, китәләр» дип сөйлиләр. Һәр карышының үз тарихы булган туган җирне, салкын чишмәле, саф урман-таулы, болын-әрәмәле туган җирне, үзенчә сөйләшә, моңлана, җырлый һәм авыруларыңны дәвалый ала торган туган җирне ташлап китүе әллә җиңелме?! Китүче, әгәр таш йөрәкле генә булмаса, «читтә рәхәт яшим» дип, ничек кенә юанмасын, туган авылыннан аерылганда, калкулыкларына басып бер борылып карагач, үзендә түләнмәгән җан бурычы сизеп, барыбер яшерен генә яшь сыгып аладыр. Ник сыкмасын: бу бит — ата-бабалар бишеге, монда, якынча, уналты буын дөньяга килеп, кояш белән саубуллашып, дөньядан киткән. Илебезнең төрле шәһәрләрендә бик күп алар, шушы җир кешеләренең меңләгән-меңләгән оныклары!

Бер яктан, бу китү — кешенең, җиргә генә берегеп яшәмичә, теләгән җиргә барып урнаша, эшли алу азатлыгы, рухның җирдән югары күтәрелә алу азатлыгы. Заманның бу олы казанышыдыр. Шулай ук авылдан киткәннәрне гаепләп тә булмый. Чөнки шәһәрдәгеләр дә, кемдер атаганча, шәһәр ялкавы булып йөрмиләр. Шау-шулы эссе цехларның ялыктыргыч конвейерлары янында сигезәр сәгать буе басып эшләп әнә шул киткәннәр дә тудыра техника-машиналарны.

## Кемнәр китә? Нигә?

Авылдан кемнәр китә? Бу китү нигезлеме? Һәртөрле шәһәр һөнәрләренә, зур гыйлемнәргә хиресләр китсен, ә җир белән аналарча сөйләшеп, чәчәк-гөл, туфрак телен, башак шавы җырын аңлаганнар, җир җанлылар, җирсез яши алмаучылар, Табигать Аксакалы, Кыр Батыры булырдай, иҗат итеп эшләрдәй кешеләр калсын иде! Авылда калырга теләп, анда тормышка ашырыр хыялы булганнар да, объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында, җиргә битарафлана һәм китә. Әмма аның бит җаны авылда калды. Шәһәрдә ул җаны-тәне белән бирелеп эшли алырмы? Гомере буе адашкан көч булып йөрмәсме?

Бу бик сагайта. Беренчедән, йөзләгән Алыплар көчен үзенә җыйган техника авылның йомшак туфрагына капылтрак килеп төште. Агач төпләгән бабаларның да һәм гасырлар буена шушы авыллардан шәһәрләргә китә барган меңләгән авылдашларның да беләк көчләре, могҗиза сыман, шушы техникага тупланган. Арба-чананы һәм атны гына күтәрергә күнеккән йомшак туфрак бу куәт авырлыгыннан сыгылып, ыңгырашып куйды сыман. Крестьян күңеле белән дә бераз шулайрак булды, ахры. Бер уйласаң, авылның табигатен ата-бабалар хыялланган рухи матурлык чыганагына әверелдерер өчен нәкъ менә хәзер мөмкинлек туды сыман. Әнә шул йөзләгән ат көчле машиналар белән җирне нәкъ менә хәзер күз карасы кебек кадерлә, саклап кына эшкәрт, ашлама керт, җимерелә барган ярларга, кырларга һич тә соңармыйча агачлар утырт, һәр авылда камышлы күлләр булдыр, чылтырап аккан чишмә янындамы, төбәгеңнең барлык үлән-гөле,

чәчәге үсә торган кагылгысыз табигать почмагы яса, гомумән, гасырлар буена населеңне туендырган җирне туйганчы бер иркәлә, басулар бирердәй байлыкны гына санама, ә һәр сырт-болынның, һәр төбәкнең серләрен ач, шуларны белгән аксакаллар белән киңәш, Җир Акылын тот, кыскасы, син аны гармонияле чәчәк аттыр!

Әмма бу кадәр мең гасырлык куәт тупланган техниканы дөрес файдаланырга авыл әле бик үк әзер түгел, аның культурасы җитми булып чыкты. Күпчелек очракта, рульдә утырган кешедә дуамаллык инстинкты өстенлек алыпмы, техниканың авыл табигатенә каршы агрессиясе башланды. Теләсә кайдан, теләсә ничек таптатып, урамнар йөри алмаслык чокыр-чакырларга, яланнарның күп өлеше яргаланган яраларга (элек чәчәк-гөл генә үскән Әнәк яланын барып күрсәгез иде сез!), кырларның шактые эрозиядән ермак-ерганакларга әверелде. Язгы сулар белән бергә кубарылып, ата-бабалар туфрагы елый-елый акты. Җирнең аңа биргәндә генә бирә алуын онытып, аны чиктән тыш җәфалаудан, камил агротехника сакламаудан иде бу. Болар авыл табигатен, димәк, аның тормышын да, бермә-бер ямьсезләтте, аның элекке котын-матурлыгын алды.

Икенчедән, мин — куәт, мин — көч, дип килеп төшкән техника, үзе бер колхозга әверелеп, кешеләргә ихтыяҗны киметте, бетерде сыман. Авылга техника, шофер, тракторчы хуҗа и вәссәлам. Син — архитектор, син — бизәүче, син — урманчы, син — декоратор, син — шагыйрь генә, син кечкенә, көчең дә чамалы, сиңа китсәң дә ярый, янәсе...

## Эшлеклеләрнең колагына бер сүз

Миңа бик эшлекле саналган җитәкчеләр белән очрашырга туры килде. Әмма алар да кайчак иң үзәктә кеше күңеле икәнен онытып җибәрәләр. Әйтик, озак еллар буе терлекчелектә эшләгән уңган колхозчы, шул ук вакытта биш бала тәрбияләп үстергән ана пенсиягә чыга икән, син инде аңа бүләкне шоферың аша гына бирең җибәрмә, ә кеше алдында, зурлап, үзең тапшыр. Маңгай тирен түгеп, үз эшен яратып эшләгән яшь шофер өйләнә икән, аның туен котлап чыгарга да вакыт тап. Колхозда эшләп картайган пенсионерга: «Утын булды, әби, 50 чакрымдагы урманнан, ну, кайтартуын үзең кара янсә балаларың кайтартсын инде, әби!» — дип, аның кулына язу кисәге тоттырып китмә! Син, җитәкче, барын да күмәк хуҗалыкча үзең оештыр.

«Балаларың кайтартсын», дигәннән. Кайбер авылларда, колхоз оешканнан бирле, комбайн урынына ураклар урып картайган пенсионер карчыкларның, утын мәшәкатен генә түгел, гомумән, бөтен ихтыяҗларын балалары җилкәсенә авыштырып калдыру модага кергән. Беренчедән, төрле балалар бар. Бар намуслысы, бар бөтенләй ата-анасын онытканы... Әмма баласы нинди генә булмасын, пенсионер үзе эшләп өлеш керткән колхоздан башкалар алган ярдәмне алырга хокуклы. «Балаң бар, ярдәм итсен»,— дигән сүз карчыкларның күңелен җәберли, аны шул ук балалары һәм тирә-күрше каршында ким-хур итә. Шәһәрдә бит әнә бер дә: «Улың бар, квартираңны шул ремонтласын, улың бар, улыңда тор, сиңа квартира бирмибез»,— димиләр.

Әллә пенсионер карчыкның, балалары каршында, колхоз тарафыннан хөрмәт ителүен, хезмәтенең юкка чыкмаганлыгын күрсәтәсе килми дисезме сез?! Килә, бик килә, ничек кенә килә әле!

Эшләп картайганнарның күңелен күрә белсәң, көт тә тор, шәфкатьле җитәкче буларак, даның җырларга күчәр.

Күңел күрү дигәннән, Түбән Камада «Камэнергостройпром» дигән берләшмә бар. Шушы предприятие озак еллар буе артта калып килде. Аңа яңа җитәкче итеп Вәгыйзь Әхмиевич Яһудинны билгеләделәр. Ярты ел да үтмәде, предприятие алдынгылыкка чыкты. Кызыксындым.

— Ничек шулай бик тиз өзеклектән чыктыгыз соң? — дим. Иптәш Яһудин кыска җавап бирде:

— Мин кешеләр турында уйлыйм, ә кешеләр — эш турында.

Чыннан да, аз гына вакыт эчендә ул эшчеләргә җиләк-җимеш бакчалары, шәхси гаражлар булдырды, ашханәне яхшыртты. Цехларны кеше күңелен күтәрерлек итеп чистарттырды, буятты, тиз арада квартираларны да шактый күп салдырды.

Һәм гөрләде эш тимер-бетон заводында. Менә шулай оештырырга, әлбәттә, батырлык та, талант та кирәк.

Шулай ук мин Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсенең генераль директоры Социалистик Хезмәт Герое Николай Васильевич Лемаевның җитәкчелек стилен дә үрнәк итеп китерер идем. Ул атна саен үткәрелә торган зур планеркаларын һәрвакыт эшченең тормыш-көнкүреше турында сөйләшүдән башлый да, түтәлләрдә үсәчәк гөлләр, тәрәзә каршында шаулаячак агачлар хакындагы фикерләрен әйтеп тәмамлый.

Түбән Камадагы уңышлар КПСС Үзәк Комитетының махсус карарына лаек булган икән, аңа әнә шулай һәр даим кеше турында кайгырту нәтиҗәсендә ирешелгән.

## Бар ул иҗатчылар!

Әллә авылда сокландыргыч җитәкчеләр юкмы? Бар, әлбәттә. Һәм үзем әлеге сәяхәттә күргән ундүрт авыл тормышында да уңай яктан телгә алып сөйләрлек яхшылык-яңалыклар да күп.

«Урожай» (Мөслим районы) колхозының даны, мәсәлән, бөтен тирә-күрше районнарга таралган. Серен беләсе иде бит: ни өчен анда эшләр гөрләп бара?

Актаныш районына кергән туган авылым Әнәктән уникe генә чакрым ул. Чиктәшләр. Беркөнне җәяүләп шунда юл тоттым. Тирә-якта өлгереп килгән игеннәр шаулый, дөньяга өмет тулы хозур чаклар...

Грунт юл бу колхоз җиренә килеп керү белән биек итеп күтәртелгән олы юлга әверелде. Әле эшләнеп ята. Союзкүләм трасса салалармыни! Аңа менгәч, офыклар киңәеп киткәндәй булды. Бераздан бу юл вак ташлы шоссега әйләнде. Як-ягында берьеллык үлән үсә, билдән! Яшь наратлар тезелеп киткән. Колхоз үзеге Тат. Буләргә якынлашкан саен, аның да яшеллеккә төренеп утырганын чамалыйсың. Кайбер авылларда файдаланырга уңайсыз һәр җирне чүп басып утырса, монда яшь урманчыклар шаулый. Һәр йорт янында җиләк-җимеш бакчалары. Әйе шул, яшеллеккә, шау чәчәкле бакчаларга да төренеп утырмагач, нинди авыл ди ул! Каралты-куралар бер төрлерәк. Такта белән тышлатылган өйләр күбрәк лимон төсендәге якты, шатлыклы төскә буялган, капкаларда — кояшлы чәчәк рәсемнәре. Менә бусы, бер-берсенә охшаш, бердәй матур булып елмайган яңа йортлар ахры яшьләр урамыдыр. Аларын колхоз салдыра икән.

Әнә үзенә бер ямьле формада корылган янгын депосы, әнә шәһәрдәге зур предприятиеләр генә төзи ала торган биек, иркен мастерскойлар күтәрелеп килә. Культура йорты авыл пейзажына ничек килештереп салынган! Бизәлеше белән дә үзенә чакырып тора!

Колхоз идарәсенең ике катлы кирпеч бинасы һәртөрле шәһәр иҗатчыларының зәвыгы белән ярышырлык: гөлләр, колхоз тормышын сурәтләүче фотолар белән бизәлгән. Рәсемнәрдәге йөзләрдән көч-куәт, шат тормыш нуры балкып тора!

Авылның гүя үз эстетика инженерлары, үз архитекторлары бар! Кайбер авыллар яныннан үткәндә, кеше күзенә ташланып торган чүпләкләр, динозавр кабыргасын хәтерләткән түбәсез иске корылмалар, инде беркем дә яшәми торган җимерек йортлар күреп, җан өши.

Баксаң, әнә авылга да, Тат. Буләрдәге сыман, борынгы авыл архитектурасын да, милли орнаментларны да, табигатьне дә сакларга тырышып эш итүче архитекторлар, капка, кәрниз бизәкләрен камилләштерүне дәвам итүче, үткәнне киләчәк белән бәйләп, матур корылма салучылар бик кирәк икән! Монда күңел үзенә бер ял табып, рәхәтләнеп китте.

Гомумән, Мөслим районында табигатьне кадерләүче кешеләр яши, ахры. Былтыр бу район аша узганда, юллары начаррак булса да (Пучыдан Мөслимгә барганда), бер нәрсәгә — җир эрозиясенә каршы көрәшнең көчле булуына, һәр җирдә яр, чокыр, ермак читләренә бик күп агачлар утыртылуына сокланган идем. Һәр авылда яңа өй бураларының күплеге дә куандырган иде. Район үзәге капкасына, бик матур итеп, бизәп: «Мөслим якларын онытмагыз!», «Хәерле юл сезгә, иптәшләр!» кебек сүзләр язып эленүе дә күңелгә хуш килеп, биредә бөтен район бизәнә, тәртипкә керә бара, дигән тәэсир калдыра.

Безгә, гомумән, авыл капкалары һәм анда нинди сүзләр язу турында да бөтен республика күләм ныклап уйланасы бар әле. Алар культуралы да, шигъри дә, күңелләрне дәртләндерә торган да булсыннар иде!

Мин күптән очрашырга теләгән кешеләрем — колхоз председателе Мирхаҗиян Сәләхов һәм партком секретаре Илдус Җиһангиров белән идарәдә сөйләшеп утырам. Сорауларым һаман бетми. Беләсе килә дә беләсе килә. Бөтен бу төбәккә иң алдынгы колхоз ич бу! Болар мине ике-өч сан белән «егып салдылар». Ышанмаслык. Уйлап карагыз, терлекчелектә корылыклы 1981 елда да район буенча, игътибар итегез, район буенча, 660 мең сум саф табыш алынган. Шуның 430 меңе бер колхозныкы — шушы «Урожай»ныкы! Сызгырып куярсың! 1982 елгы 4550 центнер еллык ит планын да 18 июньгә үк инде 4578 центнер итеп арттырып үтәгәннәр.

— Мөслимдә дә, Актанышта да, Минзәләдә дә бу кадәре продукция саткан хуҗалык юк,— дип куйдылар ир-егетләр. Горурлыклары бик ошады миңа.

Моның серләренә тирәнрәк кереп карамау гөнаһ булыр иде. Кама, Агыйдел буендагы кебек иркен болыннар да юк бу якларда. шундый уңышларга ничек ирешкәннәр соң?

## Серләр...

Колхоз тимер юл станцияләреннән, һәртөрле базалардан ерак. Минераль ашламалар да бу якларга озак килә. Бәс шулай икән, димәк, серне җирнең үзеннән эзләргә кирәк. Һәм тапканнар. Бик тирәннән, бик борынгыдан башлаганнар. Борынгы кардәш төрки бабаларыбыз исемен йөрткән Бажана елгасыннан ел саен йөз меңләгән тонна торф чыгаралар. Аны тирес белән катнаштырып бер ел тотып (монда шунысын әйтеп үтү дә урынлы булыр: шәхси хуҗалыклар да үзеннән арткан тиресне, кайбер авыллардагы кебек чокыр япсә яр буйларына аудармый, ә колхозга бирә, шуның өчен акча да ала), сөрү җиренең һәр гектарына унбишәр тонна кертәләр.

Җиргә бирсәң, җир бирә икән! Каерылып үсә терлек азыгы. Күпьеллык үләне генә дә гектарыннан — 500, азык чөгендерен — 683 центнер алалар. Әлбәттә, бу уңышлар Татарстанның атказанган агрономы Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Тимершаех Фазуллинның күңел нурлары белән дә үстерелә.

Өлгергән азык тагын юньле кеше кулына эләгә. Терлекчелекне, азык хәзерләүне Татарстанның атказанган зоотехнигы, үз эшенең фанатигы Зөфәр Солтанов җитәкли. Печәнен, сенажын, онын — барысын да үз вакытында арзан да, сыйфатлы да итеп әзерләп куялар. Хәтта теге корылыклы елны да терлек азыгы эзләп беркая да чыкмаганнар.

Механизаторлардан Әнвәр Илдарханов, Расил Фазлыев, Имам Вәлиев, шоферлардан Хәлфетдин Ильясов, Мирхаҗиян Мәхмүтов, Әнвәр Нәсертдинов, Мирхаҗиян Сәләховлар — терлек азыгы әзерләүнең чын осталары.

Кызыксындыру чаралары да уйланылган: терлекчегә һәм механизаторга класслылыгы һәм стаж өчен өстәмә түләнә.

Уңышларның икенче сере — терлекләренең нәселле булуы икән. Яхшы нәселле атлар, нәселле сыерлар, нәселле дуңгызлар һәм сарыклар. Менә шул сыйфатлы мул азыкны ашап симергән нәселле терлек боларга гаҗәеп зур табышлар китерә. Әйтик, 1981 елда мөгезле эре терлекнең һәрберсе уртача 446 килограммнан

тапшырылган. Ә 400 килограммнан арткан һәр баш терлек өчен 50 процент өстәмә түләнә! Шушы хисапка гына да 120 мең сум табыш алганнар.

Тана симертүчеләр — Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Дамирә Хисмәтуллина, Рәзимә Хәйдәрова, Рузия Каюмова, Фәндусия Шаһалиева, дуңгыз симертүчеләр — бригадир Рәшит Хөсәенов, Әсләх Гозәеров, Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы Ания Низамова, III дәрәҗә Хезмәт Даны орденлы ферма мөдире коммунист Фәндәлия Низамова, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Почет билгесе орденлы бригадир коммунист Шәйхенур Локманов, һәр сыердан ел саен өчәр мең килограммнан артыграк сөт сауган Сәгыйдә Хәйруллина, Сәхия Кәшапова, Нәҗибә Нәҗиповалар сабан туе батырларыча горурлана алалар.

Бу колхозның тагын бер даны бар — атлар, юртаклар тотуы республикага гына түгел, илгә таралган. Атларны, сабан туйларын яратучы шагыйрь Зөлфәт үз туган ягы турында, бәлки, шуның өчен генә дә өзелеп язадыр әле.

Бөтен тирә-күрше районнардагы сабан туе ярышларында болардан сатып алынган атлар беренчелекне тота. Бүгенге көндә 25 баш юртак Куйбышев өлкәсе ипподромында сынау үтә. Колхоз һәр елны 20 шәр нәсел аты сата, кайберсе 15—20 шәр меңгә китә. Атчылыкның үз-үзен аклавы 150 процент булып, елына 120 мең сум табыш бирә. Кадерен белеп асрасаң, атлар әнә нинди файдалы икән!

Атлар турында сөйләгәндә председательнең тавышлары ук үзгәреп, дәртлерәк булып яңгырый.

— Мин 30 ел чамасы элек бирегә эшкә килгәндә җигәргә ат юк иде. Атсыз авыл — нинди авыл инде ул?! Башлап җибәрдек. Аннары бу эшне яратучы да табылды. Зөфәр Солтановка, ат булса, ашың да кирәкми. Күп көч куя. Ат заводларына йөри. Җайдак Фаздалов Исламгалигә дә ат җене кагылган...

Әлбәттә, кайда юньле атлар — анда кымыз! Бабаларыбызның борынгы гадәтен яңартып, кымыз цехы ачып җибәргәннәр.

Кымыз цехы! Бу турыда салкын кан белән генә язарга мөмкин түгел. Заманында бөек Тукайлар, Толстойлар, Чеховлар, әллә кемнәр тагы, Кырымнарны да калдырып торып, шушы колхозга чиктәш башкорт төбәкләренә кымыз белән дәваланырга йөргәннәр. Кымызга эләгә алган кешеләр: «Болай булгач, терелдем, яшәрдем!» — дип, үзләрен иң зур дәвага юлыгучыга санаганнар.

Соңгы дистә елларда, техника белән ярышта атлар җиңелгәч, акрынлап бетүгә йөз тоткач, кымыз ясау шөгыле дә тәмам сүнеп бара иде. Һәм менә яңарыш! Борынгы игелекле шөгыльне, тазалык һәм дәрт чыганагын яңадан торгызганнар!

Бүген бу шифалы эчемлекне гап-гади колхозчылар эчә, пионер лагерьларында укучы балалар эчә, болынга ял итәргә төшүчеләр эчә, больницаларда эчеп дәваланалар.

Рәхмәт сезгә татбүләрлеләр! Шул ук тынмас җан Зөфәр Солтанов, кымыз цехы начальнигы Насретдин Сәрваров, кымыз осталары Рәшидә һәм Эльвира Әкъмаловалар, бия савучы Рәсимә Закировалар, рәхмәт сезгә!

Көненә 25—30 бия дүрт тапкыр савыла. Һәр биядән 4—8 литр сөт алына. Бу тәүлегенә 120 сумлык кымыз дигән сүз. Ел әйләнәсенә менә сиңа тагын 43 мең сум табыш.

— Моны һәр колхоз-совхоз оештыра алыр иде,— ди председатель Сәләхов.— Башкалар да моңа тотынсалар, кымыз сорап, бик ерактан килүчеләр азаер иде. Гомумән, булмый ул, дип, сылтау табулар, һәртөрле акланулар белән килешә алмыйм мин. Безне төрлечә өйрәтеп карадылар инде. Әлбәттә, өйрәтүгә дә колак салырга кирәктер. Әмма җирнең үз авазын тыңлау, аның борынгы мөмкинлекләрен ача белү хәерлерәктер. Мәсәлән, специальләштерү, дип, кайбер колхозларда сарык, тавык фермаларын бетерделәр. Ул хуҗалыкларның башка ягы да алга китмәде, ни сөте, ни ите калмады. Ул фермалар матур гына яшәп килсә, иш янына куш булыр иде! Терлекчелек ул табигый үсәргә тиеш. Кымыз да — әнә шул табигыйлек җимеше.

Бу төбәкләрдә мин Сәләховка иярергә хыялланучыларны да очраттым. Туган колхозыма яңарак эшкә килгән яшь председатель Таһир Әхмәевнең сарык фермасын торгызырга, кымыз цехы ачарга һәм Ык елгасы буена колхозчылар өчен ял йорты салырга йөрүе бик ошады миңа. Уң булсын!

«Урожай»да умартачылык та — табышлы тармак. 300 баш умартадан елына 15—20 мең саф табыш алалар. Ә анда нибары дүрт кеше эшли. Колхозда эшләүче һәр кеше шулай 5000 саф табыш китерә алса, елына өч миллион җыелыр иде.

Шулай ук елына ярты миллион кирпеч суга торган кирпеч заводлары да табышлы эшли. Ул булмаса, 60 кешелек төзүчеләр бригадасы тотып, һәр авылда мәһабәт итеп мәктәпләр, клублар, медпункт һәм кибетләр салынып иде микән?! Ә башкалар, тимер-бетонны һәм силикат кирпечне шушы ерак төбәккә Казаннардан ук ташу өчен, күпме мал түгәләр?!

Колхоз хуҗалыгын яхшы исәп-хисап белән алып баруда экономист Дилфас Әминов, баш бухгалтер Зариф Мостафиннар зур өлеш кертә.

Әлбәттә, иң әүвәл кеше турында ныклап кайгыртылмаса, бу уңышларга ирешү мөмкин булмас иде. Колхозчы йорт сала башласа, аның ярты бәясен колхоз үз өстенә ала, бурасын, материалын — кадак, пыяласына хәтле колхоз бирә. Колхоз хисабына 52 йорт төзелгән. Анда яшәүчеләр ай саен колхозга түләп баралар һәм, билгеле бер сроктан соң, йорт колхозчыныкы булып кала. Шәп бит!

Гомер буе бу кыр як авыллары суга интеккән. Хәзер колхоз, 250 мең сумга төшереп, полиэтилен торбалар салдырта, чиста чишмә суы эчертә.

Тат. Бүләр урамнарында әле кайбер район үзәкләрендә дә булмаган асфальт тротуарлар сузылган.

Колхоздагы 588 хуҗалыкның һәрберсеннән бер кеше чамасы эшче кулы, ягъни 600 колхозчы, 6300 гектар сөрү җирен эшкәртә. Шушындый ук мәйданлы кайбер колхозларда болардагының яртысы гына эшләвен искә алсаң, күп монда эшче кулы. Шулай да колхозчылар сафын яшь көчләр белән тулыландыру турында һаман да даими кайгырталар. Урта мәктәпне тәмамлагач, колхозда калырга теләк белдерүчеләргә яңа шартлар буенча каралган бөтен уңайлыклар тудырылган.

Әмма, шушындый уңышларга ирешүгә карамастан, монда да хәл ителәсе мәсьәләләр күп әле. Председатель сөйли:

— Шулай да, туган, авылда эш артык күп әле крестьянга. Төгәл билгеләнгән эш сәгате юк, билгеле бер ялы юк. Авыр әле, авыр. Терлек абзарлары төзү дә кыенлык белән бара. Материал җитешми. Авыл белән шәһәр тормышы арасында гына түгел, хәтта үзебезнең авыл җирендә дә шактый контрастлар бар. Самавырның борынын икенче якка борып куя алмасак та, әйтик инде. Районда «Сельхозхимия», ПМК кебек оешмалар бар бит. Менә шуларның эшчеләре генә дә, колхозчыга караганда эшкә соң киләләр, иртә кайтып китәләр. Яллары да бар. Үзләре колхозчы белән бер үк кырда эшли бит. Ни уйламас колхозчы?!

Мин тәҗрибәле председатель Мирхаҗиян Сәләховның сүзләрен йөрәгемә бик якын кабул иттем. Чәчләренә чал йөгергән колхоз ветераны, РСФСРның атказанган зоотехнигы, Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Почет билгесе орденнары кавалерының фикерләренә тиешле оешмалар да колак салырлар шәт.

Әлбәттә, бу колхозда да җитәкчеләр белән генә сөйләшеп калынмады. Әле яңадан да ялгызым гына авыл тарихын өйрәнеп йөрдем. Һәм күп төрле гыйбрәтле сүзләр ишеттем. Монда да печән, утын хәзерләү әле үзәкләштереп бетерелмәгән. Миңа Мари Бүләр авылында пенсионер карчыклар яшәгән йортлар өстендә искереп беткән салам яисә кабык түбәләр булуы бер мичкә балга төшкән тамчы деготь сыман тоелды. Аныйсын гына рәтләрлеге бар ич инде бу хуҗалыкларның.

Безнең сүз тагын Азык-төлек программасына кайтып калды.

— Әлбәттә, бу без көткән карар булды,— диде парторг Илдус Җиһангиров.— Дөрес, без анда күрсәтелгән кайбер чараларны инде куллана да башлаган идек. Шулай да үзең генә уйлап чыгару — бер хәл, дәүләткүләм конкрет кулланма кирәк иде! Бу Программа безгә киң юл ачты, кыюлык бирде...

«Урожай»лыларның эше уң булсын, алар үрнәгенә иярүчеләр ишәйсен иде!

# Рифкат Кәтиев,

«Тататомстрой» идарәсе баш инженеры урынбасары

# АЭС ҺӘМ АВЫЛ



*Җәй башланган иде инде. Төзүчеләрнең зарыгып та, якты өметләр белән канатланып та көтеп алган айлары. Кама Аланында Татарстанкүләм беренче атом электр станциясен салучылар өчен елның бу фасылы бигрәк тә кадерле, чөнки кышкы-көзге-язгы юллардан китереп җиткерә алмаган кирәк-яракларны Кама буйлап ташу җае ачыла. Инде менә табигать, ниһаять, ишекләрен киңәйтә төшкән — рәхим ит! Шуңа да төзүчеләр бер минутны кырыкка бүләрдәй булып эшлиләр: гүя нәкъ шушы кулай шартларда үзләренең нинди каһарманлыкларга сәләтле икәнлекләрен күрсәтеп-раслап калырга ашыгалар.*

*Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр белән, аерым алганда, журнал һәм АЭС төзелеше арасындагы иҗади хезмәттәшлек Килешүенә имза салучыларның берсе, идарәнең баш инженеры урынбасары Рифкат Кәтиев белән кабат очрашу шушындый шартларда үтте. Барысын да минутлап бүлделәр. Йортлар төзү комбинатының мондагы идарә начальнигы Рәис Сәләхов: «Хәзер барыбыз да төшке ялга туктыйбыз,— диде.— Төзүчеләр ун-унбиш минут тамак ялгап алырлар, калган кырык биш минутны әдәбиятка багышлыйбыз!»*

*Чыгыш ясарга тиешле кешеләр үзара сөйләшкән арада, Рифкат Кәтиев тә үз мөмкинлекләрен санап күрсәтте: «Шигырь тыңлаганнан соң мин тагын берәр сәгатькә тоткарлана алам әле,— диде.— Сәгать икедә объектта булырга тиешмен».*

*Әңгәмәбез исә бик табигый, яңа гына тыңлаган шигъри сүзләргә ялгангандай башланды.*

**Сорау.** Ничек уйлыйсыз: вагоннарда гына яшәп көн иткән, хезмәт шартлары да әле эзгә салынып җитмәгән төзүчеләр өчен, көндезге ялга бүленгән вакытларын алып, әдәби очрашу үткәрүнең эшкә уңай йогынтысы булырмы?

**Рифкат Кәтиев.** Һичшиксез! Күрәсезме: төзүчеләребез — яшьләр. Әлегә культура сарайларыбыз, театрларыбыз, кино-залларыбыз юк. Тәвәккәлләп, очрашуны шушы төзелеш мәйданында, тау-таш арасында оештыруыбыз аларга бик ошый. Мин монда үзем дә гаҗәеп бер уртаклык тоям, хезмәт мәйданнарыбыз, азга гына булса да, чын-чынлап бергә кушылып ала. Төзүчеләрнең күбесе төшке аштан баш тартты. Шаярып сөйләшкәннәрен ишеттем: «Әй, ашаган бар ла ул! — диләр.— Менә тере язучы күреп калырга иде!..» Бу көн безнең хәтердә озак сакланачак. Ә бүген, төштән соң, мин һич шикләнмим, хезмәт нормалары арттырып

үтәлгән булачак. Минемчә, монда икеләнерлек урын да юк, җанга ятышлы сүз, сәнгати матурлык белән күзгә-күз очрашу һәркемгә бары тик уңай тәэсир генә итә ала. Төзүчеләр исә — үзләре дә иҗат иясе бит алар. Дөрес, алар әдәби образ белән эш итмиләр, алар берсеннән-берсе матуррак, җайлырак йортлар яки конструкциясе бик катлаулы промышленность объектлары салалар. Шуңа күрә безнең бер-беребезне тирәннән аңларга бөтен мөмкинлекләр бар дип беләм мин.

**Сорау.** Монда килгән язучылар сезне үз иҗатларындагы яңалыклар белән таныштырды. Сез дә хезмәтегездә ирешелгәннәргә тукталсагыз иде!

**Рифкат Кәтиев.** Алар шактый күп: шатлыгы да, борчулары да. Мин, нигездә, атом станциясен салучылар эшенә тукталырмын инде. Матбугат, радио һәм телевидение күбрәк торак салучылар уңышын яктырта. Миңа калса, инде хәзер станциянең үз төзелеше турында да авыз тутырып сөйләр чак җитте. Без быел «Пионер базасы»н салуда унсигез миллион сумлык эш башкарырга тиеш без. Башлангыч еллар өчен аз түгел бу. Ике йөз егерме урынлы ашханә өлгертү, ГДРдан китерелгән тулай торакларны файдалануга тапшыру, чистарту җайланмаларын көйләп җибәрү — барысы да шуңа керә. Атом станциясенең үз мәйданында да яңалыклар шактый. Инде, акрынлап, төп мәйданга аяк бастык. Безнең монда «түбәнге», «өске» дип исем алган мәйданнар бар. «Өске»сендә төзелеш идарәсенә, автохуҗалыкка, субподряд оешмаларга кирәкле объектлар салына. Тәэминат бүлеге базасы да шунда. «Түбән» мәйдан җылылык чыганагы өчен бүленгән. Андагы котельный эшне дә, поселокны да җылы су белән тәэмин итәргә тиеш.

**Сорау.** Төзелешнең хәзерге стадиясендә кулны тотып торырдай нинди кыенлыклар очрый?

**Рифкат Кәтиев.** АЭС төзелешендә дә башка урыннардагы кебек үк җитешсезлекләр тулып ята. Без инде аларга күнегеп беткән. Төзелеш гөрләп барсын өчен нәрсә кирәк? Моны һәр төзүче әйтеп бирә ала: кадрлар, хезмәт мәйданы, материал, юллар һәм торак — биш нәрсә! Кызганычка каршы, кагыйдә буларак, шул бишнең һәрчак бер-икесе җитенкерәми. Башта юлсызлык интектерде. Аннары измә мәсьәләсе алга чыкты. Без бөтен төзелешне, ягъни торак йортлар салу оешмасын да, үзебезнекеләрне дә тәэмин итәрлек бетон измәсе җитештердәй җайланманы көйләп куярга тиеш идек. Шактый алдан: «Измә җайланмабыз әзер!» — дип, хәбәр таратып та өлгердек. Ул үзе чыннан да әзер иде. Тик измә генә чыгара алмыйбыз, чөнки цемент килеп җитми. Хикмәт ара ераклыкта гына да түгел, кадерле бу чималга, гомумән, туя алмыйбыз без. Шунлыктан төзелешкә кирәкле измәне я Зәй шәһәреннән, я Түбән Камадан ташырга мәҗбүр булабыз.

Кадрлар белән дә эш бик шәптән түгел. Ташчылар, сылаучы-буяучылар кирәк. Механизаторларны, монтажчыларны әзерләү яхшы куелган, ә менә отделочниклар аз. Аннары аларны училищеда укыту гына да җитми, бу хезмәт тәҗрибә туплауны сорый. Сылаучы-буяучы, берничә ел эшләми торып, остарып җитә алмый ул.

Ни генә булмасын, без быел бу кыенлыкларны чишеп бетерергә тиешбез. Вакыт кыса. 1983 елны, без, үзебезчә, старт алды елы дип атадык. Киләсе ел планнары бик зур. 1984 тә без утыз биш миллион сумлык эшне үтәп чыгарга тиеш булачакбыз. Быелгыга караганда, ике мәртәбәгә диярлек, артык бит бу. Һәр мәйданда зур-зур корылышлар башланачак. «Түбән» мәйданда тимер-бетон конструкцияләр заводына нигез салыначак. Су буенда төп причал булдырылачак. Станциянең төп мәйданында да төзелеш сизелерлек алга китәчәк. Су буйлап китерелә торган йөкләрнең күбесе турыдан-туры станция төзелеше ихтыяҗларына тотылачак.

**Сорау.** Ә төзүчеләр тормышында нинди яңалыклар бар?

**Рифкат Кәтиев.** Бер карасаң, әллә ни үзгәрми дә кебек. Исәпли китсәң, алга китеш шактый. Элекке елларда, мәсәлән, бездәгедәй зур корылышка тотынган коллективлар авыл хуҗалыгы белән ниндидер бәйләнешкә керү турында уйлап та карамыйлар иде. Хәзер бөтенләй башка хәл. Бөтен ил бер булып Азык-

төлек программасын үтәү юлына баскач, безнең коллектив та бу бурычтан читтә калмаска карар кылды.

Үзәге Ширәмәт авылында булган «Прикамский» совхозы белән ярдәмләшү килешүе төзедек. Аның нигезендә без совхозда шактый эшләр башкарырга тиеш булабыз: язгы чәчүдә, урак өстендә, көзге мәшәкатьләр чорында ун механизатор, ике-өч терлекче җибәрәчәкбез. Совхоз бүлекчәләре арасында елына биш-алты чакрым юл күтәрәбез, бер урында яшелчә саклау биналары төзибез, совхоз эшчеләре өчен икешәр квартиралы дүрт өй салабыз...

**Сорау.** Бик күпкә китә түгелме соң, шул кәгазьдә генә торып калмасмы икән ул бурычлар? Кай арада башкарып бетерерсез?

**Рифкат Кәтиев.** Мин кабатлап әйтмәсәм дә, беләсездер — хәзер буш сүзләр сөйләү белән генә ерак китеп булмый. Безнең әлеге авыл хезмәтчәннәренә биргән вәгъдәләребезнең һәр саны, һәр сүзе конкрет мөмкинлекләрдән чыгып, төгәл исәпләүләргә таянып билгеләнде. Бусы — бер. Икенчедән, без генә совхозга ярдәм итеп калмыйбыз бит. Төзүчеләрнең үзләрен кызыксындырырдай чаралар да бар. Аларның теләгәннәренә, яшелчәдер, бәрәңгедер кебек нәрсәләр үстерер өчен, совхоз өчәр-дүртәр сотый җир бирә. Монысы — төзүчеләрнең ял вакытын төрләндереп үткәрергә дә бер файда. Болардан тыш, совхоз, төзелеш ашханәләрен яшелчә, бәрәңге белән тәэмин итеп торырга алынды.

Гомумән, бу төзелеш биредәге авыллар тормышына сизелерлек үзгәрешләр алып килде. Атом электр станциясенә кирәкле мәйдан колхоз-совхозлар өлешеннән алына бит. Кайбер авылларның да мәйданы кирәк булып чыкты. Мәсәлән, сиксән йортлы Белякчи авылының яңа төзелеше тулаем безнең идарә җилкәсенә төшә. Авылга кирпечтән менә дигән йортлар салып бирәчәкбез. Проектларны «Татаргражданпроект» оешмасы әзерли. Өйләрнең күбесе беркатлы булачак. Терлек абзарларын гына панельләрдән салачакбыз.

**Сорау.** Бу яңалыкларга авыл халкы ничек карый соң?

**Рифкат Кәтиев.** Авыл кешеләре белән безнең арада урнаша торган мөнәсәбәт, башлыча, безнең үз-үзебезне ничек тотуга бәйле: җирне, борын-борыннан шунда яшәгән халыкның гадәтләрен олылыйбызмы без, әллә алар белән санашып тормау юлына басабызмы... Әлегә кадәр аңлаша килдек. Зарланучылар юк кебек. Кунак булсаң, тыйнак бул, дигәндәй, монда, әлбәттә, безгә үз ниятләребезнең изгелеген раслап күрсәтергә туры киләчәк. Аннары, яшерен-батырын түгел, ил күләмендә сизелерлек энергия бирердәй станция салынгач, бу як авылларның тормышы бөтенләй үзгәрәчәк. Алар яшәреп, дәртләнеп китәчәкләр. Гомер-гомергә зур шәһәрләрдән шактый еракта йомылып яшәгән бу яклар инде хәзер үк шактый яңаралар. Алар хәзер Түбән Кама, Брежнев шәһәрләренә нык юллар буйлатып барып-килеп йөри башладылар. Тормышлары яктырып китте. Әле атом җегәренә таянып эшләүче станция утлары да кабынса...

Ул матур киләчәк турында хыяллана башласам, кичерә күрегез зинһар өчен, мин үзем дә шагыйрьләрчә фикер йөртергә тотынам. Шушы чал елгабыз, кеч-кенә генә борынгы авылларыбыз куенныннан илаһи энергия ургып чыгачак. Андый көч-куәтне әби-бабайлар төшләрендә дә күрә алмаган, андый нәрсә хәтта борынгы әкиятләрдә дә юк. Димәк, кеше бу хакта хыяллана да алмаган әле. Безнең төзүчеләр әнә нинди чикләрне үтеп киттеләр!..

— Юллары уң булсын! Җавапларыгыз өчен рәхмәт сезгә!..

*

* *

*Рифкат Кәтиев тә, әңгәмәне тыңлап торган Рәис Сәләхов та, кай арададыр, кайсы вагонга кереп тә, тиз генә киемнәрен алмаштырып чыктылар. Шигырь тыңларга, әдәби журнал битенә төшәрдәй сүзләр сөйләшергә дип, алар затлы костюмнар киеп килгәннәр иде. Рәис Сәләховның күгелҗем кримплен костюмы, Рифкат Кәтиевнең саргылт галстуклы күлмәк өстеннән кигән саргылт кун пиджагы минут эчендә төзүчеләрнең гади курткасына алышынды. Без, шагыйрьләр һәм язучылар, Рифкат Кәтиев җитәкчелегендә, асты-өскә актарылган мәйданнардан үтә-үтә, Татарстан атом электр станциясе салыначак урыннарны, ГДРдагы дуслар җибәргән җыелмалы тулай торакларны карап йөрдек. Күңелләрдә бу яңа төр төзелеш тормышына карата иң изге теләкләр уяндары: эшләре уң була күрсен!*

Әңгәмәне **КОЯШ ТИМБИКОВА** алып барды

Ибраһим Нуруллин

# ИЛЕҢ ТУРЫНДА УЙЛА...

Төп темасы «Геройлар, проблемалар» дип билгеләнгән сөйләшү бүгенге татар прозасының артта калуына ачыну, моның сәбәпләрен эзләү рәвешендә башланып китте. Темадан читкә тайпылу димәс идем мин моны. Чөнки әдәбиятның дәрәҗәсе, барыннан да элек, типларның яңалыгы, күпсыйдырышлылыгы, гомумиләштерү һәм шул типларда гәүдәләнгән иҗтимагый проблемаларның зурлыгы белән билгеләнә.

Шекспир дидекме, шундук Гамлет яисә Отелло күз алдына килә. Гоголь турында сүз чыктымы, Чичиков, Манилов, Собакевич һәм Хлестаковлар тезелеп китә. Бальзак хакында сүз башладың исә, Гобсек, Вотрен яисә Растиньяк калкып чыга. Яки менә атаклы «артык кешеләр» галереясы: Онегин, Печорин, Рудин, Лаврецкий, Обломов...

Үзебезнең татар әдәбиятына кайтсак та, шул ук хәл. Үсеш-үзгәреш юлы аның багана булып калкып торган типлары буйлап бара. Хатын-кыз образларын гына алыйк: Хәят, Газизә, Галиябану, Гөлбану, Рәүфә, Галия, Миңлекамал, Нәфисә, Гөлзифа һ. б.

Бүгенге татар совет прозасы күп кенә бүтән әдәбиятларның прозасыннан калыша дип сөйлибез икән, тормышның катлаулы һәм каршылыклы күренешләрен гәүдәләндерә торган масштаблы, күпсыйдырышлы типлар җитәрлек түгел дигән сүз бу.

Чынлап та без артта калдыкмы? Бүтән халыкларның прозасы буй үстереп, безнеке генә кәрлә булып калдымы?

Ачынып, кайнарланып, җете буяу һәм тапкыр сурәтләр кулланып язган мәкаләсендә А. Гыйләҗев әйтә: әйе, артта калдык. «Без, үз утрауларыннан башканы күрмәгән, белмәгән, башкаларның булу ихтималын башларына да китермәгән Блефуску утравы лилипутлары хәлендә калмадыкмы икән? Аларда да бөекләр булган, адмираллар, акыл ияләре булган. Ә Гулливер килеп, утрауга аяк басуга, нинди нәни һәм көчсез булып калганнар алар!» Эффектлы сурәт, кискен хөкем.

Р. Мостафин А. Гыйләҗев белән бәхәскә керә, хөкемен йомшартырга теләп, беренче мәкаләдә телгә алынмаган исемнәр һәм әсәрләр китерә дә «прозабызның картинасын ул кадәр үк аянычлы түгел» дип белдерә. Әмма, ары китеп, үзе дә А. Гыйләҗевнекеннән күпкә йомшак булмаган хөкем чыгара. Ул да, тапкыр сурәт кулланып, күпмилләтле совет әдәбиятын катнаш урман белән чагыштыра. Абага да бар анда, ди, артыш һәм чикләвек куаклары да, миләш һәм каеннар да, тез нарат һәм мәһабәт имәннәр дә бар. Аннары, прозаның үзенә күчеп, болай ди: «...безнең хәтта иң биек дигәннәребез дә совет һәм дөнья әдәбиятының киңрәк фонында еш кына уртачадан узмаган гади агач булып, кайчакта куак кына булып күренә».

Асылда бер үк фикергә кайтып кала торган ике авторның дәлилләре нидән гыйбарәт соң? Прозаларның буен ничек үлчиләр, нинди аршын кулланалар?

Барыннан да элек, алар Ч. Айтматов, В. Быков, Н. Думбадзе, В. Шукшин, Ю. Балтушис, М. Кәрим кебек «гулливер» яисә «имән»нәрне бастырып куялар да «карагыз, шуларга тиңләшерлек кемебез бар?» диләр.

Үзәктә була торган югары утырышларда, әйтик, соңгы ике съездда, ди А. Гый-

ләҗев, татар язучыларының «сәнгать әсәре буларак, сәнгатьнең үсешен билгеләүче буларак», бер генә әсәре дә телгә керә алмады. Р. Мостафин да моңа кушыла һәм үзеннән тагын бер дәлил өсти. «Дружба народов» журналы, ди ул, бөтән республика әдәбиятларының яхшырак әсәрләрен сайлап алып, бездән тәкъдим ителгәннәрне кире кага килә. Тәнкыйтьче бер мисал да китерә: һәйбәт кенә автобиографик әсәрләр бездә дә бар, әмма журнал М. Кәрим повестен өстенрәк күрде.

Дәлилләр, әлбәттә, саллы. Ләкин алар шулай да аңлатма бирүгә, төзәтмә кертүгә мохтаҗ...

Чагыштыру, иңен-буен үлчәү мәсьәләсенә кайтыйк. Нигә әле сөйләшүне башлап җибәрүчеләр бөтән әдәбиятларның чыгып торган «сөңгеләрен» генә тулаем татар прозасы белән чагыштыралар? Күренекле вәкилләре телгә алынган әдәбиятларда «вак куаклар» бер дә юкмыни?

Кыскасы, әлеге ике мәкаләдәге кискен хөкем хәтта без фәкыйрегезнең дә намусына килеп тиде. «Гулливер»ларыбыз янсә башы болытка тигән тупылларыбыз юк дәрәҗәсендәмени? Әллә кеше казы күркә булып күренәме? Яки инде үзебезнең «гулливер»ларга без бинокльне әйләндереп карыйбызмы?

Моннан күп еллар элек, союздаш республикалардан берсенең күренекле язучысы белән танышкач, мин аның кирпеч калынлыгы романын укырга керештем. Совет власте урнаштыру өчен көрәш темасына багышланган иде ул. һәр халыкта диярлек мондый темага бер яки берничә зур әсәр язылган. Моны мөһим социаль заказ үтәү итеп карарга кирәк. «Онытылмас еллар» трилогиясе белән бу заказны бездә И. Гази үтәгән иде.

Укыйм романны, ә үзем, ихтыярсыздан, «Онытылмас еллар» белән чагыштырып барам. Әсәр начар түгел, ярлылар да бар анда, урталар да, байлар һәм муллалар да, рус чиновниклары да, өйрәтеп һәм оештырып йөрүче рус большевиклары да бар. Әмма нәрсәдер җитми... Тозсыз аш кебегрәк... Бер нәрсәгә аеруча игътибар иттем: калын романда аз гына да юмор юк. И. Гази трилогиясе, мәгълүм булганча, гаҗәеп җанлы, үзенчәлекле, каршылыклы типларны эченә алуы белән бергә, баштан ахырына чаклы юмор белән сугарылган. Тормышның үзендә дә шулай бит: кайгы һәм куаныч, күз яше һәм уен-көлке, фаҗига һәм мәзәк аралашып бара.

Романны укып чыккач, мин И. Гази трилогиясенең (хәер, ул вакытта дилогия генә иде) көч-куәтен, сәнгать дәрәҗәсен һәм зурлыгын күрдем. Янәшә бастырып куйгач, безнең әдип мәһәбәт имән булып калыкты. Әмма гыйбрәтле хәл: телгә алынган роман, берничә мәртәбә үзәк нәшриятта басылып чыгу белән бергә, соңрак Бөтенсоюз романнары сериясенә кертелде. И. Гази әсәре исә, үзебездә эшләнгән начар тәрҗемәсе белән дөнья күрсә дә, үз өебездән күп читкә чыкмады.

Яки менә узган ел ахырында килеп ирешкән күңелле хәбәр. Ростов-Дон китапханә хезмәткәрләре, милли язучылардан кемнәрне яратып укыйсыз дип, китап укучыларга мөрәҗәгать иткәннәр. Җаваплар буенча беренче урынга Ч. Айтматов, икенче урынга... Ә. Еники чыккан. Әгәр бу язучының хикәя һәм повестьлары рухы һәм талант дәрәҗәсе белән үзенә таңгәл бирәр рус язучысы тарафыннан тәрҗемә ителгән булса? Югары трибунадан янсә үзәк матбугаттан зур исемле бирәү Бөтенсоюз әдәбият җәмәгатьчелегенең игътибарын аның иҗатына юнәлтсә? Өстәвенә, әдип үзе «оештыру» сәләтенә ия һәм активрак та булса? Исемнәре саналган һәм саналмаган «гулливер»лар арасында Ә. Еники дә лаеклы урын алмас иде микән?

Ниһаять, тагын бер исем: С. Баттал. Гаять үзенчәлекле һәм талантлы шагыйрь. «Олы юл буйлап» поэмасы белән ил киңлекләренә чыккан иде. «Сигезенчесе кем?» повесте талантлы прозаик та булганлыгын кабат раслады. Ни сәбәптәндер, тәнкыйть бу язучыны оныта төште. Татар совет әдәбияты тарихына караган хезмәтләрдә дә аңа карата саранлык күрсәтелә.

Ничектер соңлабрак миңа С. Батталның прозасын кабат укырга туры килде. «Баштан үткәннәр» исемле автобиографик повесте белән исә, оятыма каршы, беренче кат таныштым һәм, соклану белән берлектә, аптырап калдым: ничек шушы көнгә кадәр бу әсәр нә докладларда, нә мәкаләләрдә телгә алынмады? М. Кәримнең «Озын озак балачак» повестендагы кебек үк, монда да — карап торышка зур булмаган деталь янсә кечкенә эпизодта тирән мәгънә күрү, көтелмәгән ассоциацияләр

ясау, кыю гомумиләштерү һәм фәлсәфи фикерләү. Шуның өстенә — барлык төсләр белән елкылдап тора торган юмор.

Әсәрдән мисал китерми уза алмыйм. Автор үз авылының биш тилесен (шуларның берсе — «Вазих тилесе», ягъни Баттал үзе) сыйфатлап чыга да «Нәрсә соң ул тилелек?» дигән сорау куя. Иң элек ул аны яшьлек, мәхәббәт һәм шигърияттә күрә. Менә Ләйләнең сөйгәне Мәҗнүн, менә «җүләр, саф, яшь мәхәббәт чагысын» җырлаган Тукай. Менә «Их син, яшьлек, их син, тиле яшьлек!» дип аваз салган Такташ.

Тилелекнең мәгънәсе киңәя һәм тирәнәя бара. «Безумству храбрых поем мы славу!» дигән Горький телгә алына, «акылдан язды» дип сөргенгә озатылган Радищев искә төшерелә.

Прогресс арбасын төпкә җигелеп тартучылар нәкъ менә, үз шәхси мәнфәгатен онытып, хәвеф-хәтәр, хәтта һәлакәт турында уйламыйча, ялкынланып яшәүче һәм көрәшүче шул «тилеләр», шул «башсызлар» түгелмени?

С. Батталның повестен һәйбәтләп тәрҗемә итсәң һәм үзәк журналларның берсенә юлласаң, белмим, кире кагылыр иде микән?

Ахыр килеп, Аяз Гыйләҗевнең үзен алыйк. Аның «Язгы кәрваннар» һәм башка кайбер повестьлары, минемчә, теләсә кайсы әдәбиятны, шул исәптән рус әдәбиятын да бизи алырлар иде.

Юк, безнең әдәбият та төшеп калганнардан түгел, безнең прозаның да биек агачлары һәм гулливерлары бар.

Шулай да, шулай да... Р. Мостафин һәм А. Гыйләҗев сүзләрен җилкә аша җиңел генә атып бәрү кыен. Укучы бәлки игътибар иткәндер: «биек агачлар» эзләп без аксакаллар катына килдек. Урта буында да андыйлар аз табыла. Уртадан яшьрәк һәм яше белән дә яшь прозаиклар арасыннан исә атап күрсәтү дә кыен. Күренә ки, прозабызның бүгенге хәле белән очынып мактанырга нигез юк... Революциягә кадәр прозасы бөтенләй булмаган әдәбиятларның алга чыгуы, безнең белән ярыша башлаулары, ара-тирә шедеврлар белән куандырулары шулай ук күп нәрсә турында сөйли.

Дискуссиядә катнашып моңарчы журнал «трибунасына» менгән иптәшләр, арттакалуның сәбәпләре турында да уйланып, күп кенә фикерләр әйттеләр. Үзебезгә һәм, бер-беребезгә таләпчәнлек җитми, әдәби тәнкыйть кыюсыз, ди А. Гыйләҗев. Традицияләргә ябышып яту, дөнья әдәбияты тәҗрибәсеннән җитәрлек өйрәнмәү, ди Р. Мостафин. Уртакул әсәрләрнең басып китүе, тиешле бәясен бирү урынына андыйларны мактау, чын сәнгать әсәрләре белән бер дәрәҗәгә кую тенденциясе, ди Т. Миңнуллин. Безгә, аеруча яшьләргә, интеллектуальлек җитми, ди С. Шәмси.

Моннан бүтән сәбәпләр дә китерелде. Боларга тагын да өстәргә мөмкин булыр иде. Әмма, дөрес диагноз кую өчен, аталганнарын күз уңыннан ычкындырмаган хәлдә, төп сәбәпне, хәлиткеч сәбәпне табып алу кирәк. Ул сәбәп, минемчә, безнең бүгенге көн прозасына гражданлык пафосының җитенкерәмәве. Бу урында Н. А. Некрасовның бөти итеп тагарлык сүзләре искә төшә: «Шагыйрь булмасаң булмассың, гражданин булырга тиешсең».

Гражданлыкның иң мөһим күрсәткече — ватандарлык тойгысы. Әмма совет патриотизмы ил турында, Ватан турында купшы сүзләр сөйләүдән гыйбарәт түгел. Бу тойгы туган авылың һәм колхозың, цехың һәм заводың мәнфәгатен өстен куеп эшләүдән, уңышларына сөенүдән, кимчелекләренә көенүдән башлана. Аннары ул әлеге авыл һәм колхоз, цех һәм завод, мәктәп һәм институт кебекләрне эченә алган зуррак төбәкләр мәнфәгате хакына яшәү рәвешендә киңәя, байый, ахыр чиктә, бөтен ил киңлекләренә чыгып, совет патриотизмы булып әверелә.

Ватандарлык тойгысы язучыга иңелатә, өчләтә кирәк. Әнә шул төбәкләрдә хезмәт белән яшәгән намуслы кешеләрне бәхетле итү хакына эшләүче азмы-күпме талантлы язучының гына әсәрләре, халык йөрәгенә аша үтеп, аңына барып җитәргә мөмкин. «Шагыйрьлеген» алга куеп, ягъни шөһрәт һәм акча өченрәк язган үтә зур талант иясенең дә киң укучылар массасы мәхәббәтен яулап ала алуына мин шикләнеп карыйм. Йөрәктән чыккан гына йөрәккә үтеп керә бит.

Адәм баласы — тагын бер төбәкнең, дөресрәге зур бер коллективның әгъзасы. Ул да булса милләт. Бүтән халыкларга хөрмәт белән караганы хәлдә, үз туган халкын, үз милләтен, культурасын, туган телен һәм әдәбиятын ярата икән кеше, шуларның

үсеше, уңышы хакына яна-кояэ, кочен кызганмый икән, бу табигый хәл. Чөнки сүз кешеләрнең яңа берләшмәсе — совет халкының бер состав өлеше булган социалистик милләт турында бара. Сүз эчтәлеге белән социалистик, формасы белән милли культура турында бара. Берничди милләтчелек тә, милли чикләнгәнлек тә юк монда. Үз анасын яратмаган кешенең бүтән аналарны яратуын күз алдына китереп булмый.

Әнә шул мәгънәдәге милли патриотизм, күренә ки, гражданлыкның бер чагылышы, бер органик кисәкчәсе. Әдәбият очрагында бу тойгының әһәмияте аеруча зур. Язучы бит үз милләтенең күкрәк сөтен имеп буй үстергән, үз халкы тормышын биш бармагын белгән кебек белә, шул тормышны, үз халкының гасырлар буе эшләп чыгарган сурәтләү чараларын кулланып, үз халкы телендә чагылдыра.

Әдәбиятыбыз тарихы да гражданлыкның бер элементы булган милли патриотизмның ничаклы зур роль уйнаганын күрсәтсә кирәк.

XIX гасырның соңгы чирege. Татарларда милләт булып оешу процессы бара. Укымышлы һәм прогрессив карашлы бер төркем шәхесләр гасырдан килә торган артталыктан котылу, алга киткән милләтләрне куып җиту, җәмгыятьне кешегә бәхет тәэмин итә торган рәвештә үзгәртеп кору юллары турында уйланалар. Моның өчен бердәнбер корал — мәгърифәт, дигән нәтиҗәгә киләләр. Мәгърифәтнең куәтле чараларыннан берсе исә — әдәбият һәм сәнгать. Һәркайсы кулына каләм ала, яза башлый. Яңа тип проза туа, драматургия барлыкка килә.

XX йөз башы. 1905 елгы революция. Милли-азатлык хәрәкәте моңарчы күрелмәгән колач ала һәм социаль азатлык өчен барган көрәшкә кушылып китә. Социаль һәм милли азатлык идеяләрен халык аңына җиткерүнең самодержавие шартларындагы — бердәнбер үк булмаса да — иң кулай һәм чагыштырмача җайлы трибунасы шулай ук әдәбият һәм сәнгать. Менә ни өчен бу трибунага талант артыннан талант күтәрелә, әдәбият сыйфат сикереше ясый, театр туа. Проза, һич арттырып әйтмәстән, төрки телле әдәбиятлар арасында беренче урынга чыга.

Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, егерменче еллар. Татар халкының күптән теләгән чын азатлыкка һәм тигезлеккә ирешүе. Революциягә кадәр үк танылган күп кенә әдипләрнең үз каләмнәрен революцияне җырлауга, аның казанышларын саклау һәм ныгытуга корал итүләре. Гражданнар сугышы утыннан һәм буразнадан дистәләгән талантларның килүе. Нәтиҗәдә татар әдәбияты, шул исәптән аның прозасы, рус әдәбиятыннан кала, әйдәп баручы милли әдәбиятларның берсенә әверелә. СССР язучыларының I Бөтенсоюз съездында татар әдәбияты буенча өстәмә доклад куелу әнә шуның бер күрсәткече иде.

Прозабызның соңгы елларда артта кала башлавының моннан элекке мәкаләләрдә телгә алынган сәбәпләренә кире кайтыйк. Алар барысы да тегеләйме, болаймы әлеге төп сәбәпкә — гражданлыкның кимүенә барып тоташалар, шуннан килеп чыгалар.

...Әйе, әдәбиятка талантлар аз килә. Аларны эзләү, табу, кайгыртучанлык һәм таләпчәнлек күрсәтеп үстерү юнәлешендә дә әле һаман җитәрлек эшлибез дип әйтеп булмый. Табигать исә бушлыкны яратмый: талантлылар җитәрлек түгел икән, ул бушлыкны уртакул сәләтлеләр, хәтта бөтенләй талантсызлар тутыра. Уртачалык массовый төс ала икән, әлеге дә баягы, вак куаклар гадәти агач булып күренә башлый. Эчләренә кереп адаштыңмы, өч-дүрт адымда гына үсеп утырган наратны яисә имәнне инде күрмисең.

Мондый хәл әдәби тәнкыйтькә дә йокмый калмады. Анда да критерийлар алмашына төште, таләпчәнлек кимеде. Күп кенә тәнкыйтьчеләр, объектив булам дип, уртакул әсәрдән уңай яклар, яхшы әсәрдән кимчелекләр эзләп язулары сәбәпле, прозада «тигезләү эше» алып баралар. Акны ак, сорыны соры, караны кара дип әйтергә теләгән принципиаль тәнкыйтьчегә исә караш бик үк шәптән түгел. Чөнки ул уртачалык мәнфәгатенә кагыла. Мондый авторларның кесәләрендә шулай ук союз билеты, бер-берсенә бик нык береккәннәр, тавышлары көр. Тәнкыйть, диләр, объектив булырга тиеш, тәнкыйтьчене кусәк куллануда гаеплиләр.

Әдәби хәрәкәт белән җитәкчелек итү, аерым алганда прозаның үсешенә этәргеч бирү — иҗат союзыбызның төп вазифасы. Әнә шул юнәлештә әле барысы да эшләнә дип әйтергә нигез юк. Прозаикларның әсәрләрен рус һәм бүтән телләрдә

чыгару мәсьәләсен генә алыйк. Т. Миңнуллин хаклы: бу эш бездә үз агымына куелган. Авторы өлгер һәм өстыручан булса, уртакул әсәр үзсктә чыга, ә өлгер түгел, ләкин талантлы язучының әсәре еш кына үз өебездә торып кала.

Мактаышырга, бер-беребезне күтәрешергә, мактаулы исемнәр бүлешергә бик тә остарып киттек. Шул ук вакытта гражданин булып танылган чын талантларга карата еш кына кечкенә генә кадер-хөрмәт, гап-гади кайгыртучанлык та күрсәтә белмибез.

Ш. Маннур диган әдибебез бар иде. Шагыйрь буларак ул күптән инде әдәбият тарихында лаеклы урын алды. «Муса» романы, «Агымсуларга карап» һәм «Чын сөю бармы?» повестьлары белән үзен менә дигән прозаик итеп тә танытты. Әмма аның прозасы үзе исән чагында тиешле бәя алмый калды.

Яисә менә Ә. Еники. Әдәбиятка керткән зур өлешен тегеләйме, болаймы билгеләп үтү бер якта торсын, җитмеш яше тулу уңае белән «Литературная газета»да котлау сүзе дә чыгара алмадык. Илле яки алтмыш яшен тутырган кемнәр генә чыкмый анда!

Юк, иптәшләр, олыбыз һәм кечебез җаваплы пост биләгән һәм биләмәгән язучылар, культурабыз, әдәбиятыбыз мәнфәгатен бар нәрсәдән дә өстен куеп, бер җан, бер тән булып эшләмәсәк, прозаның чәчәк атуына түгел, үсешенә дә өмет аз.

Еш кына уйланам: әдәбиятка дулкын-дулкын булып талантлар килеп торган, кыйммәтле әдәби мирас калдырганнар. Менә Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Һ. Такташ, К. Нәҗми, М. Максуд. Менә Г. Бәширов, И. Гази, Т. Гыйззәт, М. Әмир, Ш. Маннур, Ф. Хөсни. Менә Ә. Еники, С. Хәким, Н. Арсланов, Ш. Мөдәррис, А. Расих, Р. Төхфәтуллин. Бит алар бөлем һәм хәзерлек ягыннан түбәнрәк ноктадан башлаганнар. Тормыш-көнкүреш шартлары да шәптән булмаган.

Хәзерге яшьләрнең теоретик хәзерлеге дә зуррак, мөмкинлекләре дә күбрәк. Ник алар акрын үсә, ник соңгарып өлгерәләр? Күрәсең, баштагы өч дулкында булган бер сыйфат җитенкерәми. Ул да булса, әлеге дә баягы, гражданлык.

Мәкаләне, мәгълүм строфаны чак кына үзгәртеп, шагыйрь сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

Үзең турында уйлама,
Илең турында уйла.
Илең турында уйласаң,
Гомерең озын була.

---

## Нияз Акмалов

# КҮҢЕЛНЕ КУЗГАТАМЫ?

Журнал битләрендәге проза хакында сөйләшүне игътибар белән күзәтеп барам. Язучылар, әдәбият белән шөгыльләнүчеләр һәм укучылар тарафыннан кызыклы гына фикерләр әйтелә. Тик үзем кайбер фикерләр белән уртаклашыйм дип кулга каләм алганчыга кадәр күңелдә шундыйрак бер шик йөрде: әле бер повесть та язып бастырмаган без яшьләргә бу сөйләшүдә сүз алу тыйнаклык булырмы? Теләсә кайсы әсәр авторының «Менә шулай, энекәш, башта син үзең язып кара әле!» — дип кенә җавап бирүе мөмкин түгелме?

Ләкин әлеге шикне икенче бер уй алыштырды: әгәр дә язучының әсәре журналда дөнья күргән, китап булып чыккан һәм, инде килеп, укучыга барып кергән икән — бу әсәр инде аның үзенеке генә түгел, ә бәлки кешеләрнеке. Укучы буларак та, әдәбият белән кызыксынып та алар әсәргә карата үз сүзләрен, үз хөкемнәрен әйтергә хаклы.

Беренче сүз проблемалылык турында. Чөнки бүгенге көн проза әсәрләребез ның

беренче чиратта менә шушы яктан яхшый дип исәплим. Беркемгә дә сер түгел, иң житди хикәя, повесть, романнарның асылында проблемалар ята. Әнә шул проблемаларны язучы ни дәрәҗәдә сизгеррәк күреп ала, ни дәрәҗәдә сәнгатьчә итеп күтәрә — талантның зурлыгы шунда, әсәрнең көче, уңышы шунда. Халыкның зәвыгына җавап бирүче әсәрләр бар. Халыкның зәвыгын тәрбияләүче әсәрләр бар. Соңгылары исә нәкъ менә шул проблемалы булулары белән зәвык тәрбияли, иҗтимагый фикер тудыра, тулы бер буыннарга үз идеалларын ачыкларга ярдәм итә.

Әмирхан ага Еникинең «Рәшә»сеннән соң шактый калын әсәрләр туганы бар. Ләкин әлеге «Рәшә»дәге социаль проблема югарылыгында язылган әсәрне, Зөфәр Сабитов кебек социаль тип буларак ачылган геройны табу авыр. Ни өчен? Социаль типлар тормышыбызда юкмы? Әллә без аларны күрә генә алмыйбызмы?

Проблема дигәч, тагын шул якка да игътибар итәсе килә. Кайбер әсәрләрдә, киресенчә, «проблемалар» тулып ята. Тик мондыйлары геройны «ачу» өчен көчләп тагылган проблема булып чыга. Әйдәгез, конкрет әсәрләрне атап тормыйча күрсәтеп кенә китик: салам яндыру кебек «проблема» авыл тормышына, колхоз тормышына караган кайбер әсәрләрдә зур бер проблема итеп, кире беткән председательнең «чын йөзен» ачар өчен кулланылмадымыни? Әй сүкте автор мондый председательне! Хурлады! Ә уйлап баксаң, әлеге «проблема» күптән инде көндәлек матбугатта үз тәнкыйтен алган иде. Монысы беренчедән. Ә икенчедән, чын әсәр кире яки уңай геройларның кылган эшләрен сурәтләү генә түгел. Ул — әлеге хәрәкәтләрне тудырган яшәү фәлсәфәсе, дөньяга караш, психология кебек нәрсәләрне сәнгатьчә ачып салу, шулар белән акланган адымнарны сурәтләү.

Геройлар турында сүз кузгалгач, аларның характер үсешенә караган бер-ике фикер әйтәсем килә. Хәтерлисездер, моннан элгәрәк бездә «уңай» һәм «кире» герой турында сөйләшүләр булып алган иде. Пакьтән пакь геройлар, кире беткән геройлар турында ул чакта да шактый кызыклы фикерләр әйтелде. Язучылар, нәрсәнедер үзгәртергә теләгәндәй, «уңай» геройларын бераз «кара төскә» дә буяштыргалый башладылар. «Туктале, бу гел фәрештә булмасын әле» дигәндәй, уңай геройны хатыны белән талаштырдылар, семья ягын бераз кыенрак иттеләр. Әмма уңай герой үзенең кыяфәтен әллә ни үзгәртмәде. Ни өчен? Чөнки безнең әсәрләрдә характер үсеше дигән нәрсә һаман да юк дәрәҗәсендә калды. Геройлар ничек туса, шулай үлде. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романында геройларда характер үсешен, алардагы эчке бер үзгәрешләр күреп сокланырга була. Шулай ук, мондый эчке бер үзгәрешне Г. Ахуновның «Чикләвек төше»ндә дә кызыксынып күзәтәсең. Каян тапкан язучы үз героеның мондый үсеш халәтен. Чөнки бу геройларда, аларның күңелендә тормышка карата аерым бер караш, фәлсәфә яши. Әнә шул яшәү фәлсәфәсе аша фикерләр, уйлар бәрелеше, характерлар бәрелеше. Нәтиҗәдә, бу бәрелешләр аша геройларның кылган эшләре дә, аларның үз характерлары да, тормышка карашлары да үстерелә.

Әгәр инде без күп кенә әсәрләрдә геройлар, электрон машина кебек, алдан билгеләнгән программа буенча яши, аларның сүзләрен, кылачак эшләрен, үзләрен кайчан ничек тотасыларын алдан белеп торып була икән, әгәр без әлеге геройларда характер үсеше юк дибез икән — димәк моңа бу геройлар түгел, ә бәлки аларны үзенчәлекле бүтән типлар белән бәрелештермәгән һәм төп проблеманы ачуда шушы бәрелешләрне кулланмаган язучы гаепле. Ә инде уңай герой турында әйтсәк: уңай герой — һәрчак газаплы герой ул. Әгәр шулай түгел икән, аның укучыга тәэсир көче дә булмый. Уңай геройның дөреслеккә бару юлындагы ялгышулары, газаплары гына укучы күңелен тетрәндерә ала.

Геройларының кабатланмас булуы, аларның үзенчәлекле тормыш фәлсәфәсен сурәтләве белән М. Мәһдиев шактый кызыклы эзләнүләр ясады. Җиңелчә, җылы юмордан алып, аерым урыннарда сарказм дәрәҗәсенә күтәрелгән сөйләм стиле һәм җанлы, халыкчан тел дә үзенекен эшләде: язучы үз укучыларын, даими укучыларын тапты, үзенең геройлары белән, аларның җанлы характеры белән укучының күңеленә кереп урнашты. Ләкин монда да күңелгә шик сала торган бер нәрсә бар. М. Мәһдиевнең кайбер әсәрләре штрихларга корылган төсле... Кем белә, автор бәлки әле үзенә зур бер социаль проблеманы ачып салырдай геройлар җыядыр, ул аларны туплау, өйрәнү процессындадыр? Һәм әлеге без яратып укый торган әсәрләре әнә шул яңа, зур бер эш өчен җирлек, таяну ноктасы булып калырга тиештер бәлки?

# «ТЫЙНАК ТАБЫН»ГА КИЛ, УКУЧЫ!

Хәзерге татар поэзиясендә Шамил Анактан да сәеррәк шагыйрь юктыр. Мин әле аның шигырьләренең тышкы формасын, бирелеш үзенчәлеген, дөньяны сәнгатьле күрү алымнарын күздә тотмыйм. Ул хакта сүз алдарак. Шагыйрь агымдагы әдәби процесста бөтенләй диярлек катнашмый, ел йомгаклары да, поэзия турында барган дискуссияләр дә аны борчымый. Ул каядыр читтә, еракта яши. Шулай итеп, шагыйрь турында бөтенләй диярлек онытып, элек язганнары якты балкыш булды дип фараз кылырга җыенганда, кинәт терелеп, ялкыннарын чәчрәткән вулкан шикелле, Ш. Анак яңа шигырьләре, җыентыклары белән яңадан үзенә игътибарны җәлеп итә. Аның Мәскәүдә чыккан «Оды мирным вещам» китабы киң җәмәгатьчелекнең игътибарына лаек булды. Һәм, ниһаять, алдыбызда Ш. Анакның «Тыйнак табын» җыентыгы.

Тәнкыйтьче Витаутас Кубилюс күптән түгел «Дружба народов» журналында литва шагыйре Альбинас Бернотасның шәһәрне ташлап китеп, урман янында, авылда яшәве хакында хәбәр бирде, шагыйрьнең шунда иҗат иткән шигырьләре турында язып чыкты. Безнең өчен тәнкыйтьченең төп нәтиҗәсе кызыклы: Бернотас, дәрвишлек язмышына һәм тормышына дәгъва итеп, шәһәрне, цивилизация үзәген ташласа да, әдәбиятның төп магнит кырыннан, үзәк юнәлешеннән читкә китә алмаган, принципиаль яңалыкка ирешә алмаган. Чөнки үзеңнең хис һәм фикерләү рәвешеңнән качып булмый икән, ди тәнкыйтьче.

Шамил Анак иҗатында исә хәл бөтенләй башкача. Ул ничектер читтә торып, Казаннан еракта яшәп, 60—70 нче еллар әдәби процессына, бигрәк тә Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Р. Мингалимов, Р. Гатауллиннарның эзләнүләренә шактый көчле тәэсир ясый алды. Сүз ирекле шигырьгә, иркен композициягә, тар рамкалардан «коткарылган» образлы фикерләүгә киң таяну турында гына бармый. Шамил Анак иң гадәти, күзгә чалынып, күренеп, туйдырып, ялыктырып бетергән төшенчәләрнең дә поэзия бөрки алуларын исбат итә алды. Юкка гына ул «Өйрәнсәң иде иң бөек сәнгатькә — сүз ирке сәнгатенә» дими. Нәкъ менә шул сыйфаты белән ул бер буын яшьләр өчен үрнәк булды.

Р. Фәйзуллинның «Нюанслар иле» циклында, «Гадиләргә гимн» поэмасының рухында, Р. Харисның йорт, җир, тынычлык, икмәк, сөлге кебек гадәти төшенчәләргә багышланган бәйләмнәрендә Ш. Анак әсәрләренең эстетик рухы сизелеп-сизелеп үтә. Кабатлау турында сүз бармый. Сүз сиңа чаклы ирешелгән казанышларга, башкаларның язу тәҗрибәләренә таянып, үзеңнең иҗат мөмкинлегеңне киңрәк ачу, поэзиянең көше рухына үтеп керү мөмкинлекләрен максималь файдалану хакында бара.

Ш. Анак шигырьләрен тематик рамкаларга гына сыйдыруы кыен. Аның «Гади әйберләргә мәдхия», «Прага дәфтәре» цикллары безгә күптән таныш иде. Бу китапта шуларга бик күп яңалары өстәлгән. Ул үз-үзенә турылыклы: гадилектән шигърият таба, табигать матурлыгын рәссамнарча, каударланмыйча, ашыкмыйча, тәфсилләп тәсбихка тезә. Өлгереп килгән кырлар, тугайлар матурлыгы, күзне чагылдырырлык аклык, пакьлек, пөхтәлек, «бәйрәм көндә ак күлмәк кигәндәй — җылы ихтирам», «җан-тән белән бирелеп сөйгәндәй — кешелекле ихтирам», ихлас күңел, саф вөҗдан — болар барысы да аның поэзиясенең нигез ташлары, илһам чыганагы.

Шагыйрь табигый хозурлыкны тасвирлау белән генә чикләнми. Чөнки әле дөньяда гуманизмның төп дошманнары — әшәкелек, явызлык бетмәгән. Алар тирә-юньдә,

хәтердә. Фучик шәүләсе, «үләннәргә кунган» Хиросима үлеме, «карыны мәңге буш булачак ана, кабат ата була алмаган ата»лар хәтере бар.

**Мин —**
**Хиросима 6 августта 1945 елда.**
**Кешеләр, бу көнне онытмадыгызмы!**

Ш. Анакның реализмы кырыс, драматик, шулай әйтергә яраса — усал. Ул — хәтта куркыта, зиһенне әрнетә, тәнне бөрештерә:

**Җирнең бөтен үлекләре күтәрелә төптән,**
**бөтен яндырылган, асылган, атылганнар,—**
**ни турыда ялваралар алар күктән!**
**Әллә ләгънәт укыйлармы,**
**мәңгелек йокыларын бүлеп!**
**Алар барсы — илле миллион үлек.**

**(«Реквием»).**

Ш. Анакның күпчелек шигырьләре новелланы, кыска хикәяне хәтерләтә. «Хатирәләр кайтавазы» бәйләменә кергән «Знакум», «Мәрхүм абзыйга элегия», «Күлмәк», «Авыл хатирәсе», «Иске кабер ташындагы язу», «Мәхәббәт күзе» кебек шигырьләргә игътибар итик. Үзәктә — сөйләп бирерлек сюжет, тормыш һәм язмыш турында уйлану, кеше гомере...

...Унөч бала тудырып та, үләрендә күзен йомдырыр кешесе булмаган Әхмәт кызы Хәтимә, матур күлмәк кию хыялы белән гомере ярлылыкта узган Сабрия әби, «эчкән, тарткан, зина кылган», азгын уеннан ләззәт табып, каргышка эләккән, туктаусыз кагылган, сугылган, әмма «сихри моң иясе», «сабый кебек саф күңелле, керсез» абый образлары хәтергә сеңеп кала. Чехов, Ш. Камал хикәяләре искә төшә. Сөйләм эзлекле фабула канвасы буенча барә. Шигырь белән проза арасындагы чик, киртә бөтенләй югала, фикер агышы, зиһен уены сине үз артыннан ияртеп китә. Җитмәсә, әсәргә еш кына, драмага хас, шигырьнең классик канунннарына баш бирмәгән диалоглар килеп керә:

**Мин гаҗәпкә калдым: акылмы бу, нәрсә!**
**«Сез,— дидем,— ялгыш фикердә булса кирәк».**
**«Юк,— диде ул,— тормышны белгән ир генә**
**була ала хатын-кызга нык терәк».**
**Мин каршы төштем: «Ә яшьләр!»**
**«Яшьләрме! Алар тапмаган әле үз йөзен».**
**Ул бераз тынып торды да: «Әйе,— диде,—**
**сукыр дисәләр дә мәхәббәт күзен,**
**яшьтән бигрәк акыл йә талант өчен**
**сөяләр бит кешене гадәттә».**

**(«Мәхәббәт күзе»).**

Классик төгәл, салмак иҗекле, көйле, моңлы ритмлы шигырь традициясендә тәрбияләнгән колак мондый прозаизмга тиз генә өйрәнә алмый. Чачмаме бу, әллә тезмәме — яисә каядыр урталыкта, синтезда туган яңа жанрмы?

Дөрес, бу төр әсәрләр башка әдәбиятларда да туа тора. Руста А. Вознесенский, В. Солоухин, украинда И. Драч, казахта О. Сөләйманов шигырь белән проза арасында күпер кебек калкып һәм ике әдәби төрне бәйләп торган әсәрләрне аз язмадылар. Ләкин аларның берсе дә бу өлкәдә тәҗрибәне Ш. Анак кебек эзлеклелек, даимилек һәм мәгълүм уҗәтлек белән алып бармый. Аның соңгы елларда иҗат ителгән әсәрләре белән танышкач, аларда тормыш табигыйрәк чагылмыймы, үз яшәеш формасына якынрак килмиме икән дигән фикер дә туа. Шагыйрь поэзиягә

кас шартлылыкны җиңәргә тырышмыймы? Дөрес, мондый омтылыш иллюстративлыкка, статик сурәтләүгә, таныш информацияне гади кабатлауга да алып килә («Иске кабер ташы янында уйга талган карт утыра ялгызы. Замандашлары күптән инде ял итә монда». «Тел — милләтне милләт иткән иң беренче шарт» һ. б.).

Ләкин Ш. Анакның уңышлы әсәрләрен укыганда, сәнгать законнары турында уйламыйсың. Шагыйрьнең тынгысыз уе, үз тормышы, үз язмышы турында ачыктан-ачык, яшермичә сөйләве, импульсив, хәрәкәтчән, интеллектуаль фикере, кадрларны көтелмәгән яклары белән, экспрессив чаралар ярдәмендә яңача, үзенчә үзгәртә, алыштыра, яңарта белүе, комдагы алтын кебек, ялтырап киткән нәфис бизәкләр, анафора, ялгау, цезураны һич көтмәгәндә бүлү, өзү, авазлар тәңгәллеге сокландыра, уйландыра, гаҗәпләндерә. Күзәтү, деталь, төсмер, төс, ис, фикер агышына идеягә буйсына. Тирәннән күтәрелгән фикер, тормыш күренешләре гомумиләштерүгә алып чыга. Бик сирәк әсәр йомгаксыз кала. Вакыты белән ул нәтиҗәсен укучының интуициясенә, әзерлегенә ышанмыйча, «көчләп» тага. «Каен суы җыю» шигыре мифик ырымны сөйләгәннән соң, киң теләк белән тәмамлана.

**Борынгы ырым. Ана булырга әзерләнү ырымы.**
**Йөзләре ак, күкрәк сөтләре пакь булсын!**

Шагыйрь аңлы рәвештә тышкы хистән, эмоциядән качарга тырыша. Ләкин моннан җылылык, кешелекле моң кимеми. Бу сыйфаты А. Пушкинны, С. Есенинны, Н. Хикмәтне, Х. Туфанны сагынып язган элегик әсәрләрендә тирән ачыла.

**Ә кич шундый моңсу. Әллә акчарлаклар**
**Кешедәй моң сызганга!**

**Хәтеремә килә кайчандыр**
**сагышланып узганнар...**
**Күбекле дулкыннар сугыла ташларга,**
**күбекле тормыш дулкыннары...**
**Алып килә алар заман, язмышларның**
**фаҗигасен, моңнарын.**

Хәсән Туфан поэзиясенең аһәңен, көчен шагыйрьнең язмышы белән кочанмичә бәйләп менә шулай образлы ачып биргән шигырьләр күп түгел.

Ш. Анак поэзиясе — катлаулы күренеш. Аның шигырьләрен бер бөтен итеп кабул итәргә кирәктер. Шигырьнең эчке ситуациясе, фикерләү үзенчәлеге бер әсәрдән икенчесенә күчә, образ катламы тулырак ачыла бара. Алар бер-берсенә сырышып, ятышып, бина булып күтәрелгән блокларны хәтерләтә.

Ш. Анак шигыренең көче, җегәре — образлылыкта, тормыштан алынган детальдә. Күп сыйдырышлы, мәгънәле, тормышчан детальнең көче кыска парчаларда бигрәк тә ачык сизелә:

**Үлемле кеше, үлемсез кешелек.**
**. . . . . . . . . .**
**Вакыт узмый, без узабыз вакыт аша.**
**. . . . . . . . .**
**Беренче нур иртәнге урманга килеп орынды да**
**ачы итеп кычкырып җибәрде —**
**һәм урман уянды.**

Шагыйрь халык мифологиясенә, ышану-ырымнарына иркен таяна, анда халыкның уй-фикерләү рәвешен, аң үсеше юлын күрә:

**И, гүзәл ай кызы, көянтәңне иңнәреңә салып,**
**кинди йолдызга суга китеп барасың!**
**Кайчандыр җир кызы булганыңны хәтерлисеңме!**

«Каен суы җыю...» шигырендә халык ышануы ана изгелегенә җан җырлау булып кабул ителә:

**Май башында каенсарда кызлар каен суы җыялар.**
**Күлмәкләре ап-ак. Ир-аттан беркем юк — ярамый.**
**Кайчандыр, мең-мең еллар элек, ерак әбкәләре**
**үтәгән шикелле, кызлар борынгы ырымны үтиләр.**

Кызлар эре, саф каен тамчыларын учларына җыеп, битләренә, күкрәкләренә сөртәләр, «йөзләре каен тузыдай ак һәм күкрәк сөтләре каен суыдай шифалы булсын дип...» Кыскасы, ул символикадан курыкмый, борынгы мифны хәзерге әхлакка хезмәт иттерә белә.

Бу төр шигырьләр «Тыйнак табын» җыентыгын бизиләр.

Ш. Анакның татар поэзиясендә үз урыны бар. Аны башка шагыйрь белән бутавы кыен. Бүгенге татар шигърияте үз иҗади йөзләре ачык шагыйрьләргә, төрле стиль юнәлешләренә бай. Шулар арасында Ш. Анак булуы уртак байлыкны ачыграк күрергә, бәяләргә ярдәм итә. Кайвакыт без аның турында «онытып» поэзиябезне ярлыландырабыз икән.

«Тыйнак табын»га рәхим ит, укучы. Анда һәркем үз рухына, ихтыяҗына, эстетик таләбенә якын булган ризык табар. Табигый һәм туклыклы, бәрәкәтле һәм мәрхәмәтле булган рухи азык табар.

Тәлгат **ГАЛИУЛЛИН.**

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ШИГЪРИЯТ

**Балчыктан, уттан, судан яралганбызмы,**
**Адәм-һавадан туып таралганбызмы,**
**ә бу канлы сугышлар, бәла-казалар,**
**гасырларча сузылган газап-җәзалар**
**дөньяның камил булмавына дәлилме,**
**әллә кешеләрнең сабыйлык мәлеме —**
**ни генә булмасын, хас безгә бер нәрсә:**
**яңа юллар эзләп без баш ватабыз,**
**гомер бакый «матурлык!» дип җан атабыз,**
**бөек хыяллар белән яшибез янып,**
**өр-яңадан кормак булабыз дөньяны...**

Шагыйрь Шамил Анакның әлеге шигыре аның бөтен иҗатына эпиграф була ала шикелле... Чыннан да, барлык әсәрләрендәге кебек, бу шигырьдә дә шагыйрь чынбарлыкны киң колачлаган һәм кеше күңеленең тирәндәге хасиятләренә үтеп кергән образлы фикер әйтә. Биредә дә Шамил Анак шигъриятенә хас үзенчәлекле интонация һәм табигый сөйләмгә бик якын булган поэзия яши. Бу очракта да шагыйрь инде күнегелеп беткән, гап-гади кебек тоелган сүзләрне тыныч кына сөйләп бара да укучы күңелендә тотрыклы һәм нык тәэсир итә торган шигъри климат урнаштыра... Шулай итеп: әле генә без мисалга китергән шигырь исемендәге «гаҗәп үзлек» килеп чыга. Әйе, бу әсәр бик тә үзенчә, ул күпчелек шигырьләр кебек язылмаган. Ләкин, шуңа карамастан, ул гаҗәп тәэсирле һәм күңелгә якын. Моның сере, хикмәте нидә соң?

Шамил Анак иҗаты турында уйланганда һәрвакыт бер факт искә төшә. Аның беренче китабы «Юл өстендә кояш» 1962 елда Мәскәүдә басылып чыкты. Шуннан соң дүрт ел вакыт үткәч Казанда татар телендә дөнья күрде бу китап!

Иҗат юлының башыннан ук Шамил Анак традицион типтагы шагыйрь түгел иде. Ул шигырь поэтикасында новатор иде. Аның шигырьләренең ритмик яктан иреклә-

леген һәм сөйләм интонациясенә якын торган тыенкы дәртле булуларын күпләр аңлый да, кабул да итә алмады. Шул нигездә бәхәсләр, шагыйрьне сүгүләр, тиргәүләр китте. Ул вакытта Шамил Анакны ниләрдә генә гаепләмәделәр?! Аны татар теленең законнарын белмәүдә дә гаепләделәр. Ә чынлыкта ул «Татар теленең төзелеше» турында кандидатлык диссертациясе әзерләгән кеше иде... Шагыйрьне телнең традицияләрен җимерә дип тә сүктеләр. Ә асылда ул әнә шул традицияләрне бик саклап дәвам итә иде... һәм ниһаять, аны көнчыгыш поэзиясенә хас булган элементар нормаларны бозуда гаепләделәр. Ә Шамил Анак бу өлкәдә дә энциклопедик белемле иҗатчы иде... Шулай итеп, шагыйрьгә зур-зур һәм төрле-төрле гаеп ташлаучылар үзләре бик күп яктан формалист булып калдылар. Чөнки алар бары тик үзләре күнеккәнчә шигырь язуны гына хуплыйлар иде, шигырь шулай гына булырга тиеш дип саныйлар иде!

Әлбәттә, биредә татар әдәби җәмәгатьчелегенең иркен шигырьне кабул итү өчен әле әзерлекле булмавы да зур гына роль уйнагандыр. Рус укучысының китап киштәсендә Брехт, Аполлинер, Элюар, Неруда, Лорка, Хикмәт, Уитменнарның иркен шигырьләреннән тәрҗемәләр бар иде бит. Аның өстәвенә әле рус поэзиясе тарихында Пушкиннан алып бүгенге көнгәчә иркен шигырь белән язган бик күпләрне санап була. В. Солоухин хәтта шундый әсәрләрдән торган «Кояшны ничек эчәргә» дигән китап та чыгарды. Җитмәсә, рус шигырь төзелеше әле үзе дә сыгылмалырак һәм мөмкинлекләргә баерак: биредә басымнар күчемле, шигырь конструкциясе иркенрәк, юлдагы сүзләр инверсиясе иркен, ассоциатив уйлауны көчәйтүче рифмалар күп. Шуңа да карамастан, бүгенге рус шигъриятендә әле һаман чиксез иркенлеккә омтыла тосле.

Соңгы елларда татар әдәбиятында да иркен шигырьгә игътибар көчәя төште. Н. Хикмәт һәм У. Уитмен сайланмалары үз телебездә басылып чыкты. Алар татарча матур яңгыраш тапты, татар укучысын иркен шигырьгә якынайтуда байтак эш башкарды. Үз шигъриятебезнең тамырында ук булган иркен шигырьне үстерүдә бүген талантлы һәм перспективалы шагыйрьләрнең тулы бер отряды актив иҗат итә. Алар татар укучысын яңадан-яңа шигырь цикллары белән, тирән мәгънәле һәм бай тәэсирле поэмалар белән куандыра киләләр.

Инде Шамил Анак иҗаты үзе дә укучы өчен көтелмәгән күренеш түгел. Аның китаплары Мәскәүдә дә, Уфада һәм Казанда да еш басылып тора, чит илләрдә дә дөнья күрә. Шагыйрь турында күренекле рус әдипләре Борис Слуцкий һәм Станислав Куняев, Мостай Кәрим һәм Сибгат Хәким бик җылы сүзләр язып чыктылар. Ә мәрхүм Назыйм Хикмәт аны аеруча үз күрә, аеруча ярата иде. Ул Анакның яшьлек шигырьләрендә үк «илаһилык чалымы» тапты, үзенең акыллы киңәшләре белән аларны үстерергә, көчәйтергә ярдәм итте. Татарча укый белгән Назыйм Хикмәт, әлбәттә, яшь шагыйрьнең нинди юнәлеш сайлаганын бик яхшы белгән. Ялкынлы революцион фикерләрне традицион шигырьнең йомшак түшәгендә генә урнаштыру мөмкин түгеллеген үз җилкәсендә татыган әдип яшь дәвамчысына иҗатта бетмәс-төкәнмәс түземлек тә теләгәндер, мөгаен...

Менә безнең алдыбызда Шамил Анакның 1982 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан яңа китабы «Тыйнак табын». Бу җыентыкта укучыга инде таныш булган «Прага дәфтәре», «Гади әйберләргә мәдхияләр» белән беррәттән шагыйрьнең соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре дә тупланган.

Мин —
шәһәр,
ләкин бу тимүг алмасын җибәргән
шәһәр түгел.
Мин —
бу тимүг алмасы төшкән шәһәр.
Мәңгелек хурлык, мәңгелек каһәр.
Мин —
Хиросима 6 августта 1945 елда.
Кешеләр, бу көнне онытмагызмы!

Китаптагы иң гуманистик, якты өметләр белән сугарылган һәм шул ук вакытта дәһшәтле хәлләрне онытмаска да чакырган шигырьләрнең берсе бу. Аны укыганда бүгенге тынычсыз планета да, һәрберебезнең йөрәк тибешебез дә сизелә. Шигырьнең көче, тәэсире шунда. Ул укучы күңелендә әнә шундый җитди «эчке климат» тудыра.

Ләкин бу урында әле шигырьнең форма ягына аерым игътибар итәсе килә. Күргәнебезчә, рус поэзиясендә күбрәк Маяковский исеме белән бәйләп йөртелгән форма бу. Әмма бирегә, икенче чор шагыйре тудырган шигъри әсәргә автоматик рәвештә генә, үзеннән-үзе генә килеп кергәнме соң ул?

Юк! Безнеңчә, бүгенге көчле гражданлык тойгысының әнә шулай чагылышы ул! Киң халыкара масштабларда яңгырый алырлык политик лириканың бик әйбәт мисалы бу. Бүгенге кешенең реаль тойгылары әнә шул рәвешчә: пульс кебек өзек-өзек булып, кискен-кискен булып, зур тәэсир көче белән яши ул юлларда.

Тагын бер генә шигъри гыйбарәгә тукталыйк. Монда бик борынгыдан бирле «ызгыш алмасы» дигән сүз йөри. Ә шагыйрь биредә неологизм кертә — тәмуг алмасы. Һәм менә шул сүз шигырьгә әллә никадәр ассоциация агымы алып керә. Ул ассоциацияләр укучы күңелендә атом шартлавына бәйле, кеше тормышына бәйле бихисап уй-тойгылар уята. Шагыйрь әнә шулай итеп укучыны «Кешеләр, бу кәнне онытмадыгызмы?» — дигән гаять мөһим сорауга әзерли. Болар барысы да шигырь эчендә бара һәм менә шул табышларда, шигырьнең бөтен агышында, яшәвендә — шагыйрьнең бу теманы хәл итү үзенчәлеге, иҗат үзенчәлеге.

Шамил Анакның яңа китабында тагын «Торналар җыры» дигән бик әйбәт шигырь бар. Аның ахыры болай:

**Мәркәзләрдән киттем. Авылда мин.**
**Уңдыңмы, юкмы —**
**анда түгел кызыгы.**
**Кем соң, кем соң алдан әйтә ала,**
**кайда, ничек өзелә гомер сызыгы!**
**Анда, мәркәзләрдә, яшәп торып,**
**гомер мәгънәсез, буш үтәме!**
**Әллә монда, тәмра күк далада,**
**Очкан торналарның җыры кебек,**
**горур бер җыр җырлап бетәме!**

Бу шигырь мәшһүр рус шагыйре Сергей Есенинның «Кайтмам инде туган йортыма...» исемле шигъри әсәре белән күпмедер дәрәҗәдә авазваш та кебек. Ләкин ике төрле тарихи чор лирик геройларны барыбер бер-берсенә охшамаган ике язмыш итә. Есенин шигырендә «Мәңгелек сәфәр»гә тартучы тиктормас шагыйрь җаны, Анакта исә туган якны җирсү, туган якка таяну: «Тик мине дә авылыма дәште әчкелт тәмле дала емшаны».

Шулай итеп, сәнгать дөньясының катлаулы, ләкин ныклы диалектикасы биредә дә үзен бик ачык сиздерә. Охшашрак моментларда шагыйрьләрнең, иҗатчы шәхесләрнең үзенчәлекләре ачыграк күренеп китә, индивидуаль сыйфатлары тулырак күзаллана.

Менә бу урында Шамил Анак биографиясендәге шактый кызыклы бер күренешкә тукталып китү кирәк кебек. Нәкъ менә югарыда китерелгән шигырь юлларының дәвамы төсендә... Шамил Анак байтак еллар элек Мәскәү дәүләт университетында көнчыгыш телләр буенча аспирантура тәмамлаган иде. Аннан соң ул М. Горький исемендәге әдәбият институтында укыта башлады. Аңа менә дигән фән сукмагы һәм гыйлем үрләре ачылган иде. Ләкин, без барыбыз да әнә шулай дип уйлап йөргәндә, Шамил Анак кинәт кенә гаҗәеп карар кабул итте. Ул бөтенләйгә авылга кайтырга карар кылды!

Хәзер мин бу хакта кат-кат уйлыйм, Шамилне ул адымга алып килгән төп көчне аңларга телим һәм үз-үземә шундый җавап тапкан кебек булам. Мөгаен, ул вакытта сәнгать дөньясы белән фән дөньясы арасындагы зур аерманы нык лап аңлап алган-

дыр Шамил Анак! Сәнгатьтә, әдәбиятта бит шундый уникаль үзенчәлек бар: анда тормыш бүлгәләнмичә, өлешләргә таркатмыйча өйрәнелә, шулай тере хәлендә сурәтләнә һәм карала. Фәнни фикерләү исә өлешләргә бүлүне, тәгәл логиканы һәм абстракт уйлауны таләп итә. Ә җанлы тормыш һәм аны чагылдыручы әдәбият-сәнгать дөньясы законнарга гына сыеп бетәме соң?!! Юк, әлбәттә! Әдәбият теле, поэзия теле ул — киң колачлырак һәм тулырак!

Галим булачак Шамил Мәхмүдсаны шагыйрь Шамил Анак итеп авылга алып кайткан көч әнә шунда дип уйлыйм мин... Шигъри сүзнең чиксез көчен тойган һәм аны оста иярләгән шагыйрь бүген безне үзенең уңышлары белән сөендерә. Аның иҗаты аша без тагын бер мәртәбә татар шигъриятенең колачы киң икәнлегенә, мөмкинлекләре һәм перспективасы зурлыгына ышанабыз.

Шамил Анакның «Ташлар белән сөйләшү» исемле шигырендә шундый сорау куела:

> — Кем без, ник килдек! Нәрсә ул заман!
> Чал картлармы, әллә сабыймы без һаман!

Бу сорау китаптагы шигырьләрне укыганда киң яңгыраш ала. Әсәрләр яшәүнең иң тирән, иң четерекле мәсьәләләре хакында уйландыралар. Ә авторның лирик герое образы шигырьдән-шигырьгә үсә, тулылана, зурая бара. Китапны укып чыккач безнең күңелдә ул — тормыш тәҗрибәсе белән баеган шәхес булып, яшәүнең бик күп сабакларын үзләштергән акыллы кеше булып истә кала. Китапның лирик герое шул ук вакытта бик белемле дә һәм ул тормышта да, үз-үзендә дә бихисап ачышлар ясаган. Аңа бераз гына ирония дә хас. Чөнки ул бүгенге көнгә хәтле үзе белгәненең дә тулы хакыйкать булмаганын белә, чынбарлыктагы мәгънәләрнең чиксезлеген, тормыш диалектикасының мәңгелек хәрәкәттә икәнен белә... Әнә шул тойгы шагыйрь шәхесен һаман тынгысыз итә, аның рухи дөньясын һаман актив һәм уяу итә.

Һәм, ниһаять, шагыйрь Шамил Анак иҗатына хас булган, аның шигъриятенең нигезендә яткан бер фәлсәфи концепциягә кагылып үтик. Шагыйрьнең бик нык ышанган бер хакыйкате бар: аның уйлавынча сәнгать — ул тормыш турында ни дә булса әйтү генә түгел. Аның уйлавынча, бу вазифа күбрәк публицистикага кагыла. Ә әдәбиятның, сәнгатьнең максаты — икенче бер шартлы тормыш хасил итү, тудыру. Шигърият дип алганда исә, сүз ярдәмендә яши һәм ачыла торган шартлы дөнья тудыру. Ләкин бу очракта да тагын бер бик мөһим таләп куела: әлеге сәнгатьле һәм шартлы сүзләрдәге яшәүнең югары культуралы укучы күңеле белән очрашуы кирәк, нечкә һәм тирән бәйләнеше кирәк. Шул чакта гына шигырьләрдәге икенче чынбарлык ачылып китә. Шул чакта гына шартлы яшәү үзенә көч һәм төрек ала, укучыга бик күп мәгънә төсмерләре һәм гүзәллек бирә.

Шамил Анакның бөтен шигъряте, минемчә, әнә шул принципка корылган. Ягъни, гадиләштереп әйткәндә, аның әсәрләренең тулы яшәеше хасил булсын өчен укучы күңеленең үзенең бай һәм тирән булуы, югары культуралы булуы гаять мөһим. Һәрбер югары сәнгать, чын сәнгать белән очрашкандагы шикелле. Бүтән төрдәге югары сәнгать әсәрен тулы тою өчен дә кабул итүченең нинди булуы гаять әһәмиятле бит.

Югары шигърият үрнәкләре тудыру җирлеген шагыйрь татар халык теленең бетмәс-төкәнмәс байлыгында күрә. «Яңа формаларны иң элек халык теле үзе китереп чыгара,— дип сөйләгән иде ул миңа бервакыт.— Ә мин исә заманыбыз рухына тәңгәл килердәйләрен, бүгенге катлаулы тормышта яшәүче укучыга тәэсир итәрдәйләрен генә алырга тырышам... Форманың һәм эчтәлекнең әнә шундыена омтылам...»

Бу мәкаләдә мин шагыйрь иҗатының кимчелекле якларына юри тукталмадым. Чөнки әдәби тәнкыйтьнең төп максаты туры мәгънәсендә тәнкыйтьләү түгел. Әдәби тәнкыйтьнең төп максаты — әдәби күренешләрне аңлау һәм аңлату. Кыска гына мәкаләдә мин дә Шамил Анак иҗатына әнә шул яктан, шул максат белән карарга тырыштым. Әлбәттә, шагыйрь иҗаты әле киләчәктә тагын да күбрәк тикшеренүчеләрне үзенә тартыр, алар бу иҗатта тагын бик күп кызыклы ачышлар ясарлар...

Шамил Анакның «Тыйнак табын» китабында шушындый бер шигырь бар:

**Өч җыры бар кешеләрнең җирдә,**
**шул өч җырда бөтен яшәү мәгънәсе.**
**Ике җырны — туу белән яшәү җырын —**
**җырлый җирдә кешеләрнең һәммәсе.**

**Өченче җыр — бөтен калган җырлар:**
**бәхет, сөю, ирек, көрәш җырлары.**

**Бу җыр — һәркем йөзен нурламый:**
**берәүләр җырлый аны,**
**ә берәүләр җырламый.**

Җирдә яшәүчеләрнең өченче төренә шагыйрь Шамил Анак үзе дә керә. Аның иҗаты, чыннан да — бәхет, сөю, ирек һәм көрәш җырларына бик бай. Әнә шундый җырлар шагыйрьнең иҗатын һәм йөзен нурлый!

Илдус **АХУНҖАНОВ.**

**Гомәр Сабирҗанов,**
тарих фәннәре кандидаты

# ТАТАРСТАНДА КУЛЬТУРА РЕВОЛЮЦИЯСЕ

Хакимлек иткән сыйныфлар кешене кеше эксплуатацияләүгә нигезләнгән җәмгыятьнең бөтен тарихы дәвамында материаль байлыкларны, политик һәм экономик тормыштагы зур постларны гына түгел, рухи культура казанышларын, халыкка аң-белем бирү өлкәсендәге барлык чараларны да үзләренең даими контрольлекләрендә тотарга омтылдылар. Икенче сүзләр белән әйткәндә, укыту-агарту учреждениеләренең ишекләре банкларның һәм политик учреждениеләрнең ишекләрен ачып керә торган ачкычлар белән ачылды. В. И. Ленин билгеләп үткәнчә, мәгариф һәм фән гаять күп санлы кешеләрне коллыкта тоту өчен изү коралына, монополиягә әверелде.

Октябрь революциясе җиңгәннән соң илнең бөтен тормышын социалистик нигезләрдә өр-яңадан, тамырдан үзгәртеп кору башлана. Бу чорда хезмәт ияләренең культура, белем һәм политик аңлылык дәрәҗәсен үстерү мәсьәләсе партия үткәрә торган иң мөһим чараларның берсе булып көн тәртибенә килеп баса. Әгәр партия Октябрьның беренче көннәреннән үк культура революциясен тормышка ашыруга бөтен көчен куеп керешмәгән булса, илебезне социалистик үзгәртеп коруга ирешә алмаган булыр идек. СССРда тормышка ашырылган культура революциясенең конкрет тарихын өйрәнгән кебек үк киләчәктә аның теоретик аспектларын өйрәнү дә зур фәнни һәм тәрбияви әһәмияткә ия икәнлеге үзеннән-үзе аңлашыла. һәм билгеле булганча, бүгенге көндә культура өлкәсендә социалистик үзгәртеп кору тарихын төзү, культура революциясенең гомуми закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен өйрәнү буенча иҗтимагый фәннәр белән шөгыльләнүче галимнәребез тарафыннан шактый эш башкарылган. Моны бигрәк тә аерым регионнарга һәм барыннан да элек союздаш республикаларга карата әйтергә кирәк.

Татарстан АССРда культура өлкәсендә ленинчыл милли политиканы тормышка ашыруны яктыртуга килгәндә исә, М. Мөхәррәмов, М. Тутаев, М. Сәйдәшева һәм башка кайбер галимнәребезнең берничә хезмәтен исәпкә алмаганда, бу проблемага багышланган фәнни-теоретик тикшеренүләр хәзергә әле бездә бармак белән генә санарлык.

Татарстанда культура революциясе белән бәйләнешле күп кенә мәсьәләләрнең әле хәл ителеп бетмәвенә дә карамастан, матбугатта басылып чыккан хезмәтләр аның тарихының кайбер әһәмиятле фәнни-теоретик якларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Республикабызда гамәлгә ашырылган культура революциясе тарихында байтак кына үзенчәлекле моментлар күзгә ташлана. Аларны исәпкә алмый торып, культура революциясе тарихына, андагы уңышлы якларга күпкырлы һәм объектив бәя биреп булмый.

Татарстанда яңа культура тудыру эшенә җитди кыртә булып торган үзенчәлекләрнең берсе, мәсәлән, халык массаларының аңын гасырлар буена дин идеологиясе белән агулаудан гыйбарәт. Милли мәгариф учакларында, мәктәпләр һәм мәдрәсә-

ләрдә уку-укытуның бөтен системасы дини схоластикага нигезләнгән була. Бу исә халыкның, бигрәк тә авыл халкының культура үсешен һәм гомумән тормыш-көнкүреш рәвешенең уңай якка үзгәрүен бик нык тоткарлый. Патша заманыннан мирас булып калган һәм хезмәт ияләренең аңында яшәп килгән милли каршылыклар, төрле хорафатлар һәм юк-барга ышанулар халык арасында культура-тәрбия эше алып баруда зур комачаулык тудыралар.

Шуның өстенә Татарстан җирендә бер елга якын диярлек — 1918 елның августыннан 1919 елның июненә кадәр кан коюлы сугыш — гражданнар сугышы бара. Халык хуҗалыгына, культура үсешенә шактый зыян килә, культура революциясе эшен актив оештыручыларның бик күбесе һәлак була. Аннан соң ике ел узуга, Татарстан бөтен Урта Идел буен чолгап алган. 1921 елгы ачлык кочагында кала. Барлык бу хәлләрнең кире нәтиҗәләре күз алдында. Әмма монда шуны басым ясап әйтәсе килә: яңа культураның үсеш юлында килеп туган күп төрле авырлыкларны җиңеп чыгу өчен көрәштә өлкә партия оешмасына ВКП(б) Үзәк Комитеты, Совет Хөкүмәте һәм В. И. Ленин үзе кичекмәс ярдәм күрсәтәләр. Бу хакта конкрет-тарихи материаллардан төзелгән «Татарстан хезмәт ияләре В. И. Ленинга» дигән китапта, шулай ук М. Мөхәррәмов, М. Сәйдәшева һәм башкаларның фәнни хезмәтләрендә сөйләнә.

Алда әйтелгәннәрне раслау өчен Н. К. Крупская җитәкчелегендәге агитация-пропаганда бригадасының «Красная звезда» пароходында махсус рейс оештырылу кебек фактларны искә төшереп узу да җитә. В. И. Ленин тәкъдиме белән бу бригада колчакчылардан азат ителгән Идел һәм Кама буе районына җибәрелә, Татарстан җирендә ул Казанга, Кама Тамагы, Лаеш, Балык Бистәсе, Чистай, Алабуга һәм Бондюгка тукталә. Н. К. Крупская җитәкләгән агитбригада үткәргән чаралар республикабыз хезмәт ияләренең культура-идеология тормышындагы, халык мәгарифе һәм культура-агарту эшләре өлкәсендәге мөһим бурычларны хәл итүдә бәяләп бетергесез зур роль уйный. Надежда Константиновна соңыннан да Татарстанда акрынлап юлга салына барган культура төзелеше белән якыннан һәм даими кызыксынып тора, мәктәпләрдә уку-укытуны җайга салу, урыннарда китапханәләр һәм башка культура-агарту учаклары төзүне тизләтү мәсьәләләрендә һәрвакыт якыннан булыша. Бөтенроссия Башкарма Үзәк Комитетының 1920 елда кабул ителгән һәм М. И. Калинин кул куйган «Татарстан республикасында халык мәгарифе турында»гы декреты да мәктәпләрдә уку-укытуның яңа системасын булдыруга юнәлдерелгән. 1926 елның 28 декабрендә РСФСР Халык Комиссарлары Советы, Татарстан АССР Хөкүмәте докладын тыңлап, социаль-культура төзелеше өлкәсендә республикага конкрет ярдәм күрсәтү турында карар кабул итә. Карарда Татарстан АССРда балаларга белем бирүне, хезмәт ияләренә китапханә хезмәте күрсәтүне, урыннарда халык хуҗалыгы өчен белгечләр хәзерләүне яхшыртуның, югары һәм башка уку йортларының материаль-техник базасын ныгыту һәм төрле авыруларга каршы көрәшне көчәйтүнең киң программасы билгеләнә.

Партия һәм хөкүмәтебезнең аталарча кайгыртуы һәм күпкырлы ярдәме, бөек рус халкының ихлас булышлыгы, халкыбызның үзенең культура мирасы, алдынгы рус культурасы белән борын-борыннан тыгыз элемтәдә торуы республиканың рухи тормышын тамырдан үзгәртеп корырга һәм татар халкының яңа, социалистик культурасын төзү программасын уңышлы төстә тормышка ашырырга мөмкинлек бирдә. Фактлардан күренгәнчә, югарыда саналып узылган кайбер үзенчәлекле якларына да карамастан, Татарстанда культура революциясе тулаем алганда шушы революциягә хас булган гомуми закончалыклар рамкасында узды. Ул хезмәт ияләре политик властьны яулап алу белән башланды. Яңа культураның формалашуы һәм алга таба үсүе өчен социаль-экономик шартлар тудыруда хәлиткеч рольне халык массалары уйнады. Халыкның рухи тормышындагы бу тарихи үзгәрешләргә коммунистлар партиясенең төп максатка юнәлдерелгән күрсәтмәләре белән коралланү нәтиҗәсендә һәм турыдан-туры аның җитәкчелегендә ирешелде. Культура революциясе бөтен ил буенча нинди стадияләр узган булса, Татарстанда тормышка ашырылган культура революциясе дә үзенең үсешендә нигездә нәкъ шул ук стадияләрне үтте.

Әмма шуның белән бергә, республиканың культура һәм рухи тормышындагы социалистик революциянең нинди конкрет-тарихи шартларда барганлыгын тулырак

ачыклау өчен, әлеге шартларны төп халыкларының рухи тормышлары революциягә кадәр Татарстан хезмәт ияләренекенә охшаш булган башка милли республикаларда ясалган культура революцияләре шартлары белән чагыштырып карау кирәктер. Болай эшләү совет властеның беренче елларында Татарстанда культура революциясен хәзерләү буенча оештыру эшләрен җәелдереп җибәрү өчен кирәкле шартлар башка республикалардагы, мәсәлән, Идел һәм Урал буе, шулай ук Совет Көнчыгыш республикаларындагы шартларга караганда яхшырак булганлыгын күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә.

Бу чорда В. И. Ленин халык массаларының культура дәрәҗәсен күтәрү, аларны кичекмәстән укырга-язарга өйрәтү мәсьәләсенә аеруча зур игътибар бирә. Аның тарафыннан әлеге бурычларның көн тәртибенә шулай җитди һәм кискен куелуы үзеннән-үзе аңлашыла: хезмәт ияләре алып барган көрәшнең туль җиңүе өчен һәркемнең аң-белемгә ия булуы сорала, ә масса-күләм информация һәм пропаганданың иң үтемле чарасы булып ул елларда басма сүз хезмәт итә. Илебездә яшәгән күп кенә халыкларның тоташтан дип әйтерлек укый-яза белмәве исә партия һәм дәүләт органнарына идея-политик һәм хуҗалык оештыру эшләрен алып баруны бик нык кыенлаштыра.

«Надан кеше политикадан читтә тора, аңа башта әлифба өйрәтергә кирәк. Шунсыз политика була алмый, ансыз имеш-мимешләр, гайбәтләр, әкиятләр, хорафатлар гына була, — ди В. И. Ленин 1921 елның октябрендә политик агарту өлкәсендә эшләүчеләрнең II Бөтенроссия съездында ясаган докладында... — Шуны аңларга кирәк: халык алдында политик бурычларыбызны күрсәтергә мөмкин булсын өчен, халык массаларына: — Без менә нинди бурычларга омтылырга тиеш,— дип әйтергә мөмкин булсын өчен (ә без моны эшләргә тиеш булыр идек!), массаларның культура дәрәҗәсен күтәрү таләп ителә. Культураның шул мәгълүм дәрәҗәсенә ирешергә кирәк. Шунсыз безнең бурычларыбызны эштә тормышка ашырып булмый»[1].

Элеккеге Казан губернасы, хәзерге Татарстан территориясендә яшәгән халыклар арасында бу бурычларны хәл итү, ягъни хезмәт ияләренең культурасын үстерү һәм аларны актив социаль тормышка күпләп тарту өчен гаять мөһим алшартлар әзер була. Аларның берсе — халык арасында, бигрәк тә Татарстанның төп халкы арасында грамоталы кешеләрнең чагыштырмача күп булуы. Байтак кына нигезле һәм төпле тикшеренүләрдә, шул җөмләдән Мәскәүдәге «Наука» нәшриятында басылып чыккан «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дигән зур күләмле монографиядә бу факт инде күп тапкырлар мисал итеп китерелде. Башка фактлар белән бәррәттән әле телгә алып узылган хезмәттә без Бөгелмә өязендә яшәүче татар хезмәт ияләренең белем дәрәҗәсен өйрәнү йомгаклары буенча Самара губернасының статистик органнары ясаган нәтиҗә белән дә танышабыз. Анда да татарлар арасында укый-яза белүчеләрнең күп булуы турында әйтелә.

Революциягә кадәрге чорда Татарстанда мәгариф һәм культураның үсүе турында сөйләгәндә Казанның, халыкны укыту-агарту эшенең генә түгел, рус фәне һәм культурасының да эре үзәкләреннән берсе буларак, үзенә аерым бер урын алып торганлыгын да онытырга ярамый.

1892 елда Казан губерна статистика идарәсе «Идел буе шәһәрләре һәм Казан губернасы авыллары» дигән китап бастырып чыгара. Аның Казандагы уку йортларына багышланган бүлегендә менә болай диелә: «Уку йортларының саны һәм гомуман уку-укыту эшенең куелышы ягыннан Казан Идел буена урнашкан губерналардагы шәһәрләрне генә түгел, Киев һәм Харьков кебек эре үзәкләрне дә узып китте».

Россиядә елына бер тапкыр чыга торган статистик җыентыкның 1910 елгы мәгълүматларны эченә алган басмасында да Казан губернасында мәгариф эшенең алга китүен чагылдырган кызыклы гына мисаллар бар. Ул мисаллардан күренгәнчә, губернадагы башлангыч, урта һәм югары уку йортларында 1000 кешегә 64,8 укучы туры килгән. Россиянең Европа өлешендә бу саннан югарырак күрсәткечкә ия бары тик берничә генә төбәк ирешелгән. Революциягә кадәр губернада өч югары, тугыз махсус урта уку йорты булган. 1914—1915 уку елында Казан губернасындагы гомуми белем мәктәпләрендә 117,2 мең укучы исәпләнгән. Ягъни Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төркмәнстан һәм Әрмәнстан мәктәпләрендә укучыларның барысын бер-

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 33 том. 1963. 57—58 битләр.

гә кушып исәпләгәнгә карағанда 1,7 тапкырга күбрәк дигән сүз. Югары һәм махсус урта уку йортларына килгәндә исә 1914 елда хәзерге территориясләрне эченә алган Белоруссиядә, Үзбәкстан, Казагыстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Әрмәнстан һәм Төркмәнстанда бер генә югары уку йорты да, ә Кыргызстанда, Таҗикстан һәм Төрекмәнстанда хәтта техникумнар да булмаган. Халыкка аң-белем бирү өлкәсендә бездәге уку йортлары арасында Казан университеты үзенә аерым бер урын алып торган. Моның шулай икәнлеге С. Михайлованың бай фактик материалга нигезләнеп язылган «Казан университеты һәм унтугызынчы йөздә Идел һәм Урал буе халыкларының культурасы» дигән монографиясендә ышандырырлык итеп тасвирланган.

Унтугызынчы йөзнең башларында Казан татарлары арасында мәгариф һәм культураның сизелерлек алга китүенә В. И. Ленин да игътибар итә. «Соңгы ун елда,— ди ул Отто Гетчның 1913 елда басылган «Рус Төркстаны» дигән китабы буенча язган конспектында,— Россиянең мөселман халкы культура ягыннан нык үсте: Казан татарларында... һәр ике җенестән 100 җанга бер мәктәп туры килә; ә православныйларда — 1500—3000 кешегә бер мәктәп. Китап һәм газета әдәбияты тарату мөселман-татарларда чагыштырмача тагын да югарырак» [1].

Моңа тагын шуны да өстәргә кирәк, «Россиядә капитализмның үсеше» дигән хезмәтендә В. И. Ленин Казан өязен Россиянең Европа өлешендәге фабрика-завод промышленностеның әһәмиятле үзәкләре исемлегенә кертә. Санап узылган фактлар фонында, безнең карашыбызча, игътибарны тагын бер нәрсә үзенә җәлеп итә. 1915 елда Казан губернасында беренче бөтендөнья сугышының өлкәдәге хуҗалык-экономик хәлгә һәм социаль-политик тормышка ясаган йогынтысын рәсми өйрәнү уздырыла. Бу тикшерүнең йомгаклары игълан ителгән очеркта без мәнә мондый юлларны укыйбыз: «Татар массалары... яңа идеяләрне үзләштерү сәләтеннән мәхрүм түгелләр. Моңа алар уку-укыту эшләре яңа ысул белән алып барыла торган мәктәпләр, шулай ук татар телендә чыгып килгән һәм күпчелеге азмы-күпме укый-яза белгән халыкка барып ирешкән газета-журналлар ярдәмендә ирешәләр».

Бу уңайдан игътибарга алынырлык тагын бер нәрсәгә тукталып үтәсе килә. Сүз губернада яшәүче керәшен татарлары һәм рус булмаган башка халыкларның балаларын русча укыту өлкәсендә кулланылган көчләү чаралары нәтиҗәләренә берьяклы бәя бирүдән баш тарту, ул халыклар өчен рус алфавиты нигезендә махсус төзелгән әлифбалар булдыру турында бара. Керәшен татарлары өчен махсус әлифбалар төзү, татар авылларында рус мәктәпләре яки татар мәктәпләрендә һәм мәдрәсәләрендә рус классларын ачу, керәшен татарлары арасыннан алар өчен укытучылар хәзерләү— боларның барысы да Көнчыгыш халыклары телләренең һәм культураларының танылган белгече, христиан миссионеры Н. И. Ильминский системасы буенча һәм патша хөкүмәтенең 1870 елның 26 мартында кабул ителгән «Россиядә яшәүче рус булмаган башка милләт кешеләрен укырга-язарга өйрәтү чаралары турында»гы карарына туры китереп эшләнә.

Әлбәттә, моның бөтенесе царизмның колонизаторлык политикасын үтемлерәк чараларга таянып, мөмкин кадәр эффектлырак итеп уздыруга исәпләнгән була. Лакин бу программаны гамәлгә ашыру үзенең объектив нәтиҗәләре буенча патша хөкүмәтенә һәм христиан миссионерларына үз максатларына ирешү өчен бик аз ярдәм итә. Әмма, аның киресе, татарлар яшәгән шәһәрләрдә һәм авылларда рус мәктәпләренең саны ишәя, татар халкы арасында рус теле киңрәк тарала, бу исә үз нәүбәтендә рус һәм татар эшчеләренең һәм крестьяннарының бер-берләренә тагын да якыная баруына китерә. Бу мәсьәләне башлап һәм җентекләп өйрәнүчеләрнең берсе булган А. Н. Григорьев болай дип язды: «Ильминский системасы, патша хөкүмәтенең христианлаштыру өлкәсендә моңарчы кулланган башка барлык ысулларыннан аермалы буларак, язма әдәбият белән, мәктәпләр һәм милли интеллигенция кадрлары хәзерләү белән бәйләнгән иде. Ул кадрларның байтагы массаларга алдынгы идеяләрне җиткерүчеләр булды».

1913 ел башында Казанда хатын-кызлар өчен җиде мәктәп эшли. Мәчет карамагында булмаган бу мәктәпләрнең өчесендә хәтта рус теле укытыла, ә дәресләр яңа ысул нигезендә алып барыла. Казан губернасында яшәгән татарлар арасында аң-белем таратуның торышын чагылдырган бу фактлар үзләре турында үзләре бик

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 39 том. 1968. 549 бит.

ачык сөйли шикелле. Ләкин монда сүзнең хәзерге көндә без аңлаган киң мәгънәдәге аң-белем турында түгел, аның иң гади баскычлары турында барганлыгын тагын бер тапкыр искәртеп китү урынлы булыр. Революциягә кадәрге чорда мәгариф халык массаларны дөньяны танып-белүгә өйрәтүдән бигрәк, аларның аңын фәнгә каршы килә торган фикер һәм карашлар белән томалау өчен клапан вазифасын үтәде. Ләкин... клапан бар һәм аны элек-электән мирас булып калган рухи ярлылыктан котылу өчен көрәш коралы итеп файдаланырга мөмкин иде. Нәкъ менә укучылар массасы булуы, халыкны укыту-агарту кирәклеген аңлау прогрессив интеллигенция вәкилләрендә татарларның вакытлы матбугатын булдыру буенча махсус проектлар төзү теләге уятты. Кызганычка каршы, күп санлы ул проектлар патша хөкүмәте тарафыннан бер-бер артлы кире кагыла килде.

Татарлар арасында социал-демократик идеяләрне пропагандалау өчен нәкъ менә шушы клапанның булуы кирәк иде. Татар телендә легаль социаль-демократик газета — «Урал» газетасы чыга башлау зур трибуна булды. Күренекле ленинчы-революционер Хөсәен Ямашев җитәкчелегендә Оренбург шәһәрендә оештырылган бу газета 1907 елның 4 гыйнвареннан 27 апреленә чаклы чыгып килде һәм татарлар яши торган җирләрдә киң таралды.

Патша хөкүмәтен бәреп төшерү, Бөек Октябрь казанышларын саклап калу һәм совет властеның беренче елларында социалистик үзгәртеп коруларны хәл итү өчен татар халкын көрәшкә тартуда вакытлы матбугатны масштаблы һәм интенсив файдалану Т. Насыйровның монографиясендә бай материалларга нигезләнеп яктыртыла.

Шулай итеп, комплекслы тикшерүне сорый торган бик күп конкрет һәм объектив фактлар яшәп килә. Ләкин алар үзләренә әлеге яшиләр, ә культура-идеологик шартларга күп кенә хезмәтләрдә әле әнә шул фактлардан башка бәя бирелә. һәм кайчандыр гамәлгә кереп киткән мондый бәя үзенең яшәүчәнлеге аркасында бер җыентыктан икенчесенә бик җиңел күченеп йөри. Халыкның культура-тарихи мирасына шушындый нигилистик мөнәсәбәт кайчагында, мәсәлән, ТАСС хәбәрчесе А. Дьяченко имзасы белән «Комсомолец Татарии» газетасының 1972 елгы 12 ноябрь санында басылган «Йөз том поэзия һәм проза» дигән мәкаләдә иң соңгы чиккә җиткән форманы ала: «Бөек Октябрь социалистик революциясенә кадәр,— диелә анда,— татар телендә китаплар басылмады». Ә бит бу мәкаләнең авторына 1913 елда гына да татар телендә 1 671 мең тираж белән 340 китап басылып чыкканлыгын белү өчен культура үсеше мәсьәләләрен чагылдырган телисә кайсы статистик җыентыкны ачып кына карарга кирәк иде. Шул ук елны Россиядә моннан күбрәк китап бары тик рус телендә генә басылган.

Хәер, бу мәсьәләдә әлеге авторны «новатор» дип әйтеп булмый. 1923 елның 3 июлендә «Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты хәбәрләре» газетасында С. Арбатовның Совет властеның беренче елларында татар язучыларының әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итү буенча башкарылган эшләрнең нәтиҗәләренә багышланган мәкаләсе урнаштырыла. «Татар әдәбияты — моннан биш-алты ел элек гади рус укучысына, хәтта күпчелек белгечләргә — әдәбият тарихчыларына да бу сүз бик тә гаҗәп булып тоелыр иде,— дип башлап китә автор үзенең мәкаләсен.— Кешеләр еллар буена татарлар арасында яшәгәннәр, татар журналларын һәм газеталарын көн саен диярлек күреп торганнар, әмма татар әдәбияты, аның поэзиясе, беллетристикасы белән кызыксыну дигән нәрсә беркемнең дә башына килмәгән. Бары тик Октябрь революциясенең җиңүе генә азчылык милләтләрнең төрле культура оешмаларын төзергә, милли культураларга үсәргә, аларны киң пропагандаларга мөмкинлек бирде. һәм, ниһаять, башкалар рәтендә Татарстан автономияле республикасы да татарларның бай әдәбияты барлыгын раслады...» Моны әле аңларга да мөмкин, чөнки бу сүзләр күптән язылган. Ә менә шуңа ук охшашлы версияләрнең соңгы елларда дөнья күргән фәнни-тикшеренү характерындагы хезмәтләрдә һәм публицистик чыгышларда кабатлануы үкенечле хәл түгелмени?! Бу нәрсә культура тарихын өйрәнүдәге төрле буталчыклыкларга китерә. Мисал өчен М. Абдуллин һәм С. Батыевның 1977 елда басылып чыккан «Татарстан АССР: чынбарлык һәм буржуаз мифлар» дигән китабын алырга була. «Халкының яртысы өлешен татарлар тәшкил иткән Казан губернасы,— диелә анда,— укый-яза белү буенча Россиянең Европа өлешендәге илле губерна арасында кырык дүртенче урында торган. 1897 елда уздырылган халык санын алу

мәгълүматларына караганда, татарлар арасында укый-яза белүчеләр 16 проценттан чак кына артыграк, русча укый-яза белүчеләргә килгәндә исә хәл тагын да начаррак булган... Россиядәге бернichә миллион татардан нибары 800 кеше русча укый-яза белгән». (105 б.)

Шушы бер тәкъбирдә генә дә әллә ничаклы төгәлсезлек бар. Беренчедән, әлеге 16 процентка нәкъ менә русча укый һәм яза белүчеләр керә. Икенчедән, «Казан губернасы буенча 1913 елгы күзәтүләр» дә игълан ителгән мәгълүматлардан күренгәнчә, губернада 898653 татар яшәгән һәм телгә алынып узылган өземтәдә китерелгән 16 процент бөтен Россиядә яшәүче татарлар нисбәтендә түгел, ә бәлки губернаның үзендә яшәүче әнә шул татарлар санына карап чыгарылган. Укый-яза белүчеләр 800 кеше булган, дип раслау да дөреслеккә туры килми. Аны 150 мең кеше дип төзәтү сорала. Мондый мисалларны башка галимнәребезнең хезмәтләреннән дә китерергә мөмкин булыр иде.

Шик тә юк, мондый хезмәтләрнең күбесе патша хөкүмәтенең халык массаларын, бигрәк тә рус булмаган халыкларны рухи культура казанышларыннан ераклаштыруга юнәлдерелгән реакцион социаль политикасының нинди коточкыч нәтиҗәләргә китерүен калкурак итеп күрсәтү нияте белән чыгып язылган. Ләкин шундый изге ниятне күздә тотып эшләнгән эшнең нигезсез дәлилләргә таянып түгел, ә бәлки чынбарлыктагы фактларны гомумиләштерү ярдәмендә башкарылырга тиешлеге турында сөйләп торырга кирәкме икән?! Билгеле ки, фәнни тарихилыкның бөтен методологиясе, тарихи фактларга ихтирам белән карауның ленинчыл принциплары ул фактларга игътибарлы булуны һәм аларны объектив анализлауны таләп итә. Шуннан башка халык массаларының революцион аңлылыгы нәрсәгә таянганлыгын дөрес күз алдына китерү бик авыр. Тагын шуны сын да истән чыгарырга ярамый, фактлар белән исәпләшергә теләмәүнең юкка чыгару өчен генә һәрнәрсәне кире кагу юлына этәрүе бар. Ленин басым ясап әйткәнчә, «диалектикада, һичшиксез, инкарь элементы бар һәм ул аның бик әһәмиятле элементы,— диалектика өчен характерлы һәм төп нәрсә коры инкарь түгел, төпсез инкарь түгел, скептик инкарь түгел, икеләнү, шикләнү түгел, бәлки бәйләнеш моменты, үсеш моменты булган инкарь, ягъни уңайны саклап калучы, ягъни һичнинди икеләнүсез, һичбер эклектикасыз инкарь»[1].

Тикшерелә торган мәсьәләгә «уңайны саклап калып» әнә шулай бәя бирүгә якын килү соңгы вакытта КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиевнең Татарстан АССР төзелү уңае белән язылган һәм 1977 елда «Знание» нәшриятында басылып чыккан «Ленинчыл политика хәрәкәттә» дигән хезмәтендә чагылыш тапты.

Казан тарихына багышланып язылган «Борынгы шәһәрнең яшьлеге» дигән монографиядә ул тагын да төптәнрәк тикшерелә һәм соңыннан тарих фәннәре докторы М. Мөхәррәмов редакциясендә 1980 елда чыккан «Татарстан АССР тарихы» китабында тулырак яктыртыла. Ә аңа кадәр күп элегрәк исә бу темага педагогия фәннәре докторы, педагогия фәннәре Академиясе член-корреспонденты М. Мәхмүтов Бөтенсоюз матбугатында гаять нигезле итеп язып чыга.

Халыкның аң-белем һәм культура дәрәҗәсе турындагы мәсьәлә культура революциясен тормышка ашыру буенча алып барылган практик эш дәвамында килеп туган икенче бер проблема белән тыгыз бәйләнгән. Культура революциясе тарихын өйрәнгәндә ул һәрбер илдә принципиаль әһәмияткә ия булып тора. Бирегә сүз культура өлкәсендә үзгәртеп корулар үткәрүдә интеллигенциянең ничек катнашуы турында бара. Бу проблема культура революциясе алга куйган бурычларны уңышлы үтәүгә ярдәм итә торган төп факторларны ачыклаганда килеп туа.

Революциягә кадәр татар интеллигенциясенең аз санлы булуы һәм аның башлыча мәктәпләр тирәсендә формалашуы әдәбиятта дөрес күрсәтелә. Ләкин шуны инкарь итәргә ярамый: Октябрь революциясе җиңгәндә инде татар милли интеллигенциясе булган, һәм аның күпчелек өлешен укытучылар тәшкил иткән. Китап һәм газета-журналлар басу, китапханә, финанс, сәүдә һәм башка белгечлекләр буенча эшләүчеләрнең дә билгеле бер төркеме шулай ук интеллигенция составына кергән. Тормышларын әдәбият һәм сәнгатькә хезмәт итүгә багышланган талантларның — язучыларның, һәм артистларның, җырчыларның һәм музыкантларның бөтен бер плеядасы үсеп чыккан.

---

[1] Ленин В. И. Әсәрләр. 38 том. 1963. 228—229 битләр.

«Татар халкы арасында хисапсыз күп зыялылар,
Сирәк ләкин, дөрес әйтсәм, кешелекле хәялылар»,[1]

ди Тукай 1909 елда язган «Бәгъзе зыялыларымыз» шигырендә. Шагыйрь монда бу темага бездә язылган традицион мәкаләләрдәгечә, татарларда укымышлы кешеләрнең, интеллигентларның аз булуы өчен түгел, аларның бер өлешенең, милли идеологияя җирлегенә эләгеп, дин йогынтысына бирелүе, икейөзлегә әверелүе өчен борчыла. Татар интеллигентлары арасында ул үз чорының саф вөҗданлы, һичбер нәрсәгә сатылмый торган тугры көрәшчеләрен күрергә тели.

Хәзер без большевиклар партиясенең татар интеллигентлары арасыннан нәкъ әнә шундый көрәшчеләр тәрбияләп үстергәнлеген раслаучы дистәләрчә, йөзләрчә мисаллар китерә алабыз. Аларның күбесенең исемнәре илебездә барган революцион көрәш тарихына җуелмаслык булып язылган. Ленинчыл-большевиклар Х. Ямашев, Г. Сәйфетдинов, В. И. Ленин тәкъдиме белән башта РСФСР Халык Комиссарлары каршындагы Эчке Россия мөселманнары эшә буенча комиссар, соңыннан Үзәк мөселман комиссариаты председателе итеп билгеләнгән М. Вахитов, татар пролетар әдәбиятына нигез салучы һәм күренекле революционер Г. Колахметов, атаклы язучы, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов, Казанда һәм Урта Азиядә совет власте урнаштыру өчен актив көрәшчеләрнең берсе, бүгенге көндә генерал-лейтенант Я. Чанышев кебек фидакарьләрнең эшчәнлекләрен халкыбыз беркайчан да онытмас.

Бу исемнәр рәтендә без Татарстанның үзендә яшәгән һәм культура фронтында революциягә кадәр үк эшләп килгән җитәкчеләр һәм активистлардан тыш Урта Азиядә халык мәгарифен оештыручыларның берсе булган татар язучысы З. Бәшири, революциядән соң Сәмәркәнд өлкәсендә чыга башлаган «Михнәттәшләр тавышы» газетасында эшләгән, ә 1920 елдан РКП(б)ның Төркестан край комитетының хатын-кызлар белән эшләү бүлегенә җитәкчелек иткән З. Борнашева исемнәрен дә күрәбез. Мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин, һәм алар К. Маркснын, фикер ияләре күзгә күренмәс җепләр аша халыкның җаны-тәне белән һәрвакыт бәйләнештә тора, дигән тирән мәгънәле фикерен тагын бер мәртәбә раслыйлар. Татар интеллигенциясенең алдынгы карашлы вәкилләре дә патша строе шартларында татар халкының милли һәм политик хокуксызлыкка мәхрүм ителгәнлеген яхшы аңлыйлар, аны алдынгы рус культурасының шифалы йогынтысыннан аеру өчен корылган киртәләрне күреп-тоеп яшиләр. Менә шуңа күрә дә Октябрь революциясеннән соң аларның күбесе, тормышта барган вакыйгаларның асылын тирәнтен аңлап, үз тәбәкләрендә яңа культура төзүчеләр сафына килеп кушылды. һәм бу үз нәүбәтендә халык мәгарифе өлкәсендәге бурычларны уңышлы хәл итүдә, сәнгатьне үстерүдә, хезмәт ияләре арасында күпкырлы культура-агарту эшләре алып баруда аз роль уйнамады.

Алда саналып узылган барлык шартлар республикада культура революциясенең әһәмиятле катализаторлары булып хезмәт иттеләр, һәм аларны бәяләп җиткермәү дөрес булмас иде. Хәер, моңа охшашлы мәсьәләләргә үзвакытында тиешле бәя бирелеп килде. Милли культура мирасына карата мөнәсәбәт һәм яңа тормыш төзү процессында аның роле турындагы мәсьәлә 1927 елның 19 июнендә партия өлкә комитеты бюросы утырышында тикшерелде. Анда кабул ителгән резолюциядә, хезмәт ияләре массаларын социалистик төзелешкә тарту коралы буларак, милли культураның әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтүчеләргә кискен отпор бирелде. Аннан соңгы тикшеренүләр һәм төрле документ-материаллар бу позицияне яңадан карап чыгу өчен бернинди дә нигез бирмиләр һәм аның тормышчанлыгы, реальлеге без мисал итеп китергән фактларның татар халкының гына түгел, башка төрки халыкларның рухи культура тарихларында да зур әһәмияткә ия булуы белән раслана. М. Ауэзов, Б. Кербабаев, Ч. Айтматов һәм башка күренекле культура эшлеклеләренең бу уңайдан әйткән сүзләре безнең өчен аеруча кызыклы. Чыңгыз Айтматов, мәсәлән, «Советская Татария» газетасында басылган мәкаләсендә болай дип язды: «Төрки халыклар арасында татарлар рус һәм бөтендөнья культурасы белән беренче булып таныштылар һәм шуның нәтиҗәсендә беренче булып үзләренең хәзерге язма әдәбиятларын тудырдылар, беренче булып газеталар, журналлар чыгара башладылар, милли театрларын оештырдылар. Кыргыз халкы әле рус телен белмәгән ул заманда, ягъни ре-

[1] Хәялылар — вөҗданы булган кешеләр.

волюциягә кадәрге чорда революцион идеяләр кыргыз хезмәт ияләренә татар теле аша килеп җитте».

Әмма китерелгән факторлар татарларда культура революциясе башлануын тизләтсә, инде алда әйтеп узылганча, аның киң колач алуына комачаулык иткән моментлар да аз булмады. Татарстанның социаль һәм рухи үсешен анда яшәүче хезмәт ияләренең барысы да диярлек авыл халкы булуы бик нык тоткарлады. 1923 елда барлык халкының 90, ә 1926 елда 89,2 проценты авыл халкы иде. Менә шуңа күрә дә социаль-культура өлкәсендәге яңалыкларга һәм алдынгы идея-политик карашларга салам түбәләр астына үтеп керү бик үк җиңел булмый.

Капитализмнан социализмга күчү чорында ясалган культура революциясе социаль-экономик, идея-политик шартларда культура-агарту эшләрен юлга салган кебек үк халык массаларының рухи тормышын да тамырдан үзгәртте. 1939 елда уздырылган халык исәбен алудан күренгәнчә, укый-яза белүчеләр Татарстанда яшәүчеләрнең 90,4 процентын, шәһәр халкының 95,1 һәм авыл кешеләренең 88,9 процентын тәшкил итте. Моның әйбәт күрсәткечләр икәнлеге түбәндәге саннардан да ачык күренә: ул вакытта бөтен ил һәм күп кенә республикалар буенча халыкның белем дәрәҗәсен чагылдырган саннар моннан шактый түбәнрәк иде. СССР буенча ул 87,4 процент, Украина буенча 88,2 һәм Белоруссия буенча 80,8 процент булды. Үзбәкстан буенча исә 78,1 процент исәпләнде.

Татарстан АССРда культура революциясенең төп нәтиҗәләре итеп, бөтен илдәге шикелле үк, культураның киң халык массалары казанышына әверелүен, рухи тормышның барлык өлкәләрендә марксизм-ленинизм идеологиясе расылануын, халык хуҗалыгы өчен кирәкле кадрлар, шул исәптән милли интеллигенция арасыннан ук меңнәрчә кешеләр хәзерләнүен культура мирасын файдалануда ленинча чын принципларны кулланып эш итү нәтиҗәсендә татар халкының эчтәлеге белән социалистик, рухы һәм характеры белән интернационал булган милли культурасы төзелүен санарга кирәк.

Соңгы елларда, нык үскән социализм чорында, Татарстан АССР, гомумән, бөтен илебез шикелле үк, фән һәм культура биеклекләренә зур сикереш ясады. Культура революциясе дәвамында моңарчы яшәп килгән иҗтимагый мөнәсәбәтләрне өр-яңадан үзгәртеп кору халык тормышының барлык өлкәләрен колачлады.

## Мәхмүд Галиев

# «МӨХӘММӘДИЯ» МӘДРӘСӘСЕННӘН — МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНӘ

Революциягә кадәрге татар мәдрәсәләре халкыбызны аң-белемле итүдә, милли культурабызны, мәгарифебезне һәм әдәбиятыбызны үстерүдә зур роль уйнадылар. Караңгылык, хорафат, милли дошманлык һәм деспотизм хөкем сөргән заманда алар, мәгълүм чикләнгәнлекләренә дә карамастан, яктылыкка, мәгърифәткә чакырып янган якты маяклар булдылар. Мәдрәсәләрдән агылган мәгърифәт нуры йокымсырап барган бик күп зиһеннәрне яктыртты, меңнәрчә сүрелгән күңелләрдә өмет һәм киләчәккә ышаныч уты тергезде. Ул чорда халкыбызның махсус һәм югары уку йортлары булмау сәбәпле, татар мәдрәсәләре аларның вазифасын да үз өсләренә алып бик күп милли белгечләр әзерләделәр.

Мәгариф өлкәсендә үз чорында күренекле роль уйнаган «Мөхәммәдия» мәдрә-

сәсенең элеккеге бер шәкерте буларак, кайбер истәлек-хатирәләрем һәм уйлануларым белән уртаклашып китмәкче булам.

Билгеле булганча, революциягә кадәр балаларга татар телендә белем бирү ике юл белән алып барылды. Берсе аның традицион, иске (кадимчә) методикага нигезләнгән укыту булса, икенчесе заманына күрә яңа алымнар белән (җәдитчә) укыту иде.

Кадимчә ысул белән укытканда, әлифба урынына иман шарты кулланылды. Шәкертләр хәрефләрнең исемнәрен ятладылар һәм аларны иман шартындагы гарәп сүзләреннән эзләп укырга өйрәнделәр. Бу ысул белән хәреф таныту, укырга өйрәтү гадәттә өч-дүрт елга кадәр сузыла торган иде. Мәдрәсә программасына кертелгән дәресләрнең һәммәсе дә диярлек дини характерда булды, дөньяга бәйләнешле фәннәр аз укытылды. Укуга, белемгә дәртләре зур булган кайбер зиһенлерәк шәкертләр генә рус телен өйрәнделәр һәм аның аша башка фәннәрне дә үзләштерделәр. Хорафат сөременнән арына алмаганнарын исә наданлык һәм томаналык үз кочагына алды. Шулай булса да, гасырлар дәвамында китапны изге итеп күрергә гадәтләнгән, аң-белемгә зур хәзинә итеп караган татар халкы үз балаларын укытырга, аңлы-белемле итәргә омтылды.

Кадим мәдрәсәләренең кимчелекләрен үз башыннан кичергән алдынгы мәгърифәтчеләр прогрессив ысуллар турында фикер йөртә башладылар. Нәтиҗәдә, җәдитчә (яңача) укыту бәрлыкка килде. Мондый мәктәпләрдә хәреф таныту төрки сүзләргә нигезләнгән иде һәм анализ-синтез ысулы белән алып барылды. Әлеге ысул белән сүзләрне — иҗекләргә, иҗекләрне авазларга аерырга һәм авазлардан — иҗекләр, иҗекләрдән сүзләр оештырырга өйрәттеләр. Шул рәвешле, бала 3—4 ай эчендә укырга-язарга өйрәнә иде. Укуны болай оештыру баланың күңелен биздермәде, вакыт ягыннан да отыш бирде.

Искечә һәм яңача укытулар арасындагы төп аерма, әлбәттә, укытыла торган фәннәрдә, программаларда иде. Кадим мәдрәсәләрендә бары дин дәресләре генә укытылды. Гәрчә мантыйк (логика) дигән фән булса да, ул диндәге хода төшенчәләрен аңлату белән чикләнде. Мәсәлән, «Инә күзеннән дөяне үткәреп буламы?» дигән сорау куела. «Була» яисә «Булмый» диючеләр үзләренең фикерләрен исбат итәргә тиешләр. Шунда бер белдеклесе: «Ходаның кодрәте бик киң, ул теләсә, инә күзеннән дөяне генә түгел, хәтта шәһәр, авылларны да үткәрә ала» дип барысының да «авызын томалый» торган иде. Җәдит мәдрәсәләрендә исә дин дәресләре белән бергә, тел, әдәбият, хисап, география, табигать белеме, рус теле кебек дөньяви фәннәр дә укытылды. Бу ике тип мәдрәсә арасындагы янә бер үзгәлекне дә искәртеп узу заруридыр. Гадәттә, кадим мәдрәсәләренең башында мөдәррис булып, ул шул ук мәхәлләдә имамлык кыла иде. Аның кул астында өч-дүрт хәлфә эшләде. Җәдит мәдрәсәсенең башында мөдәррис торса да, аның муллалык итүе шарт түгел иде. Ул кул астындагы мөгаллимнәр белән киңәшә, фикер алыша. Шул максаттан чыгып эчке совет оештыра. Анда барлык мөгаллимнәр, дингә тел тидермәү шарты белән, укыту, тәртип, өлгереш хакында фикерләрен әйтә торган булганнар.

Белемгә омтылган татар яшьләре XIX гасырга кадәр Бохара мәдрәсәләрендә укыдылар. Ә анда схоластика хөкем сөрде, дин тәгълиматы өстенлек итте. Шул сәбәпле, күпчелек мәдрәсә әһелләренең дөньяга карашы формалашуда Бохара мәдрәсәләренең йогынтысы зур булды. 1882 елда әтисе акчасына «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен (хәзерге Тукай урамы, 34 нче йорт) салдырган Галимҗан Баруди да Бохарада белем алган. Яңа мәдрәсә ачкач, ул хисап, география кебек дәресләрне дә кертеп, башта кадимчә ысул белән укыта башлый. 5—6 мөгаллимнән торган коллектив туплый. Ул 1891 елда Россиядә беренче булып балаларны хәреф (анализ-синтез) ысулы белән җәдитчә укытуга күчә. Шул ысул белән укыту өчен үзе «Сәвадхан» (грамота иясе) исемле әлифба да төзи. Бу китап татар дөньясына яңа ысул белән һәм төркичә язылган беренче әлифба булып санала. 1891—1915 еллар эчендә ул 12 тапкыр басыла.

Мондый метод белән хәреф өйрәтә торган әлифбалар рус телендә күптән яшәп килсә дә, татар мөгаллимнәре диннәре башка булган милләтләрнең мәгарифенә ияргәскә тырыштылар, ислам динендәге милләтләргә карап тигезләнүне артыграк күрделәр. XVI—XVIII гасырлардагы царизмның көчләп чукындыру политикасыннан әркеп калган татарлар руска охшаудан курыктылар. Ә җәдит мөгаллимнәренә исә күпчелеге кадимчеләр тәэсирендә булган, һәр яманлыкны яңача укытудан күргән халыктан еш

кына җәбер, каргыш сүзләре ишетергә туры килә иде. Болары гына бер хәл, байларның, хәлле кешеләрнең мәдрәсәгә матди ярдәм күрсәтүне туктатулары да бик мөмкин иде.

Шуның белән бергә, патша хөкүмәте дә мәгариф өлкәсендәге һәр прогрессив күренешкә аяк чалып килде, җәдитчеләрнең эшчәнлегендә җимерү эшләре, царизмга каршы көрәш күрде. Кадимчеләрнең һәм рус карагруһчыларының вакытлы матбугатында җәдитчеләргә каршы пычрак кампания башланды. Мәгариф өлкәсендәге һәр прогрессив күренешкә, бигрәк тә мәдрәсәләрдә рус теле укытуга нык каршы булган Мөхәммәтҗан Хафиз, Җиңги Садыйк кебек кара фикерле бәндәләр һәм аларга ияргән томана куштаннар — Печән базары әһелләре өере җәдитчеләргә каршы надан халыкны өстерделәр, алдынгы карашлы мөгаллимнәр өстеннән патша охранкасына донослар яздылар. Карагруһчылар «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең мөдәррисе Галимҗан Барудины, Яңа бистәдәге 10 нчы мәчет мәдрәсәсе мөдәррисе Салихҗан Галиевны сөргенгә сөрдерүгә ирештеләр. Мәдрәсә мөдәррисе, Фатих Әмирханның әтисе Зариф һ. б. бик күп мөгаллимнәр карагруһчылар тарафыннан шактый җәбер күрделәр. Аларны полиция яшерен күзәтү астына алды.

Ачык фикерле намуслы муллалар һәм дин эшлеклеләре карагруһчы руханиларга мондый пычрак эшләре өчен мәчетләрдә ләгънәтләр укыдылар, халыкны аларга иярмәскә өндәделәр.

XIX гасыр ахырында җәдит мәдрәсәләрендә рус мәктәпләрендәге кебек аяклы парталар, кафедра, кара такталар, тарих һәм география карталары, плакатлар булдырылды. Шәкертләр дәрестә утырма якалы тужурка, башларына тигез түбәле кәләпүш киеп утыралар иде. 1901 елда «Мөхәммәдия»нең тышкы коллегиясе (аңа мәдрәсәгә булышучы байлар, өлкән укытучылар һәм Г. Баруди керә иде) 60 мең сум акча туплап, ике катлы мәдрәсәнең алгы ягына үзәктән ягып җылытыла торган өч катлы бина салдырды. Элеккеге биналарга да үзәктән җылыту системасын эшләделәр. Ишек алдына ашханә, кухня, авырулар өчен шифаханә, итек-читек, кәвеш төзәтү, агач эше, китап төпләү мастерскойлары булдырылды. Шифаханә артында бакча булып, кышын кайбер шәкертләр тимераяк белән катокта шуалар иде. Шәкертләр саны арта баргач, мәдрәсәне киңәйтү мәсьәләсе көн тәртибенә килеп басты. Тик мәдрәсәнең яңа бинасын төзү өчен кадимче Йосыф хәзрәтнең ике класслы бәләкәй мәдрәсәсен җимерергә кирәк иде. «Мөхәммәдия» җитәкчелеге һәм тышкы совет хәзрәтне бу эшкә ризалатып, аңардан рөхсәт кәгазе ала алды. Ләкин көне килеп җиткәч, Йосыф хәзрәт кинәт кенә биргән вәгъдәсеннән кире кайтты. Шул сәбәпле, мәдрәсәнең өч катлы бинасы Йосыф мәктәбе артына салынды. Хәзрәт үлгәч кенә (1907 елда) әлеге ике класслы мәдрәсә «Мөхәммәдия»гә кушылды.

«Мөхәммәдия»нең төп классларына өстәмә рәвештә мәчетнең беренче катындагы ике бүлмәсендә ярлы һәм ятим балалар өчен башлангыч фокара (фәкыйрьләр) мәктәбе яшәде. Анда ятим яки укытырга хәленнән килми торган кешеләрнең балалары укый иде. Аларга дәфтәр, дәреслек, карандаш бушлай өләшенде. Киемнәр белән дә тәэмин ителде. Балаларны кызыктыру һәм урамда хәер (сәдака) соратып йөртмәү өчен, дәрескә килгән көннәрендә аларга өчәр тиен «стипендия» түләнде. Ярлы халык арасында бу фокара мәктәбенең авторитеты бик зур булып, ятим балаларны мәхәлләләрдән җыеп халык үзе китереп тапшыра башлады. Фокара мәктәбен тәмамлаган балаларны гадәттә кибетләргә өйрәнчек итеп эшкә урнаштыралар яки «Мөхәммәдия»нең төп классларына укырга кабул итәләр иде.

Моннан башка, «Мөхәммәдия»дә поляк татарлары өчен дә бер класс (1915—1916 еллар) ачылган иде. Ләкин, телләр аермасы зур булу сәбәпле, бу класс озак яшәмәде, таралды. Шулай ук «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе каршында оешкан «Маһруй абыстай мәктәбе» дип аталган кызлар классының да абруе шәһәр күләмендә зур булды. Бу мәктәпнең җитәкчесе Г. Барудиның хатыны Маһруй абыстай иде. Маһруй абыстай укый белә башлаган кызларны үзенә ярдәмче итеп алып, аларны да «мөгаллимә» иткәләде. Берничә елдан соң, Чувашиле (хәзерге Зеленодольск районы) авылыннан Ләбибә исемле укымышлы кызны үзенә ярдәмче итеп алдырып, икәүләп укыталар. 1904 нче елда Маһруй абыстай үлгәч, Галимҗан хәзрәт димләве буенча байлар акча җыеп Ләбибәгә ике катлы мәдрәсә (хәзерге Нариманов урамы, 105 йорт урыны) салдырдылар. Мәдрәсә мөгаллимәләр әзерләүне максат итеп куйды. Ләбибә мәдрәсәсендә дин

тәгълиматы дөньяви фәннәр белән бергә үреп алып барылды. Ләбибә мәдрәсәсен тәмамлаган кызлар урта белемле булып исәпләнделәр һәм совет вакытында мөгаллимәлек хокукы алдылар.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шулай үсә, зурая барды. 1908 елларда аның егермеләп классында һәр елны уртача исәп белән 500 ләп шәкерт укый иде инде. Мәдрәсә киңәйгән саен, хуҗалык һәм укыту чыгымнары арта барды. Шуңа күрә Галимҗан Баруди, матди ярдәм сорап, еш кына байларга мөрәҗәгать итә иде. Үз акчасына «Хөсәения» мәдрәсәсен салдырган һәм аның барлык чыгымнарын каплауны да өстенә алган миллионер Әхмәт Хөсәенов, мәсәлән, «Мөхәммәдия»нең өч катлы бинасын салдыру өчен 30 мең сум акча бирә. Сәүдә капиталының һәм либераль буржуазиянең эре вәкиле кадим мәдрәсәсен тәмамлаучылар белән генә ерак бара алмавын яхшы аңлаган, ана татарча яза алган, русча сөйләшә-аңлаша белә торган белгечләр, хисап эшен булдыра алган бухгалтерлар кирәк була башлаган. Әхмәт бай мәдрәсә бетергән Ибраһим Әмирхан кебек зиһенлерәк шәкертләрне үз исәбенә Бәйрүтнең махсус белем бирүче инглиз урта мәктәбенә укырга җибәрә.

Байлар таләбен искә алып, практик ягын да чамалап, Г. Баруди башлангыч мәктәпкә бер ел өстәп, анда хисап, бухгалтерия кебек фәннәрне укыттыра башлады. Бу адымны мәдрәсәнең тышкы советы да хуплап каршы алды. «Мөхәммәдия»нең яшь мөгаллимнәре һәм күзләре ачыла башлаган шәкертләре мәдрәсә җитәкчелегеннән реформаны кинрәк уздыруны, дөньяви фәннәрнең санын арттыруны, рус телен укыту планына кертүне ныграк һәм кискенрәк рәвештә таләп итә башладылар. Беренче рус революциясе исә бу таләпне көчәйтеп кенә җибәрде. Революция шәкертләр аңына нык тәэсир итте. Шәкертләр демонстрацияләргә катнашу, полицияне коралсызландыру, халык милициясен төзү эшләренә җан-тәннәре белән бирелделәр. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бу көннәрдә умарта күчедәй гөжләп торды. Закир Шакиров, Ибраһим Килдиев, Нургали Мамин, Габдрахман Мостафин, Фатих Әмирхан, аның энесе Ибраһим Әмирхан һәм Галиәсгар Камаллар халык милициясен төзү эшендә зур активлык күрсәттеләр. Студент-большевик С. Гассар белән нык бәйләнештә булган Хөсәен Ямашев татар учительләр мәктәбенең укучылары белән бергә мәдрәсәдә революцион рухны күтәрүдә җитәкчелек итте. Гафур Коләхметов та шәкертләр арасында зур агитация эше алып барды. Казан шәһәренең полицмейстры 1905 елның 1 февралендә губерна жандармерия идарәсенә язган рапортында болай дип зарланды: «Казанда хәлләр куркыныч... Мөселман халкы арасында Г. Баруди мәдрәсәсе шәкертләре политик яктан ышанычсыз...»

Шул ук елны «Мөхәммәдия»дә яшерен рәвештә мәдрәсәләрдә ислах (реформа) уздыру комитеты төзелде. Комитет башында Фатих Әмирхан, Гарифҗан Мостафин, әгъзалары Ризван Ибраһимов, Ибраһим Әмирхан, Вафа Бәхтияров, Габдрахман Мостафин, Нургали Мамин, Миргазиз Укмасый лар иде. Алар шәкертләрнең беренче яшерен съездын җыйдылар. Яшерен рәвештә гектографта басып «Әлислах» газетасы чыгардылар. Полиция яшерен газетаның эзенә төшеп, Нургали Мамин өендә саклаган материалларны конфискацияләде, үзен кулга алды. 1906 елда Казан мәдрәсәләре шәкертләренең I съезды булды. 1907 елда ислах комитеты зур шәһәрләрдәге мәдрәсәләрдән дә вәкилләр чакырып, шәкертләрнең II съездын җыйды һәм шунда «Әлислах» газетасын рәсмиләштерде. Һәр ике съездга да Фатих Әмирхан җитәкчелек итте.

Шул елларда Г. Мостафин «I садә» (аваз) шигырен, Хуҗа Бәдигыйның абыйсы мулла Әхмәт Бәдигый «II садә» шигырен яздылар. Бу әсәрләр Россиянең барлык мәдрәсәләренә дә диярлек таралды. Моннан кала, Г. Мостафин «Марсельеза»ны да татарчага тәрҗемә итте. Тәрҗемә әдәби яктан йомшак булса да, шәкертләргә ул сугышчан рухы белән якын иде.

Шәкертләр хәрәкәте, бер яктан караганда, мәдрәсәләргә реформа кертергә омтылу гына булып күренсә дә, асылда ул шәкертләрнең уянуы, дөньяга карашлары үзгәрүе, аларга революция рухы керү турында сөйли.

Шәкертләр хәрәкәте басымы астында һәм тормыш таләбе белән, шулай ук укытучылар теләген искә алып, мәдрәсә коллегиясе педагогика, методика, психология, гигиена, укыту практикасы, алгебра, физиология, физика-химия элементлары кебек фәннәр укытуны да гамәлгә кертте.

Г. Барудиның сөргендә йөргән вакытында мөдәррис булып калган һәм русча

укыту ягында булган Таһир Ильяс, Закир Шакиров, Әхмәтҗан Мостафин һ. б. лар программага зур үзгәреш керттеләр. Нәтиҗәдә, 1912—1914 нче елларда «Мөхәммәдия»нең иң соңгы уставы һәм программасы барлыкка килде. Бу программа элгәрегеләрдән шактый үзгә иде. Яңа программа буенча алты еллык башлангыч мәктәпне тәмамлаучылар шәригатьне аңлап гамәли рәвештә динне (намаз, ураза һ. б. лар) белгәннәр, бераз гарәп сүзләрен аңлаганнар, төрки телендә максатларын язып төшендерә алганнар, тарих, география, табигать фәннәреннән хәбәрдар булганнар. Аларны шулай ук хисаптан бөтен саннар һәм вакланмалар белән булган мәсьәләләрне чишәргә, русча укырга-язарга да өйрәткәннәр. Алты еллык рөшдия (урта) бүлегендә гарәп теле, шәригать (дини этика), рус теле һәм башка дөньяви фәннәр укытылды. Аны тәмамлаучыларның күпчелеге гадәттә мөгаллим яки мулла булып китәләр иде. Мәдрәсәнең бер еллык галия (югары) бүлегендә укучылар дин гыйлемен үзләштереп имам-мөдәррислеккә әзерләнделәр.

1912—1914 елгы программа буенча башлангыч бүлектәге атналык дәресләрнең 39 сәгате дин тәгълиматына, 111 сәгате дөньяви фәннәргә бирелде. Урта бүлектә дин тәгълиматы 43 сәгать, дөньяви фәннәр 131 сәгать укытылды. Рус гимназияләре белән чагыштырганда, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дин дәресләре бераз күбрәк булса да, Духовный семинариягә караганда (анда фәннәрнең 70 процентын дин тәгълиматы тәшкил итте) чагыштырмача азрак иде. Моннан тыш, татар мәдрәсәләренең беркүк вакытта гимназия һәм семинария хезмәтен үтәвен дә истән чыгарырга ярамый.

1912 елгы программа буенча дәресләр челтәре түбәндәгечә иде:

**Башлангыч мәктәпнең атналык дәрес челтәре**

| Фәннәр | Хәзерлек | Класслар 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| дин дәресләре (сәг.) | 1 | 8 | 9 | 8 | 6 | 7 | 39 |
| төрки теле | 12 | 10 | 8 | 5 | 7 | 6 | 48 |
| хисап | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 | 3 | 22 |
| тарих | 1 | 1 | 1 | 2 | — | 2 | 8 |
| гарәп теле | — | — | — | 1 | 1 | 1 | 3 |
| фарсы теле | — | — | — | 1 | 1 | 1 | 3 |
| география | — | — | — | — | 1 | 1 | 2 |
| рус теле | — | — | 3 | 6 | 6 | 6 | 21 |
| табигать | — | — | — | — | 1 | 1 | 2 |
| рәсем | 1 | 1 | 1 | 1 | — | — | 4 |
| | дин 1 | 8 | 9 | 8 | 6 | 7 | 39 сәг. |
| | фән 17 | 16 | 17 | 18 | 22 | 21 | 111 сәг. |
| | барлыгы 18 | 24 | 26 | 26 | 28 | 28 | 150 сәг. |

**Башлангыч һәм урта классларда (барлык классларны бергә кушып исәпләгәндә) атналык дәрес челтәре**

| Фәннәр | Башлангычта | Урта мәктәптә |
|---|---|---|
| дин | 39 | 43 |
| төрки теле | 48 | 13 |
| гарәп теле | 3 | 41 |
| фарсы теле | 3 | — |
| рус теле | 21 | 36 |
| математика | 22 | 13 |
| тарих | 8 | 11 |
| табигать фәннәре | 2 | 3 |
| география | 10 | 8 |
| методика, педагогика | — | 6 |
| | дин 39<br>фәннәр 111 | 43<br>131 |

Татар мәдрәсәләре күбесенчә иганәдән җыелган акчага яшәгәнлектән, күрсәтмә әсбаплар, дәреслекләр җитешмәде. Төрки телдә укытырга әлифбалар юк иде. Юга-

рыда әйтелгәнчә, Галимҗан Баруди үзлегеннән төрки теле дәреслек-кулланма төзеде. Шулай ук татар мәгърифәтчеләренең, бигрәк тә Ибраһим Терегулов, Каюм Насыйри кебек галимнәрнең хезмәтләре дә дәреслек урынына файдаланылды. Дәресләрдә Габдулла Тукай әсәрләре киң кулланылды. 1910 нчы елларда Җамал Вәлиди, Габдрахман Сәгъди, Риза Фәхретдинов, Галимҗан Ибраһимовларның татар теле дәреслекләре, Харис Фәйзинең (Әхмәт һәм Җәүдәт Фәйзинең атисе) табигать, география китаплары, Мөхетдин Корбангалиевның география китабы «Мөхәммәдия»дә шактый вакыт дәреслек булып йөрделәр.

Дәреслекләргә мохтаҗлык зур булганлыктан, шәкертләр кайбер фәннәрне төрек, гарәп телендә укыдылар. Г. Баруди дәреслекләрне сайлау, аларны программага кертү мәсьәләсендә мөгаллимнәргә тулы ирек биргән иде. Дәреслекләр булмаганга күрә, мөгаллимнәр гарәпчәдән яки русчадан тәрҗемә итеп файдалана иделәр. Гәрчә кайбер фәннәр программада булмаса да, Г. Баруди өстәмә дәресләр уздыруны гамәлгә кертте. Доктор Әбүбәкер Терегулов — медицина, гигиена, адвокат Сәедгәрәй Алкин — хокук, Фатих Әмирхан төрле партияләр, шул җөмләдән, социал-демократик эшчеләр партиясе турында да дәресләр бирде.

Дәресләргә әзерләнгәндә, мөгаллимнәрнең күбесе газета-журналларда басылган материаллардан, өстәмә әдәбияттан киң файдалана иделәр. Эчке коллегиядә мөгаллимнәр сайлаган материалларга тикшерү булмады. Хәтта коръәнне мәкам (көй) белән укыта торган Вәли Карый да дәрес ахырында халык җырларын җырлата иде. Мәдрәсә җитәкчелеге шәкертләрнең иреген бик үк чикләп тә бетермәде. Гадәттә, шәкертләр намазга әленке-салынкы гына йөриләр, ә уразаны исә бөтенләй тотмыйлар иде. Моңа Галимҗан Баруди да, башка мөгаллимнәр дә ачуланмады. Намаз уку һәм ураза тоту һәркемнең үз эше дип саналды. Үз вакытында шушы мәдрәсәдә укыган шәкертләрнең истәлекләре дә «Мөхәммәдия»дә искән яңа җилләр турында сөйли.

Башлангычның дүртенче сыйныфында укыганда мин укытучы Нәҗип хәлфә Зәетовның электр тогы ярдәме белән суны кислородка һәм водородка аерылуын күрсәткәнен хәтерлим. Шулай ук башлангычта укыганда безгә укытучы Айның — Җир тирәсендә, Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен, елның дүрт сезонын, көн-төннең ничек хасил булуын махсус теллорий исемле прибор ярдәмендә аңлаткан иде. Берничә айлар буе кайсыбер урыннарда кояшның батмавын күрсәткәч, «Игез, болай булса, ураза тоткач, авызны кайчан ачабыз?» дип, безнең күңелгә дин турында шөбһә салды. Үзе җавап бирмәсә дә, безне бу турыда уй-фикер йөртергә мәҗбүр итте.

Башлангыч мәктәптә укыгандагы тагын бер эпизод исемдә калган. Бер укучы: «Борһан абый, безнең дәрескә бәйләнеше булмаган бер соравыбыз бар»,— диде. Хәлфәбез: «Я, сорагыз»,— дигәч, укучы: «Теге дөнья, җәннәт, җәһәннәм бармы?»— дип сорады. Борһан абый бераз елмайды да: «Бик беләсегез киләмени?»— диде. Без һәммәбез дә: «Беләсебез килә шул»,— дидек. Кыстатмады. «Алайса, тыңлагыз: теге дөнья юк, җәннәт белән җәһәннәм бар»,— диде. Бу җавап безне аптырашта калдырды. Борһан абый сүзен дәвам итеп болай диде: «Теге дөнья юк. Кеше үлгәч аның өчен хәят, яшәү бетте дигән сүз. Ә җәннәт белән җәһәннәм бар, ләкин бу дөньяда. Начарлык, бозыклык эшләсәң, кешегә җәберең тиеп торса, кеше үтерсәң, урласаң, үләр алдыннан әнә шул эшләрең күз алдыңнан кичә, үлемең башкаларныкына караганда йөз тапкыр авыррак була. Ә инде игелек эшләсәң, күңелең саф була, үз-үзеңнән риза булу тойгысы уяна. Синең үлем дә җиңел булачак».

Хәзерге көндә Ленинградта яшәүче профессор Әхәт Госманов, атказанган сәнгать эшлеклесе скульптор Бакый Урманче, доцент Рәүф Гилдиевләр хәлфәләр безне намаз укымаганга ачуланмадылар дип искә алалар. Шагыйрь Әхмәт Исхак: «Мин урта бүлектә укыганда дингә каршы журнал чыгара башладым. Бу журнал, кулдан-кулга йөреп, гарәп теле укытучысы Габдрахман Галиев кулына эләгә. Ул мине очратып: «Кара әле Әхмәт, синең журналыңны укып чыктым. Синдә язучылык сәләте бар икән. Әгәр син, зур булмаса да, гарәп телендә журнал чыгарсаң, яхшы булмасмы икән? Башка телне өйрәнү бер вакытта да зарар итмәячәк, мин ярдәм итәрмен»,— диде.

Мәдрәсә идарәсе шәкертләр арасыннан сәләтле, эшлекле, өметле булганнарын мөгаллимлек хезмәтенә алып кала иде. Мәсәлән, Г. Камал 1900—1904 елларда татар теле укытты. Шәкертләр хәрәкәте башында йөргән Фатих Әмирхан рәшидиядә география, шәкертләр хәрәкәтендә актив катнашкан Закир Шакиров — тарих, география,

Зәки Уразаев — математика, Хуҗа Бәдигый — татар теле, Борһан Хәбиб — физика, Мирза Гөзәеров һәм Әхәт Богдановлар математика укыттылар.

Закир Шакировның география дәресенә Габдулла Тукай килергә теләгән белдерә. Закир хәлфә дәресен карта, плакат һәм проекция фонаре белән алып бара. Тукай дәрестән бик канәгать булып китә.

«Мөхәммәдия»дә укып чыккан шәкертләр мәдрәсәдә алган белемнәрен таратуда эчке Россия белән генә чикләнмичә, Себер һәм Урта Азия халыкларына да җиткерделәр, анда яшәүче җирле халыклар арасында күп санлы җәдит мәдрәсәләре ачтылар. Мәсәлән, 1905 елны мәдрәсәнең галия бүлеген тәмамлаган Тәүфикъ Биккининны Г. Баруди Хива ханы Әсфәндияр соравы буенча мөгаллим итеп җибәрә. Ул беренче булып, Хива ханлыгында җәдит мәдрәсәсе ачып, хан балаларына сабак бирә, төрекмән, үзбәк, каракалпак балаларын укыта.

Зариф Бәшири Казахстанның хәзерге Талды-Курган өлкәсендәге Капал шәһәрендә җәдитчә ысул белән укыта торган мәдрәсә ача. Вәли Минһаҗев Кыргызстанның Пешпәк (хәзерге Фрунзе) шәһәрендә, Гыйрфан Сөбханкулов, Наманган өлкәсендә җәдит мәдрәсәләре ачалар. Хәбиб Хәмзин Башкортстанның хәзерге Стәрлетамак районы авылларында мәгърифәт таратып йөри. Шулай итеп, 1882 елдан алып 1918 елга кадәр яшәгән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шул чорда Казан губернасында иң алдынгылардан берсе иде. 36 ел эчендә ул меңнән артык шәкерткә башлангыч һәм урта белем бирде. Алар арасында — Хөсәен Ямашев, Мәхмүт Дулат-Али, Камил Якуб, Касыйм Туйбактин кебек ялкынлы революционерлар, Миргазиз Укмасый, Зариф Бәшири, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Әнәс Камал, Кәрим Тинчурин, Гыйбад Нугайбәк, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый, Фәхри Әсгать, Фазыл Туйкин, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Исхак һ. б. күренекле әдипләр һәм галимнәр, Борһан Шәрәф, Әхмәтгәрәй Хәсәни кебек журналист һәм нәширләр, Габдрахман һәм Габдулла Камал кебек талантлы артистлар, композиторлар Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, скульптор Бакый Урманче... «Мөхәммәдия»нең рөшдия (урта) бүлеген тәмам иткән шәкертләрнең бик азы гына мулла булып китте. Аларның күпчелеге мөдәррис, мөгаллим, мәдәният хезмәткәре, әдип, журналист, нәшир, революционер булдылар. Революциядән соң ачылган техникум һәм институтлар яңа буын кадрлар әзерләп өлгергәнче элеккеге мәдрәсә шәкертләре мәгариф фронтының алдынгы отряды булып совет дәүләтенә чын күңелдән бирелеп эшләделәр. «Мөхәммәдия»дә укыткан Габдулла Гыйсмәти революциядән соң җиң сызганып Башкортстанда эшләде, автономияле республиканың Үзәк Башкарма комитеты члены һәм мәгариф халык комиссары постларын биләде. Шәриф Байчура пенсиягә чыкканчы партия һәм совет матбугаты органнарында җитәкче эштә булды. Баку эшчеләре арасыннан күтәрелгән һәм «Мөхәммәдия»нең югары классында укыган Хәсән Ризван да озак еллар буе дәүләт аппаратында эшләде. Габдрәшит Солтанов Казанда Верховный суд члены һәм финанс министрлыгының җаваплы работнигы иде. Мирзасалих Хөсәенов Урта Азиядә судья булды. Фәрит Хәсәнов совет аппаратында хезмәт итте. Гәрәй Имаметдинов, гражданнар сугышында катнашып, соңра партия һәм совет эшләрендә эшләде. Мөселман Социалистлар комитетында эшләгән Каюм Гобәйдуллин Совет органнарында озак еллар буе хезмәт итте. Фәтхи Бурнашның абыйсы Кадыйр Бурнаш шактый вакыт балалар укытты... Мондый мисаллар бик күп.

Җәдит мәдрәсәләренең, шулар эчендә «Мөхәммәдия»не тәмамлап укытучы булып киткәннәрнең революция чорындагы дөньяга карашларын һәм политик йөзләрен күрсәтү өчен Надежда Константиновна Крупскаяның фикеренә игътибар итү урынлы. Ул 1919 елның июль аенда «Красная Звезда» исемле агитация пароходы белән Татарстанга килә һәм бу сәяхәт турында Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты сессиясендә речь сөйли. Бирегә аның речennән бер өзекне мисал итеп китерик: «Казанда... мәктәпләрдә эшләүче рус укытучылары совет властена риза булсалар да, кайбер рус педагоглары (гимназия һәм университет укытучылары) Совет властена каршы чыктылар,— ди ул.— Мин татар һәм азчылык милләт укытучыларының Совет властена бик нык тартылганнарын күрдем».

Без бу сүзләрне татар халкы арасыннан укымышлы белгечләр, шул исәптән, фән, әдәбият, сәнгать, культура һәм мәгариф эшлеклеләре тәрбияләнгән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең прогрессив эшчәнлегенә бирелгән бәя дип тә уйлый алабыз.

# СОҢГЫ СӘЯХӘТ

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның рухи дөньясы чиктән тыш күп төрле вакыйгаларга бай һәм гаять катлаулы. Әдип тормышындагы халәтләрне тирәнрәк аңлау өчен аны чолгап алган мохитне, аның тормыш юлын тагын да ныграк өйрәнергә кирәк. Шуңа күрә Ф. Әмирханның Буага һәм Уфага бару вакыйгаларына тәфсилләбрәк тукталып узу файдалы булыр, дип уйлыйм.



Үзенең авыру булуына да карамастан, ул сәяхәт кылырга ярата, күбрәк кешеләр белән аралашырга тырыша. Язучының 1901 елда Идел буйлап сәяхәткә чыгуы белән укучы «Мөхәммәт Фатих ибне мелла Зариф Әльәмирханның юл истәлеге» дигән хикәя буенча яхшы таныш. Безне бу искиткеч талантлы каләм иясенең башка сәяхәтләре дә кызыксындыра, чөнки юл аның тормышын баеткан, киләчәк иҗаты өчен материал тупларга булышкан. 1914 елның 1 июнендә «Кояш» газетасында Ф. Әмирханның шундый юлга чыгуларыннан берсе — Буага килеп җитүе турында кыска гына хәбәр басылып чыга. Әмма кайда һәм кемдә тукталуы турында ләммим бер сүз дә юк. Кызганычка каршы, бу хакта язучының якын замандашларының нинди дә булса истәлекләре дә безгә килеп җитмәгән. Хәзер бары тик әдип биредә сәламәтлеген ныгыту өчен кымыз эчәргә килгәндер, бәлки, дип фараз итәргә генә мөмкин.

Ул вакытта татар интеллигенциясе вәкилләре Кырым яки Кавказ ял йортларына сирәк баралар, чөнки моның өчен акча күп кирәк була. Ләкин алар кымызның ифрат та шәп дәвалау сыйфатлары барлыгын анык беләләр. Мәсәлән, әдәбият сөючеләр Тукайның кымызга Уфа һәм Троицк якларына баруы белән яхшы таныш.

Бөек Октябрь таңы атканнан соң, егерменче еллар башында Ф. Әмирхан берничә мәртәбә Башкортстанга барып кайта. 1923 елда ул үзенең кымызы белән дан тоткан Кара Якуп авылында була. Юл уңаеннан Уфадагы танылган мәгърифәтче Р. Фәхретдинов өенә кереп чыга. Бу хакта Р. Фәхретдиновның кызы Әсма апа язган кызыклы истәлек тә бар.

Фатих Әмирханның 1924 елда Уфада булу вакыйгасы аерым сүз алып баруны таләп итә. Бу юлы ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе буенча элекке сабакташы Гарифҗан Мостафин өендә туктала. Бу иптәш үз вакытында шәкертләр арасында киң таралган

«Беренче садә» исемле революцион җырның авторы була. Бу баруында Ф. Әмирханның үзләрендә яшәвен Г. Мостафинның улы Искәндәр Мостафин яхшы хәтерли. Уфаның бу районында күп кенә татар һәм башкорт интеллигенциясе вәкилләре туплаңган була. Биредә шагыйрьләр С. Рәмиев, Т. Ченәкәй, С. Агиш, Р. Фәхретдинов, революционер Ш. Ходайбердин, журналистлар И. Рәми, И. Бураганский һәм башкалар яшәгән. Якында гына, шәһәрнең иң матур җирендә урнашкан, хәзер А. В. Луначарский исемен йөрткән бакча шәһәр халкының бик теләп ял итә торган урыннары булган. Шуңа күрә дә монда еш кына Ф. Әмирханны очратулары бер дә гаҗәп түгел. Сәйфи Кудаш үзенең «Онытылмас минутлар» дигән китабында күренекле әдип белән нәкъ шушы бакчада очрашуы турында сокланып яза.

Ф. Әмирхан белән Г. Мостафинның мәдрәсәдә бергә укыган көннәрдә башланган дуслыклары озак еллар буе дәвам итә. Ул вакыттагы кызыксынучан һәм гайрәтләре ташып торган шәкертләрне дәресләр өчен каралган программа канәгатьләндерми, билгеле. Алар революцион хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә булган «Мәркәз ислах комитеты» дигән оешма төзиләр, укуларындагы схоластик тәртипкә каршы чыгалар. Бу оешманың рәисе Фатих Әмирхан, секретаре Гарифҗан Мостафин була. Шәкертләрнең тормыш тәртибен яңарту уе, татар җәмгыятенең алдынгы көчләренә авазлаш булу теләге көн үзәгендә торган мәсьәләләр турындагы спектакльләрне куюэше белән дә мавыгырга өнди аларны. Бу турыда Ф. Әмирхан 1916 елда «Аң» журналында язып калдырган. И. Мостафинның әйтүенә караганда, аның әтисе, Мәҗит Гафури, танылган тел белгече Закир Шакиров якын дуслар булалар. Алар, билгеле, ки, Фатих Әмирхан белән дә бер генә сәгать аңгәмә кормаганнардыр. Мәгълүм булганча, һәммәсе дә бу өлкәгә зур өлеш керткән кешеләр бит. Шунысы бераз кызганыч: Ф. Әмирханның Мостафиннарда күпме вакыт булуын ачыклап булмады. Ләкин шулай да, якты йөзле хуҗалар кунакларын алай тиз генә озатмаганнардыр, дип уйларга тулы нигез бар.

Бу сәяхәт күренекле әдибебезнең Уфа каласына соңгы тапкыр баруы була.

**Эльмира ГОБӘЙДУЛЛИНА.**

*Искәндәр Мостафин фотосы.*

# ФАТИХ ӘМИРХАН ЯДКАРЕ

Мондый фоторәсемнең матбугатта элегрәк басылып чыкканы бар. Ләкин бу нөсхәнең артында әдипнең үз кулы белән язылган шундый юллар бар:

Хөрмәтле Фатимаи-Зөһрә туташка.

$19\frac{27}{1}17$ Фатих Әмирхан

**Мәңге гашыйк булма, күңел, айны, үзгәрт инде хәл;**
**Мәңгелек булмас матур төш, шагыйранә бер хыял.**

Мәңгелек түгел чәчәкләр дә — алар да шиңәләр.
Мәңгегә сайрамый кошчыклар, алар да туктыйлар.
Мәңгелек яз булмаган ул, җир йөзендә булмас ул,
Сүнмәс ул һич бер йөрәктә мәңгелеккә тормас ул.

Бу шигырьнең әдәбиятта күренгәне юк иде әле. Аны Фатих Әмирхан үзе язган булырга тиеш. Безнең башка прозаикларыбызның да аерым кешеләргә багышлап шигырьләр язганлыгы билгеле бит.






Кем соң ул Фатиман-Зөһрә? Ул Казанда татар демократ-яшьләре белән бергә беренче спектакльләрдә катнашып йөргән туташ. Шәриф Байчура үзенең «Татар яшьләре хәрәкәте һәм Фатих Әмирхан» исемле мәкаләсендә («Казан утлары», 1961, 1 сан, 118 бит) аны да искә ала. Совет чорында ул юрист булып эшләгән, Казанда вафат булган.

Тарих өчен аерым бәягә лаек бу фоторәсемне журнал редакциясенә Хәсән Габәйдуллин тапшырды.

# БИШЕНЧЕ ЕЛ ӘДИБЕ

Гасырлар аша сузылган татар әдәбияты берсе икенчесенә охшамаган, талантлы язучылар тезмәсен хәтерләтә. З. Һади да шундый якты маякларның берсе.

Закир Һади 1863 елда элекке Уфа губернасы Бәләбәй өязе Ярәмкә авылында урта хәлле крестьян семьясында туа. Аның әтисе, «Бәхетле кыз» повестендагы Ибәт агай кебек, кыш көннәрендә балалар укыта торган була. 12—13 яшьләренә кадәр Закир авылда үз әтисе мәктәбендә укый. 1875 елда аны Тымытык мәдрәсәсенә укырга илтәләр. Биредә ул ун ел укый. 1885 елда З. Һади бәхет эзләп Нижний Новгород шәһәренә барып чыга.

1882 елларда Бәкер әфәнде дигән укытучы Кырымда, Бахчасарай шәһәрендә, балаларны Төркия мәктәпләрендә башланган яңа ысул (ысул җәдит) белән укыта башлый. 1883 елда чыга башлаган «Тәрҗеман» газетасы яңача укытуны яклап аваз күтәрә. Касыйм (Ханкирмән) шәһәре янындагы Татарбай авылы мишәрләре, «Тәрҗеман»да укып, үзләрендә дә шундый мәктәп ачарга карар кылалар һәм укытучы табуда ярдәм сорап «Тәрҗеман» газетасына мөрәҗәгать итәләр. Укытучы табылмагач, әлеге Бәкер әфәнде Татарбайга үзе күчеп киләсе итә. Бер елга гына дип килсә дә, ул Татарбайда алты елга кала, шуннан соң да 25 ел буена Касыйм ягы авылларында яңа ысулны өйрәтеп, пропагандалап яши. Бәкер әфәнде мәктәбе Идел буе татарларында беренче яңа тип мәктәпләрдән иде. З. Һади Нижний Новгородта чагында шул мәктәп ачылу хәбәрен ишетеп, әлеге мәктәптә укырга китә. Ул Бәкер әфәнденең яңа ысул укытучылар хәзерләү курсын үтеп, шул яктагы Мулла дигән авылда укытучы булып эшли башлый. Шул рәвешчә, З. Һадига башлангыч елларыннан ук, яңа мәктәп өчен көрәш фронтының алгы сызыгында торып катнашырга туры килә.

1905 ел революциясе гөрелтеләре аны көрәш юлында икенче адым ясарга — кулына каләм алырга мәҗбүр итә. 1903 елда, кырык яшендә, ул үзенең «Бәхетле кыз» дигән беренче повестен яза. Аның әдәби иҗат эшчәнлеге революция елларына туры килә. Аны 1905 ел революциясе әдибе дип атарга була: революция җиңелү белән, иҗади үсешенең югары ноктасында, ул язудан туктый. Одесса, Харьков кебек Украина шәһәрләрендә яшәүче татарлар арасында укытучы булып яши. Октябрь революциясеннән соң туган авылы Ярәмкәгә кайта. 1921 елда тагын Касыйм ягына китә, Бимсала дигән авылда балалар укыта. 1932 елда шул авылда үлә.

З. Һади иҗаты әдәбият тарихында гаять үзенчәлекле күренеш. Аның мәгънәсен, үзенчәлекләрен шул тарихи чорны күз алдына китерү аша гына аңлап була.

Россия беренче рус революциясе алдына килеп баса. В. И. Ленин күрсәткәнчә, бу революциядә күп миллионлы «вак милләтләр» — «инородецлар» да мөһим роль уйнарга тиеш булалар. Алар, я консерватив көчләр кулындагы сукыр коралга, революциянe буучы көчкә әйләнергә, яки пролетариат ягына күчеп, революцион көчләр арсеналына әйләнергә тиешләр. Революция таңында татарлар арасында прогресс өчен, яңа мәктәп, европача культура өчен көрәш көннән-көн көчәя бара. Шул шартларда демократик әдәбият, революцион-демократизм идеологиясе югарылыгына күтәрелеп, халык массасына революцион аң тәрбияләүдә, халыкны кара көчләр кулыннан тартып алуда мөһим казанышларга ирешә. Ф. Кәрими, Р. Фәхретдинов кебек язучылар иҗатында консерватив феодаль көчләрнең йөзе фаш ителсә, Шакир Мөхәммәдев иҗаты татар буржуазиясен фаш итеп чыгарлык югарылыкка күтәрелә. Киң крестьян массасында прогресс өчен көрәш идеясен кабул итәрлек караш һәм

настроениеләр тәрбияләүдә З. Һади иҗатының да әһәмияте зур. Бу проблема әдип иҗатының төп пафосын тәшкил итә. Соңгы әсәрләренең берсендә бу максат ачыктан-ачык билгеләнә: «...Әүвәл, сөйләргә, халыкның фикерләрене төзәтергә кирәк: фикерләре үзгәргәч, эшкә килгәндә, эшләүчеләр дә булыр. Фикер үзгәрмәенчә, эш эшләнмидер. Шуның өчен дә, халыкка фикер бирмәк — бөек хезмәттән хисап ителәр; иң бөек адәмнәр дә — халыкка фикер биргән адәмнәрдер...»[1] Автор менә шул «бөек хезмәт»не башкару эшенә үзе дә зур өлеш кертә.

Киң катлау крестьян массасында «фикер үзгәртү» максаты автор иҗатының художество-стиль үзенчәлекләрен, композиция һәм идея-тематик структурасын билгеләли. Язучы чорның яңа идеяләрен, яңа әдәбиятның иң соңгы казанышларын киң катлау халык авырсынмый «йота алырлык» традицияләр белән кушып җибәрә ала.

З. Һади иҗатының конкрет эволюциясе әсәрләрендә ачык күренә. Аның беренче хикәясе — «Бәхетле кыз» — 1903 елда язылып, 1904 елда Оренбургта басылып чыга. Әсәр очерк рәвешендә башланып китә. Автор мәчете дә булмаган, халкы татар һәм башкортлардан торган бәләкәй, ярлы бер авылның иҗтимагый тормышын, социаль мөнәсәбәтләрне типик картиналар аша сурәтли. Әсәрнең персонажлары шул чор авылының типик вәкилләре булып хәтердә уелып калалар. Автор дөньяга яңача караш нигезендә, бу агайларның көнкүреш принциплары һәм дөньяга карашлары хата гына түгел, мәгънәсезлек үк икәнен дәлилле рәвештә фаш итә бара. Бала тәрбияләү, кыз балаларны укыту мәсьәләсе аеруча кискен куела. Автор шул чор авыл тормышындагы һәр күренешнең сәбәбен эзли, аны иң гади укучы да аңларлык, бәхәссез кабул итәрлек рәвештә ачып бирә. Ишан һәм муллаларның укыту, тәрбия системасын аеруча кискен тәнкыйтьли.

Әсәрдә гади авыл малае Габбасның яңа тип белемле кеше булып җитешү юлы сурәтләнә, наданлык йокысына чумган авылны хәрәкәт, яңару юлына чыгару өчен көрәше күрсәтелә. Габбасның Гайшә белән мәхәббәтләре, төрле интригаларны җиңеп чыгып кавышулары әсәрне мавыктыргыч сюжетлы итә.

Тиз темплар белән якынлашкан революция авторны ашыктыра, кискенләшә барган проблемалы әсәрләрен бер-бер артлы әдәбият мәйданына бирергә мәҗбүр итә. 1904—1905 елларда татар әдипләре арасында З. Һади аеруча активлык күрсәтә. Мәсәлән, бер 1904 елда гына да авторның дүрт әсәре («Хәер-дога», «Бәхетсез кыз», «Официант», «Идел буе») цензурадан үтә. Ә авторның 1905 елда язылган төп әсәрләре дөнья күрми юкка чыгалар. Бу хакта М. Х. Гайнуллин мондый мәгълүмат бирә: «1905 елгы беренче рус революциясе күтәрелешкә барган вакытларда З. Һади Одесса шәһәрендә яши... Бигрәк тә рус монархистлары тарафыннан Одесса шәһәрендә еврейларга каршы оештырылган погромнар аңарда зур нәфрәт уята. Истәлекләргә караганда, З. Һади патша хөкүмәтенең шул ерткычлыгын хикәя итеп озын гына бер повесть та язган була... З. Һадиның Рус-япон сугышы темасына язган зур күләмле бер поэмасы да булган, ләкин бу соңгы әсәрләрнең кулъязмалары сакланмаган»[2]. Ә 1906 елда язучының «Мәгъсум», «Мәктәп вә мулла, яхуд Миңлебай суфиның тәгълиме вә программасы» кебек әсәрләре китап булып чыга.

З. Һадиның бу чор әсәрләре сугышчан рух арта баруы белән характерлы. Автор революция юк итәргә тиеш искелекләрне күрсәтеп, демократик бурычларны билгеләп калыйм дигәндәй эш итә. Кайбер әсәрләрнең эшләнешендә бәлки ашыгу билгеләре дә үзләрен сиздерәдер. Әмма алар җитлеккән зур проблемаларны көн кайнарлыгын саклап яши алырлык рәвештә һәм шул көндә мәйданга куелулары белән әдәбиятыбызда уникаль ядкарьләр булып торалар.

Әсәрләрдә публицистика роле тагын да арта. Менә, мәсәлән, «Хәер-дога» хикәясе. Бирелә автор авыл муллаларының үз шәхси мәнфәгатьләре өчен халыкны алдап яшәүләрен билгели дә: «...бер адәм үз файдасы өчен күп адәмнәрнең һәлакенә сәбәп улса, ул адәм инсандан хисаб иделмәиб, фәкать инсан сүрәтендә улан хәйваннан хисап иделмәктәдер»,— дигән нәтиҗә чыгара.

«Официант» хикәясендә шул ук тема шул ук кискенлектә куела. Әмма әсәр бер урында таптану булып чыкмаган. Автор хикәясендә яңа герой, яңа социаль

---

[1] Закир Һади. Сайланма әсәрләр. Казан, 1957. 180 нче бит.
[2] Гайнуллин М., Закир Һади. Сайланма әсәрләр. 1957. 5—6 битләр.

типлар күрсәтә. Әсәр татар әдәбиятына өр-яңа тип — шәһәрләргә китеп эшләүче татарлар — «питрәйләр» (биредә, Петербургка китеп яллы эштә эшләүчеләр) темасын алып килә. Мәгърифәтче автор бу тип социаль катлауга «мәгърифәтле булу» программасын сызып күрсәтә. Петербургка барып официант булып урнашкан егет буш вакытын әчү, күңел ачу юлында түгел, ничек булса да белемен арттыру, уку дәртендә үткәрә, шуның чараларын таба. Өйдән әтисенең үлем түшәгенә егылуын ишетеп, авылга кайта. Шул уңай белән авыл мәзиненең тупаслыгы һәм наданлыгы, мулланың комсызлыгы бөтен шәрәлегендә фаш ителә. Әтисен күмгәч, дүртәүләп Питердан кайткан дусты Әхмәткә, икенче авылга чәйгә баралар. Анда шул тирәдәге муллалар, мәзиннәр турында белем-тәрбия эшенең чиктән тыш начар куелышы турында сөйләшеп утыралар. «Безнең татарлар,— ди автор,— башларыны, энҗе-җәүһәрләр илә, ялтыравыклы киемнәр илә зиннәтләп, адәмнәрне дә кием сурәтенә карап тәкъдир итәләр, үлчиләр. Әмма башка, мәдәниятле кавемнәр башларыны фәнун вә мәгариф җәүһәрләре илә, гәүдәләрене-әдәб, тәрбия, нәзафәт, нәзакәт илә зиннәтләп, адәмнәрне дә гыйлем, мәгърифәтенә карап тәкъдир итәләр, үлчиләр. Башында гыйлем вә мәгърифәт булмаган адәмнең башына, энҗеле түбәтәй өстеннән, алтын тас кидерсәң дә, гыйлем вә мәгърифәт илә зиннәтләнгән башның кыйммәтене тотмас. Башының, эчендәге зиннәт улмадыкта, тышындагы зиннәт илә кыйммәте артмас. Бер сумлык картус кигән рус башы йөз сумлык түбәтәй кигән татар башыннан артык эш күрәчәк...»

«Бәхетсез кыз» әсәрендә З. Һади шундый ук кисскенлектә кыз балаларны укыту мәсьәләсен куя. Белемсезлекне һәм шуңардан туган, шуның ышыгында яшәгән төрле иске гореф-гадәтләрне ул хатын-кыз бәхетсезлеге чыганагы, халыкның килэчәге — яшь буын өчен һәлакәтле нәрсәләр итеп күрсәтә. Бу әсәрдә дә публицистик үйлануларга киң урын бирелә. Әмма алдагы ике хикәясеннән аермалы буларак, биредә алар халык этнографиясе, халык көнкүрешеннән алынган типик эпизодлар белән өретелгәннәр.

...Шаулы революция еллары узып китә. Кара реакция көннәре башлана. Реакциянең беренче елында З. Һади «Яңа әсхабе кәһәф», «Җиһанша хәзрәт» повестьларын яза һәм 1908 елда бастыра. Бу повестьларда авторның үз иҗаты һәм гомумән, татар әдәбияты яңа югарылыкка күтәрелә. Авторның революция алды, революция елларында язылган хикәяләрендә идея, сюжеттан аерылып, публицист фикере итеп бирелә иде. Сюжет шул идеяләргә иллюстрация кебек бер нәрсә генә булып кала иде. Ә реакция чорында язылган әсәрләрендә автор инде идеяне үзе сөйләми, ул объектив тормышны, аның закончалыклары ачылырлык итеп сурәтләп күрсәтә.

«Яңа әсхабе кәһәф» повестенда Сәфәргали һәм Миңлешаһ дигән ике егет: «Бу начар тормыштан ничек итеп котылырга, үземезгә яхшы тормышны ничек итеп табарга?» — дип бәхет эзләргә чыгып китәләр. Юлда боларга кәтүче Тимербай һәм аның әте Сарбай иярә. Бер картның киңәше белән, болар Ташлы елга дигән авылга, ишан хәзрәтнең караңгы тау куышын хәтерләткән мәдрәсәсенә барып эләгәләр. Ул мәдрәсә — гаять тә осталык илә корылган бер рухи тозак, «шул тозакка адәмнәр үз ихтыярлары берлә килеп эләгәләр дә, тозак коручыларның әсире вә колы улып, үзләренең һәлакәтләрене сизмәенчә, йөрәкләре оеган кеби йокыга бирелеп үләләр...» Әлеге егетләрне дә ишан хак алмый эшләүче колларына әйләндерә: җәен үгез урынына эшләп, кышын укыгандай булып, шунда яталар. Сәфәргали 55 яшендә мәдрәсә курсын тәмамлагач, мулла итеп алмаслар микән дип авылына кайтса, шәкертлектә гомере үтеп китканлеге, үзе дөнья хәлләреннән, тормыштан коточкыч артта калганлыгы ачыла. Үзе бу фаҗигане аңлый алмаган карт шәкерт кире мәдрәсәгә кайткач, ютәл авыруы көчәеп, бер ай эчендә үлеп тә китә. Аның белән бәхет эзләргә чыккан башка иптәшләре дә шул тау куышы кебек мәдрәсәдән чыга алмыйча, шунда үлеп калалар.

Иске мәдрәсәне сурәтләүдә автор сатирик гомумиләштерү алымын файдалана. Әмма бу сатира билгеле бер күренешнең объектив мәгънәсен художестволы итеп күрсәтү чарасы гына, ул сюжет үсешенең үзеннән килеп чыга. Әсәрдә сюжеттан читкә китә торган бер генә деталь дә юк. Һәр образ, һәр сүз, һәр интонация теманы художестволы яктыртуга хезмәт итә.

«Җиһанша хәзрәт» — З. Һади иҗатының иң югары казанышы. Автор ишанлык кебек, сатира объекты булып калган күренешнең социаль йөзен, эксплуататорлык табигатен ачып күрсәтүне, аның фәлсәфи нигезләрен, иҗтимагый табигатен фаш итүне проблема итеп ала. Язучы гади крестьян малаеның дәһшәтле сорыкорт — ишан булып формалашу юлын реалистик планда һәм эзлекле күзәтә. Яңа дәвер ишаны Җиһаншаның буржуаз эшкуар булып җитешүен ачу — әсәрнең казанышы. Җиһанша, яшьтән үк, нәкъ Ницше философиясендәге индивидуалист кебек, эгоист, «сверхчеловек» буларак формалаша. «Җиһанша бигрәк тә үткен бер бала... адәм баласы булганлык сәбәпле адәм булуны... адәмнәрнең дә иң беренчесе булуны теләгән иде». «Безнең Җиһанша да үзен сөяр, каршысында булган нәрсәләрнең иң яхшысын үзенә сайлар, һәрвакытта үзенең башкалардан өстен булуын уйлар иде»,— ди автор. «Җиһанша, үзенең үткенлеге сәбәпле, мужик хезмәтендә булган мәшәкать белән муллалык хезмәтендә булган рәхәтне уйлап һәм үлчәп карый». Әтисенең һәм укытучы абыстайның: «Балам, тырышып кына укы, мулла булырсың!» — дигән үгет-нәсихәтләрен дә ул үзенчә аңлый, бар көчен, сәләтен, хәйләкәрлеген, осталыгын, намуссызлыгын шул максатка ирешү — мулла булу өчен файдалана. Үзенең конкурентларын (Таһирҗан хәлфә, Фәхретдин хәзрәт, Шәриф хәзрәтләрне) намуссызлык, мәкер белән читләштереп, ул һаман алга атлый. Теләгән һәр максатына ирешкән саен, Җиһаншаның да аппетиты арта бара. Бохарада укып кайта. Конкурентларын читләштереп, алга чыга. Ишанлык байрагын күтәрә. Үзенең интригаларына нарүне шәригать юлы дип күрсәтә. Мөритләр күбәйтә. «Фәкыйрь вә юзшләрне таяк берлә кыйнап, байларыны вә усалларыны бәддога берлә куркыта... Шулкадәр әхлаксызлык, тәрбиясезлек вә диваналыгы илә халык телендә «гайрәтле» хисап итәләр. «Бер адәмнең өч аты булса, берене — сәдакага бирергә, өч сыердан да — берене, вә башкача артык малларыны һаман сәдака кылырга боера». «Мөритләр исә андый сәдакаларны ишан хәзрәттән башкага бирүне теләмиләр». Хәзрәт «берничә йөз дисәтинә җирләрне дә, дога кылып осталык берлә» үз кулына кертә. Кыскасы, Җиһанша — халыкның мәктәпләр салырга, һөнәр һәм сәнгать уку йортлары ачарга, укучыларга һәм укытучыларга ярдәмгә тотылырга тиешле малларны, җиңел генә, бит сыпырып кына, үз кесәсенә җыеп ятучы эксплуататор. Ул шул шартларны мәңге саклау өчен бар көченә тырыша: һәр нинди яңалыкка каршы таш койма булып тора. Ул мәдрәсә тота, мәдрәсәсендә өч-дүрт йөзләп шәкерт укый, ә тирә-якта һәм үз авылында үз исемен яза белгән кеше бер-ике генә. Аның мәдрәсәсе илне, халыкны караңгылыкта калдыру юнәлешендә эшли. «Аның шәкерт җыюы, мәдрәсә каравы — җигәр өчен ат, савар өчен сыер, йон өчен куй асраудан аермасы юк иде»,— ди автор. З. Һади соңгы вакытта хәзрәткә каршы көчле хәрәкәт формалашуын да сурәтли. Яңа фикерле Хәсән мулла газета, китаплар укый, халыкны дөнья хәле белән таныштыра, Җиһанша хәзрәтнең илгә китергән зарарларын эзлекле рәвештә халыкка аңлата башлый. Өченче хатынлыкка Фәхрелбәнат дигән кызны яучылап йөргәндә, кыз хәзрәткә үтергеч җавап хаты язып, Хәсән муллага кияүгә чыга...

З. Һади кадимче ишаннар, хәзрәтләр образын сатирик сурәтләүне яңа югарылыкка күтәрә, аны реалистик социаль анализ белән баета. Авторның бу тип персонажларга реалистик социаль характеристикасы, шундый конкрет, шундый күләмле, шундый тулылыкта ки: аны бүген дә әле язучының үз сүзләрен файдаланмастан бүтәнчә төгәл биреп булмый. Бу — әдәбиятыбызның тормышны реалистик сурәтләүдә сүз — образларны төгәл үзләштерүе, тормыш күренешләрен художестволы социаль анализлауны үзләштерүе,— әдәбиятның критик реализмга күчүе иде. Реакция һөҗүмгә күчкән көннәрдә, идеологик таркаулык башланган чорда бу казаныш яңа революцион демократик әдәбият өчен: Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камаллар этабы өчен ныклы җирлек, мәгънәви таяныч, инде ярланган платформа булып калды.

Революция көннәрендә әдип иҗаты киң катлау татар хезмәт ияләрен революцион көчләр таянычы, союзнигына әйләндерү юнәлешендә эш алып барды, халыкка тормышны яңарту өчен көрәшү кирәклеген аңлатты. Менә шул казанышлары З. Һади иҗатын әдәбиятыбызның искермәс идея-эстетик кыйммәткә ия хәзинәсенә әйләндерә.

**Мәсгут ГАЙНЕТДИНОВ,**

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре.

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯЛӘР

Халык иҗатында кешегә акыл бирү нияте белән теге яки бу хәлгә бәйләп гыйбрәт итеп сөйләнә торган һәм әхлакый мәсьәләләргә багышланган кыска хикәяләр бар. Бу дөньякүләм фольклорда киң таралган күренеш. Славян халыкларының күпчелегендә ул жанр «притча» дип атала. Татарча аны «гыйбрәтле хикәя» дип йөртергә мөмкин. «Гыйбрәт» чыгышы белән гарәп сүзе булып, сабак мәгънәсендә йөри һәм сабак булырлык, уйланырга мәҗбүр итә торган берәр вакыйгага яки хәлгә карата кулланыла.

Безнең фольклор фәнендә «гыйбрәтле хикәя» (притча) жанры турында әлегә махсус сүз булганы юк кебек. Шулай ук гыйбрәтле хикәяләрне генә туплаган аерым җыентыкларның булмавын да әйтеп китәргә кирәк. Әмма моңа карап, гыйбрәтле хикәяләр бөтенләй басылмаган дияргә хакыбыз юк. Борынгы чыганаклардан алып егерменче йөз башына кадәр чыккан күп санлы фольклор китапларында бу жанрга караган әсәрләрнең «хикәятләр» исеме астында, гадәттә, әкият һәм мәзәкләр белән бергә урын алуын күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, Салихҗан Кукляшевның «Диване хикәяте татар», Таип Яхинның «Саби вә сабияләр өчен мәргуб булган хикәяләр вә мәкальләр һәм олугларны тәнбиһ өчен гаҗәиб булган гыйбрәтләр», Мелла Симругъ псевдонимы астында чыккан «һәртөрле хикәяләр», Каюм Насыйри төзегән җыентыкларда һәм төрле елларда чыккан «Кыйраәт китапларын»да гыйбрәтле хикәя үрнәкләре аз түгел.

Совет чорында исә бу жанрга караган текстлар я әкият, я мәзәк рәвешендә төрле җыентыкларда дөнья күргәләп киләләр. Мәсәлән, безнең карашка, Гомәр Бәширов төзегән «Мең дә бер мәзәк» җыентыгындагы кайбер текстлар гәрчә мәзәк җыентыгына кертелсәләр дә, жанр сыйфатлары ягыннан гыйбрәтле хикәяләргә карый. Гыйбрәтле хикәяләрнең мәзәкләр рәтендә йөрүенең төп сәбәбе итеп, беренчедән, жанрның өйрәнелмәвен, икенчедән, ул жанрларны якынайта торган уртак яклар булуын күрсәтергә кирәк.

Гыйбрәтле хикәя — дидактик характердагы, төп вазифасы үгет-нәсихәт, вәгазь бирүдән гыйбарәт булган жанр. Ул кешенең кимчелекләрен, җитешсез якларын төзәтүгә хезмәт итә. Мәзәкләрнең дә төп максаты тормыштагы, аерым кеше характерындагы кире сыйфатларны фаш итү, аларга каршы көрәшүгә кайтып кала. Ләкин әсәрдә сабак булырдай фикергә бу жанрның икесендә ике юл, ике ысул белән ирешелә. Мәзәкнең төп алымы көлү булса, гыйбрәтле хикәянеке — турыдан-туры үгетләү, вәгазьләү, нәсихәт бирү.

А. Яхин «Мәзәк жанрын өйрәнү» исемле хезмәтендә мәзәк төзелешенең һәрвакыт ике компоненттан торуын һәм аларның үзара капма-каршы мөнәсәбәттә булуын әйтә. Икенче компонентның вазифасы беренчесен инкарь итүгә юнәлтелгән була, диелә хезмәттә.

Гыйбрәтле хикәядә дә бер төшенчә ике өлешкә бүленә, әмма бу өлешләр мәзәктәге кебек бер-берсенә капма-каршы мөнәсәбәттә түгел, бәлки берсе икенчесен тулыландырып, дәвам итеп килә. «Әгәр син болай булсаң, ул вакытта менә нәрсә булачак» формуласына корыла гыйбрәтле хикәя. Бу формула логикада импликация дип атала. Моны раслаучы бер мисал китерик:

Карт бабай малаена:

— Мин картайдым инде, улым, үләрмен,— дигән. — Исеңдә тот, икмәгеңне гел балга манып аша.

— Ул кадәр байлыкны кайдан алырмын соң, әти? — дигән малае.

— Чын күңелдән тырышып, тир түгеп эшләсәң, икмәгең балга манып ашаган кебек тәмле булыр,— дигән атасы.

Карт улар алдыннан улына васыять итеп: «Тырыш бул, тырышсаң, тормышың бай булыр»,— дип әйтергә тели. Фикерен үтемлерәк итеп, улы гомере буена истә калдырырлык итеп әйтү өчен, сүзенең икенче өлешен беренчесенә караганда алдарак әйтә. Моның белән әйтелә башлаган фикергә серлелек бирә, шул юл белән кызыксыну уяна. Серне улы чишә алмый, әмма моның өчен ул хөкем ителми, ягъни, мәзәктәге кебек көлкегә калдырылмый. Чөнки әсәрдәге ике элемент капма-каршы мөнәсәбәттә түгел, берсе икенчесен раслап кына килә. Чагыштыру өчен тагын бер сюжетка тукталыйк.

Печәнгә киткәндә иренең «Иң тәмле ризыкны китерерсең»,— дигән сүзенә карап, хатыны болынга су алып бара. Әсәрнең беренче өлешендә «иң тәмле ризык» төшенчәсенең мәгънәсе ачык түгел. Хатын иң тәмле ризыкны белер өчен бик күп ашамлыклар пешереп карый. Шактый гына ризыкларны авыз итә-итә сусаган хатын өчен иң тәмле ризык су булып чыга. Ашаганнан соң су чыннан да тәмле. Әгәр бу әсәрнең икенче өлешендә, кырда бик нык эшләгән ир кеше өчен иң тәмле ризыкның нәрсә булуын аңлатып, нәтиҗә ясалып килгән булса ул гыйбрәтле хикәя булыр иде.

Гыйбрәтле хикәя жанрының тагын бер үзенчәлеген билгеләү өчен, аның мәкальләр белән булган бәйләнешенә тукталасы килә. Атаклы рус галиме В. Даль «Мәкаль— кечкенә генә притча» ди. Гыйбрәтле хикәядә әйтергә теләнгән фикер аерым мәкаль формасында да бирелә алыр иде. Бу ике жанр арасындагы аерма шунда ки: мәкаль әйберләр арасындагы нисбәтләр чагылышыннан гына торса, гыйбрәтле хикәядә исә шул нисбәтләр эпизодлар (алар ике яки берничә дә булырга мөмкин) аша бирелә-ләр, ачыкланалар. Шуңа күрә һәр гыйбрәтле хикәяне нинди дә булса мәкальнең киңәйтелгән тасвирламасы диярга була.

Гыйбрәтле хикәяләрне халыкның көнкүреш әкиятләре, тәгәлрәге, аларның гыйбрәтле сюжетларга нигезләнгән төркеме белән чагыштырмача якынлыкта карарга да була. Жанр сыйфатлары ягыннан гыйбрәтле хикәя булган аерым текстларның әүвәл-әүвәлгедән көнкүреш әкиятләре рәтендә йөрүе юкка гына түгел. Чөнки әкияткә дә һәм гыйбрәтле хикәягә дә гыйбрәтлелек хас, аларның һәркайсында гыйбрәтле нәтиҗә бар. Бирелә һәр жанрның поэтик алымнарыннан башка аның үтәгән функциясен дә истән чыгармаска кирәктер. Әйтик, әкият, нигездә, мавыктыргыч, күңел ачу нияте белән сөйләнә яки укыла. Тыңлаучы яки укучы аны реаль тормыштан аерып, «әкият» буларак кабул итә, гыйбрәтле хикәя исә тормыш ситуациясе белән тыгыз бәйләнештә тора, һәм шуңа күрә тыңлаучының мөнәсәбәте аңа үзгәрәк, җитдирәк.

Ниһаять, гыйбрәтле хикәяләрнең язма әдәбият белән бәйләнеше турында да берничә сүз булса да әйтергә кирәк. Әхлакый нәсихәткә һәм дини дидактикага корылган гыйбрәтле хикәяләрнең аерым үрнәкләре әле бик борынгы заманнарда ук мәгълүм була. Аларның бер өлеше дини китапларда — «Инҗил», «Тәүрат», «Коръән» битләрендә урын алса, икенчеләре аллегорик формада мәсәл жанрына якынайтылып, һиндларның «Панчатантра», гарәпләрнең «Кәлилә вә Димнә»ләрендә күп очрый. Безнең урта гасыр татар әдәбиятына караган әсәрләр тукымасында да гыйбрәтле хикәяләр байтак. Мәсәлән, Мәхмүд бине Галинең «Нәһҗ эл-фәрадис», Сәйф Сарайның «Гөлстан» әсәрләрен мисалга китерергә мөмкин.

Әмма бу хакта аерым тикшеренүләр сорала.

Гомуман алганда, гыйбрәтле хикәя жанры татар фольклор фәнендә башка традицион жанрлар белән беррәттән һәм тарихи, һәм поэтик яктан өйрәнелергә хокукы булган жанр дип әйтәсе килә.

«Гыйбрәтле хикәя»ләрнең кайбер үрнәкләре Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында саклана. Шуларның берничәсен журнал укучылары игътибарына тәкъдим итәбез.

**Әсия САДЫЙКОВА,**
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре.

# Ялганчы кол

Кол билэү дэверендэ берэү базардан кол ала. Колны сатучы:

— Колның башка гаебе юк, лэкин ялганчы,— ди. Алучы, ялганлаудан гына нинди зыян булсын, эшен эшлэсэ, шул житэ дип, колны ала. Кол боларга килеп тора башлагач, хуҗаның хатынына:

— Синең ирең икенче хатын белэн йөри, сине яратмый,— ди. Хатын колдан яраттыру турында киңэш сорый. Кол аңар:

— Син аның сакалыннан төк кисеп ал да шуны яныңа тагып йөр, шуннан соң яратыр,— ди.

Кол ирне күреп:

— Сине хатының үтерергэ йөри, саклан,— ди.

Ир хатыныннан сакланып йокламый башлый. Беркөн хатын пычак ала да иренең сакалыннан төк алырга килэ. Ир, суярга тели дип белеп, хатынын үтерэ. Бу хэбэрне ишетеп, хатын кабилэсе килэ дэ ирне үтерэ.

Шулай итеп, ялганчы кол аркасында икесе дэ дөньядан китэлэр.

# Аш ашка — урыны башка

Элекке заманда бай урамнан узып баручы хэерчене өенэ чакырып кертэ дэ, моңа ашарга бирэ. Хэерче ашый, туя. «Туйдыңмы?»— ди бай. — «Туйдым»,— ди теге. Бай хэзер икенче төрле, тэмлерэк ризыклар китерэ. «Аша»,— ди. Хэерче тагын ашыйашый да: «Туйдым»,— ди. Бай өченче төр азыклар китертэ. Тагын шул хэл кабатлана. Бай сорый гаҗэплэнеп:

— Менэ син өч мэртэбэсендэ дэ туйдым дип эйттең. Ничек болай була инде ул? — ди.

Хэерче бер кисмэк китертергэ кушкан. Кисмэкне таш белэн тутырткач, байдан сораган:

— Тулдымы? — дигэн.

— Тулды,— дигэн бай.

— Ком китерт,— дигэн хэерче. Комны бу таш араларына тутырткан да:

— Тулдымы? — дигэн.

— Тулды! — дигэн бай.

— Су китерт! — дигэн хэерче. Суны кисмэккэ сала да:

— Тулдымы? — ди.

— Тулды,— ди бай.

— Тулса, менэ шул,— ди хэерче.— Аш ашка — урыны башка.

# Мин акчамны өчкэ бүлэм

Бер кешедэн сорыйлар икэн, алган акчаңны нэрсэгэ туздырасың дип.

Теге кеше:

— Акчамны өчкэ бүлэм. Бер өлешен койма аша атам. Бер өлешен бурыч түлим. Бер өлешен бурычка бирэм,— ди икэн. — Койма аша атам диюем, кызлар тэрбиялим. Алар миннэн китэчэклэр. Бурыч түлим дидем, эти-энилэр мине ашатып, эчертеп, укытып, киендереп үстергэннэр. Хэзер мин аларны тэрбиялим. Бурычка бирүем, балалар үстерэм. Ашатам, киендерэм, укытам, килэчэктэ мине дэ улларым тэрбиялэрлэр дип уйлыйм.

## Күпне көтеп, аздан коры калу

Ике ярлы туган кәсепкә тотынып, берсе чүлмәк сата, икенчесе пыяла куючы булып, яхшы гына баеп китәләр. Чүлмәкче кыйммәтле савыт-сабалар сәүдәсенә керешеп, пыялачы кыйммәтле көзгеләр сата башлый. Беркөн болар акчаларын бүлешеп беткәннән соң, бер потлы иске гергә калгач, гауга кубаралар. Чүлмәкче:

— Гер миңа тиеш, аны мин алдым,— ди.

Көзгече:

— Миңа тиеш, миңа ул әтидән калды.

Берсе тарта, икенчесе җибәрми, өсләрен ертып бетерәләр.

Ахырдан пыялачы:

— Мә, башыңа яп,— дип чүлмәкченең кыйммәтле савыт-сабаларына ыргытып, челпәрәмә китерә.

Чүлмәкче тиз генә герне барып ала да көзгеченең дә кыйммәтле көзгеләренә атып бәреп, көл итә. Кыйммәтле малларыннан һичбер нәрсәләре калмый. Үзләре әүвәлгедән дә ярлы калып, көнлекләп хезмәт итәргә керешәләр.

## Күршеләр җибәрсә, барырбыз

Борын заманда ирле-хатынны бик ярлы кешеләр яшәгән. Беркөн боларны кунакка чакырырга килгәннәр.

Хатыны:

— Күршеләр җибәрсә, барырбыз,— дигәч:

Ире:

— Әй, карчык, син ни сөйлисең? Бездә күршеләрнең ни эше бар,— ди икән.

Боларга кунакка барыр вакыт җитә. Киеп барырга киемнәре булмагач, күршеләреннән сорыйлар. Күршеләре:

— Үзебезне дә чакырганнар иде, үзебез дә барасы идек шул,— диләр.

Инде кунакка киеп барырга кием тапмагач, баралмый калалар. Шуннан соң хатыны иренә:

— Син, минем күршеләр җибәрсә барырбыз дигән сүзгә ышанмаган идең, инде күрдеңме, күршеләр җибәрмәде бит,— дигән.

# БАТЫР МӘЙДАНДА ЧЫНЫГА

Безнең илдә спортта ирешелгән уңышларга һәркем куана, абыну-сөртенүләргә яше дә, карты да көенә. Европа һәм дөнья беренчелегенә барган ярышларны төн уртасына кадәр телевизордан карап утырабыз икән, димәк, без совет спорты данын яклаучыларга җиңү телибез. Спортчылар исә безне күп очракта шатландыралар. Бар безнең мактанырлык уңышларыбыз!

Ә Татарстан спортчылары илебездә мәйдан тотучылар сафындамы? Республикабызда физкультураны һәм спортны тагын да үстерергә нәрсәләр комачаулый?

Шушы мәсьәләләрне журналыбызда яктырту максатыннан, язучы **МӘГЪСҮМ ХУҖИН** Татарстан АССР Министрлар Советы каршындагы Физик культура һәм спорт комитеты председателе урынбасары **ИЛДАР НАСЫЙРОВ**тан интервью алды.

Язучы. Илдар Ибраһимович, безнең бу әңгәмә мәйданда алышуны хәтерләтсен иде! Шуңа күрә, спорт комментаторлары әйтмешли, һөҗүмне разведкасыз башлыйм. Һәм менә беренче сорау. Безнең республикада физкультура һәм спорт ни өчен канәгатьләнерлек түгел?

Илдар Насыйров. Алышуны болай, баштан ук, Сезнең җиңү белән тәмамлап куюю дөрес булмас, минемчә. Ни өченме? Беренчедән, без спорт өлкәсендәге уңышларыбызга күз йомган булыр идек. Бу исә, белгәнебезчә, эшкә бәя биргәндә берьяклы фикер йөртүгә китерә. Икенчедән, һөҗүмнән сакланырга ышанычлы калкан булырдай дәлилләрем бар.

Язучы. Сакланыгыз!..

Илдар Насыйров. Соңгы биш елда Татарстан РСФСР күләмендәге ярышларда дүрт тапкыр күчмә Кызыл байрак алды. Җитмештән артык коллектив арасында яулаган җиңүләр болар!

Инде килеп, республикабызда ел саен өч йөз илле меңнән артык кешенең ГТО нормалары тапшыруын, шул кадәр үк разрядлы спортчылар әзерләнүен әйтик. Һәр елны өч мең ярым — дүрт мең кеше беренче разряд яки спорт мастерлыгына кандидат нормасын үти. Алтмышынчы елларда мастерларыбыз саны елына 30—35 кешегә арта иде. Җитмешенче еллар тагын да уңышлырак булды. Мәсәлән, 1978 елда — җитмеш алты, 1979 елда туксан алты спорт мастеры әзерләнде. 1980 елда мондый осталарыбыз бер йөз унбиш кешегә ишәйде. Былтыр исә җитмеш бер спортчыбыз мастер исеме алды. (Сүз арасында искәртим, бу күрсәткеч нормативларның үзгәрүе нәтиҗәсендә дә кимеде.) Узган ел тугыз якташыбыз халыкара класслы спорт мастеры дәрәҗәсенә күтәрелде. Ә Тәтеш кызы Светлана Якимова СССРның атказанган спорт мастеры исеменә лаек булды. Ул стендта ату буенча Аргентинада үткәрелгән бөтендөнья беренчелегендә алтын медаль яулады. Тәтеш атучылары, Казан фехтование осталары Татарстан спортын дөньякүләм аренасына чыгарды!

Язучы. Болар — сөенеч. Шулай да җавабыгыз мине сыртым белән җиргә сыламады. Моны, кеше биленә сөлге сала белмәсә дә көрәш мәйданына чыккан беркатлы агай үҗәтлеге, дип санамагыз. Әгәр бу әңгәмәдә Сез мине «егасыз»

икән, мин шатланырга да әзер. Тик әлегә... беренче сорауга биргән җавабыгызга тагын нәрсә өсти аласыз? Бездә спортның кайсы төрләре бигрәк тә артта кала?

**Илдар Насыйров.** Әйткәнемчә, республикада спортны канәгатьләнмәслек дип бәяләү дөрес түгел. Минемчә, сүз аның үсеш темпы турында булырга тиеш. Безне шул канәгатьләндерми. Илебез һәм дөнья күләмендә дан казанган спортчыларның исемнәре журнал битенә сыймас иде. Үсешнең һәр өлкәдә кануны бер — алга карап эш итү. Спорт белән һәркем шөгыльләнсен, талантлы спортчыларыбыз тагын да күбрәк булсын — республика комитеты менә шушы максатны алга сөрә.

Инде кайсы төрләрдә артта калабызмы? Ат спорты, теннис, җәядән ату, бокс, футбол... Саный китсәң, шактый җыела, әлбәттә.

Әмма бер нәрсәне онытмыйк: спорт белән шөгыльләнү һәркемнең үзенә бәйле. Әйтик, иртән йөгерү белән берәүгә дә берни дә комачауламый, моның өчен кемнеңдер үгетләвен көтәргә кирәкми. Урамнар киң, сквер-парклар җитәрлек — йөгерә бир!

Буш вакытны спорт мәйданчыгында яки залында уткәрү файдалы. Шулай да кайберәүләр сыраханә яки кафе төбендә «каравыл торалар». Җаваплылыкны үз өстебездән төшерү булып аңлашылмасын, шулай да һәркемне спортка тарту республика комитетының гына түгел, ә бөтен җәмәгатьчелекнең бурычы. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, спорт белән шөгыльләнүче эшченең хезмәт житештерүчәнлеге, физкультурага йөз чөерүчеләргә караганда, биш-ун процентка артыграк. Менә ул — хезмәт белән спортның уртак нәтиҗәсе!

Яңа төзелә торган йортлар тирәләрендә спорт мәйданчыклары ясала. Тик аларның торышына күз салыгыз: кемдер анда келәм кага, кайсыдыр волейбол баганаларына кер бавы тарттырган... Үзебез хуҗа була белмибез бу мәйданчыкларга. Шунысын да әйтим, аларны төзегәндә үк кайбер нәрсәләрне онытабыз. Чишенү, коену-юыну (җәен) урыннары булса, анда барасы килеп торыр иде.

**Язучы.** Югары күрсәткечләргә ирешү өчен, спорт корылмаларының әйбәт һәм кирәкле санда булуы шарт. Бу мәсьәләнең спортчыларны гына түгел, ә спорт сөючеләрне дә (ягъни тамашачыларны да) кызыксындыруы аңлашыладыр. Шуннан чыгып, икенче сорау: республикада стадионнар, спорт мәйданчыклары һәм заллары, йөзү бассейннары һәм башка корылмалар җитәрлекме?

**Илдар Насыйров.** Хәзерге вакытта республикада 27 стадион, 1006 зал, 10 йөзү бассейны, ике спорт сарае һәм бик күп башка корылмалар бар. Җитәрлекме болар? Минемчә, спорт белән шөгыльләнүчеләр һәм шөгыльләнергә теләүчеләр зарланмас. Татарстанның барлык шәһәрләрендә соңгы елларда әйбәт спорт корылмалары файдалануга бирелде.

Дөрес, йөзү бассейннары аз. Хәзер бу кимчелекне бетерү өчен дә тырышабыз. Әлмәт, Алабуга, Лениногорск, Бөгелмә, Брежнев шәһәрләрендә соңгы елларда салынган бассейннарны уңай бәялиләр йөзәргә яратучылар. Спорт комитеты республикада йөзә белмәүче кеше булмасын, дигән бурыч куйды.

Зеленодольскида төзелә торган уку-спорт базасы заман таләпләренә җавап бирәчәк. Унберенче бишьеллыкның һәр елында республикада 40 спорт залын файдалануга тапшыру планлаштырылган иде. Һәм бу план үтәлә. Быел, мәсәлән, 48 зал сафка керәчәк. Моның аз түгеллеге белән килешәсездер, шәт? Тормыш таләбе зуррак, әлбәттә!

**Язучы.** Инде дә килеп, бу корылмаларның сан исәбендә генә йөртелгән нәрсә юкмы? Әйтик, Казандагы «Хезмәт резервлары» һәм «Спартак» стадионнарында нинди ярышлар уздырыла? «Рубин» стадионын тулы бер спорт комплексына әйләндерү тагын күпмегә сузылыр? Заманында туплы хоккей буенча илебез күләмендәге ярышлар уздырылган (анда Казан командасы да катнаша иде) «Динамо» стадионы кайчанга чаклы ярым ташландык хәлдә булыр?

Предприятиеләрдә, ирекле җәмгыятьләрдә спортчылар өчен мөмкинлекләр тудырылганмы? Тагын атап сорыйм. Воровский исемендәге спорт клубында кул тубы белән шөгыльләнергә шартлар бармы? Мөмкинлекләр һәм шартлар турында сөйләгәндә, авылларны да истә тотсагыз иде! Авылда спорт эшен яхшырту буенча нинди чаралар күрелә?

**Илдар Насыйров.** Спорт корылмаларының торышы, барлык эштәге кебек, аның хуҗасы нинди булуга бәйле. Сез телгә алган стадионнарга барып килик.

Алар турында атап соравыгызның сәбәбен аңлыйм. «Динамо», «Спартак» һәм «Хезмәт резервлары» стадионнары заман таләпләренә җавап бирми. «Хезмәт резервлары»на капиталь ремонт кирәк.

«Динамо» һәм «Спартак» стадионнары үзгәртеп төзеләчәк. Ниһаять, күп еллар буена ярым ташландык хәлдә булган «Спартак» стадионына хуҗа табылды. Аны тәртипкә китерүне Татарстан транспорт идарәсе үз өстенә алды. Дөрес, бередә меңнәрчә тамашачы өчен трибуналар булмаячак. Спорт белән шөгыльләнүчеләр санын ишәйтүдә, беренче чиратта, футбол кырының, йөгерү юлларының, җиңел атлетиканың башка төрләре буенча күнегүләр һәм ярышлар үткәрү мәйданчыкларының әйбәт хәлгә китерелүе әһәмиятле. Билгеле, стадионны яңартканда, тамашачылар турында онытылмаячак. Югыйсә, бер мең ярым да (моны сы авыл җирләре өчен дә) тамашачыга трибуналары булмаган корылма стадионга саналмый бит.

«Рубин» стадионын реконструкцияләү нигездә тәмамланды, анда футбол буенча илебез беренчелегенә ярышлар да уздырылды. С. П. Горбунов исемендәге авиация производство берләшмәсе стадионны әйбәт тотуга чын хуҗаларча карар дип ышанабыз.

Кайбер спорт корылмалары тулысынча файдаланылмый, бу хәл безне дә нык борчый.

Предприятиеләрдә спорт сөючеләргә шартлар тудырылганмы? — дисез. Завод-фабрикаларда, югары һәм урта уку йортларында спорт корылмалары бар. Воровский исемендәге спорт клубында һәм предприятиедә барлык хезмәт һәм эшчеләр диярлек физик чыныгу белән шөгыльләнә. Берләшмә җитәкчеләре атнаның бер көнен сәламәтлек цехында, ягъни спорт корылмаларында, пионер лагерьларында булудан, мондагы эшләрне оештыруда практик ярдәм күрсәтүдән башлыйлар. Күпләр өчен әйбәт үрнәк бу!

Ә клубның кул тубы командасы ил чемпионатының икенче лигасында уңышлы гына уйный, беренче лигага чыгу өчен көрәшә. Берләшмәнең кул тубы уеннары өчен җайлырак, зуррак зал булдыру турында уйланабыз.

Сез хаклы: авылда спорт корылмалары аз, булганнарының да күбесе начар хәлдә, баганасына кәҗә бәйләнгән волейбол мәйданчыклары да юк түгел.

Республика һәм район комитетлары, колхоз-совхозлардагы физкультура коллективлары җитәкчеләре тиешле дәрәҗәдә эшләмиләр. Бу кадәресе бар. Шулай да...

Авыл җирләрендә әйбәт стадионнар булмауда таякның юан башы урындагы җитәкчеләргә төшә түгелме соң?! Ни өчен әле район яшьләре спорт корылмаларын үзләре төземәскә тиеш ди? Минемчә, башлап йөрүче булса, авыл җитәкчеләре барча ярдәмне күрсәтерләр иде. Димәк, инициатива кирәк. Стадионны төзеп биреп, яшь егетне һәм кызны, спортта катнашучылар санын ишәйтү өчен генә, йөгерү юлына җитәкләп алып керү заманнары узды.

Һәм авылдагы ярышларда җиңүдән башлаган яшьләр, киләчәктә район, республика күләмендә көч сынашу өчен, белемнәрен күтәрергә, яхшы эшләргә, осталыкка омтылалар. Кешенең рухи үсешенә, физик чыныгуга спортның ярдәме менә шунда күренәчәк. Кабатлап әйтәм, туган авылында спорт белән мавыгырга тулы уңайлыклар юк икән, моның сәбәбен яшьләрне оештыра белмәүдән эзләргә кирәк.

Спорт сөючеләрнең инициативасы турында бер генә мисал. Былтыр республикабыз башкаласында икенче трамплин сафка басты. Аны спортчылар үзләре күтәрде! Әйбәт үрнәк. Ә авыл җирендә (һәм шәһәрләрдә дә) стадионнар төзүдә яшьләр үзләре тир түксәләр, алар спорт корылмаларын сак тотуда да хуҗаларча кайгыртырлар иде. Халкыбызның борын-борыннан килгән матур гадәтен онытмаска кирәк — спорт корылмалары салуда өмәләр оештырмаска икән!

Бер куанычлы хәлне искәрик. Хәзерге Культура сарайларында спорт заллары да була. Республика матбугатында бу хакта хәбәрләр дә бирелде.

Язучы. Мин Азнакай районының Карамалы Культура йортында спорт залы булуын беләм. Көндезен ул мәктәп балалары карамагында, кичен аңа яшьләр хуҗа. Шул ук районның «Октябрьның 50 еллыгы» колхозы үзәгендә дә, сигезьеллык мәктәп белән берләшеп, спорт залы төзеләчәк...

Илдар Насыйров. Димәк, авылда кышын спорт залында күнегүләр һәм ярышлар уздырырга мөмкин, авыл спортчыларының осталыгы даими үсәчәк, дигән сүз.

Әлбәттә, авыл спорты бөтенләй начар, дип нәтиҗә ясарга ярамый. Узган ел Мамадыш районында, мәсәлән, кырыктан артык ярыш уздырылды. Мамадышның үзендә спорт мәктәбе бар. Арча районындагы һәр авылда диярлек волейбол мәйданчыгы (184) бар.

Бу соравыгызга җавапны кайбер гомуми саннар белән тәмамлыйм. Хәзер авылларда — 491 спорт залы, 12 чаңгы базасы, 182 ату урыны исәпләнә. Болар — таләпләргә тулысынча җавап бирә торганнары. Ә авылларда стадионнар юк. Дөрес, футбол кыры, йөгерү юллары һәм башка секторлары булган корылмалар бар барын. Әмма стадион исемен алу өчен, әйткәнемчә, аның әле кимендә, бер мең ярым тамашачыга чамаланган трибунасы һәм башка уңайлыклары да булырга тиеш.

Авыл җирләрендә өч йөз меңнән артык кеше спорт белән даими шөгыльләнә.

Язучы. Безнең буын кешеләре «Шара-кәшә», «Чебенле» һәм башка уеннарны хәтерлиләр. «Шара-кәшә» уенының чирәмдәге хоккейга, ә «Чебенле» уенының (монысын төрле якта төрлечә атыйлар. Бу уен турында мин «Ялкын» журналында басылган бер хикәямдә язган идем) бура уенына охшашлыгы бар. Шулай итеп, өченче сорау: Халкыбызның борынгыдан килгән уеннарын оныттырмау өчен, спорт комитеты нәрсәләр эшли?

Илдар Насыйров. Дөресен әйткәндә, бу өлкәдә, татарча көрәшне исәпләмәгәндә, җитәрлек эш алып барылмый. Көрәштә исә уңышларыбыз шатланырлык. Татарстан командасы РСФСР күләмендә ел саен беренче яки икенче урыннарны ала. Ә татар халкының башка кайбер уеннарын сабан туйларында гына күрәбез. Димәк,— безнең эшләп җиткермәү. Киләчәктә татар халкының спорт уеннарын яңадан җәелдерү буенча нәтиҗәле эш башларга кирәк.

Халыкның матур традицияләрен баетуга, коммунистик тәрбиядә спортның роленә партиябез аеруча игътибар бирә. Партия Үзәк Комитетының «Физик культура һәм спортның массовыйлыгын тагын да күтәрү турында»гы карарында (1981 ел) спортның массовый төс алуына, аның милли төрләрен үстерүгә аеруча басым ясап күрсәтелә. Чөнки борынгыдан килгән уеннар яхшы традиция бит. Хәзер республикада сабан туйларын ярышлар комплексы итеп уздыруны максат итеп куябыз. Көрәш, бау тарту, гер күтәрү, капчык белән «сугышу» һәм башка уеннарның уртак кагыйдәләре эшләнә. Аларны ветеринария институтының физик тәрбия кафедрасы мөдире, РСФСРның атказанган тренеры Магаз Сәхабетдинов белән мин бергәләп төзибез. Ат чабышы буенча методик күрсәтмәләр басылды инде. Шулай әйтергә ярасә, киләчәктә сабан туеның спорт ярышлары өлеше авыл, район спартакиадасы төсен алачак. Сабан туена кешеләр физик культура белән даими шөгыльләнеп, чыныгып килсен. Бу исә, беренчедән, язгы эшләр бетеп, урып-җыюга әзерләнгәндә көч тупларга бер этәргеч булса, икенчедән, сабан туе мәйданнарында без булачак мастерларны табарбыз. Ә моңа мисаллар бар. Самбо буенча спорт мастерлары алты бертуган Мадьяровлар, мәсәлән, олы спортка юлларын сабан туйларында көрәшүдән башлаганнар иде. Спорт һәм халыкның милли уеннары турында күптән түгел чыгарылган «Халык һәм спорт уеннары» дигән китапның (Сез әйткән уеннар турында да язылган анда) безгә пропагандада һичшиксез ярдәме тиячәк. Димәк, мәйдан киңәер, ягъни хезмәт батыры спорт мәйданында да чыныгыр!

Язучы. Олы спортка юл балачактан башлана, дибез. Сезгә билгеле булганча, Одессадагы «Тополек» балалар бакчасында, илебездәге мәктәпкәчә балалар учреждениеләрендә беренче буларак, «Шахмат клубы» ачыла. Һәм нәни шахматчылар, беренче-өченче класс укучыларының шәһәр күләмендә команда

ярышларында катнашып, җиңеп чыгалар. Белергә теләгәнем — тагын менә нәрсә. Республика комитеты балаларда спортка мәхәббәт тәрбияләүдә Мәгариф министрлыгы белән кулга-кул тотынып эшлиме?

Җавабыгызда физкультура укытучылары, тренерлар хәзерләү, аларның ничек һәм кайда эшләве, фәнни эшнең торышы турында да әйтсәгез иде!

Илдар Насыйров. Мәгариф министрлыгы һәм ирекле спорт җәмгыятьләре системасындагы 86 спорт мәктәбендә 45 меңләп бала укый. Татарстан спорт комитетының 3 югары спорт осталыгы мәктәбендә 500 ләп кеше 13 төр буенча осталыгын күтәрә. Мәгариф министрлыгы белән элемтәбез әйбәт.

Казан шәһәренең кайбер мәктәпләре физкультура дәресләрен йөзү бассейннарында үткәрәләр. Лениногорскида йөзә белмәүче укучылар юк. Брежнев шәһәрендәге 25 балалар комбинаты бассейннарында нәниләр йөзәргә өйрәнә. Болар — Мәгариф министрлыгы белән спорт комитетының йөзә белмәүчелекне бетерүдә бергәләп эшләве нәтиҗәсе.

Спорт мәктәпләрендә укыту-тәрбия эшен нык яхшыртырга кирәк. Кадрлар җитми, аларның биштән бер өлешенең диярлек махсус югары яки урта белемнәре юк. Россия федерациясе күләмендә дә хәл шулай. Республикада ел саен дүрт йөз чамасы белгеч әзерләнә, аларның йөзе генә бүтән өлкәләргә җибәрелә. Эшсез йөрүчеләрне белмим мин.

Барлык югары уку йортларының физик тәрбия кафедраларында фәнни эш алып барыла. Университет, авиация, химия-технология, педагогия институтларында һәм физкультура институтының Казан филиалында бүгенге бурычларны хәл итүгә аеруча игътибар ителә.

Язучы. Татарстанда тәрбияләнгән күренекле спортчылар аз түгел. Танылган якташларыбыз бездән китмиме?

Илдар Насыйров. Бәхеткә каршы, дөнья күләмендә уңышка ирешкән спортчыларыбыз соңгы елларда бездән китмиләр. Нигә китсеннәр алар? Татарстанда яшәп тә илебез данын бөтендөнья ярышларында яклап була бит. Фехтование чемпионнарыбызны искә төшерегез! Атказанган спорт мастеры Наилә Гыйлаҗева былтыр Италиядә шәхси беренчелектә алтын медаль яулады.

Спортчыларны зур ярышларга ныклап әзерләү, матурлап озату, олылап каршылау бездә матур гадәткә әйләнде. РСФСР халыклары спартакиадасында катнашкан җыелма командабыз членнары өчен махсус истәлек чыгардык һәм вымпел эшләдек. Дөнья күләмендә җиңүгә ирешкән спортчыларны республика җитәкчеләре кабул итә. Шундый әйбәт мөнәсәбәт булганда, нигә китәргә? Әле китүчеләр дә кире кайта. Спорт мастеры Геннадий Маслов берничә ел югары лига командалары составында уйнаган иде. Узган сезонда ул Урицкий исемендәге клуб командасында чыгыш ясады. Әгәр безнең хоккейчылар беренче лигадан дүрт команда арасында югары лигага чыгу өчен көч сынашканнар икән, монда тәҗрибәле спортчыларыбызның да өлеше зур, минемчә.

Ә кайберәүләрне үзебездә бәйләп тоту урынсыз да булыр иде. Виктор Колотовка, мәсәлән, зуррак мәйдан кирәк иде, һәм ул Киев «Динамо»сының халыкара ярышларында да совет футболы данын күтәрү өчен тырышып уйнады. Нил Фәсәхов волейбол буенча СССР җыелма командасы капитаны, Олимпия уеннары чемпионы булды. Хәзер ул үзе тренер.

Танылган спортчыларга республикабызда хөрмәт зур. Менә мисаллар: Р. Нәҗметдинов мемориалы, А. Курынов истәлегенә Бөтенсоюз ярышлары, Зеленодольск районында һәр елны В. Колотов призына көч сынашулар...

Лениногорск һәм Әгерҗе районнары спортчылары батыр якташыбыз Газинур Гафиятуллин призына ярышларда теләп катнашалар. «Социалистик Татарстан» газетасының Муса Җәлил исемендәге зур призына татарча көрәш күпләрне кызыксындыра... Җыйнап әйткәндә, Татарстан спортчылары, күренекле якташларыбызга атап, 180 призга хуҗа булу өчен ярышалар. Сүз уңаеннан әйтим, кандидатлык диссертациямнең бер бүлегендә мин герой якташларыбыз призына ярышларның яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү чарасы булуын конкрет нигезләргә тырыштым.

Язучы. Авыл сабан туен күз алдына китерик әле. Яшьләр җир селкетеп

көрәшәләр! Һәм... туган авылына шәһәрдән кунакка кайткан егет батыр кала. Әллә соң спортчылар авылдан да китәмс, дип уйлап куясың шул чакта...

**Илдар Насыйров.** Бу хәл күпмедер дәрәҗәдә табигый. Авыл җирләреннән Казанга килсә дә, ул бит Татарстанда кала, республикабыз данын Бөтенроссия, Бөтенсоюз ярышларында якларга әзерләнә. Киләчәктә сабан туйларын яңа программа буенча уздыруның спортчыларга киңрәк мәйданга чыгарга ярдәм итүе чагылышы булыр бу. Светлана Якимованы, мәсәлән, Тәтештә яшәтүдән ни хәер? Аңарга, ирешкән дәрәҗәсен саклау өчен, белемен һәм осталыгын тагын да күтәрергә кирәк. Ул хәзер Волгоград физкультура институтының Казан филиалында укый, аны тәмамлагач, Светлана Тәтешкә кайтыр, бәлки.

**Язучы.** Республикаларның футбол, хоккей, волейбол һәм башка командалары (мин илебез беренчелегенә ярышларда катнашучыларны күз алдында тотам) нигездә төп милләт спортчыларыннан тора. Бу мәсьәлә бездә ничек хәл ителә?

**Илдар Насыйров.** Командага уенчылар сайлаганда, принцип бер — кем көчле! Һәм, әйтергә кирәк, җыелма командалар составының яртысыннан артыгын татар егетләре һәм кызлары тәшкил итә.

Шулай да бер нәрсәне онытырга ярамый: РСФСР һәм СССР беренчелегендә уйнаучы командаларны туплаганда, кайбер ирекле җәмгыятьләр һәм хәтта предприятие җитәкчеләре мәсьәләне җиңел генә хәл кылырга тырышалар, осталарны читтән чакыру белән мавыгалар. Болай эшләү дөрес түгел, көчлеләрне без үзебез тәрбияләргә тиешбез!

Бу урында күренекле спортчылар әзерләүдә милли кадрлар үсеп чыгуын әйтү дөрес булыр. Тәтеш мәргәннәрен Солтан Яруллин, дөнья һәм Олимпия уеннары чемпионы Николай Колесниковны Бөгелмәдән Ифрат Тимержанов, кылыч уены мастеры Эльбрус Баяновны Фәрит Хәсәнов тәрбияләде. Хәзер алар өчесе дә — РСФСРның атказанган тренерлары.

**Язучы.** Татарстан спортчылары быел нинди зур ярышларда катнашачак?

**Илдар Насыйров.** Илебезнең спорт тормышындагы төп вакыйгалар: РСФСР һәм СССР халыкларының VIII җәйге спартакиадалары. СССР халыкларының бишенче кышкы спартакиадасында бездән 23 спортчы чыгыш ясады. Анда Алия Сабирова — алтын һәм көмеш, Рузалин Бакиев — көмеш, Анатолий Романов бронза медальләр алдылар. Шунысы куанычлы: безнең спортчылар, Идел буе, РСФСР халыклары спартакиадаларында җиңүчеләр сафларында булып, СССР халыкларының һәр спартакиадасында катнаштылар.

Татарстан спортчылары быел шулай ук илебез, Европа һәм дөнья күләмендәге башка ярышларда көч сынашачаклар. Һәм боларда иң югары күрсәткечләргә ирешүчеләр 1984 елгы Олимпия уеннарында илебез данын яклаячак.

**Язучы.** Республика матбугатында спорт һәм талантлы спортчылар турында шактый языла. Әмма китаплар күп түгел. Спортчыларның үзләре язган китаплар аеруча аз. Рәшит Нәҗметдиновның күптән түгел басылып чыккан «Шахмат уены» (икенче басма) исемле китабы бик җылы каршыланды. Аның «Сайланма партияләр» (рус телендә) китабы да тиз таралып беткән иде. Шахмат сөючеләр Рәшит Нәҗметдиновның оста комбинацион уенына хәзер дә сокланалар. Шушы җәһәттән бер кечкенә вакыйга искә төшә.

Күптән түгел мин Кавказ егете белән таныштым.

— Казаннан мин бер генә кешене әйбәт беләм,— диде ул миңа. — Нәҗметдиновны!

— Сез шахматчымыни?

— Юк, укытучы мин. Шахмат уйнарга яратам. Рәшит Нәҗметдинов белән уйнаганым булмады, аны күреп белмим. Әмма мин аның иҗатын беләм. Чын художник ул!

... Ә татар язучыларының илебездә шахмат буенча да, шашка буенча да иң беренче мастер булган, ил күләмендә яхшы уенчылар тәрбияләгән СССРның атказанган тренеры Рәшит Нәҗметдинов турында китап язганнары юк.

Моңарчы бу әңгәмә-алышуда мин һөҗүм итәргә тырыштым. Хәзер өстен-

лек Сезгә күчә бугай. Язучыларга, фән, культура һәм сәнгать эшлеклеләренә ни әйтергә телисез?

**Илдар Насыйров.** Республика газета-журналлары спорт темасына күбрәк урын бирергә тиешләр, минемчә. «Правда» газетасы физкультура һәм спорт мәсьәләләренә бик игътибарлы. Радио һәм телевидение халыкка информацияне вакытында җиткерсен, аннары, бу темага материалларда коры санау гына түгел, ә спортны аңлаешлы пропагандалау да булсын иде!

Язучылар, сәнгать эшлеклеләре спорттан читтә әле. Дөрес, соңгы вакытта спорт казанышлары һәм спорт уеннары турында татарча китаплар басыла. Дөнья күләмендә танылган мастерларның үз китапларын чыгару безгә көчле спортчылар тәрбияләүдә зур ярдәм итәр иде. Кылыч уены остасы, яшьләр арасында дөнья чемпионы Эльбрус Баяновның «Ялкын» журналында басылган язмалары кызыклы, спортчы психологиясен өйрәнүгә ярдәме тиярлек. Аның китабы чыгуы — спортның бу төрен пропагандалауда шатлыклы хәл.

Наилә Гыйлаҗеваның, иллегә якын спорт мастеры, өч халыкара класслы спорт мастеры тәрбияләп үстергән РСФСРның атказанган тренеры Фәрит Мәдьяровның китапларын чыгаруда язучылар да читтә тормаска тиештер, мөгаен. Яисә күренекле спортчылар турында нигә документаль әсәрләр язмаска?! Наилә Гыйлаҗева алты тапкыр дөнья чемпионы булды бит инде. Алты тапкыр! Ә батыр кызыбыз хакында күләмле әсәр түгел, хәтта зуррак очерк та юк, язучы иптәшләр!

Рәссамнар да спортны бик сирәк искә төшерәләр. Ә фән эшлеклеләре белән безнең ара якынрак. Күп кенә галимнәр югары уку йортларының физик тәрбия кафедралары эшендә нәтиҗәле булыша. Баскетбол буенча халыкара категорияле судья, техник фәннәр докторы, профессор Габделнур Хәбибрахманович Мөхәммәтҗанов турында аерып әйтергә телим. Ул Татарстан АССР баскетбол федерациясендә ярышлар уткәрүдә катнаша, судьяларның семинарларын уздыра, судьялык итү кагыйдәләре буенча методик күрсәтмәләр бастырды.

«Тополек» шахмат клубын телгә алган идегез. Сүз дә юк, әйбәт башлангыч. Әмма безнең республика матбугатында бу хакта хәбәр дә булмады. Кирәк иде! Хәтта атаклы шахматчыбыз Рәшит Нәҗметдинов турында да бүгенгәчә бер китап юк бит! Ниһаять, бу эшкә алынучылар бар, дип ишеттем.

Әйткәнемчә, Казанда Р. Нәҗметдинов мемориалы уздырыла. Киләчәктә анда көчле шахматчыларның күбрәк катнашуын көтәбез. Моңа башкалабызда яңа шахмат клубы салынуы (Тукай урамында) аеруча ярдәм итәр.

Физкультура һәм спорт турында язылган материаллар кызыклы, файдалы булсын, аларда физик культураның сәламәтлек һәм хезмәт өчен әһәмияте һәркем төшенерлек итеп аңлатылсын иде. Спорт темасына язарга һәм спорт белән шөгыльләнергә теләүче язучыларга, фән һәм сәнгать эшлеклеләренә ярдәм кирәк, дисәгез, безнең комитет әзер.

**Язучы.** Спортның кайбер төрләре турында бөтенләй диярлек язылмый. Мәсәлән, теннис, гимнастика, акробатика һәм җәядән ату турындагы хәбәрләрне минем күптән инде укыганым юк. Әлбәттә, барысын да колачлавы кыен. Әмма һәркем, шул исәптән язучылар һәм журналистлар да, спортның бер төрен күбрәк ярата бит. Димәк, алар спортны һәрьяклап пропагандалауда булыша алалар. Сез бу өлкәдә күп эшләр башкарасыз, моңа хезмәт урыныгыз мәҗбүр итә, ә спортчы булуыгыз исә ярдәм итә. Мин Сезнең спорт биографиягез белән күпмедер таныш. Чаңгы, футбол, җиңел атлетика буенча разрядларыгыз булуын, йөзүдә мастерлыкка кандидат икәнлегегезне беләм. Алтынчы Бөтенроссия студентлар уеннары чемпионы, «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең РСФСР һәм Бөтенсоюз күләмендәге ярышларында берничә тапкыр җиңүче һәм призер булуыгыз, су астында йөзү буенча СССР чемпионаты финалында иң көчлеләр белән узышта сынатмавыгыз хакында үз вакытында матбугатта язылды. Ә хәзерге спорт биографиягез?..

**Илдар Насыйров.** 1960 елда Казанда беренче бассейн ачылды һәм шунда йөри башладым. 1963 елда, ярышларда яшүсмер буларак катнашып, ирекле стиль белән ике йөз метрга йөзүдә зурлар өчен Татарстан рекордын куй-

гач, үземне бик бәхетле санадым. Республикабыз спортына бәяләнерлек беренче өлешем иде бу. Барысын да санау уңайсыз, мактану тоелыр. Кайберләрен үзегез әйттегез дә инде. Кыскасы, ярышларда күп катнаштым, хәзер дә иртәсенкичен йөзәм, тик нәтиҗәләр... Элекке түгел инде...

Казан педагогия институтын тәмамлагач, Татарстанның йөзү буенча яшүсмерләр җыелма командасы тренеры булдым. Өч ел ВЛКСМ өлкә комитетының спорт һәм оборона-масса эшләре бүлеге мөдире булып эшләдем. 1978 елдан — биредә.

**Язучы.** Алдагы сорауга бәйләп, спортчының нинди сыйфатларын югары бәяләвегез турында әйтсәгез иде!

**Илдар Насыйров.** Намуслы, көчле рухлы, коллектив уңышы өчен көчен һәм тырышлыгын аямаучы, тугры, яхшылыкны онытмаучы кешеләрне хөрмәт итәм. Бу сыйфатлар әйбәт спортчыга да хас. Бүгенге спортчы, югары күрсәткечләргә ирешүне максат итеп, нык эшләргә тиеш. Югыйсә, көненә ике-өч сәгать җиңелчә күнегүләр ясап кына ерак китә алмыйсың. Авыр нагрузканы күтәрергә чыдам-түзем булу сыйфаты да кирәк.

**Язучы.** Әңгәмә-алышуда беребез дә җиңелмәде кебек,— «ничья» ягъни. Хәер, журнал укучысы отса, Сез дә, мин дә канәгать булырбыз, дип уйлыйм.

**Илдар Насыйров.** Риза.

**Язучы.** Уңышлар Сезгә!

# КИТАП ҺӘМ УКУЧЫ

Безнең илебез китап бастыру буенча дөньяда беренче урында тора. Басылып чыккан һәр җиде китапның берсе — совет китабы. Татарстанда гына да ел саен йөзләгән җыентык укучы кулына керә. Әле шуның өстәвенә һәр гаилә газета-журнал да алдыра.

Китап — гасырлар дәвамында халыклар туплаган рухи байлыклар тутырылган сандык шикелле. Ул — сөйләм теле кебек үк, аралашу чарасы, халыкка фәнни һәм эстетик информацияне илтүче, чынбарлыкның серенә ачкыч, читкә китеп үз-үзеңә карау. Әсәр укыганда кеше геройлар тормышын күзәтә, үзен борчыган сорауларга җавап эзли, «үкенеп, шикләнеп, көенеп, көлеп, елап, җәлләп һәм теләктәшлек күрсәтеп» кеше язмышын, кеше батырлыгын үзенең холык-фигыле белән «үлчәп» карый. Һәм әнә шул вакытта, Ю. Бондарев сүзләре белән әйткәндә, кешеләр акылына һәм йөрәгенә аның йогынтысы башлана.

Хәзер китап совет кешеләренең тормышына һәм көнкүрешенә нык кереп урнашты. Китапны массаларга якынайту кирәклеген В. И. Ленин Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң ук әйткән иде. Ул революцион бурычны — культураны бөтен халык байлыгы һәм иҗаты итү бурычын хәл итүдә иң әйбәт чараларның берсе — китап дип санады.

Ильич васыятьләре тормышка аша — илебез хәзер дөньядагы иң күп китап укучы ил. Социологик тикшеренүләрдән күренгәнчә, халыкның барлык катлаулары да диярлек матур әдәбиятка өстенлек бирә, шәһәр кешеләре исә китап укуга көн саен 25—30 минут вакыт бүлә.

Әмма җыентыкларда теркәлгән рухи байлыклар биниһая күп төрле. Һәр кешенең дә информация кабул итү мөмкинлекләре бертигез түгел. Әйтик, көн саен якынча 100 бит укыса, кеше бер елда 300 битле 120 китап укый ала, ди. Шул тизлектә укуын дәвам итсә, ул 50 елда бары 6000 китап укып өлгерә. Совет власте елларында безнең илебездә генә дә 2 миллион исемдәге зур һәм кечкенә китаплар чыкты. Димәк, бу диңгездә адашып калмау бик мөһим.

Язучылар, галимнәр, философлар, социологлар китапларның ничек укылуы белән бик нык кызыксыналар. Моның фәнни һәм практик әһәмияте бар. В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсе ил күләмендә үткәргән тикшерүнең максаты кечкенә шәһәрләр тормышында китапның тоткан урынын билгеләү булды.

Башка тикшеренүләр укучылар белән матур әдәбият арасындагы мөнәсәбәтләрнең бүтән якларын ачыклады. Республикабызда үткәрелгән тикшеренүләр әсәрләрнең укылу структурасын ачыкларга ярдәм итте. Мәсәлән, 1980—1982 елларда Казан дәүләт культура институты укытучылары һәм студентлары совет кешесенең рухи йөзен барлыкка китерүдә матур әдәбиятның ролен өйрәнде. Казан, Зеленодольск шәһәрләре һәм Актаныш районындагы дәүләт китапханәләренә йөрүче 5000 кешенең нинди әсәрләр укуы анализланды. Формулярлары карап чыгылганнан соң анкета сорауларына җавап биргән укучыларның күпчелеге — 30 яшькә җитмәгән кешеләр. Алар — өлкән класс укучылары, студентлар, эшче яшьләр, квалификацияле белгечләр, хезмәткәрләр, механизаторлар, терлекчеләр.

Бу тикшеренү республикабыз яшьләре гомумән матур әдәбиятны яратып укыйлар, рус, совет, чит ил классикасы һәм хәзерге әдипләрнең күп әсәрләре шәһәрдә дә, авылда да кызыксынып укыла диген фикергә китерде.

Бер нәрсә күзгә ташлана. Эшче яшьләр һәм профтехучилище укучылары укыган

китапларның яртысы, студентлар кулга алган әсәрләрнең өчтән бере. Актаныш районы яшьләре сораган җыентыкларның 60 проценты — матур әдәбиятка карый. Яшьләрнең матур әдәбиятка тартылуы анкетадагы сорауларга җавaплардан да күренә. 100 анкетада рус совет әдәбиятыннан 108 автор, 18 рус классик язучысы, 23 тугандаш әдәбият вәкиле, 32 татар совет язучысы аталган.

Укучы аерым китапларны гына түгел, «Казан утлары», «Новый мир», «Октябрь», «Юность» кебек журналларда басылган әсәрләрне дә эзләп укый, әдәбият яңалыкларыннан хәбәрдар булырга омтыла. Анкета тутыру юлы белән шәһәрдә һәм авылда матур әдәбият укылу рәвеше ачыкланды. Шәһәрдә яшәүчеләрнең 23,5 проценты, авыл кешеләренең 27,5 проценты рус һәм совет язучыларын укый икән. Зеленодольск районы яшьләренең шәһәрдә — 22,5 проценты, авылда 29 проценты татар язучылары әсәрләрен яратып укый. Чит ил авторларын шәһәрдә дә, авылда да бер чама (15—18 процент) укыйлар. Күргәнебезчә, укучы рус һәм татар совет әдәбиятына өстенлек бирә. Бүгенге укучы тормышны, үз күңелен аңлыйсы килгәндә матур әдәбият әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Чынбарлык, замандашларыбыз язмышын сәнгатьчә сурәтләү совет авторлары әсәрләренә бәхәссез өстенлек бирә. Илебезнең башка төбәкләрендә уздырылган күзәтүләр дә шул фикерне раслый. РСФСРдагы 24 шәһәрдән алынган мәгълүматларга караганда, укылган әдәбиятның 62 проценты — совет авторларыныкы.

Казанда яшәүчеләрнең күпчелеге рус совет авторларын һәм классикларын ешрак сорый. Авыл яшьләре исә (Актаныш районы мисалында) татар язучыларын яратыбрак укый.

Һәр кешенең интереслары үзгә икәнлеген белсәк тә, кайбер социаль-демографик факторлар йогынтысын да кире кагып булмый. Кеше яшенә, җенесенә, белем дәрәҗәсенә, шөгыленә бәйле рәвештә үзе укыячак әсәрне сайлый. Олыгая барган саен китапка хирыслык кими бару күзәтелә. Әдәби әсәрләрне иң күп «йотучы»лар — 14—20 яшьлек кызлар. Авыл хатын-кызлары ирләрдән күбрәк укый, һәм алар татар авторларын ешрак алалар.

Нинди телдә укуга, кешеләрнең хезмәт коллективында, гаиләдә кайсы телдә сөйләшүләренең, милләтара элемтәләрнең киңлеге дә нык йогынты ясый. Шәһәрдә русча, авылда татарча китапларның күбрәк укылуы шуның белән аңлатыла да. Әмма биредә бер кызыклы моментка игътибар ителде. Укучыларның шактый өлеше, шәһәрдә дә, авылда да шигырьләр, юмористик хикәяләр, халкыбызның тарихи үткәне турында язылган китапларны татар телендә укырга омтыла.

Яшьләр чәчмә әсәрләрне күбрәк укый икән. Алар белем, профессия, милләт һәм яшь аермаларына бәйсез рәвештә роман һәм повестьлар ярата. Кызганычка каршы, шигырьләр азрак укыла. Шагыйрьләрнең исемнәре телгә алынмаган анкеталар да очрады. Бу һич тә кешеләр поэзиягә битараф дигән сүз түгел. Яшьләрнең байтагы шигъри әсәрләрне укырга түгел, тыңларга яраталар икән. Бу очракта радио, телевидение аларга ярдәмгә килә, шагыйрьләр белән очрашу кичәләре күтеп алына. Драматургия белән дә шуңа охшаш хәл.

Фантастика әсәрләре китапханәләргә кайтып керми дисәк, ялгышмабыз, маҗаралы әдәбиятның да язмышы шундыйрак. Ни дип тә булмый: фән һәм техника көнләп түгел, сәгатьләп үскән заманда яшьләр якын киләчәгебезнең матур әдәбиятта мавыктыргыч, сокландыргыч, эмоциональ гәүдәләнешен, заманыбызның актуаль мәсьәләләренең иң гүзәл, иң гуманлы чишелешен күрергә тели.

Яшьләрне матур әдәбиятта кызгатылган ниндирәк темалар җәлеп итә соң? Җавапны тикшерү материалларыннан эзләп карыйк. Яшь кеше, үзен ни дә булса борчыганда, кулына китап ала, замандашлары, яшәү мәгънәсе, Ватанга тугрылык турында язылган, әхлак мәсьәләләренә багышланган әсәрләргә мөрәҗәгать итә. Хәзер профессия кешеләре турында, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр хакында сөйләүче әсәрләр кулдан-кулга йөри. Яшь укучылар тарих белән дә шактый кызыксыналар. Әмма, күзәтүләрдән бер төркем яшьләрнең әдәби әсәрләрне укыганда талымсызлыгы, кулларына ни эләксә шуны «йотып» барулары беленде.

Укыган китапларына укучылар үзләре биргән бәя мәгълүм кызыксыну тудыра. Әлеге тикшеренүдә укучыларга үзләре укыган әсәрләрдән алган тәэсирләрен ачыклардай «Укый торган китабыгыз сезгә ошыймы, юкмы?», «Нәрсәсе ошый яки оша-

мый?» кебек сораулар тәкъдим ителде. Җавап бирүчеләрнең күпчелеге китапларны ошаткан, әмма әсәрләргә бәя бирү критерийлары гаять күп төрле. Кемгәдер әсәрнең сюжет, темасы, геройлар, проблемалар, автор, гомумән, әсәр үзе ошый икән.

Вакыйгаларның киеренкелеген, динамик үстерелешен, кайбер укучылар китапны бәяләгәндә төп критерий итеп куялар. Аларның төп игътибары сюжет линиясен күзәтүгә, «вакыйганың ни булып бетәрен» беләсе килүгә юнәлә, ягъни төп критерий итеп кызыклылык алына.

Икенче бәрәүләр китапка бәя биргәндә әсәрнең героена, аның эшчәнлегенә зуррак әһәмият бирә, геройга мөнәсәбәтләре белән әсәргә мөнәсәбәтләрен билгели: «Китап ошады. Герой теләсә нинди хәлләрдә теләгенә ирешә», «Ошый, герой бернинди кыенлыклар алдында каушап калмыйча, тормышта үз юлын таба».

Өченче бәрәүләрне күп персонажлар катнашкан, характерлар катлаулы конфликтларда ачылган әсәрләр җәлеп итә. Тормыш күренешләрен колачлау киңлеге дә бәяләү өлгесе итеп карала: «Китап ошый, чөнки ул кешеләр турында, тормыш һәм табигать, яшьлек һәм мәхәббәт хакында».

Идеал итеп әсәр герое түгел, язучы үзе аталганда, без әдәби зәвыгы формалашкан укучы белән очрашабыз. Алар күбрәк туры сүзлелек, кешеләрне ярату, ихласлык кебек төшенчәләргә өстенлек бирәләр. Әсәрнең эчтәлек һәм форма үзенчәлекләре автор позициясенең һәм аның шәхси сыйфатларының чагылышы буларак кабул ителә, бәяләү өлгеләре шуңа бәйләнешле була: «Ул (Горький) кешеләрне яраткан, шуңа күрә бик ошады («Италия турында әкиятләр»)».

Яшьләрнең бер өлеше өчен матур әдәбият кешелек дөньясы язмышы һәм идеяләр көрәше хакында уйлануга этәрүче көчкә әверелә. Укучы социаль һәм политик проблемаларга битараф түгел. «Романда мөһим проблемалар күтәрелә, әнә шул бик ошады», «Философик яки психологик планд[illegible]ы китапларны яратып укыйм»,— ди укучы.

Гражданлык, проблематиканың актуальлеге һәм тирән мәгънәлелеге дә әһәмиятле шарт итеп алына. «Китап кыюлыкка, Ватанны яратырга өйрәтә»,— дигән бәяләмәләр еш очрый.

Кайсыбер укучы әдәби әсәрне тулаем кабул итә. Образларны сәнгатьчә ачылу осталыгына, авторның әхлакый позициясенә, аның дөньяга карашына нык әһәмият бирелә. Укучылар кайбер әсәрләрне, образлы итеп, тормыштан алып язылган өчен ошатсалар, А. Пушкин поэзиясен аһәңле, хиссияткә бай булганга яраталар.

Әсәрләрне анализлый белү сәләтеннән мәхрүм укучылар да очрый. Моның сәбәбе бер генә: зәвык ярлылыгы, тәҗрибә җитенкерәмәү.

Матур әдәбият әсәрен кеше ничек сайлап ала соң? Анализдан күренгәнчә, бу эшкә китапханәчеләр шактый зур йогынты ясый икән. Авыл кешеләренең —19, шәһәр кешеләренең 17 проценты алар киңәшен тота. Вакытлы матбугат та әдәбият дөньясында юл күрсәтүче ролен үти. Яшьләрнең 10 проценты яңа китаплар турында телевидение тапшырулары буенча белә. Димәк, телевидение, радио, газета-журналлар китаплар пропагандалауда мөһим урын тоталар, һәм алар укучыларга, бигрәк тә яшьләргә әдәби зәвык формалаштыруда ышанычлы таяныч булырга, җәмгыятебезнең гаять зур байлыгыннан файдалана белергә өйрәтергә тиешләр. Зәвыкны тәрбияләү, китаплар сайлауда ярдәм итү мәсьәләсе актуаль булып кала. Интеллектуаль хәзинәне һәм кешелек дөньясы туплаган рухи байлыктан белеп һәм мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга, замандашыбызның рухи йөзен формалаштыруда аларның ролен күтәрергә кирәк.

Кешеләр, китаплар укып, дөньяга карашларын киңәйтә, рухи дөньяларын баета алсыннар өчен, китапханәләр бик күп нәрсә эшли ала. Биредә гаять күп социаль, фәнни һәм эстетик информация тупланган басма әсәрләр җыйналган. Безнең республикада дәүләт системасына керүче 1,5 мең китапханәнең 20 миллионлы фонды бар. Китапханә эшчәнлегенең күп яклары: фонд туплау, библиография эшен оештыру, әдәби хезмәтләрне халыкка җиткерүнең төрле форма һәм алымнарын үстерү-камиллаштерүгә мохтаҗ. Тикшерү нәтиҗәләре буенча матур әдәбиятны пропагандалау эшен яхшыртырдай тәкъдимнәр кертелде, һәм аларның күбесен бик теләп кулланалар.

Китапханәләрдә матур әдәбиятның бик әйбәт дип табылганнарын туплауга игъ-

гибар көчәйтелергә тиеш. Кешеләр әдәби хезмәтләрне бигрәк тә авыл җирендә китапханәдән алып укый бит. Ләкин, социологик тикшеренүләр ачыклавынча, китапханәләргә йөрүчеләрнең 52 проценты андагы фондтан канәгать түгел. Әсәрләре китапхана фондында булмау сәбәпле бик күп кызыклы һәм талантлы язучылар укучылар игътибарыннан читтә кала. Кайбер китаплар бик аз булу аркасында аларны уку өчен озын-озын чиратлар ясала, укучы ябырылып укый торганнары исә бөтенләй булмый. Балалар китапханәләрендә СССР Мәгариф министрлыгы тәкъдим иткән китапларның 30—50 проценты, авылларда 80 проценты бөтенләй юк.

Хәзерге шартларда укучыларга хезмәт күрсәтү эшчәнлегендә ярдәмлек библиографияләрнең әһәмияте зур. Гомуми культурасы үскән белемле укучы белән эшләгәндә анык яше, социологик һәм психологик үзенчәлекләре исәпкә алынырга тиеш. Матур әдәбият әсәрләренең иҗтимагый әһәмияте һәм сәнгать сыйфатлары турында күрсәтмә булырдай библиографик белешмәләр, ярдәмлекләр җитми.

Бу эшнең юлга салынуы китапханәчеләрнең профессиональ әзерлегенә, осталыгына да бәйле. Матур әдәбиятны тормыш кушканча пропагандалау, укучылар зәвыгын тәрбияләү кебек зур мәсьәләне югары квалификацияле белгеч кенә башкара ала. Китапханә эшчесе азмы-күпме педагог та булырга, төрле кызыксындыру чаралары оештыра белергә тиеш.

Шундый китапханәчеләрне Идел буе республикалары өчен Казан дәүләт культура институты әзерли. Вузның укыту планнары һәм программалары эрудицияле белгечләр хәзерләү системасындагы төрле якларны күздә тота. Махсус курс һәм семинарларда бу әзерлек тагын да тирәнәйтелә. Безнең институтта моңа зур әһәмият бирелә. Эстетик зәвыклары үскән, сәнгатьнең төрле өлкәләреннән хәбәрдар, гармоник үскән шәхес, чын интернационалистлар тәрбияләүдә китапның әһәмиятенә инанган белгечләр хәзерләүдә «Китап уку психологиясе», «СССР халыклары әдәбияты» һәм «Идел буе халыклары әдәбияты» кебек махсус курслар нык ярдәм итә. Укытучылар җитәкчелегендә студентларның фәнни түгәрәкләрендә төрле халыкларның әдәбият тарихларын өйрәнәләр.

Матур әдәбиятны пропагандалауның яңа төрләрен һәм алымнарын тагын да үстерәсе бар. Совет кешеләренең рухи ихтыяҗларын хезмәт күрсәтүнең традицион формалары гына канәгатьләндерә алмый. Алдынгы карашлы китапханәчеләр халык арасында эшләүнең киләчәген комплекслы чараларны киңәйтү белән бәрәттән, шигърият сөючеләр түгәрәге, фантастлар клубы, әдәби берләшмәләр эшен киңәйтүдә дә күрәләр. Шундый очрашулар вакытында төрле фикерләр, төрле карашлар көрәшендә хакыйкать табылыр иде.

Бер нәрсә бәхәссез ки, хезмәт ияләрен китапка, рухи байлыкларга якынайту проблемасы язучылар, тәнкыйтьчеләр, социолог галимнәрнең, китапханәчеләрнең активлашуы, күңел бирел эшләвен көтә. Культура учреждениеләре, нәшриятлар, китапхана һәм сәүдә челтәре эшчеләре бердәм көчкә берләшеп коммунистик җәмгыять кешесе тәрбияләүгә, аның иҗади сәләтләрен ачуга хезмәт итәргә тиешләр.

Хәзер һәр язучы бөтен ил күләмендә үз укучысын таба ала, бу — җәмгыятебезнең бөек казанышы. Китап яратучы халык соңгы ун елда гына да бик үзгәрде. Язучы белән укучы, сәнгать әсәре белән тамашачы, әдәбият белән халык арасында принципиаль яңа мөнәсәбәтләр урнашты диләр тикшеренүчеләр. Әлбәттә, кулына китап алган һәр кешене әдәбият сөюче дип булмый. Шәхси китапханәсендә соклангыч әсәрләр саны ишле булган һәркемне зәвыкка ирешкән шәхес дияргә ашыкмыйк.

Чын укучы — китапка бирелгән кеше ул. Әсәрләрдә аны иң элек гомумкешелек дөньясын борчыган проблемалар, бүгенге чынбарлыкның сәнгатьчә сурәтләнеше җәлеп итә, ул алардан үз кичерешләренә тәңгәл килердәй нәрсәләрне эзли. Хәзерге укучы күңелен яулау өчен әсәр талантлы, новаторларча язылган, һәркемне дулкынландырган мәсьәләләрне күтәргән булырга тиеш. Бары шул вакытта гына укучы белән китапның очрашуы нәтиҗәле булыр.

**Рәхилә ШӘМСЕТДИНОВА,**
Казан дәүләт культура институты ректоры.
**Татьяна ДУНАЕВА,**
библиография һәм китапны өйрәнү кафедрасы мөдире.

# ЛЕГЕНДАР ТАНКИСТ

*Редакциягә илебезнең төрле якларыннан хатлар килә. Бу хат исә Украинадан, Львов шәһәреннән. Аның авторы, сугыш ветераны Михаил Алексеевич Матвеев, якташыбыз танкист Якуб Рәфиковның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән каһарманлыклары турында яза. Ул геройның туганнарын яки сугыш юлларыннан бергә үткән иптәшләрен эзләп табарга тели. «Материаллар СССР Оборона министрлыгының Үзәк архивыннан алынды, дөреслегенә шик булырлык түгел», — дип яза ул. Бу язманы бәлки данлы танкист Я. Рәфиковның туганнары, якыннары да укыр. Автор алардан хәбәр көтә. Аның адресы: 290011, Львов-11, ул. Пархоменко, дом 13, кв. 10. Матвеев М. А.*

Дошман бомбаларыннан калган чокырларны әллә кайчан үлән каплады, траншеялар ишелеп-күмелеп бетте. Ә сугышларда алган яралар һәм һәлак булган геройлар онытылмыйлар, аларның якты хатирәсе безгә Бөек Ватан сугышын һаман искә төшереп тора.

Львов шәһәрендә «Дан биеклеге» — Ватан сугышында һәлак булган геройларның хәрби пантеоны бар. Шунда 10 нчы рәттәге 13 нче урынга 6 нчы гвардия танк бригадасының элекке командиры, гвардия полковнигы Якуб Билалович Рәфиков күмелгән. Утлы юлларда үзенең данлы сугышчан биографиясен язган, Иделдән һәм Мәскәүдән Германиягә кадәр сугышып үткән кеше ул.

Якуб Рәфиков 1906 елның 15 августында Казанда туган, татар, 1928 елның августыннан партия члены, 1919 елдан 1928 елга кадәр комсомол сафларында тәрбияләнгән. Кызыл Армиягә 1928 елда чакырылган. 1931 елда Мәскәүдә хәрби инженерлык мәктәбен, ә 1941 елның маенда РККАның Механикалаштыру һәм моторлаштыру хәрби академиясен тәмамлаган һәм «РККА отличнигы» дигән значок белән бүләкләнгән. Бөек Ватан сугышында беренче көннәреннән үк катнаша.

Танкист Рәфиков дошман илебез башкаласы Мәскәүгә таба ябырылып килгәндә, Смоленск тирәсендә беренче сугышчан чыныгу ала. Мәскәү өчен барган сугышлар искиткеч дәһшәтле була. Дошман җан-фәрманга алга ыргыла, безнең танкистлар тагын да катырак каршылык күрсәтәләр.

Бәрелешләр көне-төне тынып тормаган бер чакны разведка начальнигы капитан Рәфиковны тирән разведкага җибәрәләр. Беренче карашка танк якын да килә алмаслык кебек булып күренгән җирләрдән үтеп, экипаж кирәкле объектка барып җитә. Тик көтмәгәндә дошманның өстен көчләренә юлыга һәм сугыш башларга мәҗбүр була. Безнең танкистлар, дошманның өч танкы белән маңгайга-маңгай килгәндә дә, каушап-югалып калмыйлар. Тиз атып, фашистларның ике машинасына ут кабызалар, ә өченчесе чылбыры өзелеп, урында әйләнеп кала. Оста манёвр ясап, Рәфиков экипажы сугыштан чыга, эзәрлекләүдән котылып алга, үз юлына китә.

Ул алып кайткан мәгълүматлар исә искиткеч кыйммәтле була, капитанның күкрәгенә Сугышчан Кызыл Байрак ордены кадыйлар.

Шунда, Мәскәү тирәсендә үк, 1941 елның кышында безнең танкистлар, дошманның оборонасын өзәргә омтылып, ярсулы сугышлар алып баралар. Атака арты атака. Көндез дә, төнлә дә ут өермәсе уйнап тора. Шундый вакытта безнең танклар дошманның беренче траншеясын узалар һәм, пехотага дошманның оборонасын үтәргә ярдәм итеп, пулемет нокталарын изә башлыйлар. Рәфиков командалыгындагы экипаж шулкадәр мавыгып китә, күршеләреннән аерыла, танкларга каршы казылган махсус чокырга төшә, батып кала. Двигатель сүнә. Кабызырга тырышып-тырышып карасалар да, файдасы тими.

Ә фашистлар танкистларның мөшкел хәлен күреп торалар, Рәфиков танкына ут ачалар. Аның чокырга батканын күргәч, танкка каршы ата торган тупны якын ук китереп, бөтенләй юк итмәкче булалар. Әмма танкның бронясын тишә алмыйлар. Совет танкистлары исә җаен белеп сугышалар, теге тупны гамәлдән чыгаралар.

Соңыннан ачыкланганча, безнең башка танклар дошманның көчле уты астында баштагы позицияләренә чигенгән булганнар, ә Рәфиков экипажын һәлак булган дип санаганнар. Алар дошман тубының батып калган танкка якыннан атканын күргәннәр, һәм штаб танкистларның туганнарына аларның һәлак булуы турында хәбәр иткән.

Рәфиков экипажы исә бу вакытта тигезсез сугыш алып бара. Танк командиры төнлә бер иптәшен разведкага җибәрә. Тик ул танктан чыгуга ук фашистлар утына эләгә, һәлак була. Машинада өч кеше кала һәм алар дошманга бирелмәскә ант итәләр.

Төнлә фашистлар танк янына киләләр һәм, люкны шакылдатып, әсир төшүне таләп итәләр, тормышларын саклаүга сүз бирәләр, ә бирелмәгән очракта исә, танкны экипажы белән бергә яндырмакчы булалар. Тик батыр танкистлар куркып калмыйлар, һаман каршы торуны дәвам итеп, дошманның берничә автоматчысын теге дөньяга озаталар. Шулай ялсыз-йокысыз өч тәүлек сугыш алып баралар. Ашарга азмаз гына запаслары була, тик сулары юк икән. Алар төнлә, танк люгын ачып, пычранып беткән кар җыеп алалар һәм шуның белән сусауларын басалар.

Дүртенче көнне, экипажның сугыш припаслары беткәч, мотор гөрләгәне ишетелә. Үзебезнекеләр, дип уйлыйлар, сөенәләр. Әмма, карасалар, якынлашып килгән танк кара тәреле икән. Аннан дошман танкистлары төшә, безнең машинаны үзләренә трос белән тагалар: дошман безнең танкны үз тылына сөйрәп китмәкче.

Шушы җаваплы һәм катлаулы ситуациядә механик-йөртүче урынына командир Рәфиков үзе утыра. Ул моментын тоеп ала һәм дошман тарттырганда муфтаны ычкындыра. Дошман танкы безнекен чокырдан җиңел генә тартып чыгара. Ә тигез җиргә чыккач Рәфиков моторын кабызып карый, һәм мотор кабына! Танкист ялгау муфтасына баса һәм двигательне тулы әйләнеш алганчы кыздыра. Фашистлар исә аның мотор тавышын ишетмиләр, танкны үз тылларына таба сөйрәтүдә дәвам итәләр. Двигатель кирәкле режимга чыккач, Рәфиков тормозга баса. Немец танкы гусеницалары белән кар туздырып туктап кала. Безнең машина кисәк алга тартылып куя. «Т-34» танкының двигателе куәтлерәк булу үзенекен итә. Рольләр алмашына. Безнең танкист тулы газ бирә, двигатель колак тондырып үкерә һәм «Т-34» дошман машинасын оборонабызның алгы сызыгына таба дер селкетеп тартып китә.

Дошман траншеялары аша үткәндә, немец танкистлары, сикерешеп чыгып, үз окопларына кереп качу җаен карыйлар.

Һәлак булганга исәпләнгән танк, броняlы дошман албастысын тагып, салкын декабрь иртәсендә үз частена кайтып керә. Бу көтелмәгән очрашуга һәм шундый уңышка шатланып туя алмыйлар. Капитан Рәфиковның батырлыгы турында ул көннәрдә бөтен газеталар язып чыга. Аңа икенче сугышчан Кызыл Байрак ордены бирелә, ә экипаж членнары Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнә.

Сталинград янындагы тиңдәшсез авыр сугышлар барганда майор Рәфиков батальон командиры була, оста һәм куркусыз сугыша, җиңелүне белми. Аннары Курск дугасы һәм Украинадагы күп санлы бәрелешләр...

1943 елның августында, безнең гаскәрләр зур һөҗүмгә күчкәч, майор Рәфиков тагын каһарманлык күрсәтә. Һөҗүмнең дүртенче көнендә аның батальоны Глухов шәһәрен азат итә, аннары көньякка юнәләләр һәм Путивль шәһәре районында Сейм елгасын кичәләр. Аннан соң Бурынь поселогына тәвәккәл рейд ясыйлар, Ворожба-Конотоп тимер юл магистрален кисәләр. Бу сугышларда Рәфиков батальоны дошманның 10 танкын һәм үзйөрешле орудиесен юк итә. 545 солдат һәм офицер әсирлеккә алына. Тик җиңү ансат кына килми.

Бурынь поселогы өчен сугыш барганда, 1943 елның 7 сентябрендә, яралы комбатны госпитальгә алып китәләр. Ләкин көтелмәгән хәлләр аркасында ул анда барып җитә алмый.

Сейм елгасының аргы ярындагы безнең гаскәрләр кулда тоткан плацдарм куркыныч астында кала. Дошман, көчләрен туплап, киңүгә таба омтыла. Танклар безнең оборона өстенә ташкын булып килә, өзлексез атака ясап, оборона линиясен өзеп үтәргә тырышалар. Алар кичүгә һаман якыная бара. Ә анда сугыш припаслары, азык-төлек, ягулык төягән автомашиналар бик күп җыелган. Инде Сеймның аргы ягында сугыш алып барган безнең частьларның тәэминат чыганакларыннан өзелеп калу куркынычы туа. Фашистлар плацдармдагы берничә торак пунктын алалар һәм

кичүгә 300—400 метр чамасы гына ара кала. Гадәттән тыш киеренке һәм хәвефле ситуация барлыкка килә. Шул моментта майор Рәфиков армия командующие белән очраша. Генерал исә майорны яхшы белә, аның оештыру сәләте, батырлыгы, тапкырлыгы турында күп ишеткән була. Яралы майорга гаять катлаулы, ифрат җаваплы бурыч тапшырыла: дошманны ничек кенә булса да туктатырга һәм кичүне кулдан ычкындырмаска!

Шул тирәдә булган танкларны, үзйөрешле орудиеләрне һәм пехотаны бергә туплап, майор Рәфиков оборона оештыра. Дошманның пехота һәм танклардан торган зур көчләренең һөҗүмен ике тәүлек буена кире кагып тора. Яу кырын төтен һәм тузан болыты каплый. Атакага атака ялгана. Шул төтен эченнән ут чәчеп яңадан-яңа танклар килеп чыга. Әмма безнең танкистлар, тупчылар, бронебойщиклар үз позицияләреннән бер карыш та чигенмиләр. Танклар һәм туплар гөрелтесеннән командаларны, яралыларның ыңгырашканын ишетерлек тә түгел. Җиңел яралылар, яралары тиз-тиз генә бәйләтеп, яңадан сугышчылар сафына басалар. Авыр яралыларны исә тылга озату хәстәрен күрәләр.

Гвардия майоры оборонаны шулкадәр белеп оештырган була, дошман безнең гаскәрләрне аз гына да кысрыклый алмый. Безнең оборона бик чыдам, ышанычлы булып чыга. Дошман танклары һәм пехотасының котырынкы һөҗүмнәрен кире каккannan соң, Рәфиков контрһөҗүмгә күчә. Ун «пантерасын» югалтып, дүрт йөздән артык үлгән солдатын һәм офицерын калдырып, дошман чигенә башлый, терәк пунктларын калдырып китә.

Майор Рәфиков командалык иткән гаскәрләр группасы уңышлы һөҗүм белән берничә километр алга үтә. Кичү саклап калына, бөтен зона дошманнан чистартыла һәм гаскәрләр, йөкләр Сейм елгасы аша өзлексез чыгып тора башлый. Ул арада безнең зур көчләр дә килеп җитә һәм дошманның кичү районындагы группировкасы тәмам тар-мар ителә. Армия командующиеның заданиесен үтәгәннән соң майор Рәфиков инде госпитальгә барып тормый, үз батальонына кайта һәм шунда дәвалана.

Катлаулы хәлләрдә батырлык һәм тапкырлык күрсәткәне өчен гвардия майоры Я. Б. Рәфиков Беренче дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Аннары Днепрны кичү, Киев өчен киеренке сугышлар башлана. Танк бригадасының командиры итеп билгеләнгән подполковник Рәфиков үз танкистларын җиңүдән җиңүгә әйдәп бара.

Львов юнәлешендә хәлләр гаять катлаулы була. Дошман үзе басып алган җирнең бер адымын да сугышсыз бирми, ләкин курку белмәс танкистлар фашистларның батырлык бастионнарын җимереп үтәләр. Танк бригадасына почетлы исемнәр бирелү һәм байрагына Ватаныбызның олы бүләкләре тагылу юкка гына түгел. Монда аның легендар командиры Рәфиковның да өлеше бик зур.

Дошман белән Львов шәһәренең читләрендә сугышка кереп, Рәфиков танкистлары аяусыз ут яудыралар. Шәһәр урамнарында алар фашистларның 10 танкын, 7 бронеавтомобилен, 5 бронетранспортерын яндыралар, әллә никадәр пулемет нокталарын көл итәләр.

Танкистлар шәһәрнең үзәгенә бәреп керәләр һәм опера театры бинасына кызыл байрак элэләр. Комбриг һәрвакыт һөҗүм итүчеләр белән бергә була һәм сугыш хәрәкәтләренә үзе җитәкчелек итә.

Борынгы шәһәрне азат иткәндә героизм күрсәткән өчен бригада сугышчыларына Верховный Главнокомандующий приказында рәхмәт белдерелә, комбриг полковник Рәфиков үзе исә Икенче дәрәҗә Суворов ордены белән бүләкләнә.

Львовны азат иткәннән соң танкистлар сугыша-сугыша алга — көнбатышка таба баралар. 1945 елның январь башында танк бригадасы Висла плацдармыннан һөҗүм башлый. Сандомирдан көнбатыштарак, дошманның көчле итеп ныгытылган оборонасын өзеп, бригада унбер көн дәвамында каты сугышлар алып бара, күп кенә терәк пунктларын, шул исәптән Польшаның Буско-Здруй, Стопница, Ченстохова шәһәрләрен азат итеп, 264 километр алга китә.

Бу сугышларда дошманга бик зур зыян китерелә. Сугыш кырында 1 357 дошман солдаты һәм офицеры үлеп кала. Безнең гаскәрләр 17 бронетранспортер, 7 танк,

төрле калибрлы 60 туп, сугыш кирәк-яраклары белән 600 дән артык автомашина оласы, сигез сугыш припаслары һәм азык-төлек складын кулга төшерәләр.

Легендар комбриг үз бригадасын яңа җиңүләргә алып бара. Тик аңа сугыш бетбеткән якты көнне күрү насыйп булмый. 1945 елның 12 январенда Германия территориясендәге каты бәрелешләрнең берсендә ул геройларча һәлак була.

Фронт Хәрби Советының карары белән комбригның гәүдәсе салынган табут ул үзеүзе азат итешкән Львов шәһәренә китерелә һәм шунда «Дан биеклеге»нә күмелә.

Ул көннәрдән соң утыз тугыз еллап вакыт үтте. Шулай да геройның каберен зәләзләүче юк. Бәлки, бу юлларны укыгач, геройның якыннары, фронт юлларыннан бергә гә үткән дуслары хәбәр бирерләр, безгә хат язарлар яки Львовка килерләр.

Батыр танкист, гвардия полковнигы Якуб Билалович Рәфиковның исеме Бөек ВатВатан сугышы тарихына алтын хәрефләр белән язылды. Аның якты истәлеген Львовта та изге итеп саклыйлар, геройның каберен чәчәкләр бизи...

**Михаил МАТВЕЕВ,**
Совет сугыш ветераннары комитеты Львов секциясенең оештыру комиссиясе члены.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Язучыларның 30 августта булып узган ачык партия җыелышы «Авылның рухи үзгәрешендә әдәбиятның роле» дигән темага багышланды. Доклад белән СССР Педагогия фәннәре академиясенең профессиональ-техник педагогика фәнни-тикшеренү институтының бүлек мөдире, философия фәннәре докторы Л. А. Волович чыкты. Республикабыз авылларында барган социаль-сыйнфый структура үзгәрешләре турында конкрет мисаллар белән сөйләп, докладчы әдәбиятның авыл җирендә күзгә күренеп торган күркәм яңалыкларга керткән өлешен тасвирлады.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов, «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Ренат Харис, драматург Ризван Хәмид, Татарстан Язучылар союзы партия оешмасы секретаре тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Ләбибә Ихсанова катнашты.

## ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ УФАДА

Август аенда Башкортстан башкаласы Уфада Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының гастрольләре булып узды. Театр ут күршеләргә үзенең соңгы елларда иҗат иткән иң уңышлы спектакльләрен күрсәтте. Театр репертуарында Г. Ибраһимов, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Р. Хәмид әсәрләре белән бергә тугандаш халыклар драматургиясе үрнәкләре дә бар.

Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия драма театры бинасында ай буена барган спектакльләрне Башкортстанның башка шәһәр һәм районнарында да меңнәрчә тамашачылар яратып карады.

## ПАКИСТАН МИЛЛИ АНСАМБЛЕ КАЗАНДА

24 августта Казанга Пакистан музыка, җыр һәм бию милли ансамбле килде. Бу коллективны композитор Сохэйл Рана җитәкли. Концерт программасында Пакистан халыкларының музыкаль фольклор әсәрләре, ритуал биюләре һәм җырлары бар. Пакистан артистларының чыгышлары башкалабызның Химиклар һәм Төзүчеләр культура сарайларында булып, аны тамашачылар җылы кабул итте.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

16—18 августта язучы Мәхмүт Хәсәнов, шагыйрьләр Гөлшат Зәйнашева, Равил Бохараев Лаеш районында булып, игенчеләр һәм терлекчеләр, быелгы уңышны җыеп алуда актив булышучы мәктәп укучылары белән очраштылар. Бүгенге татар әдәбияты, сәнгате хакында, үзләренең иҗат эшчәнлекләре турында сөйләделәр, әдәбият сөючеләрнең күп санлы сорауларына җаваплар бирделәр.

* * *

2 сентябрьдә Казан газ аппаратлары заводында зур әдәби-музыкаль кичә булып узды. Бу кичә заводка нигез салынуга 50 ел тулу көне хөрмәтенә багышланды. Эшчеләр һәм хезмәткәрләр алдында язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин, Роберт Батуллин чыгыш ясап, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, әдәбият һәм тормыш арасындагы бәйләнешләр турындагы уй-фикерләре белән уртаклаштылар, сорауларга җаваплар бирделәр. РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Афзалова, Татарстанның атказанган артисты Миңгол Галиев, җырчы Руслан Дәминов һәм яшь композитор Риф Гатауллин катнашында зур концерт булды.

* * *

24 августта СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре әдәбият галиме Нур Гыйззәтуллин Татарстанның Әгерҗе шәһәрендә районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашты. Ул «Хәзерге татар совет әдәбият белеме һәм аның үсеш перспективалары» дигән темага чыгыш ясады.

* * *

25—29 августта РСФСРның М. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты композитор Фасил Әхмәтов Кукмара районында булып кайтты. Ындыр табакларын-

да, фермаларда, авыл культура сарайларында булган очрашуларда композитор тыңлаучыларны бүгенге татар музыкасы казанышлары һәм үзенең иҗат планнары белән таныштырды. Ә Татарстанның атказанган артистлары — җырчы Миңгол Галиев һәм баянчы Ганс Сәйфуллин аның әсәрләрен башкардылар. Очрашуларда композиторның туган якларына багышланган «Кукмара» исемле җыры да яңгырады.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисткасы **Әлфия Афзаловага**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 25 август Указы белән, «РСФСРның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре һәм нәтиҗәле фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен Казан дәүләт педагогия институтының музыка-педагогия факультеты өлкән укытучысы **Рәгъдә Халитовка** Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 29 август Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләве өчен һәм 70 яше тулу уңаеннан язучы **Тихон Кононович Журавлев**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 2 сентябрь Указы нигезендә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе солисты **Илһам Шакировка**, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 19 сентябрь Указы белән, «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор **Әгъзәм Фәттахка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1983 ел, 16 сентябрь Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.



*Шагыйрь Шәүкәт Галиев быел 11 мартта Мәскәүдә «Социализмның балалар һәм үсмерләр әдәбияты тынычлык өчен көрәштә» исеме астында уздырылган халыкара очрашуда катнашты. Аңа биредә «Заяц на зарядке» исемле китабы өчен Халыкара премия — Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы диплом тапшырылды.*

*Рәсемдә: Ш. Галиевкә Халыкара премия — Г. Х. Андерсен исемендәге Почетлы диплом тапшырылганнан соң. Сулдан — уңга: Ш. Галиев, Асен Босев (Болгария), Убайд Радисаб (СССР, Таҗикстан), Богумил Ржига (Чехословакия).*

# ЯКТЫЛЫККА ИЛТКӘН ЮЛ

РСФСР һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Лотфулла Фәттаховның тормыш һәм иҗат юлында Бөек Октябрь революциясеннән соң туган буынның язмышы күзгә кебек чагыла. Бу биография турында уйланганда әтиләре яулаган җиңүләрне кулына мылтык тотып саклаган кешеләр күз алдына килә.

Рәссамның яшьлек еллары төрле югалтулар һәм авырлыклар белән тулы була. Әти-әнисез калган унөч яшьлек малай туган җиреннән — Горький өлкәсенең Сергач районындагы Анда авылыннан җәяүләп Казанга чыгып китә. Бөтен теләге укуда була аның. Шул вакыттан ук ул каләмен шигырьләр, хикәяләр язуда сынап карый, үзе рәсемнәр дә ясый. Бу хезмәтләре өчен газеталардан алган акча аңа жидееллык мәктәпне тәмамларга һәм укуын Казан художество училищесында дәвам итәргә булыша.

1939 елның көзендә Лотфулла Фәттахов Кызыл Армия сафларына алына. Ачы сугыш еллары, яралану... Булачак рәссамга сугышның соңгы көненә хәтле күп нәрсә кичерергә туры килә.

Казанга кайткач, рәссам бөтен вакытын иҗат эшенә багышлый. Тиздән ул Татарстан сынлы сәнгатен әйдәп баручы осталарның берсенә әверелә. 1946 елдан башлап илебез һәм республикабызның бик күп күргәзмәләрендә катнаша.

Сәнгать сөючеләргә тормышны, чынбарлыкны тагын да тулырак, тирәнтенрәк ачып бирү теләге белән художник сюжетлы тематик әсәрләр иҗат итә. «Совет властеның тәүге елларында», «Мулланур Вахитов», «Яңа буралар», «Сабан туе» кебек картиналар республикабыз тарихының каһарманнар турындагы битләренә, мәшһүр революционерларның үлмәс легендалар белән баетылган образларына, авыл эшчәннәренең батыр хезмәтенә дан җырлау булып гәүдәләнәләр.

1967 елда «Совет властеның тәүге елларында» дигән әсәрнең барлыкка килүе республикабыз сынлы сәнгатенең тарихи вакыйгаларны тасвирлавында яңа бер югарылыкка күтәрелү булды. Картинаның үзәгендә — гражданнар сугышыннан кайткан солдат һәм, кызыл байрак тотып, ышанычлы адымнар белән алга омтылучы малай образлары. Рәссам, офыктагы һаваның аскы өлешен генә сурәтләп, картинасындагы кешеләрне югарырак күтәреп тасвирлый. Мондый алым кешенең галиҗанәплеген ачып бирергә мөмкинлек тудыра. Ике буынның революциягә тугрылыклы вәкилләре — солдат белән малай сурәтләре күптән түгел булып узган һәм киләчәктәге ялкынлы көрәшчеләр каһарманлыгы белән өретелгәннәр. Картинага карап, батырлыклары еш кына бөтенләй билгесезлек томанында югалып калган шундый кешеләрнең революция эшенә инанганлыгы илебезнең төрле төбәкләрендә посып утырган авылларны якты юлга алып чыккан бит, дип уйлыйсың.

Рәссамның бу әсәре буенча 20 нче еллар авылының яңадан-яңа үзгәрешләр кичеп яшәгән бәхетле һәм шомлы халәтен күзалларга мөмкин. Картина сәнгать сөючеләргә Бөек Октябрь революциясенең тагын бер яңа битен ачып бирә.

**ДИЛӘРӘ САДЫЙКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** В. И. Качалов исемендәге Зур драма театрының «Ретро» спектакленнән бер күренеш.

**Р. МАНСУРОВ** слайдлары.

Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)